ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

2.2012



# Татарстан Республикасы Президенты
# УКАЗЫ

*2012 елны Татарстан Республикасының*
*тарихи-мәдәни мирасы елы дип игълан итү турында*

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең тарихи һәм рухи традицияләрен, мәдәниятләрен һәм телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләренә җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү, мәдәни мирас объектларын торгызу, реставрацияләү һәм популярлаштыруга ярдәм итү максатларында карар бирәм:

1. 2012 елны Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бер ай вакыт эчендә 2012 елда Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы елын уздыру буенча, аларны үткәрү вакытын, җаваплы башкаручыларны, финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын күрсәтеп, төп чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларга Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенә, республика һәм урындагы массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указ ана кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н.МИҢНЕХАНОВ**

*Казан, Кремль, 2012 ел, 24 гыйнвар*

# Казан утлары
# Qazan utlari

2012

2

(1072)

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

татмедиа

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Камил Кәримов, Ләбиб Лерон, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

✉✉: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир—262-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—262-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—222-09-80.*
**Факс**—(843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# Казан утлары

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Салават РӘХМӘТУЛЛА. Без дә кошлар нәселеннән микән? *Шигырьләр*......5
Марат КӘБИРОВ. Бердәнбер һәм кабатланмас. *Роман*......10
Салисә ГӘРӘЕВА. Моңнардай ташый күңелем. *Шигырьләр*......59
Илүсә НӘБИУЛЛИНА. Борылыш. *Хикәя*......63
Әхмәт ГАДЕЛ. Җил исә, еллар үтә... *Шигырьләр*......74
Ибраһим БИЕКТАУЛЫ. Моңсу мизгелләр. *Шигырьләр*......77

**САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ**

Вакыйф НУРИЕВ. Казан күркәсе. *Хикәя*......80
Кәримизмнар......91

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Туфан МИҢНУЛЛИН. Үзгәрү......94
Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Кем белән берләшик, Рәфикъ Юныс? *(Ачык хат)*......157
Рәфикъ ЮНЫС. Иң әүвәл икәү берләшик, Адашетдин!......162

**ФӘН**

Эльмира ГАЛИЕВА. Мәдрәсәләребез — «татар академияләре»......125
«Татар энциклопедиясе» битләреннән......151
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы......154

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Рифат СВЕРИГИН. Сикәлтәле юлларда *(Рәфкать Кәрамигә 70 яшь)*......130

**ХӘТЕР**

Факил САФИН. «Шигырь — минем яшәү рәвешем» *(Кадыйр Сибгатуллинның тууына 70 ел)*......137
Кадыйр СИБГАТУЛЛИН. *Шигырьләр*......143
Фәнис ЯРУЛЛИН. Хәтер төпләрендә утлы күмер. *Көндәлекләр*......172

**КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕ**

Зиннур МАНСУРОВ. Иелгән башта таҗ тормас......145

**СӘНГАТЬ**

Әзһәр ШАКИРОВ. Татарның бөек артисты Хәлил Әбҗәлилов......165

**АК ҖИЛКӘН**

Илнар НОТФУЛЛИН. Елыйсы килә. *Шигырьләр*......181
«Хикәя яза аласызмы?»......183
Ким ШАКИРОВ. Күзләрең ачык, колакларың тырпайган булса......187

«Казан утлары» архивыннан......92
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан......190

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман М. КАБИРОВА «Единственный и неповторимый» (прод.); рассказ И. НАБИУЛЛИНОЙ; стихи С. РАХМАТУЛЛЫ, С. ГАРАЕВОЙ, А. АДЕЛЯ, И. БИЕКТАУЛЫ; К СИБГАТУЛЛИНА.
«Сенной базар»: Конкурс сатирических произведений.
«Публицистика»: Т. МИННУЛЛИН. «Меняемся» (прод.); на открытое публицистическое письмо Рафика ШАРАФИЕВА «С кем объединяться, Рафик Юнус?» откликнулся Р. ЮНУС: «Начнем с себя, тезка».
«Наука»: Э. ГАЛИЕВА. «Наши медресе — «татарские академии»; Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень».
«Литературная критика»: статья Р. СВЕРИГИНА, посвященная 70-летию Р. Карами.
«Память»: статья Ф. САФИНА, посвященная 70-летию со дня рождения К. Сибгатуллина; дневниковые записи Ф. ЯРУЛЛИНА.
«Искусство»: А. ШАКИРОВ. «Великий татарский актер Х. АБЖАЛИЛОВ».
«Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Белый парус»: стихи И. НУТФУЛЛИНА.
В номере отмечается 60-летие К. Сагдатшина и Р. Зарипова.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Апанаевская мечеть в Казани; поэт Рустем СУЛЬТИ.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and Poetry»: novel by M. KABIROV «One and only» (continuation); story by I. NABIULLINA, poems by S. RAHMATULLA, S. GARAEVA, A. ADEL, I. BIEKTAULY; K. SIBGATULLIN.
«Hay market»: Competition of satires.
«Journalism»: T. MINNULIIN. «Changing» (continuation); to an open publicistic letter by Rafiq SHARAFIEV «With whom to unite, Rafik Yunus?» responded R. YUNUS: «Let's start with ourselves, namesake.»
«Science»: E. GALIEVA. «Our madrassas — «Tatar Academy»; F. GARIPOVA. «History of our villages».
«Literary criticism»: article by R. SVERIGIN dedicated to 70th anniversary of R. Karami.
«Memory»: article by F. SAFIN dedicated to 70th anniversary of K. SIBGATULLIN; diaries by F. YARULLIN.
«Art»: A. SHAKIR. «Great Tatar actor H. ABJALILOV»6
«Pages of «Tatar Encyclopedia».
«White Sail»: poems by I. NUTFULLIN.
Issue celebrates 60th anniversary of K. SAGDATSHIN and R. ZARIPOV.
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Apanaevskaya mosque in Kazan, poet Rustem SULTI.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 01.02.2012, график буенча 01.02.2012.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ М-116. Тираж 4024.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ТУ 16-00337.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2012 ел.



Салават
Рәхмәтулла

# БЕЗ ДӘ КОШЛАР НӘСЕЛЕННӘН МИКӘН?

*Сандугачым, әйт үземә,*
*Кайсы талга кунасың?..*
Халык җырыннан

**Сандугачым, әйт үземә:**
**Кунып кайсы талларга,**
**Кайлардан**
**Моңнар аласың? —**
**Телим җырың аңларга!**

**Мин — шагыйрь генә:**
**«Шигырьләр —**
**Шагыйрьнең җыры!» — диләр.**
**Мең-мең шагыйрь — кайсыларын**
**Сиңа тыңлап кем сөйләр!**

**Шигырьләр — җырларым, җырлыйм:**
**«Илем, халкым...» — димен дә.**
**Җырымда — гел зар...**
**Булсамы**
**Сандугач моңы миндә!**

**Эх, сине сандугач иткән**
**Моңнарны кайдан алыйм?**
**Сандугач булалмам, ләкин..**
**Тик...**
**Шагыйрь булып калыйм...**

Салават РӘХМӘТУЛЛА (1942) – *Башкортстанда яшәүче татар шагыйре; татар һәм башкорт телләрендә дөнья күргән берничә китап авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.*

**Әй, сандугачым,**
**Җырымда**
**Моң булсын, зар булганчы:**
**Илем, халкымны җырлармын**
**Йөрәгем ярылганчы...**

***

**...Язмышыбыз — шаклар катарлык чор...**
**Әйтергә дә курыктык: «Без — татар...»**
**Меңәр-меңәр татар арасыннан**
**Табып булдымы — чын... йөз татар?!**

**...Хыялларга байрак кадарлык чор!**
**Һәр татарда уян, татарлык:**
**Амбразуралары утлар чәчсә,**
**Газинурлар булып ятарлык!**

## Коръән

*(эзопчарак)*

*...Хәзрәти Коръән, Зәбур,*
*Тәурат та шул, Инҗил дә шул!*
Г.Тукай

I

**Кулыма Коръән алам мин,**
**Хәйраннар кала-кала:**
**Рәсүлгә**
**Егерме өч ел (?!)**
**Иңдергән шуны Алла.**

II

**...Бутаганнар**
**Кулларына**
**Коръән алган кемне дә:**
**«Җәннәт тә — юк, тәмуг та — юк**
**Һәм юк «хисап көне» дә...»**

**Шулар —**
**«Дин — ялган юл!» — диеп,**
**Мәчет-чиркәүләр ваткан.**
**Коръәннән сүрә аңламас**
**Наданнар... акыл саткан...**

**Шулар —**
**Властька үрләп тә! —**
**(Гарьлек тә һәм... оят та...)**
**Төзи алмаган (алмый да!)**
**Юньле бер җәмгыять тә...**

**Шулар —**
**«Без — хак юлда!» — диеп**
**Иярткән — башлар бутап...**
**Шулар... упкынга җиткерде... —**
**«Уф, Алла...» — дидек, туктап...**

III

**Эх, бутадылар —**
**Кулыма**
**Коръән алгач! — мине дә:**
**«Алла да — юк, пәйгамбәр дә,**
**Дини дә — юк, дине дә...»**

**Алла бит («ул чакта» әллә**
**Галәмдә эше беткән?!)**
**Егерме өч елын**
**Җиргә —**
**Коръәнгә! — сарыф иткән!..**

IV

**«Минем арттан!» — диеп,**
**Җанга**
**Шом сала яңа ялган...**
**...Кулда — Коръән: иң хак юлны**
**Алла Коръәнгә салган!..**

***

**Һәркем бәхет өчен туа!**
**...Бәхеткә юл барында**
**Бәхетлеме, бәхетсезме**
**Күп икән җир шарында?**
**Бәхетсезләр — бихисап бит...**
**Кеше шуны аңламый:**
**Бәхеткә илткән юлда да**
**Бәхетсезлек сагалый...**

***

*Авылдашым Вәгыйз Идрисигә*

**Түм-түгәрәк дөнья:**
**Дөбердәтеп,**
**Калаларда яшәп ятулар.**
**Онытылды, авыл, бәйрәм саен,**
**Атна саен сиңа кайтулар...**

**Атнага бер түгел — аена бер**
**Хат салмаган чаклар булгалый.**
**Аена бер түгел — елына бер**
**Кайталмаган чаклар булгалый...**

**Синдә туып, синдә үскәнбез бит,**
**Иген иккән, көтү көткәнбез.**
**Калаларга чыгып киткәнбез дә...**
**Диваналар булып беткәнбез.**

**...Себерләргә китсен — кала корсын!**
**Сыра сатсын!..**
**Урам себерсен!..**
**Шагыйрь булсын!..**

**Космонавт та булсын:**
**Җиргә басып, Айга сикерсен!..**

**Юлларына таулар чыгып ятсын!..**
**Алларына язмыш таш өйсен!..**
**Тик барыбер**
**Кеше**
**Елына бер**
**Туган якка кайтып баш исен!**

***

*Кеше барыбер кошлар нәселеннән...*
С.Сөләйманова

**Без дә кошлар нәселеннән микән? –**
**Идел, Урал — туган җиребез:**
**Иделләрдә татар — беребез,**
**Беребез...**
**Уралларда башкорт — беребез.**

**Без дә, дуслар, кошлар нәселеннән! –**
**Сулар, таулар — туган җиребез:**
**Иделләрдә аккош — беребез,**
**Беребез...**
**Уралларда Бөркет — беребез.**

**Тик без — «затлы кошлар» нәселеннән! –**
**Беребездән затлы беребез:**
**«Затлы нәселдән — без!» — дип,**
**Кошларның**
**Кырылып бетеп барган төре — без...**

***

**Син — минеке!**
**Мин — синеке! –**
**Безгә**
**Тагын нинди бәхет теләргә?**
**Бәхет кирәк — бәхетсезгә,**
**Акыл**
**Кирәк булган кебек юләргә...**

## Бармаклар

**—Бармаклар нигә тигезсез —**
**Аңлаталмам һичкемгә...**
**—Йодрыкларга төйнәлгәндә**
**Тигез булсын өченгә!**

***

**Китап укучы аз булу —**
**Һич түгел каза!**
**Каза —**
**Китаплар укымаучылар**
**Үзләре... китап яза?!**

## Авылым эте

**...Аякларын күкрәгемә терәп,**
**Өрә... Өрә...**
**Үзе — тешләми?!**
**Ник тешләсен? –**
**«Сагындым!..» — дип өрә:**
**Шуңа хәтта башым эшләми...**

***

**Тормышның үз законнары**
**(Ни генә кылмый тормыш?!):**
**Ал белән гөл кавышса да,**
**«Ал да гөл» булмый тормыш...**

## Башкортстан татарларын уйлап...

*Башкорт булу өчен күп кирәкми...*
Р.Тойгын

**Татарларга татар булу өчен**
**Ниләр кирәк икән? —**
**Күп микән?..**
**Башкорт булу өчен күп кирәкми:**
**Татар булып тусаң — шул җиткән...**

## Кабер ташындагы язу

**Һәммәгез дә монда килә,**
**Киртә юк юлыгызда:**
**Аерма тик –**
**Көнегездә...**
**Аегыз...**
**Елыгызда...**

***

**Гомер — бер:**
**Яшәп калырга**
**Аяклар — йөгерә, йөгерә.**
**...Күзләр — карап кына йөри,**
**Күрәсен — башлар күрә...**

**Редакциядән:**
*Бу айда Салават Рәхмәтулла үзенең 70 яшьлек бәйрәмен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

Марат
Кәбиров

# БЕРДӘНБЕР ҺӘМ КАБАТЛАНМАС

* * *

Анна бармаклары белән матрас читен тырнап соңгы тапкыр тартышты да хәлсезләнеп тынып калды. Өзәрдәй итеп тешләгән мендәр почмагын ычкындырып, авызы белән тирән сулыш алды. Михаил анын янына хәлсезләнеп сузылып төште. Бер мәлгә бүлмәдә тынлык урнашты. Анда бары тик йөрәк тибешләре генә ишетелгәндәй булды.

—Рәхмәт сиңа, жаным!

—Бердәнберем минем.

Иреннәр тагын кыска вакытка гына бергә кушылды.

—Күршеләр сизмәде микән?..—дип гаепле елмайды хатын.—Сизсәләр харап инде...

—Юк... Тавышланмадык бит...

—Тавышланмадык?!. Йорт селкенеп торды!

—Үзебезгә генә шулай тоела ул...

—Әй, сизсәләр...—Хатын янә ирнең иреннәренә сарылып алды.—Рәхмәт сиңа, бергенәм... Мин үләм икән дип торам...

Ир дәшмәде. Елмаеп кына куйды. Һәм хатынын үзенә кысты.

Беркадәр хәрәкәтсез яттылар.

Сулышлар тигезләнде.

—Тыныч йокы, кадерлем...—дип йокы аралаш пышылдады хатын.—Мин сине яратам...

—Мин дә сине яратам...

Башкача сөйләшмәделәр. Бераздан Анна улы янына күчеп ятты да тыныч кына мышнарга тотынды. Михаилга ул йокысында да елмаеп ятадыр сыман тоелды. Ир назлы гына итеп анын башыннан сыйпады, чәчләреннән үбеп алды. Ул бәхетле һәм рәхмәтле иде. Тиздән бөтен тәненең изрәвен тоеп, йокларга дип күзләрен йомды.

Ләкин ул йоклый алмады.

Утрауга аяк баскач та ниндидер сәер халәт кичергән иде. Утрау аны ятсына, читкә тибәргә тырыша кебек тоелган иде. Хәзер ул моның алай түгеллеген аңлады. Ул үзе бу утрауны ят итеп күрә, ул үзе аннан канәгать түгел. Иксез-чиксез күлнең бер почмагында урнашкан бу онытылган утрау кайсыдыр ягы белән аңа үз тормышын хәтерләтә иде. Ул да бит нәкъ шушы утрау шикелле. Барысының да борын төбендә генә. Ләкин беркемгә дә күренми, аның

*Дәвамы. Башы узган санда.*

кемлеген дә, ниндилеген дә белүче юк. Хәтта аның өчен жанын бирердәй булып яшәгән Анна да белми аның кем икәнен. Ул Михаилны мәхәббәт хакына Алласыннан ваз кичкән бер дин әһеле дип уйлый. Үзенең Алланы да онытгырып гашыйк итәрлек хатын булуы өчен горурлана. Һәм иренә булган мәхәббәте ярларына сыймый. Бу, әлбәттә, бәхет. Бәлки, Михаилның тормышында очраган беренче һәм бердәнбер бәхеттер бу Анна. Бердәнбер һәм кабатланмас. Шуңа да ул үзенең үткәннәрен аңа сөйләргә курка. Бәлки, Анна аңлар да иде. Ә бәлки... Кем белә...

Хәтта аңлаган хәлендә дә... Михаилның кем икәнен белгәч, ул үзенекен тукый башлаячак. Болай итәргә ярамый бит, әйдә, туган ягына кайтып өйләник. Әти-әниенне, туганнарынны күрик, диячәк. Һәм Михаил моңа риза булачак. Аннага карышырлык кодрәте юк аның. Һәм үзенең дә теләге зур. Туып-үскән жиреннән бер генә өйләнеп килү өчен әллә ниләр бирергә риза. Ләкин жанында курку яши. Гомер буена ниндидер курку яшәде аның күңелендә. Шул курку идарә итте, барсын да бутап бетерде. Башта ук жиңә алган булса, хәзер бүтәнчәрәк килеп чыккан булыр иде. Һәм болай яшерен газаплар эчендә өзгәләнмәс иде ул.

Башта төрмәгә эләгүен хәбәр итәргә курыкты. Кайгырырлар, дөрес аңламаслар, гаепләрләр, дип уйлады. Аннан чыккач, беркайда да үзенә урын табалмыйча монастырьга керергә мәжбүр булды. Монда беркадәр вакытка жан тынычлыгы тапкан кебек булды. Ә күңелен корт кимерә башлагач, үзенең дөньяда барлыгын хәбәр итәргә тагын курыкты. Аны беркем дә аңламаячак иде. Хәзер тагын... Әгәр адәм баласының гомерен бер генә сүз белән билгеләргә кирәк булса, Михаилның тормышын билгели торган ул сүз бар иде—Курку. Ни өчен соң? Нигә барысы да болай килеп чыкты әле? Ә бит ул бернәрсәдә дә гаепле түгел иде.

Ул чорда авыл яшьләре Себергә күпләп китә иде. Акчаны мул түлиләр, эшкә урнашу мөмкинлеге бар, өйләнгәнче кесәңне калынайтып, дөньяңны хәстәрләп алу өчен менә дигән нәрсә. Егет тә армиядән кайткач, бергә укыган иптәше белән Сургутка юнәлде. Себерне ул ташландык урын итебрәк күз алдына китерә иде. Элек сөрген урыны булган жир ич инде. Ә юньле урынга беркемне дә сөреп жибәрмиләр. Шундыйрак уйлар белән, тормышның бөтен кырыслыгына түзәрдәй булып килеп төште. Ләкин шәһәр матур иде. Кечкенә, пөхтә генә. Хәтта Татарстанның вграк шәһәрләре дә моның белән ярыша алмый. Бөтен нәрсә дә кыйбаттыр дип уйлый иде башта. Әмма бәяләр артык аерылмый диярлек. Кием-салым кыйммәтрәк, әлбәттә. Аның каравы, азык-төлек арзан. Шәһәр аңа шундук ошады. Монда төпләнеп калсаң да үкенерлек түгел. Бер атна чамасы эш эзләп йөргәч кенә монда аны беркемнең дә көтеп тормаганын аңлады. Эш табу жиңел нәрсә түгел икән.

—Кайгырма юкка,—дип күңелен күтәрде дусты.—Тормыш үзгәрмичә тормый ул. Сиңа да бирәр жирдән урын табылыр. Мин бер айдан артык яттым беренче килгәндә.

Чынлап та беркадәр вакыт үтүгә эш табылды. Акчасын да ярыйсы түлиләр, һөнәре буенча да туры килә. Бары тик бер генә әтнәкәсе бар—прописакасыз алмыйлар. Ә эш урының булмагач, беркем дә яшәү урыны бирергә атлыгып тормый. Шайтан куласасы килеп чыкты: эшең булмагач, яшәү урыны бирмиләр, яшәү урының булмаса эшкә алмыйлар. Тәмам күңеле сүрелгән иде инде егетнең. Дусты бу юлы да ярдәмгә килде.

—Пропискага үземә алам мин сине,—диде ул.—Ләкин үземдә озак яшәтә алмыйм. Яңа гына өйләнешкән кешеләрне аңларга тырыш инде. Жиңгәннең бик көйсез чагы, бәби көтәбез бит. Эшеңә урнаш та тору урынын хәстәрләрсең.

—Әлбәттә...—Дустына ул чиксез рәхмәтле иде. Чын-дөресен ярып әйтүенә дә үпкәләмәде. Барсы да егетләрчә.—Рәхмәт, дускай. Болай да житәрлек интектердем сезне.

—Ансыз гына булмый ул...—дип елмайды дусты.—Без кемнедер интектереп киләбез дә, бер урнашып алгач, бергәләп гомер итәбез. Эшкә урнаша торган жиреңнең тулай торагы бармы соң, белешмәдеңме?

—Прописка сорарлык булгач, бүлмә бирергә бик атлыгып тормыйлардыр инде.

—Ансы да дөрес... Нишләргә уйлыйсың соң?

—Белмим әле...

Дусты әйтергәме-юкмы дигәндәй бермәл икеләнеп торды.

—Бер вариант бар.—Ул тагын туктап калды.—Әйтсәм, ачуланма түлке, яме.

—Юк инде. Нишләп ачуланыйм ди.

—Мин әйтеп кенә карыйм. Кабул итсәң, яхшы. Кабул итмәсәң, яхшы. Барсы да үзеңнән тора.

—Әйтсәң, әйт инде. Әйтмәсәң, башны катырма.

—Бездә бер тол хатын эшли. Ире сөяркәсенә күчеп киткән. Баласы юк. Теге көнне безнең конторага килгән идең бит. Шунда сиңа күзе төшеп калган. Сораштыра. Ну, мин сөйләп бирдем инде. Ул үзенә фатирга кертергә каршы түгел.

—Йортка кертергә диген инде.

—Йортка кертергә түгел. Фатирга кертергә каршы түгел.

—Күпме түләргә кирәк инде?

Дусты пырхылдап куйды.

—Ансын үзегез килешәсез. Бик дәртле хатын инде. Аңа кочаклап ятарга ир кеше булса, бүтәне кирәкми дә. Ну, ашарга-эчәргә алырсың, ансы сүзсез дә аңлашыла.

Егет уйга калды.

—Бер яклап карасаң, ярамаслык түгел. Өстең бөтен, тамагың тук була. Баш очында вакытлыча түбә дә бар дигән сүз. Аякка басканчы, ярап торырлык. Ә тора-бара үзең хәстәрлисең. Килешеп китсәгез, бергә яшисез. Килешмәсәгез, башыңны алып китәсең.

Егет дәшмәде.

—Үзең карыйсың инде.

Эшкә урнашкач, бөтен шәһәрне бер итеп яшәр урын эзләде. Ләкин берниндә дә җай килеп чыкмады. Урын тәкъдим иткән жирдә хакны кыйбат сорыйлар, очсызлысында буш урыннар юк. Кайда барсаң да бер балык башы икән бу дөнья—берсе булса, берсе юк икән. Әле вокзалда, әле бергә эшләгән иптәшләрендә, әле «жир»дәге танышларында кунып айдан артык йөрде дә, дустының теге сүзен исенә төшереп, тәвәккәлләргә булды. Башкача болай булмый иде. Эшләгән бөтен акчаң күчтәнәчкә китеп тик бара.

Хатын ярамаслык түгел иде. Егеткә ул беренче күрүдә үк ошады. Нindidер назлы, үзенә тартып тора торган бичә. Мондыйлар белән бер бүлмәдә яшәргә дә, эшләргә дә, кочаклашып ятарга да була. Беренче күрү белән шулай уйлады егет һәм күңеленең кайсыдыр почмагы белән тойды—әлеге фикерләрнең тууына чарасызлык та беркадәр сәбәпче иде. Шулай итеп бер кыек астында яши башладылар һәм беренче төнне үк бер юрган астында очраштылар. Иртән уянганда икесенең дә күз төпләрендә зәңгәрсу түгәрәкләр хасил булса да икесенең дә карашлары канәгатьлек белән балкый иде. Мәхәббәт түгел инде бу. Күрер күзгә бик назлы күренсә дә, бу хатынны уз түшәгенә яткыру өчен әлләни зур егетлек тә кирәкми. Шуңа күрә, аның белән йоклауның шатлыгы да шул чама гына. Ләкин кот

очыргыч кайгы да, зур югалту да түгел.

Ул вакытта шулай уйлаган иде егет. Хәзер ана болай булып тоелмады. Гомеренең әллә нинди чит-ят сукмакларга кереп китеп, чуалып-чияләнеп бетүе өчен нәкъ аның шушы хатынга фатир керергә ризалашуы сәбәпче булып тоелды бүген. Чөнки барысы да шуннан башланды бит. Себергә күпләр китә. Күпләр йортсыз, эшсез йөри. Ләкин барысы да үз юлын таба. Эшен дә, яшәр урынын да. Аз гына сабыр булса, вакыйгаларны үзе теләгәнчә ашыктырырга тырышмаса, ул да коры калмас иде. Ләкин ул сабырлыгын тиз җуйды һәм җинелрәк юлны сайлады. Ә ул юл менә нинди хәлләргә китереп житкерде!

Әлбәттә, бу ханым бер иргә генә канәгать булып ята торган булса, болай килеп чыкмас иде. Шулай әкрен генә үз көннәрен үзләре күреп, өлешләренә төшкәне белән канәгать булып, беркемгә дә комачауламыйча гына яши бирерләр иде.

Ләкин алай килеп чыкмады. Егетне тиздән вахталы эшкә күчерделәр. Ул унбиш көн тайгада ятты, унбиш көн әлеге хатын янында. Вахтадан кайткан вакытларында фатирда бик зур кәеф-сафа эзләрен дә күргәләде. Хатынның йокысызлыктан шешенеп беткән йөзе дә, анда-монда тәгәрәшеп яткан шешәләр дә булды. Хәтта караваты астыннан кулланылган презерватив та чыкты. Ләкин егет тавыш куптармады. Хәтта кырын күз белән дә, шаяртып та әчендәген сиздермәде. Ана, әлбәттә, уңайсыз иде. Куенында дөньясын онытып, кайнар сүзләр пышылдый-пышылдый, акылыннан шашардай булып назланган хатынны башка берәүнең кочагында күз алдына китерү бер иргә дә җинел түгел. Әмма егет артык пошынмады да. Ул аның хатыны түгел иде. Ул егет яшәгән фатирның хуҗасы гына. Акча сорамый, юкка-барга бәйләнеп тормый, хажәтен үтәп тора... Ә көнләшү дигән нәрсә булмады. Ул моңа кадәр дә кемнәрнендер куенында эрегән, моннан соң да шулай дәвам итәчәк. Һәм вәссәлам.

Егет аны беркемнән дә көнләмәде. Ләкин... Ләкин бу чибәр ханымны, түшәктә сиңа ожмахның бөтен почмакларын күрсәтеп чыга алган дәртле ханымны, чынлап яратучылар да булгандыр. Чынлап яратучылар һәм анда фатирда торган егеттән (Ә без аның белән бернинди дә мөнәсәбәттә түгел. Ул мине бөтенләй кызыксындырмый.) көнләүчеләр булгандыр. Һәм бер аннан гына да түгел.

Ә бәлки, ире шушы йортка ияләшкән берәр хатынның түземлеге соңгы чиккә житкәндер. Алай булуы да мөмкин иде. Чөнки чибәрбикә өчен өйләнгән-өйләнмәгән дигән төшенчә бервакытта да булмады. Ярарлык дәрәжәдәге матур һәм сәламәт ир булса, калганы әһәмиятсез иде. Һәм ана Ходаймы, табигатьме шундый сәләт биргән, хатын теләсә кемне дәрте ташкан айгырга әверелдерә ала иде. Кайчагында егет болай да уйлап куйгалады: «Женси куәтен җуйганнарны җыеп дәваласа, бу дөньядагы иң бай хатынга әверелер иде, шайтан алгыры! Мин беркайчан да үземне шундый сексуаль ирмен дип белми идем. Искиткеч бит, искиткеч!» Үзенең яшәү рәвеше белән телгә керсә дә, кемнәрнендер жирәнүле карашына дучар булса да, бу ханымны хөрмәт итә иде ул. Аңлап та, аңлатып та булмый торган ниндидер үзенчәлекле ярату белән ярата иде. Вахтага киткән чакларында ана тартыла, озаграк күрешми торсалар сагына иде.

Ул көнне дә сагынып кайтты егет. Ләкин кайту белән фатирга ашыкмады. Ана тулай торактан бүлмә бирергә тиешләр иде, караңгы төшкәнче шунда барып, бүлмәсен карап кайтырга булды. Ачкычын кулына алса, бүген хатын белән төн үткәрер дә иртәгәдән шунда күчәр. Ни әйтсән дә үз бүлмән булу яхшы. Ә хатын белән араны өзәргә теләмәсә, баргалап йөрер, куна калгалар... Тиз булыр, бүлмәмнән бер урап чыгармын да кайтырмын дип

уйлаган иде. Алай килеп чыкмады. Ачкычын бирде комендант. Бүлмә соклангыч иде. Бер карасаң, артык әллә нәрсәсе дә юк. Бүлмә тек бүлмә инде. Ләкин ул бүлмәнең үзеннеке булуы соклангыч иде. Кечкенә булса да үз дөньям бар дигән сүз бу. Үз тормышым белән яши башладым дигән сүз. Егет вахтадан кайткан сумкасын шунда калдырды да коридорга чыкты. Комендант аңа елмаеп күз кысты:

—Иртәгә минем ял көне. Синең дә ялга кайтыш. Бүлмәне юып алабызмы әллә?

Егетнең моңа теләге юк иде. Ләкин карышырга да кыенсынды.

—Ныклап урнашкач, иркенләп юарбыз әле...

—Ансы берсүзсез шулай. Ләкин минем бүген эчәргә кәеф бар. Шуңа күрә, без бүлмәне икәүләп чылата гына торыйк.

—Ярый, алайса. Хәзер кибеттән урыйм.

—Юк, син аңламадың... Аракы минем үземдә дә бар. Бер үзем эчәлмим ич инде. Аннан соң, сөйләшер сүз дә юк түгел.

Бүлмәгә кире кереп утырдылар. Комендант кәрәзле телефоныннан кемгәдер шалтыратты да озакламый закускалар белән бер ярты китерделәр.

—Сине бик яхшы сварщик дип ишеттем...—диде комендант икешәр рюмка түнкәреп куйгач.—Халык сөйләсә, дөрес сөйли бит инде. Ә мин бүгеннән яхшы сварщикка мохтаҗмын...

Егет, әлбәттә, риза иде.

Йомышларын йомышлап килешкәч, берешәр рюмка җиппәрделәр дә комендант чыгып китте. Аның фатирындагы торбаларны алыштырырга гына кирәк икән. Ике-өч көнлек эш инде. Бушка, әлбәттә. Ләкин яшәр урын тапкан егет өчен акча әлегә бик мөһим дә түгел иде. Ул шатланып калды. Өстәлне җыештырды да фатирына кузгалды. Комендант белән берне төшергәч, аппетиты ачылган сыман тоелды һәм ул юл уңаендагы мәйханәгә кереп йөз граммлап чыкты, аннан соң фатир янындагы супермаркеттан күчтәнәчләр җыйды. Күтәргесез иде алган нәрсәләре. Ул моңа сөенде генә. Ни генә әйтсәң дә, фатир хуҗасына рәхмәте чиксез иде аның. Иң авыр вакытта иң зур таяныч булды. Бүгенге көнне дә бәйрәмгә әйләндерергә кирәк. Табын корып җибәрерләр. Туй табынын хәтерләтеп торсын.

Дәртле адымнар белән баскычтан күтәрелде. Кыңгырауга басты. Ишек ачучы булмады. Бераздан ул ишекне үзе тартып карады. Ачык иде. Ул инде Себернең сәер гадәтләренә күнегә төшкән иде, шуңа да уйлап та бирмәде. Монда ишек бикләү әлләни әһәмиятле булып исәпләнми иде. Ул бикле булырга мөмкин, мөмкин ачык булырга. Тик сиңа бернинди дә карак кермәячәк. Тәртибе шундый.

Ишек төбенә сумкаларын куйды да аягын салды. Ишекне бикләде. Хәзер хатын аның тавышын ишетеп, атылып чыгачак, егетнең куенына ташланачак. Ә аннан соң булачак хәлләр өчен ишекнең бикле булуы бөтенләй үк әһәмиятсез түгел иде.

Егет елмаеп куйды.

—Тук-тук-тук! Хәерле кич, хөрмәтле иптәшләр!

Ул кычкырып әйтте. Өйдә кеше булса, ишетмичә кала алмый иде. Сүзен тагын кабатлады. Җавап булмады. Инде аның иренендәге елмаю җыелыбрак калды һәм ул эчкә атлады. Бер мизгелгә күнелен рәнҗү уты телде. Түрдәге караватта хуҗабикә ниндидер ир белән ята иде. Шәп-шәрә килеш. «Ник монда килдем әле мин, тиле,—дип уйлады ул.—Үз бүлмәм бар көенә нишләп йөрим монда. График буенча иртәгә генә кайтырга тиеш идек бит. Нишләп әле шуны онытып җибәргәнмен?!.» Күнелендәге үкенү, рәнҗү ачысын кинәт гаҗәпләнү алыштырды. Ир дә, хатын да селкенмиләр иде. Кинәт

ул ак простыня буйлап идәнгә тамчылаган канны күреп алды. Боларны кемдер үтереп чыгып киткән иде. Күптән түгел генә. Кычкырып җибәрде. Һәм уйларының дөреслегенә ышанырга теләгәндәй, аяк астында яткан пистолетка үрелде. Пистолет җылы иде. Ул әлеге пистолетның чын икәненә ышанырга теләмәде. Бу уенчык пистолет кынадыр. Моның белән кеше үтереп булмыйдыр. Һәм караватта яткан ир белән хатын да үле түгелләрдер. Алар бары нәрсәдер уйнаганнар гына һәм хәзер үлгәнгә сабышып яталар гына. Бәлки, чынлап та шулайдыр... Ул көч-хәл белән аякларын сөйрәде. Ләкин аларның күкрәгендәге пуля эзен күргәч, менә тамчы да ышанычы калмады. Кычкырырга итте. Тавышы чыкмады. Ул җаны суырып алынган бәндәдәй, бүлмә уртасында аңгыраеп басып торуын белде.

Бары тик өйгә кемнәрдер атылып кереп, үзен идәнгә егып салгач кына, нинди хәтәр хәлгә юлыгуын аңлады. Тик ул гаепсез иде. Ул үтерүче түгел.

Ләкин ул үзенең үтерүче түгеллеген судта исбатлый алмады. Һәм унбиш елга төрмәгә эләкте. Хәзер аңлый инде, үтерүче булмаса да гаебе юк түгел иде. Ул үз тормышын гөнаһтан башлады, ә сафлыктан башланмаган юл сафлыкка илтми. Гөнаһ... Иректә чагында бу сүз аның төшенә дә кереп карамады бугай. Бары тик картәтисе, ә кайчагында әнисе дә гөнаһ турында искә алалар иде. Ләкин егет аларга бернинди дә игътибар бирми, бер колагыннан керсә, икенчесеннән чыгып ычкына. Дин турында да артык югары фикердә булмады. Бары тик төрмәгә килеп эләккәч кенә, мәңгелек төшенчәләр турында уйланырга вакыты күбәйде.

Үтерүчеләрне, гадәттә, җансыз һәм таш күңелле кешеләр итеп күзаллыйлар. Ләкин бу дөрес түгел. Алар да бөтен кешеләр шикелле үк яхшы һәм яман сыйфатлар җыелмасыннан тора. Һәм бөтен кеше шикелле үк газаплана, шатлана, соклана, җирәнә. Алар да гади һәм гадәти кешеләр. Бары тик тормышның билгеле бер мизгелендә холыкларының алама ягы өстенлек алган. Кылган гөнаһлары өчен чын күңелдән үкенүчеләр дә, Алладан да, шайтаннан да өметен өзеп башларын сантыйга салучылар да—барысы да бар алар арасында. Төрмә тормышында әйбәт якларыңны күрсәтү өчен шартлар юк, әлбәттә. Монда усаллык хөкем сөрә. Ерткычлар зонасы. Хәтта күңеле белән бик үк явыз булмаганнар да әйбәтлеген яшерергә мәҗбүр. Изгелек монда йомшаклык билгесе шикелле кабул ителә. Ләкин төрмә яхшы эшләрдән, изге гамәлләрдән мәхрүм түгел. Һәм тоткыннарның күңелен яшерен кимергән бер нәрсә—«ник әле болай килеп чыкты?»—дигән сорау—аларны уйланырга, бөек төшенчәләр турында фикер йөртергә мәҗбүр итә. Һәм дин юлына этәрә. Әлбәттә, бүтән сәбәп тә бар. Төрмә кырыслыгыннан качарга, беразга гына булса да реаль чынбарлыктан аерылып торырга, үзеңне дә башкалар кебек үк Алланың тигез хокуклы бер бәндәсе итеп тоярга тырышу. Адәм баласы һәрвакыт аңлауга, күңел җылысына мохтаҗ. Ләкин төрмәдә аны табып булмый, эзләнеп тә булмый. Бу йомшаклык. Әмма ул җылылыкны Ходайдан эзләү—табигый нәрсә.

Аларга төрле дин әһелләре килә иде. Баптистлар да, иудейлар да, православныйлар да. Муллаларның гына никтер күренгәне булмады. Әлбәттә православныйлар еш килә, бу дин, ни өчендер, дәүләтнең рәсми дине рәвешендәрәк кабул ителә иде. Михаил да шуна тартылды. Аннан соң, зонага килгән поп үзе дә яхшы кеше иде. Тормышның ачысын-төчесен күргән егет, һәркемнең күңеленә ачкыч таба белә. Һәм аның белән аралашкан саен күңелне ниндидер җылылык, киләчәккә ышаныч биләп ала иде. Михаил... Ул чакта үз исеме белән яши иде әле ул... Ул бөтен поплар да шундый изге күңелледер дип уйлый, менә бөтен барлыгы белән ышана иде. Һәм диннең тәгълиматлары да, һәм поп та аңа якын булып

тоелды. Ул алар белән якынайган саен күнеленә тынычлык тапты. Һәм кайсы вакытларда: «Ник безнекеләр христиан динен өнәп бетермәделәр икән. Менә дигән якты дин ич. Ник бөтен ил шуны тотмый икән?»—дип уйлады. Бары тик соңыннан гына, төрмәдән чыгып, чиркәүгә урнашкач кына үзенең никадәрле хаталануын аңлады. Төрмәгә килеп йөргән поп кебекләрне сирәк очратты ул ирекккә чыккач. Һәм бер нәрсәне аңлады: дин әһелләре дә бөтен кешеләр шикелле үк яхшы һәм яман сыйфатлар җыелмасыннан тора. Һәм бөтен кеше шикелле үк алдашалар, урлашалар, талашалар, бер-берсенә мәкер коралар икән.. Алар да гади һәм гадәти кешеләр. Бары тик тормышның билгеле бер мизгелендә холыкларының яхшы ягын гына күрсәтеп алалар. Ләкин боларны аңлау Михаилга җиңеллек өстәмәде. Дин әһелләренең изге күңелле булуы аның өчен күпкә яхшырак буласы иде. Бу аның туган ягына кайту мөмкинлеген өзде. Улын күрсә, әнисенең йөрәге ярылачак иде. «Кем минем улым?!—диячәк ул, рәнҗүле күз яшьләрен түгеп,—тюремчик, поп!» Һәм ул малаеның төрмәгә эләгүен, хәтта адәм үтерүен кичергән очракта да попка әверелүен күтәрә алмаячак.

Боларны аңлау җиңел түгел иде. Михаилның йөрәген утлы хәнҗәр белән кисеп алдылар шикелле тоелды. Ул мәңгегә дә төзәлмәслек хата ясады. Үз йөрәгенә үзе хәнҗәр кадады егет. Һәм ул хәнҗәр үләргә дә, бәхетле булып яшәргә дә ирек бирмәячәк.

«Минем улым—Михаил—тюремчик һәм поп!—дип күңеленнән кабатлады Михаил.—Ә киленем—маржа!» Һәм әтисенең тавышын ишеткәндәй булды: «Әнкәсе, тавыкларыңа җим сибеп кер әле!.. Малай белән сөйләшер чак житте...»

Әлеге тавышны ул аермачык ишетте. Һәм гаҗәпкә калды. Тагы ишетелмәсме дигәндәй, колак салып торды. Ләкин әтисенеке түгел, ә хатын-кыз тавышы ишетелде. Коридордан. Өзгәләнеп кычкырган тавыш... Михаилның бөтен уйлары мизгел эчендә очып юкка чыкты. Ул сикереп торып утырды. Кемдер ярдәм сорап кычкыра иде.

* * *

Бүлмәгә кергәч, Хәлил тагын телефонына үрелде. Телефон үле иде. Ул аны ачу белән караватына ыргытты. Россиянең мәңгегә шул инде—монда бернәрсәгә дә тулысынча ышанырга ярамый. Монда һәрвакыт уяу булырга һәм алдыңны-артыңны карап йөрергә кирәк. Ул үзен америкадагыча хис итте, онытылып китте. Һәм менә... Көтмәгәндә-уйламаганда, әллә нинди сәер хәлләргә юлыкты. Соңгы ике-өч көндә генә аны беркайчан да булмаганча итеп алдадылар. Нью-Йорк урамында очраган татар кешесе төп башына утыртып китте—бер. Телефон эшләми—ике. Һәм Россиягә кайтып, җанга якын урыннарда йөрисе урынга ул Ходайның хәтереннән төшеп калган ниндидер утрауда ята—өч. Һәм бу хәлдән ничек чыгарга икәнен дә белми—дүрт. Шайтан алгыры!

Юк, монда кайтып җиткәч, Казанга кул сузым ара гына ич инде. Ник ул шунда түгел? Бүген туганнары белән күрешеп, елашып-көлешеп таңнар атканчы сөйләшеп утырасы кеше бит инде, югыйсә. Әллә нинди бер аллакчы татар сүзенә ышанып, чүплек башына да ташларга җирәнерлек иске тагаракка утырып кит, имеш. Һәм менә... Башың эшләмәсә, шулай шул ул...

Ләкин ул мондый уйларын йөгәнләргә тырышты. Күңелендәгесен Робертка сиздерергә ярамый. Ни генә әйтсән дә, Россия—Хәлилнең туган иле. Әтисенең ватаны турында улы күңелендә алама фикер тумасын. Иң мөһиме—шул. Калганы үз вакыты белән җайланыр әле.

Болай уйлауга чынлап та җиңелрәк булып калгандай тоелды. Әйе, артык

хәвефкә бирелерлек сәбәп юк иде, бер карасаң. Утрау матур. Сәяхәт күңелле узды. Һәрхәлдә, Роберт, телне белмәсә дә, бер генә минут та боегып тормады. Дуслары да шундук табылды. Инглиз телендә ничек оста сөйләшүләрен әйт әле шул балаларның. Дөньяның төрле почмагыннан җыелган кешеләр түгел, ә бергә уйнап үскән яшьтәшләр диярсең. Россиянең да искиткеч яклары бар шул. Кеше монда ясалма түгел. Әллә нинди, әйтеп-аңлатып булмаслык халык. Урысы ни, татары ни—аерма зур түгел. Барсында да ниндидер уртак яктылык бар. Ихласлык. Әнә бит Робертны ничек якын итеп, туганнары кебек күреп үз араларына керттеләр. Америкада булса, аз гына башкачарак булыр иде. Читтән килгән кешегә анда барыбер чит итеп карыйлар. Елмаялар, көләләр—ә барыбер син үзеңнең чит икәнеңне тоясың. Монда киресенчә—монда читләрне якын итеп кабул итәләр. Үзенекен тапап узса уза, әмма читтән килгәнгә хөрмәт күрсәтми калмый. Борын заманда, әнә, татарлар ханнарны да читтән чакыра торган булган. Халыкның борын-борыннан килгән бер үзенчәлеге инде бу.

Робертның теге кыз белән калуын Хәлил, әлбәттә, күреп торды. Елга вокзалында ук күз-каш сикертешәләр иде. Тәки үз дигәнен иткәннәр. Ярый, бер-берсенә ошагач, теләгәннәрен кылансыннар. Бары тик соңыннан бәласе генә булырлык булмасын. Бу хакта улы белән күп тапкырлар сөйләшкәне бар, Роберт юләр егет түгел, башын югалтмас. Аның өчен Хәлил тыныч иде. Кызы да чибәр күренә. Яшь чагы булса, ул үзе дә берәр нәрсә уйлаган булыр иде. Молодец, малай! Җебегән түгел. Күзе күргәнне кулга төшерә белә.

Боларны уйлауга кәефе күтәрелеп китте. Ул монда килүеннән канәгать шикелле иде. Әлбәттә, канәгать иде. Бары тик арыткан гына. Баштарак кәефсезләнүе дә шул алжу аркасында иде бугай. Ярый, ял итәргә кирәк. Йокларга. Ә иртәгә барсы да тәртиптә булыр.

Хәлил улы кайтуына урын җәеп куйды. Аннан соң үз түшәген әзерләде. Өс-башын алыштырып урынга ятты. Күзләрен йомды. Күзләрен йому белән әтисенең канәгатьсез йөзе пәйда булды:

—Университетка керә, имеш, берәү! Ха!

—Ә нигә! Мин кемнән ким?!

Әтисе авыр сулап куйды.

—Анда безнең ишеләрне барыбер алмыйлар. Вакыт уздырып йөрмә.

—Алалар.

—Мин сиңа эш белешеп кайттым. Берәр ярты ел тракторда йөрерсең дә, тәртибең әйбәт булса, бригадир итеп куярлар. Авылда бригадирдан да яхшырак урын юк. Моны ычкындырырга ярамый.

Хәлил дәшмәде. Әтисе хаклы иде. Бригадир авылның хуҗасы, бөтен нәрсә үз кулында. Ләкин авыл кечкенә, ә егетнең хыяллары зур һәм аның бригадир буласы килми иде. Хәлил берни дә эндәшмәде, башын иеп өйдән чыгып китте.

Өнсез генә күзәтеп торган әнисе ана иярде.

—Әтиеңә ачуланма, улым,—диде ул җанны эретерлек тавыш белән.—Гади колхозчы баласының укырга керә алуына ышанмый ул. Ә кирәкле кешесен табып «майларга» безнең акчабыз юк...

Хәлил аны кочаклап алды.

—Әни...—Егетнең тавышы назлы да, катгый да иде.—Мин үз көнемне үзем күрер яшькә җиттем инде. Мин үзем теләгән җиргә китәчәкмен. Тик син ачуланма, яме.

Әнисе дәшмәде. Тулган күңелен чайпалдырмас өчен, аскы иреннәрен кысып, тын калды.

—Ярый, миңа димәгәе, хет Әмерикәгә кит,—диде аннан соң, үпкәләү катыш наз белән.—Тик бәхетле генә бул.

Кинәт әтисенең дәһшәтле тавышы яңгырады. Ул, күрәсең, барсын да

ишетеп торган иде.

—Китми беркая да! Карчык, бар әле тавыкларыңа жим сип...

Әтисенең бу сүзе улы белән икәүдән-икәү генә калып сөйләшергә кирәк дигәнне аңлата, һәм мондый сөйләшүнең нәрсә белән бетәчәге билгесез иде. Малаен ул каеш белән каезлап алырга да, нинди дер авыр эшкә йөгертергә дә, ихатаның берәр почмагына бастырып куярга да мөмкин. Тик нәрсә белән генә тәмамланса да, малай файдасына түгел. Бүген бигрәк тә. Әтисенең кыяфәте юньлелек вәгъдә итми иде.

Икәүдән-икәү генә калгач, әтисе озак кына сүзсез торды.

—Һәркемгә үз баласы кадерле,—диде аннан соң көтелмәгән йомшак тавыш белән.—Авылда калсаң, күз алдында булырсың. Кирәк чакта ярдәм итешеп яшәрбез. Җаныбыз тыныч булыр...

—Әти, энекәшләр бар бит әле. Алар авылда калыр...

—Һәр бала бердәнбер. Бердәнбер һәм кабатланмас.

—Мин укырга керергә телим.

Әтисе тагын тын калды.

Тәмәке алып кабызды. Тартуын берничә ел элек ташласа да, ул кесәсендә гел берәр пачка «Астра» йөртә иде. Ютәлләп алды һәм сүгенеп тәмәкесен сытты.

Тагын бер тын уйланып торды.

—Ярый,—диде аннан соң, әрнүле елмаю белән.—Әниең хаклыдыр... Мина димәгәе, хет Әмерикәгә кит, тик бәхетле генә бул.

...Хәлил яңагы буйлап тәгәри башлаган күз яшьләрен сөртеп куйды. Торып утырды.

Әтисе дә, әнисе дә сайлауны шул рәвешле малайның үз иркенә калдырсалар да: «Мин укырга китәм инде. Әти-әни сау булыгыз. Уңыш теләп калыгыз»,—дип китәргә аның йөрәге җитмәде. Бу сөйләшүдән соң, Хәлил турында башкача сүз кузгатылмады. Энекәшләре инде аны авылда калырга булды, дип уйлап сөенә дә башлаганнар иде бугай. Ләкин Хәлил көннәрнең берендә энекәшләрен җыеп алды да һәркайсына кечкенә бүләк өләшеп чыкты. «Мин шәһәргә китәм, егетләр,—диде аннан соң.— Тик бу хакта әти-әнигә әле әйтми торыгыз. Кич җиткәч кенә әйтерсез. Борчылмасыннар. Барып җитү белән хат язармын. Хушыгыз». Бүләкләр өчен сөенгән малайлар аның китүе турында уйлап та бирмәделәр.

Хәлил кеше күзенә күренмәскә тырышып, ындыр артлап кына олы юлга чыгып китте.

Олы юлга...

Хәлилнең тамагына төер килеп тыгылды. Күзләре янә яшькә чыланды. Роберт кайтуына елап утыру яхшы түгел иде. Тынычланырга, йокларга кирәк. Тынычланырга һәм йокларга...

Ул сумкасында актарынып йокы даруын эзләп алды. Бер төймә йотып куйды. Бераз уйланып торды да тагы ике төймә алып йотты. Артык булмас әле. Аның ярсыган йөрәген тынычландырыр өчен бик таман гына булыр.

Хет, Америкага кит...

Ул зур компаниянең җитәкчесе һәм әти-әнисе хыяллана да алмаганча бай әфәнде иде. Аның белән очрашкач ук күпләрнең күзенә майлы ялагайлык саркылып чыга, телләрендә ярарга тырышу теләге сайрый башлый. Ләкин Хәлил бәхетлеме соң? Бәхетлеме ул?

Хәлил бу сорауга бер сүз белән генә җавап бирә алмый иде.

Бераздан бөтен булмышында арыганлык тоеп, ул урынга ятты.

Аркасы түшәккә тигәч, бөтен тәнен нинди дер ләззәт биләп алды. Утрау ташландык урын сыман тоелса да, караваты яхшы иде. Йомшак, назлы.

Бераздан Хәлил җиңелчә генә гырылдап йокыга китте.

* * *

Минем исемем Анна...

Шушы сүзне ишетү белән, Хәмитнең күнеле тынычлыгын җуйды. Тирәякта барган күренешләр аның өчен әһәмиятен югалтты. Зиһенендә бары тик бер генә сүз бөтерелде. Анна...

Болай булырга тиеш түгел иде. Ул инде иллене куган ир, буйга җиткән ике баласы, гомер буе терәк булып янәшә атлаган хатыны бар. Ул инде үсмер егет түгел, тормышка аек күз белән карарга тиешле кеше, ил агасы булырдай зат.

Болай ярамый иде.

Ләкин күнелендә бары тик бер сүз яңгырады. Анна. Һәм шул исем тынгы бирмәде.

Кинәт кенә үзгәреп китүен хатыны да сизде бугай. Ләкин ул моңа артык әһәмият бирәлмәде—күз алдында пәйда булган утрау барсының да игътибарын суырып алды, үзенең серлелеге, матурлыгы белән әсир итте.

Ә утрауда үзләре генә калгач, барсының да йөрәген шом алды. Алдагы билгесезлек бөтен уй-хисләрне үзенең ачы авырлыгы белән бастырып куйган шикелле тоелды. Моңа күнегелгән дөньяларын ташлап, нииндидер хатка алданып чыгып киткәннәре өчен үкенү дә кушылды. Һәм һәркайсы үз эченә бикләнеп, үз шик-шөһбәләре белән бер булды. Кешедә кеше кайгысы юк иде. Ләкин шул вакытта да Хәмитнең күнелендәге теге аваз тынмады. Ул сагышлы күренешләрнең музыкаль фоны шикелле, күнелдә яңгырап торды.

Бераздан, йортка урнашып, тамак ялгап алгач, кәефләр күтәрелеп киткәндәй булды. Хәмит тә гомум күтәрелештән читтә калмады, нәрсәдер әйтте, шаяртып та алды. Балалары белән дә ягымлы итеп, сүзләре күнелгә дәрт өстәрлек итеп аралашты. Ләкин теге аваз һаман туктамады.

Ул аваз йокларга яткач та туктамады һәм Хәмит бер нәрсәне ачык аңлады. Әлеге генә, бүген генә ишетелгән аваз булмаган ул. Шушы сүз, шушы исем гомер буе аның күнелендә яңгырап торган. Бары тик көндәлек мәшәкатьләр, ыгы-зыгылар белән булашып, моңарчы Хәмит аны сизмәгән генә.

Анна...

Еллар томаны акрын гына таралды да аның житен чәчләре, алсу яңаклары, озын керфекләре арасыннан сихри нур сирпеп караган зәңгәр күзләре пәйда булды. Аның күзләре тилерткеч бер гайрәт белән яналар иде. Йөрәгеңне эретерлек наз да, җаныңны телгәләрлек үкенү дә бар сыман иде бу күзләрдә. Бәлки, Хәмиткә генә шулай тоелгандыр. Югыйсә, Анна аны гаепләп бер генә сүз дә әйтмәде, бер генә шелтәле караш та ташламады бит инде. Беркайчан да.

Анна белән ул бәхетле иде. Беркайчан да, беркем белән дә булмаганча. Һәм үзләрен очраштырган, яратыштырган язмышка алар рәхмәтле иделәр. Дөнья түгәрәк, тормыш матур иде. Һәм ул киләчәктә тагы да яктырак, назлырак, матуррак булыр сыман иде. Моңа аларның ышанычы көчле иде.

Әлбәттә, егерме яшьлек чагында тормышка бүтәнчәрәк карыйсың. Гомерең—алда, һәм аның һәрбер көне сиңа чиксез шатлык, зур уңышлар гына алып килер төсле тоела. Моңа ышанырга бер сәбәбең булмаган хәлдә дә, киләчәктән тик яктылык кына көтәсең. Шуңа ышанасың.

Ләкин аларның ышанычы коры өметкә генә корылмаган иде. Берсенберсе өзелеп яраталар, ә ярату—теләсә кемне кодрәтле итә торган тылсымлы көч. Җаныңда—ярату, яныңда сөйгән ярың барда, тормышның бернинди авырлыклары да сиңе җиңә алмас сыман тоела. Син—дөньяның кендеге, син барсыннан да көчле. Ходай сиңа шундый зур ярату биргән икән, димәк

ул үзе дә сине үз итә дигән сүз. Өнәмәгән бәндәсенә ул шултиклем зур кодрәтне, шултиклем зур тылсымны ышанып тапшырмас иде.

Хәмит бәхетле иде. Аның Аннасы бар.

Анна да бәхетле иде. Аның Хәмите бар.

Анна район үзәгендәге музыка училищесында укыган күрше кызына ияреп кунакка кайткан иде. Хәмит аны автобус тукталышында ук күреп калды да, калтырап беткән иске матае белән тузан туздырып яннарыннан узып киткәч кире борылып килде.

—Сәлам, Гөлчәчәк,—диде ул кунак кызыннан күз дә алмыйча.—Ялга кайтып килешмени?

Гөлчәчәк нәрсәдер дип җавап бирде дә сумкаларын матай арбасына куйды. Һәм кунак кызына арткы утыргычка утырырга ымлап, үзе коляскага кереп чумды.

Хәмит аңа шултиклем нык рәхмәтле иде. Кунак кызы ике аягын да бер якка салындырып утырды да, егылып китмәс өчен, сак кына итеп Хәмитнең биленнән әләктерде. Кем булса да шулай итәр иде. Әмма Хәмит шат иде. Кыз аны үзе кочаклап алган сыман тоелды. Болай уйлаудан ул чак һушын җуймады. Бөтен тәнендә нииндидер рәхәтлек тоеп, дәрт белән газны ачты. Матай кинәт алга ыргылды. Тик егет урам аша чыгып барган каз бәбкәләрен күреп тормозга басты. Матай кинәт тизлеген киметте һәм кунак кызы бөтен тәне белән аның аркасына сарылды. Бары тик бер генә мизгелгә. Ләкин бу мизгелне аның мәңге оныттачагы юк. Ул аркасына кызның тыгыз күкрәкләре терәлүен, колак төбендә аның назлы сулышын тойды. Ул хәтта аның йөрәк тибешен дә ишеткәндәй булды. Һәм кинәт башы әйләнеп китте. Ярый әле Гөлчәчәк бар иде. Ул урыныннан калкына биреп, егетнең җилкәсенә кагылды.

—Хәмит!

Егет шунда гына һушына килде. Юл читенә утыртылган агачларга табан юнәлгән мотоциклын тигезләде. Тизлекне киметеп кызга борылды.

—Нәрсә дисең, Гөлчәчәк?..

—Туктап тор әле.

Хәмит туктады.

—Хәмит, бу кыз минем ахирәтем. Анна исемле,—диде Гөлчәчәк шаян бер усаллык белән.—Анна, ә бу—Хәмит, безнең күрше мала... егете. Анна белән без бер атна буе авылда булачакбыз, Хәмит. Сез әле теләгәнчә сөйләшә дә, дуслаша да алырсыз. Ә әлегә... Хәмит, пажалыста, исән-имин генә кайтарып житкер безне.

Хәмит дәшмәде. Аңа уңайсыз иде. Көзгедән Аннага күз салды. Ул Гөлчәчәккә рәхмәтле караш ташлап алды да Хәмитнең көзгедән күзәтүен күреп елмаеп куйды. Анна елмая иде. Ләкин бу мәсхәрәле елмаю түгел, ә теләктәшлек белдерү сыман иде. Хәмит хәтта аның сүзләрен дә ишеткәндәй булды. Гөлчәчәк дөрес әйтә, Хәмит. Безнең әле танышырга да, дуслашырга да вакытыбыз күп булачак. Өстәвенә син дә миңа ошыйсың... Һәм Хәмит нииндидер якты бер тынгысызлык белән кайтырга кузгалды. Капка төбенә килеп туктагач та ул бер сүз дә эндәшмәде. Нәрсәдер әйтергә кирәген тоя иде, әлбәттә. Болай үпкәләгән кеше сыман торырга ярамый иде. Тик ул берни дә әйтә алмады. Хәтта карашларын Аннадан аера алмаячагын тоеп, күзләрен дә күтәрмәде.

—Рәхмәт, Хәмит!—диде Гөлчәчәк, сумкаларын алгач.—Рәхмәт...

Хәмит дәшмәде.

Ул күзләрен күтәрде дә Аннаны күрде. Һәм... тораташ сыман булып катып калды. Юк, тораташ сыман түгел... Бу читтән караганда гына шулай тоелгандыр, ә асылда ул киеренкелекнең соңгы чигенә житеп бер мизгелгә

генә тынып калган вулкан хәлендә иде. Юк, алай да түгел...

Ул гашыйк иде.

Һәм ул Аннаның күзләрендә дә гашыйклар карашында гына балкып китә торган очкынны күреп калгандай булды.

Ул бәхетле иде.

Мотоциклын кабат кабызып тормады. Койма буена гына этәреп куйды да ләззәтле бер исерү астында верандага кереп ятты. Беренче мәхәббәтнен аяктан егарлык беренче ләззәте иде бу.

Шушы көннән алып ул гел бәхет эчендә яшәде. Вак-төяк мәшәкатьләр, күңелсезлекләр булса да—боларның барсы да бәхет эчендә иде. Ә күңелсезлек булды. Анна белән яратышып йөргәннәрен сизеп торган әнисе көннәрнен берендә гадәтенчә йомшак кына кисәтеп куйды:

—Яшьлек—тиле, мәхәббәт—сукыр була, балам... Үз хәленә күзенне ачыбрак кара әле...

—Нәрсә булган, әни?

—Белмим, балам... Әтиенә кичә: «Өйрәнә тор»,—дип татарча-урысча сүзлек биреп кайтарганнар. МТМ ирләре. Бу аптырашта калган. Шуннан синең маржа артыннан чабуынны житкергәннәр. «Киленең маржа булса, кирәк булыр. Урысчанны ныклап яңарта тор»,—янәсе.

Хәмит телсез калды.

—Ә кемнең кем белән йөрүендә кемнең ни эше бар?!—диде ул бераздан, тупаслыгын җинәргә тырышып.

—Белмим, балам... Безнең авылда маржага өйләнеп берәүнең дә бәхетле булганы юк. Бәлки, шуңа ишарәлиләрдер.

—Нинди аерма?! Маржа ни, татар ни, башка ни... Барсы да кешенен үзеннән тора ич! Татарның да төрлесе бар, алайга китсә.

—Ансы да дөрес, балам... Татарның да төрлесе бар...—Әнисе бертын уйланып торды да сөйләп китте.—Әнә, югары очтан Хафиз абыенны беләсең инде. Әнисе белән икесе генә яшиләр. Менә ул да маржага өйләнеп читкә чыгып киткән иде. Олыгайган көнендә, ике баласын ияртеп авылга кайтып төште. Хатыны куып кайтарган. Бу шахтада күмер кискәндә, өстеннән йөргән икән. Балалары да башка кешедән дип сөйлиләр. Ләкин үзләре «әти» дип кенә торгач, нишлисең...

—Барсы да андый булмый бит инде.

—Фәрит абыеңны да беләиден инде син. Аның да Начтясы үз туганнары җыелган саен: «дикий татарин», «мамай» дип мыскыллый торгач, Фәрит түзмәгән, хатынының яңагына чабып җибәргән. Ә тегеләргә шул гына кирәк булган, кыйнап имгәтеп ташлаганнар. Гарьлегенә түзә алмыйча асылынып үлде.

—Әни...

—Тыңлап бетер, балам. Маржага өйләнгән уникё кеше бар авылда. Мин һәркайсын сөйләп чыга алам. Тик берсе дә бәхетле булмадылар. Гел нинди дә булса фаҗига килеп чыкты. Минем урысны яманлыйсым килми. Үз татарына биргесезләре бар араларында. Ләкин без—ике халык. Капма-каршы ике халык. Бер казанга ике тәкә башы сыймый диләр бит. Менә без дә шулай. Без бер кыек астында тату гына яши алмыйбыз. Чөнки каныбызда гасырлар буена, буыннан буынга күчеп килгән каршылыклы хис ага. Ул хисне бернинди сәясәт тә, аерым кешеләр арасындагы дуслык та, хәтта мәхәббәт тә җинә алмый. Ул хәтта безнен аңыбызга да буйсынмый, ул хис безгә буйсынмый...

—Әни...

—Әйе, улым. Әтиең дә, мин дә риза түгелбез.

Хәмит тынып калды.

—Тик мин аны... Әни, әгәр мин аңа өйләнсәм, нәрсә була?

—Авылда уникe адәм бар дидем бит... Син уннөченче буласың, балам...

Бу сөйләшүдән соң Хәмит һушына килә алмыйча озак йөрде. Әнисенең сүзләрен тикшерергә теләгәндәй, авылдагы теге уникe кешенең язмышы белән кызыксынды. Барсы да дөрес иде. Ләкин моңа ул күңеле белән ышанырга теләмәде. Шундыйлар арасында бәхетле кешеләр дә бардыр бит инде. Аз гына булса да, бер генә булса да. Күрше авылларда булса да. Ул күрше авылдагы дус малайлары аша шундыйлар турында белеште. Тик күңелен канәгатьләндерерлек бер генә җавап та ишетмәде. Әнисе хаклы иде. Һәм аның борчылуын да, малаеның әлеге гамәленә каршы килүен дә аңлап була иде. Алар урынында булса, Хәмит, бәлки, үзе дә нәкъ шулай эшләр иде.

Ләкин...

Доктор сиңа болай ди: «Йөрәгеңдә чир бар. Бу йөрәк белән син озак яши алмаячаксың. Син бу йөрәк белән бәхетле була алмаячаксың». Һәм нәкъ шушы авыру белән бәлагә юлыкканнарны санап китә. Син, әлбәттә, аның сүзләре хак икәнен беләсең. Ләкин йөрәгеңне йолкып ыргыта алмыйсың.

Анна аның йөрәге иде.

Әлеге күңелсез сөйләшү башкача кабатланмады. Хәмит эчтән әллә нинди тетрәнүләр кичерсә дә бу хакта Аннага бер сүз дә әйтмәде. Бергә чакта мондый нәрсәләр үтә дә кечкенә булып күренде. Аларның мәхәббәте янында ул чынлап та бәләкәй, әһәмиятсез бер нәрсә иде. Алар бәхетле һәм бәхетләренә бернәрсә дә комачауламаячак иде.

Бераздан Анна училищены тәмамлап, музыка укытучысы булып Хәмитләр авылына килде. Монда, әлбәттә, егетнең дә кулы уйнады инде. Район мәгариф бүлегенең юлын хәтсез таптады ул. Ә теләгенә ирешкәч, шатлыгы эченә сыймады. Тик ул куанычны уртаклашырга гына кеше юк иде. Әти-әнисе бу хакта сөйләшүдән гел читләштеләр. Энеләре армиядә иде. Ә дус-ишләре аның шундый эчкерсез мәхәббәтен аңлап җиткермиләр сыман тоелды. Ләкин ул бәхетле иде.

Анна авылга күчеп килгәч, фатирга да Гөлчәчәкләргә урнашты. Күршегә генә. Көн дә күрешеп тордылар. Кирәксә-кирәкмәсә дә гел бергә булдылар. Хәзер инде бер-берсен өзелеп яратуларына берсенең дә күңелендә шик юк иде. Үзләрен әдәп кануннары белән артык чикләп тә маташмадылар. Сөюнең тилерткеч назларына икесе дә бер куркусыз һәм зур теләк белән ташланды. Алар сөюдән тәм табып, шуның белән бәхетле булып яшиләр һәм башкада берсенең дә бер эше юк иде.

Авылда башта таралган имеш-мимешләр, мәсхәрәле сүзләр тына төште. Хәмит белән Аннаның керсез мәхәббәтенә барсы да күңелләреннән генә соклана, һәм алар турында алама сүз әйтү ниндидер пычраклык сыман тоела иде. Аннаның тиз арада татарча өйрәнүен күреп кайберәүләр хәтта уфтанып та куйгалый: «Эх, нигә бу татар кызы түгел микән! Бигрәкләр дә соклангыч бит...»—дип әйткәли торган иде. Чынлап та Анна татарча өйрәнүе белән генә түгел, ә үз-үзен тотышы, якты күңелле булуы белән дә авыл халкының ихтирамын тиз яулады. Аңа инде чит итеп карамадылар, үз кеше булып китте. Шул ук вакытта аларның шушындый соклангыч мәхәббәтеннән барсы да фаҗига көтте. Бу тиклем илаһи яктылык, бу хәтле соклангыч мәхәббәт озын гомерле була алмас, нинди дә булса бәхетсезлеккә юлыгырлар, диделәр. Берсенең татар егете, икенчесенең урыс кызы булуы әлеге шикне көчәйтте генә. Һәм аларның хисләренә тыкшыну, гайбәткә күмү чиркангычтан да чиркангычрак бер гамәл булып тоелды. Авыл халкы алар хакында бер генә алама хәбәр дә сөйләмәс булды. Ә бу гашыйкларның киләчәккә ышанычын арттырды гына.

Хәтта теге вакытта әнисенең әйткән сүзләре дә бөтенләй башкача янгырады. «Син ана өйләнмәячәксең!»—димәде бит. «Син унөченче буласың»,—диде. Димәк, әти-әниләре аларның өйләнешүенә аркылы төшәргә жыенмый.

Бергә чакларында бик бәхетле булсалар да соңгы арада Аннаның күзләренә оялаган монсулык Хәмитнең игътибарыннан читтә калмады. Башта ул бу хакта берни дә әйтмәде. Әмма тора-бара эндәшмичә кала алмады. Ләкин Анна бернинди дә анык жавап бирмәде.

—Юк ла... Сина гына шулай тоеладыр,—дип елмаеп кына куйды.

—Тоелмый,—дип каршы төште Хәмит.—Син ни өчендер үкенәсең, нәрсәдәндер куркасын шикелле.

Анна ана беренче тапкыр күргәндәй текәлеп торды да жанны эретерлек итеп елмайды:

—Юк ла, тилекәем... Нәрсәгә үкеним инде мин?!. Ә курыксам, бары тик сине югалтудан гына куркамындыр.

Ләкин аның күзләрендә елмайганда да югалмый торган сагыш бар иде. Егет моны сизми калмады. Әмма төпченеп кызның мазасына төшүне хуп күрмәде.

—Син курыкма мине югалтудан. Һәм бернәрсәгә дә үкенмә, яме. Без бәхетле булачакбыз.

Беркадәр вакыт үтүгә Аннаның авырга узуы беленде. Хәмит аның күзләрендәге монсулыкны таратырга тырышып үзләренең киләчәктә ничек бәхетле булачаклары турында хыялланып утыра иде.

—Без синең белән икәү... Без икәү шундый итеп яшәрбез... Без синең белән...—Анна шушы сүзләрнең еш кабатлануын елмая биребрәк тынлап торды да егетнең иренено бармагын куеп туктатты. Бертын аның күзләренә карап торды. Аннан соң назлы итеп башын аның күкрәгенә терәп алды һәм егетнең уң кулын учына алып, эченә кысты.

—Хәзер без икәү генә түгел инде, Хамит...—диде Анна кыенсынып кына.—Мин... Безнең бәләкәчебез булачак.

Бу сүзне Хәмит көтмәгән иде. Башта ялгыш ишетмимме дигәндәй сагаеп калды. Аннан соң елмаеп торган Аннаны шашып кочаклады һәм тилереп үбәргә тотынды:

—Бердәнберем минем! Кадерлем! Хатыным син минем! Хатыным! Рәхмәт сиңа, жаным!

Тәүге хисләрдән тынычлана төшеп башын күтәргәч Аннаның яңаклары буйлап тәгәрәгән күз яшьләрен күрде. Ул сулкылдап елый иде. Хәмит бер мәлгә телсез калды. Аннан соң назлы бармаклары белән хатынның яңагын сөртте.

—Елама, бергенәм.

—Синең белән шундый бәхетле мин, Хамит!—диде хатын күз яшьләреннән калтыранган тавыш белән.—Син ташлама мине, яме. Бергенәм минем...

—Мин сине беркайчан да... беркайчан да ташламаячакмын...

Аннаның авырга узуын белү белән Хәмит өйләнү турында сүз кузгатты. Жаен туры китереп, әтисенең дә, әнисенең дә кәефле чагын эләктереп башлады ул сөйләшүне.

—Әти... Әни... Мин... мин өйләнергә булдым...

Бу сүз икесен дә салкын су белән коендыргандай булды. Алар мизгел эчендә башка сурәткә керделәр. Әнисенең йөзен ниндидер соры күләгә каплады. Әтисе кара болытка әйләнде.

—Кемгә?

Бу сорау вакытны сузу, зиһен туплау өчен генә иде, әлбәттә. Хәмит бераз тын торды. Аннан соң үз күңелен төшермәс өчен елмая биребрәк:

—Аннага,—диде.

Әтисе дәшмәде. Әнисе шелтәле карашын егеткә төбәп алды да идәнгә кадады.

Тынлык озакка сузылды.

Әле генә син дә мин булган гаиләдә ниндидер дошманлык рухы пәйда булды. Ул рухны тотып карарга мөмкиндер сыман тоелды. Һәм Хәмит үзе дә сизмәстән: «Никадәр ят һәм чит икән миңа бу кешеләр,—дип уйлап куйды.—Алар минем бәхетемә аркылы төшә. Алар мине дошман итеп күрә.» Һәм үзенең шулай уйлый алуы өчен гаҗәпләнеп калды. Үзенне җил-яңгыр тидермичә карап үстергән кешеләр бит. Ата белән ана. Адәм баласы өчен изге затлар. Күктә Алла бар да, җирдә—болар. Ләкин уйланасы уй уйланган иде инде

—Мин синең өйләнү хәбәренне көткән идем,—диде атасы бераздан.—Үз баланның өйләнү турындагы сүзеннән дә яктырак нәрсә юк ата өчен. Абыең, әнә, чыгып китте дә югалды. Ни хаты, ни хәбәре. Әллә исән, әллә юк. Ә син монда—безнең күз алдында. Һәм өйләнү турында сөйләп утырасың. Күптән көтелгән нәрсә турында. Бүген минем иң бәхетле көнем булырга тиеш иде. Ләкин син шушы бәхетле көннең бар ямен җибәрдең.

Йөрәк тибеше ишетелерлек тынлык урнашты.

Ләкин беркемнең дә йөрәк тибеше ишетелмәде. Әйтерсең, бу өйдә бер генә йөрәк тә юк иде.

Һәм әтисе кырт кисеп әйтеп куйды:

—Өйләнмисең маржага!

Әлеге сүз яшен булып сугарга тиеш иде. Ләкин Хәмит тыныч калды. Ул бу сүзгә әзер иде. Ул бары тик шушы сүзне генә көткән шикелле иде.

—Авылда уникe кеше маржага өйләнгән,—диде ул, тыныч кына.—Һәм барсы да ниндидер бәхетсезлеккә очраган. Мин моны беләм. Сез минем дә алама хәлгә калуымнан куркасыз. Ләкин аңа өйләнмәсәм, мин, барыбер, бәхетсез булачакмын.

Тагын тынлык урнашты.

—Әнкәсе, тавыкларыңа җим сибеп кер әле...

Әнисе теләр-теләмәс кенә чыгып китте. Әтисе акрын гына урыныннан кузгалып, тәрәзәгә капланды. Шул кыяфәтендә озак басып торды. Хәмитнең инде түземлеге бетә башлады.

—Әти...

Әтисе кинәт борылды да урыныннан калкынган егетне сугып очырды. Хәмит идәнгә барып төште. Торырга итте. Ләкин әтисе аны тагын эләктереп алды. Тагын берне кундырды. Егеткә җинел түгел иде. Аның йөрәгендә әрнү дә, үпкә дә, мәсхәрәләнү тойгысы да, нәфрәт тә—барсы да бар иде. Ләкин әтисе бу тойгыларга тамыр җәяргә ирек бирмәде, күз ачыргысыз бер көч белән улын дөмбәсләде.

Аннан соң, көч-хәл белән сулыш алып урындыкка барып утырды. Ул бер сүз дә әйтмәде. Бары тик йөзе генә коточкыч кара көйгән дә куллары гына сизелер-сизелмәс дерелди иде.

Хәмит тә акрын гына торып идәнгә утырды. Кул аркасы белән канаган борынын, ирен читләрен сөртеп алды. Авыртуны ул бик сизмәде. Ләкин кимсенүдән елыйсы килә иде. Шуңа бер сүз дә дәшмәде. Сүз әйтергә дип авызын ачса, елап җибәрер төсле булды.

Әтисе торып бәләкәй якка чыгып китте дә бераздан ярты литрлы банка белән көмешкә алып керде. Ике чынаяк алып өстәлгә утыртты. Бертын улына карап торды. Кулын сузды. Хәмит сузылган кулга карап кына куйды да үзе торып басты.

—Утыр,—диде әтисе, өстәл артына ымлап.—Берне җибәрмичә булмый.

—Мин эчмим.

—Эчәсең.

Әтисе ике чынаякка да яртылаш көмешкә салды.

—Әйдә.

Хәмит аракы белән артык дус түгел иде. Әтисе алдында беркайчан да эчкәне юк. Ул бертын кыенсынып торды да салып куйды. Аракы ирендәге яраны ачыттырып төшеп китте. Хәмит чыраен сытты. Әтисе ана көлемсерәп карап куйды.

—Туйны кайчанга дисең?

—Ә?!.

Хәмит моны көтмәгән иде. Кинәт анын бөтен үпкә, бөтен әрнүләре юкка чыкты.

—Тизрәк эшләргә инде...

—Сез, яшьләр, барсын да тиз эшләргә тырышасыз шул...

—Рәхмәт сиңа, әти!

—Рәхмәт...—дип ирештерде аны әтисе.—Татарда кыз беткәндер... Бар, чыгып ычкын, йә тагы өлеш алырсың...

Хәмит шатланып чыгып чапты.

Анна белән очрашкач, ул аны сөендерергә ашыкты.

—Минекеләр риза, кадерлем! Син сөйләштеңме? Туйны кайчангарак чамалыйбыз?

Анна дәшмәде.

Ул бертын күзләрен йомып торды да:

—Минекеләр риза түгел...—диде ниндидер бер сабырлык белән.—Татарга бирер өчен кыз үстермәдек, диләр...

—Ярый, ризалашырлар әле. Олыларны беләсең бит инде... Минекеләр дә бераз карышып торганнар иде башта.

—Минекеләр күптән риза түгел. Синең белән йөргәнемне ишеткәч тә башланган иде. Кайткан саен колак итемне ашап тордылар. Әни хәтта РОНОга да барган. Башка авылга күчерүне сорап. Әле өйләнешү турында әйткәч, өйдә гауга купты.

Хәмит аны үзенә ныграк кысты.

—Ә йөкле икәнеңне әйттеңме соң?

—Әйттем...—Анна елап җибәрмәс өчен иреннәрен кысты.—Төшертергә кушалар...

—Төшертергә?!.

Хәмит мондый нәрсәне көтмәгән иде.

—Тотынып кына карасыннар!

—Алар тотыначак, Хамит... Безгә бергә булырга язмагандыр инде...

Анна егетнең күкрәгенә капланып елап җибәрде.

Егет бер мәлгә тын калды. Аннаның күзләреннән аккан яшь утлы нәфрәт булып анын күкрәгенә тула сыман иде.

—Әгәр ризалык бирмиләр икән, алар сине кабат күрмәячәк,—диде ул.

—Нәрсә?!.

—Без синең белән качып китәчәкбез. Еракка.

—Бердәнберем минем!..

Ике көннән соң кызнын әти-әнисе янына баргач та Хәмит шул сүзләрне әйтте. Ләкин тегеләрнең исе дә китмәде. Алар хәтта Хәмитнең киләчәген белеп, әзерләнеп көтеп торганнар иде. Бу хакта хәбәр итүче булмаса да. Һәм һәр сүзенә җаваплары әзер иде.

—Татардан кыз алырга мөмкин әле...—диде әтисе.—Ләкин татарга кыз бирергә... Юк, күгәрченкәем, юк. Башыңа да китереп карама. Без Аннага да гел әйтеп килдек. Араңны өз, рөхсәтебез юк дидек. Эшләр тирәнгә киткәнче

үк бәйләнешне өзәргә иде. Мәхәббәт туйда гына кирәк ул, өйләнешеп бишун ел үтүгә бернәрсәсе дә калмый. Татарга чыгып рәхәт күргән хатын-кыз юк әле. Шулай булгач...

—Безнен өчен барсы да хәл ителгән инде,—диде Хәмит тынычлыгын җуймаска тырышып.—Әгәр каршы киләсез икән, кызыгызны башкача күзегезгә дә күрсәтмим.

—Егет! Егет кеше сүзе!—дип көлде ир.—Синең рус булмавың кызганыч мина. Ике дә уйлап тормас идем. Ә болай...

—Мин шаяртып әйтмим.

—Беләбез,—дип сүзгә кушылды әнисе.—Без синең килеренне дә белдек. Нәрсә әйтеренне дә. Һәм син дә бел, кайда гына чыгып китсәгез дә, безнең күз уңыннан ычкынмаячаксыз. Сихерче Мария үзебезнең кеше. Бер әпсене җитәр...

—Ха-ха-ха!—Хәмит бу сүзләрне җитдигә алмады.—Ярый, алайса, килештек. Мин Аннаны читкә алып китәм. Ә сез шушында теләгәнегезчә әпсенләп ятыгыз.

Аңа чынлап та кызык тоелды. Авылга кайтып кергәнче көлде ул бу сүзләрдән. Сихерче Мария, имеш... Татар, имеш... Милләтләргә, төркемнәргә бүленү ул шартлы күренеш кенә. Асылда кешене мәхәббәт яшәтә. Мәхәббәт идарә итә барсы белән дә. Һәм аның өчен бернинди милләт тә, бай да, ярлы да юк. Аның өчен кереп ояларлык саф йөрәк кенә бар.

Ләкин күнелендә аз гына юшкын да калды. Аның килерен белеп, көтеп торганнар бит. Табыннар әзерләп куйганнар. Шулай булгач, сүзләренең дөреслектән ераклыгына бик ышанмалы да түгел сыман иде. Ләкин егет моңа артык әһәмият бирмәскә тырышты. Анналың Мария сихерче хакында курку катыш сокланып сөйләвен дә колак яныннан гына уздырды ул. Хәер, болай дип әйтү дә дөрес түгелдер. Аннаның Мария турындагы сүзләре аның уеннан читтә калмады. Киресенчә, тиз арада чыгып китәргә карар кылуына нәкъ шул сихерче турындагы сүзләр сәбәпче булды. Чынмы-ялганмы, әмма бәласеннән баш-аяк—сихерчедән ераграк булуың хәерле.

Кызның әти-әнисе каршы килүен өйдәгеләр шатланыбрак кабул итәр дип уйлаган иде Хәмит. Әмма ялгышкан булып чыкты. Бу хакта ишеткәч, әтисе сүгенеп үк куйды:

—Атаң башы... Хәзер көт инде бәланең хәтәрен...

Ул нигә болай дигәндер, Хәмит аңламады. Бәлки, улының йорттан китәчәген чамалап әйткәндер. Мөгаен шулай булгандыр, чөнки читкә китәргә уйлавы турында ишеткәч, әтисе бу сүзне күптән көтеп йөргәндәй, җинел генә ризалашты:

—Ярый... Үз башың, үз язмышың... Безне онытма.—Һәм бик тә кадерле сер әйткән төсле итеп тагын бер кабатлады.—Безне онытма.

Хәмит аны аңлый иде. Абыйсы укырга китәм дип китте дә бер хәбәре дә булмады. Хәзер Хәмит китә. Балаларының ата-анасы турында уйлап та бирмәве, бер хат кисәге дә язып салмавы күнелле нәрсә түгел, әлбәттә. Һәм ул үзенең дә тиз арада әйләнеп кайтачагына, хатлар яудырып торачагына ышана да, ышандыра да алмый иде.

—Беркадәр хәбәрсез булырга туры килер инде,—диде ул.—Борчылып тормассыз. Аннан соң, барсы да тынычлангач, кайтып урарбыз.

—Ходай насыйп итсен инде.

Әтисенең сүзләрендә өметсезлек чалымы сизелеп китте.

(Ихтыярыгызда инде. Без сезне карап үстердек, калганы барсы да үзегездән тора. Онытмасагыз бик рәхмәт, онытсагыз, берни кылып булмый...)

Ул моны теле белән әйтмәде, әлбәттә. Хәмит аның тавышында әлеге

мәгънәне тойгач, аз гына үпкәләгән кебек тә булган иде. Нигә шул тиклем ышанмаучылык белдерергә инде. Нигә үпкәләргә. Тәнендә жаны юк түгел ич, күкрәгендә йөрәге дә тибә—күрәләтә әти-әнисен онытып яшәргә ни!

Ләкин әтисе хаклы булып чыкты. Анна белән житәкләшеп чыгып киттеләр дә... кабат кайтмадылар. Әллә сихерче дип куркытканнары дөрескә чыкты, әллә башка сәбәп...

Казанда гына тукталсак, бик якын булыр дип алар Уфага юлландылар. Монда Хәмитнең армиядә бергә хезмәт иткән дусты яши иде. Шул ярдәм итте. Бару белән эш тә, яшәп торырга тулай торак та табылды. Үзләренчә мул гына табын корып загска барып никахлашып та куйдылар. Тормыш көйләнеп киткән сыман булды. Алар, әлбәттә, бәхетле иде. Бер-берсе өчен үлеп торган ике гашыйк бәхетсез була аламени инде?!. Өстәвенә көннәренә-сәгатьләренә кадәр санап көткән малайлары туарга тора...

Хәбәр бирү, туган яктан урап килү теләге вакыт-вакыт жанны телгәләп алса да сабыр иттеләр. Бала тусын инде дип көттеләр. Сихерче турындагы сүзнең кодрәте кими төшсә дә сакланырга булдылар. Хатны да шул тирәдәрәк язарлар. Әйтеп-кисәтеп киттеләр ич. Әти-әниләре гаепләрлек түгел.

Бәла шатлык көткәндә килде.

Вакыты житеп Аннаны больницага салдылар.

—Мин нигәдер куркам...—диде Анна, иренен күзләренә мөлдерәп карап.—Гел нәрсәдер булыр сыман.

—Курыкма, жаным... Бер син генә түгел бит... Бөтен хатын-кыз да бала таба. Һәм барсы да менә дигән була! Синең дә яхшы булачак. Күр дә тор менә!

—Тик минем белән бер-бер хәл булса, улыбызны ташлама, яме...

—Юкны сөйләмә әле!

—Ташламассыңмы?—Анна иренен учларына ябышты.—Ташламассыңмы улыбызны?

—Ташламам, жаным. Тик бел, барсы да яхшы булачак. Барсы да!

Анна елмайды. Ул үзе дә күпмедер дәрәжәдә балага охшап торган сыман иде. Тик күзләрендә генә ниндидер моң бар.

Хәмит ул төнне керфек тә какмады. Сәгать саен диярлек телефоннан шалтыратып, шатлыклы хәбәр көтте. Ләкин аңа сөенче әйтмәделәр. Бер ханым трубкадан әрләп үк ташлады. Бер син генә түгел монда, эшләргә комачаулыйсың, башкача шалтыратсаң, хатыныңны кайтарып жибәрәбез! Хәмит бүтән шалтыратмады.

Таң алдыннан аның үзенә шалтыраттылар. Хәмит дулкынлана иде. Трубканы ташлау белән ул шатлыктан үрә сикерәчәк иде. Әмма аны беркем дә шатландырырга ашыкмады. Ниндидер салкын тавыш исем-атын сорады да тиз арада больницага килергә кушты. Хатынының хәле турында сораганын көтеп тә тормыйча трубканы ташладылар.

Баруына хатыны да баласы да үлгәнлеген хәбәр иттеләр.

Шул тиклем яктылык белән килгән мәхәббәттән үз хәленең авырлыгын сизгән Аннаның хәлсез кулы белән язылган кәгазь кисәге генә калды.

Синең белән очраштырган язмышыма шундый рәхмәтлемен. Бергә үткәргән көннәребезнең һәр мизгеле бер гомергә торырлык булды. Бәхетле бул, бердәнберем. Улыбызны да бәхетле ит. Хуш.

Барсы да бетте.

Анна...

Баштагы мәлләрдә ул үзенә кул салырдай булып йөрде. Көннең яме, яшәүнең тәме юк иде. Ләкин адәм баласы акрынлап барсына да күнегә. Ул да күнекте. Сызлануларын тормышның башка вак-төякләре күмгән кебек

булды. Тормыш Аннасыз гына, ямьсез һәм тәмсез генә акты да акты.

Ә көннәрнең берендә ул Уфа урамында Аннаны күргән кебек булды. Үз күзләренә үзе ышанырга теләмичә беркадәр вакыт артыннан ияреп барды. Һәм болай йөрүеннән уңайсызланып, кыз янына килде.

—Гафу итегез, ә сез... сезнең исемегезне белергә мөмкинме?

Кыз аңа сынаулы караш ташлады. Егет шаяртырга уйламый иде. Иләс-миләс килеп йөри торган бәндәгә дә охшамаган. Һәм ул исемен әйтмичә калырга унайсызланды:

—Лена мин... Ә сез кем буласыз?

—Хәмит...—егет соклануын яшерә алмыйча елмайды.—Сез... сез кайсы яктан?

Лена да елмайды. Бу егет аңа ошый иде.

—Хәсәнбайдан...

—Хәсәнбайданмыни...

Шулай танышып киттеләр. Һәм бер ел чамасы йөргәч, өйләнештеләр. Лена, әлбәттә, йөзе белән генә Аннага охшаган иде. Шулай да алар начар яшәмәделәр, бер-берсен хөрмәт итеп, бер-берсенең кадерен белеп тормыш көттеләр. Хәзер менә үсеп житкән балалары бар. Хәмит тора-бара Анна турында да еш хәтерләмәс булып китте, ә берничә елдан бөтенләй онытты. Һәрхәлдә үзе оныттым дип уйлый иде. Юк икән шул, онытмаган икән. Әнә бит, теге ханымның бер сүзен ишетү белән барсы да яңарып күз алдына басты.

Хәзер ул теге сихерче турындагы сүзгә беркатлы ахмаклык итеп кенә карамый инде. Бәлки, Анна белән сабыйның вафат булуында да сихер кулы уйнагандыр. Бәлки, үзенең туган ягына кайта алмыйча каңгырып йөрүенә дә шул сәбәпчедер. Моны берничек тә исбатлап та, кире кагып та булмый.

Ләкин шунсы хак, авылына ул башкача кайта алмады. Нәрсәдәндер курыкты. Бөтен авылдашлары җыелып: «Аннаны кайда куйдың?!»—дип әйтер сыман тоелды. Болай булмасын белсә дә, әлеге куркуын җиңә алмады. Авылда барсы да Аннаны хәтерләтәчәк иде. Танышкан, бергә йөргән урыннар, беренче тапкыр үбешкән, беренче тапкыр сөю назына бирелгән, «яратам!»—диешкән жирләр... Монда барсы да АНЫ хәтерләтәчәк һәм АНЫ таптырачак иде. Хәмит курыкты... Хәтта әти-әнисе алдындагы бурыч хисе дә шушы куркудан аралый алмады.

Хәтта баштагы мәлләрдә Ленаның: «Туган ягыңа кайтыйк. Әти-әниеңнең хәлен белеп килик. Болай яшәү мәгънәсезлек була бит!»—дип сөйләнеп, хәтта тиргәшеп йөрүләре дә файда бирмәде. Югыйсә, Хәмит хатыны сүзенә колак сала торган кеше иде бит. Бер мәлне хәтта җыенып та беттеләр алар. Иртәгә юлга чыгабыз дигән көнне Хәмит матайдан егылып аягын сындырды. Һәм илгә кайту уе онытылып калды. Монын да очраклы хәл генә булуын исбат итеп булмый.

Әле менә шушы утрауда, яшьлектә сөйгән ярының исемен ишеткәч, моңа кадәр тупасланып калган тойгылар кабат уянды. Һәм бөтен нәрсә турында да оныттырды. Әлеге утрау мажараларыннан котылу белән, беренче эш итеп авылга кайтырга кирәк. Болай булмый. Болай ярамый.

Хәмит бүлмәдәгеләрнең тигез сулышын тыңлап ятты. Монда аның иң кадерле кешеләре иде. Лена борынын иренең күкрәгенә төртеп йокыга киткән. Теге якта Ләис белән Ләйсән икесе ике караватта ауныйлар. Кич белән бикborгаланып, нәрсәдер пышылдашып яталар иде. Хәзер инде тынып калганнар. Утрауга килгәндә икесенең дә күңелендә мәхәббәт чаткысы уянды, жаннарына ятардай кешене таптылар бугай. Шуңа бүген сөйләшеп сүзләре бетмәде. Эх, яшьлек, яшьлек...

Көтмәгәндә коридордан нииндидер ачы тавыш ишетелде...

* * *

Айгөл Леонга аз гына үпкәләде. Соң, кыюрак булып булмыймыни инде?!. Әнә бит, Роберт кеше күплегенә дә артык игътибар итмәде, Людасы белән аулактарак калу чарасын тапты. Ә бу... Пешмәгән. Югыйсә, Айгөл, башкаларга артык сиздермичә генә, берничә кат Леонга елышырга тырышып карады бит. Ә егет уйлап та бирмәде. Бәлки, Айгөл ана бөтенләй кирәкмидер... Юк инде, алай түгел. Янында кемнен уралганын күргәч, Леонның үз-үзен тотышы бөтенләй үзгәрде. Ләкин ул бер сүз дә әйтә алмады, хәтта кыз ягына борылып карарга да курыкты. Бигрәк оялчан малай инде. Аз гына кыюрак булса, алар да Роберт белән Люда шикелле берәр аулак урында серләшеп утырган булырлар иде.

Ярый, соңгы көннәре түгел. Иртәгә берәр жаен тапмый калмаслар. Бүген йокларга, ял итәргә кирәк. Шундый уйлар белән күзләрен йомса да йокыга китә алмады, уйлары гел Леон тирәсендә бөтерелде. Ә аны күз алдына китерүгә күнелен нинди дер тылсымлы яктылык биләп алды.

Яктылык...

Ул шушы якты хисләргә бирелеп йокыга китәр иде. Ләкин әтисенен әле бер, әле икенче якка әйләнеп, туктаусыз боргаланып ятуы, әллә нинди сәер тавышлар белән ыңгырашуы хыялга күмелергә дә, йокыга китәргә дә ирек бирмәде.

Кыз әтисе яткан караватка үртәлеп карап куйды. Баштарак күнелендә «әти» дигән сүз кадерле нәрсә булып янгыраса да, юлга чыккач, Радикның туктаусыз хәмер чүмерүе, өнендә теләсә нәрсә кыланып, төшендә саташып ятуы үзәгенә үтте. «Әти» дигән кеше анын өчен әллә ни кадерле түгел иде инде. Бу бәндә белән бергә яши алган әнисе ана кызганыч та, соклангыч та иде. Вакытында аерылып дөрес эшләгән. Югыйсә, алар һаман моның белән шушылай интегерләр иде. Ә үги әтиләре начар кеше түгел. Ул аракы да эчми, авыр сүз дә әйткәне юк. Һәрхәлдә, анын янында үзеңне менә мондагыдай итеп тоймыйсың. Анын янында үзенне тынычлыкта хис итәсен.

Ләкин Айгөлнен күнелендә якты тойгылар бөтенләй үк үлеп бетмәгән иде әле. Ул әтисенен элекке вакытларын онытмаган иде. Һәм оныта алмастыр да. Көн саен диярлек эштән кайтканда балалары өчен генә нинди дә булса уенчыкмы, тәм-томмы күтәреп кайтулары. «О! О-һо-һо, минем кызым!»—дип күтәреп алулары. Урамга чыккач, алар белән бер булып кычкырып көлә-көлә уйнап йөрүләре. Мондый вакытларны берничек тә онытып булмый. Ул беркайчан да салкын булмады. Һәрвакыт, хәтта әле дә, аннан ниндидер жылылык, якты бер нур сирпелеп торган сыман. Жанга ятышсыз, күнелсез гадәтләре белән йөрәгенне әрнетсә дә үзенә тартып тора торган ниндидер бер сыйфаты бар. Бу бәлки анын яратуыдыр. Балаларын һаман да ярата бит ул. Моны күрер өчен әллә нинди зур сәләт кирәкми. Бу анын һәр сулышында сизелеп тора. Бары тик хәмер сазлыгыннан чыгалмаганга гына ул үз яратуын тиешенчә сиздерә алмый. Бары тик хәмер сазлыгыннан чыгалмаганга гына анын яратуы да чиркангычрак булып кабул ителә. Ә эчүен ташласа...

—Юк...—дип ыңгырашты әтисе.

Айгөл бер мизгелгә куркып китте. Әтисе анын уйларын сизеп ятадыр, әле анын уйларына жавап итеп шулай эндәшкәндер төсле тоелды. Әтисе кинәт каядыр омтылды да караватт янындагы стенага бәрелде.

—Мин яктыга чыгарга телим!—дип кычкырды үзе.—Яктыга чыгачакмын! Кызым хакына! Яктыга. Күпме караңгыда яшәргә мөмкин инде! Яктыга!

Кыз торып утырды.

Әтисе саташа иде.

—Әти...

Әтисе янә стенага ташланды. Әйтерсең, ул шушы стенаны җимереп кенә яктыга чыгачак иде. Кыз аның янына килде. Һәм бар көченә аны селкетергә тотынды:

—Әти!. Уян! Әти!

Кинәт әтисе тынып калды. Чалкан әйләнеп тирә-ягына күз йөгертте. Һәм ниндидер әйтеп бетергесез наз белән:

—Айгөл... Кызым...—диде.

—Әти, барсы да тәртиптәме? Син нык саташтың...

—Кызым...

—Су эчеп ал, әти... Мә...—Кыз аңа чынаяк сузды.—Тынычлан.

Әтисе суны комсызланып эчте. Һәм чынаякны идәнгә утыртты. Кармаланып кызының учын эзләп тапты. Аны назлы итеп янагына кысты. Һәм сабый баладай үксеп елап җибәрде.

—Кызым. Балакаем минем...—Ул кызның учын күз яшьләренә чылатып такмаклады.—Гафу ит, мине, кызым... Гафу итегез, берүк... Болай булырга тиеш түгел иде. Мин сезне бәхетле итәргә тиеш идем. Кызым... Балакайларым...

Бу ул иде. Бу Айгөлнең әтисе иде. Әрни, сөя, сагына белгән кеше. Балалары өчен җанын бирергә дә әзер торган кеше. Үзе дә сабый бала булып алар белән бергә уйнап йөргән кеше. Әле ул елый иде. Ул кайтты. Хәмер томаннарында ничәшәр еллар буе адашып йөргәннән соң, ул кызы янына кайтты. Айгөл моны бар күңеле белән тоя иде. Моны тоюдан аңа шундый рәхәт иде. Моны тоюдан ул бәхетле, чиксез нык бәхетле иде. Ул әтисен тапты!

Айгөлнең дә яңаклары буйлап яшь тәгәрәп төште. Ул да өнсез генә сулкылдый иде.

—Әтием...

Айгөл әтисенең чәчләреннән сыйпады. Һәм ни гаҗәп, шушы керле чәчләр арасында тормышның бөтен юанычлары җыелгандыр сыман тоелды. Әйтерсең, ул бөтен гомере буена шушы чәчләрне сыйпарга хыялланып яшәгән дә, хәзер хыяллары тормышка ашкач, ничектер канәгатьләнеп, тынычланып калган. Ул чынлап та тынычланып калды. Күңеле саф, якты нур белән тулды. Ул елмайды.

Кинәт коридорда кемнеңдер кычкырганы ишетелде. Айгөл бер мизгелгә тынып калды. Тавыш тагын кабатланды. Кемдер ярдәм сорый иде. Айгөл, тынычландырырга теләгәндәй, әтисенең башыннан сыйпап, бәпләп куйды да ишеккә юнәлде. (Син борчылма, әти. Барсы да тәртиптә. Ышанмасаң, менә хәзер үзем ишекне ачып күрсәтәм. Син ят. Тынычлан. Барсы да яхшы, әти.)

Ишекне ачу белән коридорның теге башында баганаңы хәтерләткән ниндидер яктылык томаны күренде. Беренче карашка ул матур иде. Айгөл аңа омтылып берничә адым атлады да кинәт катып калды. Бу багана түгел, ә кеше иде. Озын чәчләрен иненә таратып ташлаган хатын-кыз. Аның йөзе ачык күренми, әмма идәнгә тиеп торган ак күлмәге ак нур чәчә. Шуңа да ул беренче карашка ак томан сыман булып күренгәндер. Хатын аны күрде. Ун кулын болгап чакырды. Һәм кызның бер хәрәкәтсез басып торуын күреп чишмә суыдай салкын тавыш белән кеткелдәп куйды. Шушы тавыштан күчкән салкынлык Айгөлнең арка үзәге буйлап йөгерде. Кызның бала йоннары кабарып чыкты. Ул барсын да аңлады. Аның алдында өрәк иде. Өрәк кызга якынлашты. Ул атлап түгел, ә идәндәге күзгә күренмәс дулкыннар өстендә йөзеп кенә йөридер сыман тоелды. Айгөл моның чынлык икәненә ышанырга теләмәгәндәй, күзләрен ачып-йомып алды. Ләкин өрәк югалмады. Һәм Айгөл үзәк өзгеч тавыш ишетте. Куркып кычкырган

хатын-кыз тавышы. Бу аның үз тавышы иде. Ләкин кыз моны аңламады. Һәм әлеге тавыштан тагы да куркынычрак булып китте.

Өрәк кире чигенде дә икенче катка күтәрелә торган баскыч янында тукталып калды. Бераздан башка бүлмәләрдә дә ишекләр ачылды һәм башлар күренде. Алар бер мизгелгә генә катып калдылар да эшнең нидәлеген аңлап, кычкырып җибәрделәр. Бер мизгел эчендә бөтен йорт куркудан коты алынып кычкырган тавышлар белән тулды. Ә икенче мизгелгә теге яктылык юкка чыкты, күрәсең, ул икенче катка менеп китте. Караңгыда анда-монда йөгерешкән, кайдадыр бәрелгән, егылган, сүгенгән тавышлар ишетелде. Шушы тавышлар эчендә Айгөл бер мәлгә дөнья белән бәйләнешен өзде. Һушына килгәндә шундый ук хәл иде әле. Тик ул инде кемнеңдер кочагында иде. Әтисе.

—Тынычлан, кызым...—диде ул аның башыннан сыйпап.—Барсы да үтте. Мин сине беркемгә дә бирмим. Тынычлан.

Радик кызын ныграк кысты. Ул ни өчендер Андрей Николаевичның теплоходта сөйләгән хикәятен хәтерләде. Төн уртасында пәйда булган өрәк, теге алиһәдер, ул корбан сорап килгәндер төсле тоелды.

Бераздан кемдер ут яндырды. Ниндидер таяк башына чүпрәк урап ясалган торымбаштан төшкән яктылыкта чагылып киткән кешеләрнең йөзе үзе үк котыңны алырлык иде. Радик кызын җитәкләп алга атлады. Айгөл аңа беркарышусыз буйсынды. Ул әле аңына килеп бетмәгән иде шикелле. Бераздан Айгөлне җитәкләгән кул ычкынды. Тик шундук диярлек аны тагын җитәкләделәр. Айгөл күпмедер вакыт үткәч кенә тулысынча һушына килде. Һәм курку катыш елмаеп куйды. Ул Леон белән җитәкләшеп тора иде. Егет бернәрсә дә эндәшмәде. Бары тик кызның учын гына әледән-әле наз белән кысып алды. Кыз да аңа шундый ук җавап бирде. Аларда беркемнең дә эше юк иде.

—Хатын-кыз өрәге бу...—диде кемдер.

—Икенче катка менеп китте...

Күпмедер вакыттан соң куркуның тәүге дулкыны юкка чыккандай булды. Барсы да тынычланып калды. Мона, бәлки, торымбашларның күбәюе сәбәп булгандыр.

—Бәлки, икенче каттан урап төшәрбез?!.—диде Хәмит.—Өрәкләр ут яктысыннан курка. Без аны бер куркытсак, таңга кадәр тынычлап йокларбыз.

—Йокларбыз?! Тынычлап?!.—дип пышылдады Анна.—Михаил, синең тәрең үзең белән иде бит...

Михаил дәшмәде. Хәлләр котыңны алырлык булса да аның дин белән кабат маташасы килми иде.

—Ул хатынның куллары күп иде...—дип пышылдады коты алынган Ольга.

—Ыһ-һыы...—дип куйды Анна.

—Ул теге... Кали алиһә түгел иде микән...—дип куйды Ольга.

Айгөл дә өрәкне күрде ич. Куллары күп кебек түгел иде. Икәү генә иде. Бәлки, Айгөл барсын да күреп бетермәгәндер. Ул дәшмәде.

—Хатыннар һәм балалар бер бүлмәгә җыелыгыз,—диде Андрей Николаевич.—Ә без, ирләр, икенче катны карап төшик.

Ләкин Ольга ярсып каршы килде:

—Син бармыйсың! Мин синнән башка куркам.

—Курыкма, кадерлем...—дип юатты аны Андрей Николаевич.—Курыкма.

—Мин дә куркам...—дип пышылдады Анна.—Өрәк теге алиһәгә... Кали алиһәгә охшаган иде... Бәлки, сез икенче катка менеп киткәч, ул безнең балаларыбызны суяр...

—Алайса, бергә меник...

—Бәлки, таңга кадәр көтәрбез, ә...—Лена һаман тынычланып җитмәгән иде әле.—Бик озак та калмады бит инде...

—Иң яхшысы шул булачак!—дип җөпләде аны Ольга.—Без, барыбер, өрәкне җинә алмыйбыз. Шулай булгач, нигә котыртып, үртәп йөрергә?!

—Ярый, без бу юлы аның килгәнен барыбыз да берьюлы сизеп калдык.—дип үзенекен итте Хәмит.—Ә сизмәгән булсак?!. Әйтик, ул аерым бер бүлмәгә генә кергән булса. Үзегез бит Кали алиһәгә охшаган дидегез...

—Юк, ул ана охшамаган иде,—диде Андрей Николаевич.—Гап-гади хатын-кыз...

—Куллары дүртәү иде бугай...—Анна үз сүзеннән үзе курыккандай тоелды.—Мин шулай күрдем.

—Мин дә...

—Димәк, без аны табарга тиешбез,—диде Хәмит.—Һич югы аның нәрсә теләгәнен белергә кирәк. Ялгыш балаларыбызга кагыласы булмасын...

Кемдер кычкырып көлеп җибәрде. Бу Андрей Николаевич иде.

—Сез барыгыз да сабыйлар шикелле,—диде ул һаман көлүеннән туктый алмыйча.—Мин бит теплоходта чынлап та булган вакыйганы сөйләмәдем. Ул вакыт үткәрү өчен сөйләнгән бер уйдырма, интернеттан укыган хикәят кенә иде. Ә сез чынга алдыгыз. Кали алиһә, имеш... Юк андый нәрсә!

Бер мизгелгә тынлык урнашты.

—Куркырга да бернинди сәбәп юк,—дип дәвам итте Андрей Николаевич.—Беркем дә сездән корбан сорап йөрми.

—Өрәк чын иде бит,—диде Лена.—Аны барыбыз да күрдек.

—Өрәк чын иде. Ләкин ул корбан сорап йөрми. Ташландык йортларның һәркайсында диярлек өрәкләр яши. Ләкин бу аларның кемгәдер зыян салырга җыенуы хакында сөйләми әле. Киресенчә, файда китерүчеләре дә була.

—Кызганыч, без өрәкне куркытып җибәрдек,—дип төрттерде Хәмит.—Ә ул безгә бишек җыры җырлар өчен килгән булган...

—Йортны тулысынча тикшереп чыкмый булмый,—диде Михаил.—Шунсыз беркем дә тынычланмаячак. Әлбәттә, без өрәкне кабат күрә алмабыз. Ләкин өйнең бөтен почмагын да карап чыгу күңелгә тынычлык өстәячәк.

—Дөрес,—диде Хәмит.—Кемнәрдер аерылып калырга курка икән, бергәләп йөреп чыгыйк. Ул тиклем күп кеше түгелбез әле.

Андрей Николаевич аңа каршы төште:

—Ләкин болай итсәк, бер куркыныч бар. Ниндидер бәлагә юлыксак, барыбыз да һәлак булачакбыз. Шуңа мин төркемнәргә бүленергә киңәш итәм.

—Тик без...

Андрей Николаевич аңа башланган сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде:

—Ә бәлки, икенче катны мин үзем генә тикшереп төшәрмен?!

Тынлык урнашты.

Әлбәттә, бу начар булмас иде. Ләкин кемнедер күрәләтә куркыныч юлга җибәрергә берәүнең дә йөрәге җитмәде.

—Мин дә сезнең белән!—диде яшь тавыш. Барсы да аңа борылып карадылар. Бу Леон иде.—Икәү бергә меник.

—Өчәү!—дип өстәде аның янында торган Айгөл.—Мин дә менәм.

—Юк!—Хәмит алгарак чыкты.—Балалар эше түгел бу. Андрей Николаевич белән икәү менеп төшик, ә сез монда торырсыз. Берәр куркыныч аваз чыгу белән ярдәмгә килерсез.

Бу тәкъдимгә барсы да риза булды. Әмма Андрей Николаевич кына каршы килде:

—Яхшы тәкъдим. Ләкин сезнең ике балагыз бар. Болай итәргә кирәк. Без Ольга белән икәү менәбез. Безнең балаларыбыз юк. Ә сез монда, күтелмәгән хәлләргә әзер булып торыгыз. Бер-бер куркыныч чыкса, шундук килеп житәрлек булсын.

Мәгънәсез бәхәс ялкыта башлаган иде инде. Каршы килүче булмады. Тиздән алар икенче катка менеп китте.

Көтеп калучылар баштарак бер тынсыз булып тордылар да бераздан кечкенә төркемнәргә бүленеп пышылдаша башладылар. Айгөл тирә-ягына каранып әтисен эзләде. Радик күренмәде. Ә Леонның әти-әнисе аларга игътибар итми төсле иде. Моны Леон да сизде бугай, ул кызны сак кына итеп читкәрәк алып китте. Моны күреп торган Люда кызга ягымлы караш ташлап алды да моңсу елмаеп куйды. Айгөл дә елмаеп җавап бирде, ул Люданы аңлый иде. Люда әле ялгыз иде. Роберт та, аның әтисе дә күренмәделәр. Ләкин бу хакта артык баш ватасы килмәде.

—Рәхмәт инде бу өрәккә...—дип пышылдады Леон, башкалар янынннан читкәрәк киткәч.—Ул булмаса, бүген синең белән күрешә алмый идек.

Әлбәттә, Айгөл дә шат иде. Ләкин сер бирергә теләмәде.

—Тиле... Ә минем котым алынды.

—Мин дә курыктым, ансы... Тик хәзер...—Леон ничектер сизмәгәндә генә кызны кочаклады да чигәсеннән үбеп алды.—Хәзер мин өрәккә табынырга риза.

«Ул тиклем үк җебегән дә түгел инде бу Леон»,—дип уйлап алды кыз ләззәт дингезенә чумып. Ә егетнең иреннәре бөтен тәнгә назлы дулкыннар таратып колак яфрагына төште. Аның кайнар сулышы котып бозларын да эретергә сәләтле сыман иде. Ләкин кыз назга бирелүдән курыкты. Тагын аз гына...—һәм ул үзе өчен җавап бирә алмаячак. Рәхәтлек тә, аңа омтылу да чамасыз көчле иде. Ул егетнең куенынннан арынырга ашыкты.

—Тукта... Әле түгел...

—Мин сине яратам!..—дип дәртенә тончыгып пышылдады егет:—Үлеп яратам!

—Мин дә... Тик син тукта... сабыр ит... Кеше күрә бит...

Кызның карышуына бирелеп, егет читкәрәк тартылды. Һәм гаепле кеше сыман катып калды. Аның сулышы кабынган, йөрәк тибеше ешайган иде.

—Гафу ит...

Кыз елмайды.

—Мин үзем дә синең хәлдә...—дип назлы пышылдады ул.—Тик син бүтән алай кыланма, яме. Булыр, барсы да үз вакыты белән килер әле.

Егет аны чиксез хөрмәт белән үзенә кысты.

—Мин бүген төне буе гел сине уйлап чыктым. Сине күргән мизгелдән бирле мин бәхетнең ни икәнен белдем.

—Кадерлем минем...

Сулышлар тагын ешайды.

—Әйдә, башкалар янына барыйк,—дип пышылдады кыз, беркадәр тынычланып калгач.—Юкса...

—Ярый...—диде егет, ә үзе аны ныграк кысты.

—Яратам мин сине! Бергенәм син!—дип пышылдады ул бераздан саф татар телендә.—Бердәнберем минем...

Айгөл үз колакларына үзе ышанмагандай бер мизгелгә катып калды. Һәм татлы елмаеп куйды.

—Мин дә сине яратам...—диде ул.

Бу юлы егет аптырап китте. Һәм шатлыклы елмайды.

—Син татар кызымыни?

—Әйе, Леон...

—Ләис мин...—дип елмайды егет.—Җыен урыс арасында аерылып тормыйк дип кенә кыланган булдык. Безнең әни хәтәр бит ул яктан. Сизгәнсендер инде...

—Ә мин—Айгөл...—Кыз көлеп җибәрде.—Ахирәтләрем Аида дип тә әйткәли... Мин дә башкалардан аерылмыйм дигәнмендер инде...

—Ә аерылсак ни була?! Әйдә, моннан ары гел татарча гына сөйләшәбез.

—Белмим... Ну, әйдә...

Ләис Айгөлне тагын күкрәгенә кысты. Бу юлы ул ниндидер аерым бер ләззәт тойгандай булды. Хәзер аларның мәхәббәттән башка да ниндидер уртаклыгы бар иде. Икесе генә белгән сер, дисәң...

Бераздан алар, сиздермичә генә, икенче каттагыларны көткән төркемгә кушылдылар.

—Килдегез дә мени?!.—дип пышылдады Люда.

—Килдек, Ләйсән...—диде Ләис, мыек астыннан елмаеп.—Айгөл—татар кызы.

Ләйсән башта шелтәләмәкче иде, Айгөл турында ишеткәч, елмаеп куйды.

—Роберт та татарча анлый,—диде ул, үзе дә төшеп калганнардан түгеллеген искәртергә теләгәндәй.—Ул моны сиздермәскә тырышты. Ә мин, барыбер, сиздем.

—Ул нигәдер күренми...

Ләйсәннең елмаюы шундук юкка чыкты.

—Күренми шул...—диде үртәлгәндәй итеп.—Йокы симертәдер инде. Йә йөрәге ярылып үлгәндер.

—Бәлки, бүлмәләренә кереп, хәлләрен белеп чыгарбыз.

—Тилесеңме әллә?!

—Ярый, күрешерсез әле...

Бераздан икенче каттан төшә торган баскычта ике шәүлә күренде. Барсы да тынып калдылар. Шәүләләр ашыкмыйча гына төшеп житте. Бу Андрей Николаевич белән Ольга иде. Айгөлгә аларның үз-үзен тотышы сәер булып тоелды. Гадәттә, куркынычны бергә кичкән кешеләр арасында күзгә күренмәс ниндидер уртаклык, бердәмлек барлыкка килә. Боларда ул юк иде. Бәлки, кыз гына тоя алмагандыр. Әмма боларның атлап йөрешендә үк бер-берсе белән канәгать түгеллек, бер-берсенә үртәлгәнлек сизелгән сыман иде.

—Берни дә юк...—диде Андрей Николаевич, баскыч төбендәгеләрнең өнсез соравына.—Бернәрсә дә!

—Бөтен урыннарны да тикшердегезме соң?

—Барсын да карап чыктык.

Ольга дәшмәде. Ул төркемдәгеләрне барларга теләгәндәй һәркайсына текәлеп карап чыкты.

—Ә Роман кайда?—дип сорады аннан соң.

—Ул бүлмәгә кереп китте,—дип алдашты Айгөл. Икенче каттан төшкән бу икәүнең үз-үзен тотышы аңа ошамый иде. Монда ниндидер сер бар иде.

—Алай икән...—дип куйды Ольга.

—Без икенче катны тулысы белән тикшереп чыктык,—диде Андрей Николаевич.—Куркырлык бернәрсә дә юк. Хәзер һәркем үз бүлмәсенә таралсын. Иртәгә таң белән юлга чыгасы. Коридорда өелешеп, бер-беребезгә комачаулап йөрмик.

Тавышында рухи күтәренкелек, хәвефсезлеккә тулы ышаныч көчле иде. Ләкин шуның белән бергә аның тавышында нәрсәгәдер кәефе кырылганлык чалымы да сизелә иде. Әйе, ни өчендер ачуы килгән кебек иде анын. Бәлки, Айгөлгә генә шулай тоелгандыр.

—Ләкин без әле икенче катны гына тикшердек,—дип сүзгә кушылды Анна.—Ә бәлки, өрәк беренче каттадыр. Бәлки, баздадыр. Бу йортның базы бармы?

—Үзегез тикшерегез,—диде Андрей Николаевич.—Ә без арыдык. Һәм бүлмәбезгә кереп ятабыз.

—Ләкин алай эшләү гадел булмый.—Монсы Лена иде.—Без бергәләп тикшерергә тиеш...

Ольга бүлмәсенә борылган иренең терсәгеннән эләктерде:

—Андрей Николаевич... Гафу итегез, Андрей арыды...—диде ул ире өчен акланып.—Ләкин кызлар хаклы. Башта без барсын да тикшереп чыгарга тиешбез.

Һәм ул кире борылып килде дә баскыч буйлап аска төште.

—Монда подвал юк,—диде стенага суккалап караганнан соң.—Димәк беренче кат кына кала. Ә беренче катны җентекләп тикшерүнең бер генә юлы бар. Һәркайсыбыз үз бүлмәсенә тарала. Ләкин ишекләрне ачык калдырырга онытмагыз. Бер-бер хәл булса, башкалар ярдәмгә килерлек булсын.

Аның белән килешмичә мөмкин түгел иде.

Бераздан барсы да үз бүлмәләренә таралышты. Өрәк бер бүлмәдә дә юк иде. Торымбашлар сүнгәч, бөтен дөньяны караңгылык каплагандай булды.

—Әти...—дип пышылдады Айгөл бүлмәдә ялгызы гына калгач. Җавап бирүче булмады. Тынлык куркыныч иде. Кайда югалды соң әтисе? Нигә Айгөлгә берни дә әйтми китте? Ә, бәлки... Бәлки, аны өрәк юк иткәндер... Болай уйларга ярамый иде. Болай уйласа, ул йөрәге ярылып үләчәк иде. Эх, нигә коридорда гына тормадылар икән? Нигә бүлмәләренә таралдылар... Эх, нигә ул Ләисне дә үзе белән ияртмәде микән... Әлбәттә, ярамаган эш эшләрләр иде... Ләкин, менә мондый курку янында Ләис белән бергә булу... Юк, алай да ярамый инде... Тизрәк әтисе кайтсын иде... Бәлки, ул кече йомышын үтәргә генә чыккандыр әле. Суны күп эчте бит... Әйе, шулайдыр ул... Шулайдыр... Әтисе тиздән килеп керәчәк.... Әнә, аяк тавышлары да ишетелә бугай... Әйе, ишетелә... Тавышланмаска тырышып кына атлый... Сизелер-сизелмәс кенә... адымнары якыная... Менә ул ишек янына җитте... Тынып калды... Хәтта сулышы да ишетелә башлады... Еш-еш сулый... Аягын күчерде... Ишек тоткасына үрелде... Тотканы бора... Ура, әтисе кайтты! Әтисе кайтты!!! Ә, бәлки... Ә, бәлки, бу бөтенләй анын әтисе түгелдер... Бу теге өрәктер... Яки аннан да куркынычрак башка нәрсәдер...

—Әти!..

Җавап ишетелмәде.

Ишек акрын гына ачыла башлады. Кыз куркудан кычкырып җибәрмәс өчен авызын учлары белән каплады. Ләкин моның кирәге юк иде инде. Аның тавышы югалган иде. Ишек ачылып китте һәм анда кара шәүлә пәйда булды.

—Кем бар?!

Җавап ишетелмәде.

Бераздан ишек ябылды. Кара шәүлә нәрсәнедер идәнгә куйды. Һәм шунда гына телгә килде:

—Кызым!

Айгөл таныш тавышны ишетеп сикереп торды. Йөгереп әтисенең

каршысына килеп басты. Һәм әлеге кешенең чынлап та ул, әтисе икәненә ышанырга теләгәндәй бер тын карап торды.

—Кызым...

Һәм чынлап та үз әтисе икәнен күреп, бар көченә аның янагына чабып җибәрде. Һәм күкрәгенә ташланып еларга кереште.

—Яратмыйм мин сине, яратмыйм!.. Син миңа әти түгел... Син мине үтерә яздың...—дип пышылдады ул.—Кайда йөрдең? Нигә дәшмәдең...

—Тавышланма, кызым... Бүтәннәр ишетмәсен... Мин... Мин өрәкнең серен ачтым...

Кыз елавыннан туктап, аңа карады:

—Нәрсә?!

—Әйе, кызым... Ә куркытканым өчен гафу ит... Кешеләр ишекләрен ачып йоклый. Тавышланырга теләмәдем... Ә син молодец! Кычкырмадың. Кычкырсаң, харап иде.

—Ә өрәкнең сере?.. Ул нинди сер?

## 3. Фатыйма

* * *

Фатыйма карчык төне буе йоклый алмады. Юкка гына барды ул күрәзәчегә. Бер юньле сүз дә ишетмәде. Әлбәттә, анда бармаса да төне төн булмас иде, ләкин Хәдичә карчык аның шик-шөбһәләрен ныгытты гына. Ә ана юаныч кирәк иде. Юаныч кирәк иде. Дөреслек түгел.

Юрганга төренеп ятса да аңа салкын иде. Урамда җәй. Көне буе кояшта кызган бүлмә стеналары кулыңны пешерерлек. Ләкин Фатыйма карчыкка салкын иде. Юк, картлык галәмәте генә түгел бу. Картлыкның монда бер кысылышы да юк. Ялгызлык салкынлыгы шундый. Ире дә ашыгып китеп барды бит, ичмасам. Ул исән булса, бүгенге төн болай котсыз булмас иде. Ул исән булса, берәр чарасын табар иде. Картайган көнеңдә, ят шәһәрнең тулай торак бүлмәсендә, ялгызлыктан өшеп ят инде менә. Фатыйма карчыкның күнеле тулды. Тик ул елый алмый иде инде. Күңелендә күз яшьләре калмаган иде. Ул бары тик өшеп калтыранды гына.

Һәм юрганын атып бәрде. Көннең җылылыгы да, юрган да берни дә аңлатмый иде. Аларның бернинди дә ярдәме тимәячәк. Салкын тыштан керми иде. Салкын аның үз эченнән чыга. Сөяк җилекләреннән чыга да канына кушылып бөтен тәненә тарала...

Бу салкынлыкны җиңәрлек бер генә кояш та, бер генә кодрәт тә юк иде. Ни әҗәле килми. Үзен эзләп табып, тезләнеп ялынганны көтә, диярсең. Ул да азгын ирләр шикелле, күрәсең, яшьрәкләрне, матурракларны карый. Әҗәл каратырлык җирең дә калмасын да, яшәп яткан бул инде менә. Шәһәр урамына чыгып теләнчеләп йөр, алкаш улыңны ачтан үтермим дип тырышкан бул. Адәм тәганәсе...

Дөрес яшәлмәде бугай бу дөньяда. Дөрес яшәлсә, ахыры болай бетәргә тиеш түгел иде. Бер карасаң, пычраклыкка батып та гомер итмәде бит соң инде. Азып-тузып йөрмәде, аракы затын якын китермәде, урлашмады, алдашмады, мәкер-хәйлә белмәде... Нәкъ тә изге китапта язылганча гомер сөрде. Тик ана карап кына бер бәхете дә булмады. Бәхете булган кеше картайган көнендә шушы хәлгә каламени?!.

Эх, рәхәт чаклары бар иде дөньяның. Рәхәтлек турында уйлауга, Фатыйманың күз алдына гел бер күренеш килеп баса. Алар Хатмулла белән ат арбасының ике ягына аякларын сузып утырганнар да аркаларын аркага терәп урманга китеп баралар. Хәтта тәгәрмәчләр тавышын күмеп чикерткәләр җыры, чебен-черкиләр гүләве ишетелә. Борынны чәчәкләр

исе иркәли. Әмма барсыннан да рәхәтрәге, барсыннан да ләззәтләрәге ул—иреннең арка жылысын тою. Шушы жылылык жанны туендыра. Ә Хатмулла авыз эченнән генә бер жыр көйли:

> Бер алманы бишкә бүләек,
> беребез өчен беребез үләек...

Кайда барганнарын тәгаен генә күз алдына китерә алмый Фатыйма. Заманында алар урман юлын аз гизмәделәр. Печәненә дә, утынына да бергә йөрделәр. Хатмулла әллә нинди сәер зат иде шул. Ишегалдында матае утырса да, келәттә бензин пычкысы булса да утынга балта белән йөри иде.

—Пычкы ул, әнкәсе, дилауай агач өчен. Утынны балта белән әзерләргә кирәк. Утын әзерләү—урман тазарту бит инде ул. Корган-ниткәнен, үсерүсмәсен кисәр өчен балта кулай. Балта хәле житмәгән агачны әрәм итәргә ярамый.

Шулай дигән була торган иде. Башкаларның юан-юан агачлар кайтарып, утынга тураганын өнәми иде. Кайчагында Фатыйма:

—Мондый киртә-корта алып кайтканыңны күреп, булдыксыз дип көлергә дә күп сорамаслар әле,—дип шелтәләп алгалый иде.—Аннан сон, эре агач ырый да бит инде ул.

—Карчык,—ди торган иде андый чакларда Хатмулласы.—Кирәгеннән артыгы кирәкми аның.

—Болай вак-төяк белән үзең интегәсең бит.

—Һыммм...—дип кенә куяр иде ире. Һәм балтасын тотып, агачлыкка кереп китәр иде. Эшләгәндә жен шикелле эшләр. Фатыйма аның артыннан вак ботакларны жыеп та өлгерәлмәс, кирәк кадәрен кискәч, Хатмулла үзе аңа ярдәмләшер иде. Беркадәр булышыр да тракторга төяргә унайлы булсын дип агачларны бер тирәгә ташып куяр.

Эшне бетереп кайтырга чыгар алдыннан кискән өеменә карап торыр-торыр да ишетелер-ишетелмәс кенә итеп:

—Рәнжемәгез инде сез безгә...—дип куяр. Аның тавышында гафу үтенү дә, рәхмәт хисе дә булыр. Аннан соң Фатыйма янына килер. Кочаклап алыр. Хатынының чәчләрен иснәп мыек астыннан елмаеп куяр да, күтәреп арбага утыртыр. Һәм юлга кузгалырлар. Аркага арка терәп, бер-берсенең тән һәм жан жылысын тоеп.

Печәнгә барсалар да шул булыр. Ат арбасын келтерәтеп кенә йөрерләр. Иртә таң белән беренче булып кузгалсалар да беркадәр вакыт үтүгә «выж» да «выж» килеп матайлар, жинел машиналар узып китәр. Кайберләре туктап кызыксыныр:

—Хатмулла, нигә матай белән генә йөрмисең? Болай акрын да... Атны кигәвенгә түздерүе дә авыр бит...

Ә Хатмулла иңнәрен генә сикертеп куяр:

—Матайның утыргычын дөрес эшләмәгәннәр аның. Икәүләшеп йөрергә рәхәт түгел.

Иренең тел төбендә нәрсә ятканын аңлаган Фатыйманың күзләренә шатлыклы очкын кунар. Ә сораучы башын чайкап алыр да юлын дәвам итәр.

—Беләсеңме, нигә алар матайда йөри?!—дияр ир, дилбегәне бушайта биребрәк һәм үзе үк җавап кайтарыр.—Аларның Фатыймалары юк. Арка терәп утырырлык.

Боларны хәтерләүгә Фатыйманың арка үзәкләре жылынып киткәндәй булды. Хәтта колагына Хатмулланың яратып жырлаган жыры ишетелде: Бер алманы бишкә бүләек, беребез өчен беребез үләек... Ул ирен күрергә

теләгәндәй, артына борылып карады. Төнге таш бүлмәдә карангылыктан башка нәрсә юк иде.

Фатыйма торып утырды. Караваттан аякларын салындырып, үзен ат арбасындагыдай хис итәргә тырышты. Җиңелчә генә селкенеп караватны бәвелтеп алды. Тәгәрмәчләр келтерәве, чикерткәләр җыры ишетелер сыман иде. Тимер пружиналар гына шыгырдашып куйды. «Эх, без синң ул чакларны хәтерләтә алмыйбыз шул...»—дип ыңгырашкандай тоелды алар. Фатыйма үзе дә көрсенде.

(Хәтерләтә алмыйсыз шул... Югыйсә, нәкъ шушындый пружиналы караватта да дөньяның ямьле чаклары бар иде... Менә шушындый юрганга төренеп, менә шундый нәни генә булып ята иде ул... Ә мин менә шулай талгын гына бәвелтә идем... Һәм гел бер хикәят сөйли идем:

Дөньяга туар алдыннан бала Ходайдан сораган:

—Ник мин ул дөньяга барам инде. Анда нәрсә эшләргә тиеш булам?

Ходай әйткән:

—Мин сиңа фәрештә бүләк итәм. Ул һәрчак синең белән булыр һәм барсын да төшендереп бирер...

Яхшы хикәят иде ул...)

Фатыйма карчык юрганны алып караватка җәеп салды да, аны бала төргәндәгедәй итеп төреп, сак кына бәвелтергә керештe. Читтән берәрсе карап торса, аны чынлап та бала йоклата дип уйларга мөмкин иде. Һәм авыз эченнән генә көйләргә тотынды:

— Әлли-бәлли итәр ул
Йоклап кына китәр ул...

Фатыйма карчыкның тавышы талгын гына көчәя барды. Анда тыелгысыз дәрт, өмет, киләчәктән көткән яктылык чаткылары пәйда булды. Әлеге тавышка ышансаң, тормыш тик ихласлыктан, сафлыктан, куанычтан гына торадыр, анда бернинди дә карангылык, моң-зар, сагыш һәм сабырлык төшенчәләре юктыр сыман иде:

—Йоклап киткәч, төшендә
Әллә ниләр күрер ул...

Җыр көчәя барды. Аның белән бергә, киләчәккә, димәк, яктылыкка булган ышаныч та көчәйде.

Җәй иде. Янгыр иде. Елга буенда бәбкә саклап йөргән малайлар ыштан балакларын сызганганнар да яланаяклап өйгә йөгерәләр. Зуррак икесе бәбкәләр салынган каз оясын ике яктан күтәргән, Малик ана казны култык астына кыстырган, ә Радик бернәрсә дә тотмаган, ул артыннан йөгергән ата каздан куркып чаба. ( Мине ата каз ашаса, әтигә әйтеп каеш белән суктыртам! Малик, мелӛт, көт әле! ) Боларны күреп торган күрше хатыны буынсыз булып көлә. Аңа Фатыйма да кушыла.

—Ипләбрәк! Иплӛп! Бәбкәләрне имгәтәсез ич!—ди ул, аларга каршы атлап.—Егыла күрмәгез...

Малайлар янына житүгә, Фатыйма кулындагы япма белән бәбкәләрне янгырдан ышыклап куя. Ул арада Радик кычкырып җибәрә:

—Әни, мине ата каз ашады!

—Кайсы төшеңне тешләде, балам?...

—Менә, арткы аякны...

Абыйлары көлә:

—Юк, әни, тешләмәде ул. Канаты белән генә тиеп китте.

—Ата каз мине канаты белән ашадымыни?—дип сорый малай

абыйларыннан.—Әни, ата каз канаты белән дә ашый беләә, әйеме?!

Әниләре төпчегенен башыннан сыйпап ала да каз оясын күтәреп абзарга кереп китә. Ә малайлар кабат елга буена йөгерә. Янгыр астында яланаяк йөгерү алар өчен бәйрәм. Шатлыклы авазлары бар урамны янгырата...

Тәпи йөрер-йөрер дә
Үсеп буйга житәр ул...

Балаларның шатлыклы авазлары еллар аша үтеп Фатыйма карчыкның колагында янгырады. Шатланышып көлешкән тавышлар... Кинәт алар бергә буталды да кабат аерылды. Бу юлы инде шатлык авазлары юк иде. Ниндидер шау-шу, талаш...

—Юк, китмисең!

—Китәм!

—Мин сиңа эш сөйләшеп кайттым...

—Ә мин китәм.

Һәм әлеге тәртипсез шау-шуны ертып, Хатмулланың тыныч, әмма көр тавышы ишетелә:

—Әнкәсе... Тавыкларына жим сибеп кер әле...

Һәм аның кайтавазы булып, бер үтенеч янгырый:

—Безне онытмагыз, улым...

—Безне онытмагыз...

Фатыйманың жыры, тулай торак бүлмәсенең түшәмнәре аша узып, югарыга күтәрелде һәм, далаларга киткән балаларын эзләп табарга теләгәндәй, жир шары буйлап таралды. Биек-биек йортлар, кара урманнар, очсыз-кырыйсыз далалар, шаулы дингезләр аша урап кайтты да, хәле бетеп тынган давыл сыман, кабат тулай торак бүлмәсенә ауды. Далаларга киткән балаларны ана моны гына табалмады. Ул монда инде тыелгысыз дәрт тә, өмет тә, киләчәктән көткән яктылык чаткылары да юк иде, ул монда тик ятимлек ачысы гына сулкылдады. (Моңсызларны моң табалмый...)

Фатыйма карчык юрганын кысып кочаклап тынып калды. Юрган аның баласы иде. Ул баласын беркемгә дә бирәчәк түгел, беркайда да жибәрәчәк түгел. Аның кабат ятим каласы килми. Моннан ары аны үстермәс тә. Үсмәсен. Шушы килеш кенә калсын. Шушы килеш кенә... Гел янында булсын... Үз янында. (Баласы бар ана ятим булмый.)

Дынк-дынк-дынк-дон!..

...Фатыйма ындыр артындагы таллыкта иде. Ала каргаларның бик яман кычкырышып өерелгәнен күреп килде ул монда. Кычкырып та, каткан балчык ыргытып та каргаларны куркытырга тырышты. Тик моның бер файдасы да тимәде. Тавышы көчсез иде, ыргыткан балчыгы ике-өч атламнан ерак китмәде. Аның караvы хәле бетте. Сулышлары капты. Көч-хәл белән килеп житте. Хәле карга куркытып йөрерлек түгел иде шул, карынындагы жан иясе инде якты дөнья күрер мизгелен көтә иде. Башка нәрсә булса, бәлки, болай итеп йөрмәс тә иде Фатыйма. Ала каргаларның котсыз тавышы күңеленә шом салды. Каз бәбкәләрен кыйратып ятмагае! Ындыр артындагы кечкенә яланга житкәч, борчылуы юкка түгеллеген аңлады. Ике каз гына коты алынып сибелгән бәбкәләрен саклый алмый иде. Алар яман ысылдап әле бер башка йөгерәләр, әле икенче якка. Ә каргалар күп, бәбкәләрне берәм-берәм чүплиләр генә. Фатыйма килеп житкәндә, каргаларның эше беткән иде инде. Бәбкәләр юк иде. Бары тик ятим казлар гына үзәк өзгеч тавыш белән анда-монда чабып, балаларын эзләп йөри. Әлеге коточкыч хәлне күрүдән Фатыйманың тыны кысылды. Һәм колагында ниндидер сәер тавыш янгырады. Дынк-дынк-дынк-дон!..

Фатыймага ни өчендер каргалар килеп үзен чукый башлагандыр сыман тоелды. Бер мизгелгә генә. Кинәт эченен аскы өлешендә утлы әрнү тойды. Атлаган жиреннән катып калды. Ул үзе генә түгел, бөтен дөнья, вакыт бер мизгелгә тукталып калгандыр төсле булды. Авырту шулай эләктерен алды да талгын гына ычкындырды. Фатыйма эшнең нәрсәдә икәнен сизенгән иде инде. Ул кирегә борылды. Тиз-тиз адымнар белән өенә кайтмакчы иде, теге әрнү тагын эләктерде. Фатыйма тирә-ягына күзләрен тәгәрәтте, башын борырлык рәте юк иде, якын-тирәдә ярдәмгә килерлек кеше күренмиме?! Күренсен иде! Тик күзенә берәү дә чалынмады. Ул эчен куллары белән тотып акрын гына жиргә чүгәләде. Ул курка иде. Монда егылудан. Баласын монда табудан курка иде. Баласын тапкач, азга гына һушын жуяр да, бәләкәчен каргалар алып китәр төсле иде.

(Юк! Юк, монда табарга ярамый! Әле түгел! Берьялгызым чагында түгел. Хатмулла! Хатмулла! Жаның бармы синең, юкмы, ә?! Нәрсәнне карап йөрисең анда! Кил! Кил, баласыз калырга теләмәсәң! Хатмулла, дим!)

Юк, ул кычкырмый иде. Ул кычкыра алмый иде. Уртынны чәйнәрдәй булып көчәнгәндә тавышың чыкмый. Ләкин аның жаны кычкырды. Өнсез кычкыру белән. Ботлары буйлап ниндидер кайнар дулкын йөгергәндә, ул янә ирен чакырды.

(Хатмулла! Кил! Баланы каргалар ала. Кил! Кил!)

Ул бер мизгелгә тирә-як белән бәйләнешен өзде. Әллә нинди сәер халәт иде. Әйтерсең, аны кемдер эләктереп алды да беркадәр вакытка гына тәмугка тыгып торды. Тәмугтагы газап чыдарлык түгел иде. Тәнендәге киеренкелектән сөякләре шартлап сынган, жепселләре мертләп өзелгән төсле булды. Ул үзен тере капчык итеп тойды. Кемдер ул капчыкны әйләндереп-әйләндереп кага иде. Кинәт барсы да тукталды. Ул кабат тормышка кайтты. Бала елаганы ишетелде. Һәм шундук жанын каргалар турындагы уй чукып алды.

—Баласы бар ана ятим булмый!—диде ниндидер карт тавыш. Фатыймага ул башта карга тавышы сыманрак ишетелде. Хатын күзләрен ачты. Кендек әби иде. Тик ул чынлап та мондамы, әллә күзгә генә күренәме?

—Фатыйма!—диде ир тавышы.—Фатыйма...

Хатынның күнеле тынычланып калды. Ул елмайды. Бәлки, иреннәре елмаймагандыр, тик аның жаны елмайды. Ул бәхетле иде.

—Хатмулла, мә улынны тот...

—Улынны... Фатыйма, безнең улыбыз бар...

Кендек әбисе малайны әтисенә сузды да, ир кеше жебебрәк калгач, анасының күкрәгенә салды. Һәм аларны кемнәрдер күтәреп каядыр алып киттеләр.

—Каргалар алмады...—дип пышылдады Фатыйма.—Бәбкәмне карга алмады.

Хатмулла аның мангаеннан сыйпап куйды.

Дынк-дынк-дынк-дон!..

—Каргалар алмады,—дип пышылдады Фатыйма карчык, юрганын күкрәгенә ныграк кысып—Далалар алды...

Һәм кинәт чынбарлыкка кайтып катып калды.

Дынк-дынк-дынк-дон!..

(Ишек кагалар түгелме соң?! Әйе! Радик! Айгөл! Кайтканнар, балакайларым!)

Карчык утны яндырды да ишеккә ташланды.

—Кайттыгызмы?!

—Тетя Фая!

Карчык болай кабалануына үкенеп куйды. Тик ишекне ачкан иде инде.

Ишек төбендә нәни баласын күтәреп, бот буе малаен житәкләп басып торган Зөһрәне күреп куркып китте. Зөһрәнең күз төбе каралай янган иде. Ул Фатыйма карчыкның җавабын да көтмичә ачык ишектән эчкә узды. Артыннан ук үзе йозакны бикләп куйды.

—Тимур котыра, тетя Фая. Сезгә кереп торыйм инде. Урамда калдырма, зинһар...

—Әйдә...—диде Фатыйма карчык, ишек төбендәге тумбочкада утырган электр плитәсен кушып.—Чәй эчеп алырбыз.

—Ул төн уртасында гына кайтып керде...—Зөһрә һаман үз проблемасында кайный иде әле.—«Төнлә йөрмә, әллә кемнәргә эләгерсең, кыйнап ташларлар,»—дигән идем, тавыш чыкты. «Син мине берәрсенә әйтеп кыйнатырга йөрисеңме әле!»—ди... Адәм көлкесе... Кешечә яшәп булмады инде. Бер талашмаган көнебез юк. Эчә дә кайта, эчә дә кайта. Шул да булдымы тормыш?!.

Фатыйма карчык дәшмәде. Алар яшь чакта мондый хәлләр булмый торган иде. Өч йөзгә якын хуҗалыктан торган авылга нибары бер эчкече Иван иде ул вакытта. Иван аның кушаматы иде. Чын исемен белүче дә булмагандыр, бәлки. Фатыйма белми иде. Менә шул Иван эчеп алыр да хромкасын тартып урам буена җырлап йөрер иде. Беркемгә бер авыр сүз әйтмәс, очраган-күргән кешенең олы булсынмы ул, кечеме, хәлен сорашып китәр:

—Хәлләрең ничек туганым?! Ник моңаебрак торасың әле, берәр кайгың бармы әллә?! Проблемаң булса, Иван абзаңа әйт син. Момент юкка чыгарырбыз...

Һәм Иванга да беркем түбәнсетеп карамас, каты кагылмас иде. Аның эчкече икәнен бөтенесе дә белеп тора инде. «Эчмә, болай кыланып йөрмә»—диюнең дә файдасызлыгын беләләр. Аның алкашлыгыннан беркемгә дә зыян да, файда да юк. Авылның бер шамакае урынына яши бирә.

—Берүк, аракыны якын китерә күрмәгез, әнә, Иван абыегыз кебек булырсыз. Хатыныгыз да булмас, мал да тота алмассыз, ашарга да кешедән теләнеп ярым җимерек йортта гомер итәрсез,—дип балаларын кисәтә иде өлкәннәр.—Хәмерне якын китерә күрмәгез.

Эчүче юк та иде. Утын алып кайтсалар да, печән китерсәләр дә бер «ярты» чыгарыш бар. Табында ун адәм утырса да шул бер шешә җитә, хәтта бетми дә торган иде. Кайда ди инде ул талашып, хатын кыйнап йөрүләр. Эчүдән бер вакытта да тавыш чыкмый торган иде.

Әлбәттә, ирләрнең хатынына кул күтәрүе бар иде. Хатмулла да берничә тапкыр Фатыйманы яңаклап алды. Ул вакытта хатынның күңелен бер уй телгән иде: «Хатмулла мине кыйнады... Хатмулла миңа сукты! Сукты!» Ире аңа бөтен көче белән суккандыр, ул аны үтерергә, яки имгәтергә теләгәндер сыман тоелган иде. Һәм үз иренә чиксез нәфрәт белән карый башлаган иде. Ләкин соңрак Хатмулланың яңаклавы бары тик кисәтү генә булганлыгын аңлады. Берничә елдан соң булды ул хәл. Күрше авыл сабан туеннан кайтып киләләр иде. Алар гадәттәгечә, ат арбасында арка терәшеп утырганнар. Ике малай аякларын сузып артка карап утырган. Ә Малик, ул чакта ими баласы гына, Фатыйманың кулында. Урман куелыгына житкәч, кемдер атның авызлыгыннан эләктереп алды. Ул вакытларда акча сорап бәйләнү гадәте бар иде. Һәм менә шундый өч адәм аларга да юл басты. Нәрсәдер кычкырдылар. Фатыйманың коты ботына төште. Хатмулла да дәшми. Юлбасарлар андый-мондый гына түгел, өчесе дә озын буйлы, киң җилкәле. Хатмулладан күпкә яшьрәкләр дә. Болардан котылу юк иде инде. Юлбасарлар үзләре дә моны сизеп тора, әнә бит ничек иркен кыланалар. Берсе Фатыйманы арбадан ук сөйрәп төшерергә итеп, хатынның беләгенә

үрелде. Тик шул мизгелдә үк кайдадыр очып барып төште. Хатынның күз алдында Хатмулланың беләге генә ялтырап калды. Ул арада агачлар сынган тавыш ишетелде һәм икенче юлбасар да юкка чыкты. Агачлар арасына качкан өченче ирнең аркасы гына күренеп калды. Хатмулла дәшмитынмый гына арбага килеп утырды да дилбегәне тартты. Менә ничек суга икән Хатмулла! Үзеннән бер башка озын һәм таза ирләрне исәңгерәтерлек итеп. Фатыйма шунда Хатмулланың үзенә суккан чагын хәтерләде. Аның яңаклавын сугу дип әйтү гөнаһ булган икән. Бары тик кисәтеп кенә куйган ул, үзенең ир кеше икәнен искәртеп кенә алган. Әлбәттә, авылда андый «искәртүләр» гадәти күренеш иде. Әмма бер генә хатын-кызның да күз төбен каралай яндырып йөргәне булмады. Аракы юк иде шул ул чорда. Шуңа күрә, хатыннары—хатын, ирләре ир төсле иде. Хәзер хатын-кызын да тотып тыярлык түгел бит аның, ирен адәмгә дә санамаганнар бар...

—...аерылып кына китәр иден дә, кем сине көтеп тора инде ике бала белән... Тимур да жалкы. Үзе генә калса, бөтенләй эштән чыга бит ул...

Фатыйма карчык ирексездән караватка күз ташлады. Анда исереп йоклап яткан Радигын күрер төсле иде. Ул да аракы дингезенең төбенә төшәргә тырышты бит инде. Ул да хатынын шулай интектереп йөртте микән?! Эх, бу ирләрне... Гитлер басып ала алмаган илне аракы басып алды да ирләрне нindидер бер мәхлукка әйләндерде. Үзе дә рәхәт күрми, башкаларга да рәхәт күрсәтми торган бер ерткычка. Мескен ерткычка.

Хатмулладан туган баланың менә шундый хәшәрәтлеккә төшүе икеләтә аяныч иде. Фатыйма карчык бүтән балалары өчен ул тиклем үк әрнемәде дә кебек. Бернигә карамыйча шәһәргә чыгып качкан өлкәнен ул аңлый иде. Үз дигәненә ирешергә тырышу. Атасы холкы. Дөньяның берәр ташландык почмагында исереп йоклап ятмаса, аны гафу итеп тә буладыр. Маржасына ияреп чыгып киткән Хәмитне дә аңларга мөмкин. Хәтта кызу канлылык белән нindидер матавыкка эләгеп һәлак булса да ул хөрмәткә лаек. Тик менә Радикны гына аңлап та, гафу итеп тә булмый. Хатмулладан туган баланың менә шундый пычраклыкта аунап яшәве бернинди канунга да сыймый.

Зөһрә Фатыйма карчыкка үз киленедер сыман тоелып китте. Ул әнисенең артынарак яшеренеп торган малайны җитәкләп алды да суыткыч янына алып килде.

—Мә, улым...—диде суыткычтан алма алып.—Боегып торма, синең кебек малайларны бик яратам мин.

Малай кызарган күзләрен бер алмага, бер әнисенә йөгертеп алды. Әнисе елмаеп баш каккач, алмага үрелде.

—Рәхмәт, апа!..

—Үзенә рәхмәт, бәләкәчем!—диде ул, икенче караватның җәймәсен алып.—Соңгы егерме елда апа дип әйткәннәре юк иде әле. Һи-һи-һи... Әйдә, Зөһрә кызым, бәләкәченне менә монда яткыр. Кулга өйрәнмәсен.

—Әй, рәхмәт инде...—Зөһрә баланы караватка салды да өстен юка юрган белән каплаштырып куйды.—Төн уртасында коридорда йөрү дә уңайсыз. Берсе күрмәсә, берсе күрер... Рәхмәтләр генә яусын инде сиңа!

—Ярый, бәләкәчен уянмаган әле...—диде Фатыйма карчык Зөһрәнең игътибарын яхшырак нәрсәгә юнәлтергә теләгәндәй.—Иң мөһиме шул. Калганы үтә аның...

—Әйе... Куркып калса, яхшы булмас иде...—Зөһрә күзен чәчләре белән капларга азапланды.—Сугам дип сукмады ул... Селтәнгәндә кулы ялгыш кына тиеп китте...

—Минем дә Хатмуллам кызу була торган иде...—диде Фатыйма карчык, аны юатырга тырышып. Һәм тагы ни әйтергә белми туктап калды. «Бер син генә мондый хәлгә төшмәгәнсең, юкка кыенсынма. Бөтен хатын-кызның да

өлешенә язган нәрсә ул. Анын каравы, ир кулы тигән урын тәмугта янмый, диләр.» Шул чамарак итеп юатасы иде. Ләкин Хатмулласының исеменә кара ягу бик пычрак нәрсә сыман тоелды. Хатмулланың кулы ялгышып та болай каты кагылмады ана. Ир була белде Хатмулла.

—Әйдә, өстәлгә якынрак килегез әле...—диде карчык, әлеге хәлдән котылу юлын табуына сөенеп. Һәм чыжлап утырган чәйнекне алып, чәй пешерергә тотынды.—Үзем дә йоклый алмый газапланып ята идем. Керүегез бик әйбәт булды әле. Күсегә үлем, песигә көлке дигәндәй... Чынлап менә, Зөһрә кызым, берүзем бер бүлмәдә. Ни керүче, ни чыгучы юк. Үлеп китсәң дә хәленне белмәсләр... Әлдә, сез кердегез әле.

—Радик кайтмаган иде мени?

—Ул балалары янына дип киткән иде. Шуна күнелем тынычсызланыбрак тора. Исән-имин йөрсен инде. Алкаш булса да үз балаң бит. Ул булмагач, өйләрнең яме юк сыман, менә.

Зөһрәнең күнелен ниндидер ләззәтле хис биләп алды. Соклану иде бугай ул. Картайган көнендә урамда хәер сорашып, эчкече улын асраучы шушы карчыкка соклану хисе иде бугай. Бер уйласаң, тормышнын төбенә төшеп җиткән бит инде. Зарланудан башканы белмәскә тиеш шикелле. Әмма ул зарланмый. Киресенчә, алдагы көненә ниндидер якты өмет белән карый. Ходайның рәхмәте булып, яхшырак яши башларына ышанычы зур. Менә кайда ул сынмас-сыгылмас рух көче!

—Барсы да яхшы булыр әле,—диде Зөһрә.—Минем дә, синең дә тормышлар яхшыга үзгәреп китәр.

—Шулай булсын, кызым. Шулай булыр... Тик ышанычынны гына югалтмаска кирәк.

Фатыйма карчыкның арыганлыгын Зөһрә дә сизми калмады. Әмма ул тагы бер нәрсәне сорамаса, бүген төн йокысын йоклый алмас шикелле тоелды.

—Ә син Радикнын... эчүен ташларына ышанасынмы?

Фатыйма карчык ана кинәт сәерсенеп карап куйды. Һәм елмайды. Зөһрәне башта килененә охшаткан иде ул. Әмма ялгышкан икән. Бу бөтенләй дә аның килене кебек түгел, бу бөтенләй башка камырдан. Әлеге соравының да төбендә нәрсә ятканын аңлады карчык. Зөһрәне Радикнын киләчәге түгел, ә үз иренең язмышы борчый иде. Ул Фатыйманың улы турында белешми, ул үз уйларына таяныч эзли.

—Ышанам, кызым. Бәлки, аның адәм булырына бөтен дөньяда бер мин генә ышанамдыр да. Ләкин мин ана ышанам. Һәм беләм, кызым, аны минем ышанычым хәмер сазлыгыннан сөйрәп чыгарачак.

—Ышаныч кына чыгара алыр микән...

Зөһрә бу сүзләрен кычкырып әйтергә теләмәгән иде бугай, башында ялтлап киткән уйны колаклары белән ишеткәч, кыенсыныбрак калды. Әмма карчык моңа игътибар итмәде.

—Ышаныч—зур нәрсә, кызым,—диде ул һәр сүзенә басым ясап.—Ышаныч—тылсым.

Тын калдылар. Бераздан өстәл артыннан кузгалдылар да карчык урын җәяргә керешге, Зөһрә савыт-сабаны юып куйды. Улы урындык аркасына сөялеп, күзләрен йоммаска тырышып утыра иде.

—Баланы монда яткырырсың инде,—диде Фатыйма карчык, раскладушка җәеп.—Бик арыган бугай, бәләкәчем...

—Ярый, өчебез дә бер караватка сыйган булыр идек әле...—диде Зөһрә.—Әйдә, алайса, үзем җәя торыйм.

Карчык җәймәләрне ана тоттырды да үз урынына барып ятты.

—Әллә нишләп кинәт арып киттем әле,—диде ул акланганда.—Картлык

шатлык түгел инде ул... Сез үзегез карагыз инде барсын да... мин йоклапнитеп китсәм...

—Ярый, ярый... Тыныч йокы...

«Ышаныч—тылсым...—дип күңеленнән генә кабатлады Фатыйма карчык урынга яткач.—Әлбәттә, бу сүзләрнең дөреслеген инкарь итәсе килми инде. Әмма ышаныч тылсым булса, аның балалары әллә ничә ел элек кайтып күренерләр иде инде. Шул тиклем зур ышаныч, шундый зур өмет белән көткән аналары янына кайтмыйча түзә алмаслар иде. Тик алар кайтмадылар.

Ә кем әйтә, алар кайтмаслар дип?!.

* * *

Зөһрә чыгып киткәч, Фатыйма карчык та урыныннан кузгалды. Төне буена әллә нәрсәләр күреп саташып чыкты ул. Күргәннәренең өндәге уйлармы, саташулармы икәнен дә аермачык кына әйтерлек түгел. Әлеге уйлардан котылу өчен ниндидер хәрәкәт кирәк иде.

...балаларын шул түгәрәк эчендә бикләнеп калган. Тагын шушы сүз зиһененә уралды. Фатыйма карчык күрәзәченең сүзләрен аң җитәрлек дәрәҗәгә китерергә тырышты. Нинди түгәрәк эчендә?

Хәдичәдән кыенсынып-нитеп торасы юк. Барырга һәм сорарга кирәк. Бөтен балаларым да шул божра эчендәме? Ул божра утраумы? Нинди утрау? Шушы өч сорауга җавап тапмыйча, аның күңел тынычлыгы кайтачак түгел иде.

Тукталышта ул хәтсез генә торган кебек булды. Ләкин сирәк-мирәк тә кеше күренмәде. Шул тиклем үк иртә чыкты микәнни соң?! Кинәт башына бер уй килде дә карчык шатланудан сикереп куйгандай итте. Һәм ашыгып кесәсенә тыгылды. Ходайның рәхмәте! Акчаны ул хәтсез генә алган иде. Бәс, шулай булгач! Фатыйма карчык юлга якынрак атлады да урамга карап кулын күтәрде. Шундук диярлек, янына бер җинел машина килеп туктады.

—Кайда барасыз, әби?

Карчык адресын әйтте.

—Ярый, утырыгыз,—диде шофер елмаеп.—Акчагыз бармы соң?

—Тукта, күпме сорыйсың соң әле син?

—Йөз илле инде.

—Әй, балам, миндә ул тиклем үк юк иде бит әле.

—Күпме бар соң?

—Йөзгә ризасызмы соң?

—Утырыгыз, әйдә.

—Һәй, рәхмәт яугыры...—дип чын күңелдән сөенде карчык. Аның, әлбәттә, акчасы җитәрлек иде. Әмма саф татарча сөйләшкән шофер егетнең хисләрендә уйнап, изгелеген күреп калырга булды. Җан тартмаса да кан тарта дигәндәй, татар кешесе татар карчыгына ташлама ясамый калмый ул. Базарда әйбер сатканда булсынмы, башка урындамы—кайда да шулай.—Ходай сине игелегеннән ташламасын, улым. Гаиләңне, балаларыңны сөендереп яшәргә язсын.

—Нәрсә болай таң атмас борын кузгалдыгыз соң?—диде шофер аның рәхмәтенә җавап биргәндәй. —Берәрсе куып чыгармагандыр бит...

—Юк...—Шофер шаяру катыш сораса да карчык җитди җавап бирде.—Балаларым юлга чыгып киткән иде. Күңелем бик тыныч түгел. Төне буе начар төшләр күреп, борчылып чыктым. Шуна күрәзәче карчык янына барып карыйм әле. Бәлки, берәр юньле нәрсә әйтер.

—Хәдичә әбигә барасыз инде, алайса...

—Аны син дә беләсеңмени?!.

—Былтыр әнине алып килеп дәваладык. Буыннары бөтенләй тотмас булган иде. Хәзер таш кебек булып йөри, күз тимәсен. Хәдичә карчыкның кулы жинел аның.

Шоферның сүзләре Фатыйма карчыкка шул тиклем рәхәт булып ишетелде. Хәтта ул сораган йөз илле тәнкәне күпсенгәне өчен үкенеп тә куйды. Ярый, изге эшкә беркайчан да соң түгел. Төшкәндә бирер.

Ләкин төшкәндә дә йөз илле сум бирергә туры килмәде.

—Хәдичә карчыкка баргач, апа, сезгә бер үтенечем бар,—диде шофер бик житди итеп. Менә шушы конвертны гына тапшырыгыз әле, зинһар. Күптән кереп чыгармын дип йөри идем инде, жае чыкмый.

—Сон, әйдәгез, бергә керик.

—Юк... Унайсыз... Таң тишеге белән... Үзегез генә бирегез инде, зинһар.

Фатыйма карчык конвертны алып кесәсенә тыкты да акчасын чыгара башлады.

—Юк-юк. Кирәкми,—дип каршы төште шофер.—Акча алып тормыйм. Олы кешегә миннән бер изгелек булсын. Дога кылырсыз. Рәхмәт. Сау булыгыз.

Һәм ул китеп тә барды. Фатыйма карчык рәхмәтләр укып торып калды. Менә бит нинди кешеләр бар дөньяда, Ходайның рәхмәте! Иртәдән үк уңып башланган көн начар тәмамланмас әле, Аллаһ теләсә.

Шул ук вакытта, карчыкка бераз моңсу да иде. Шофер егет аның Хәлиле белән бер яшьләр тирәсендә булырдыр. Нинди игелекле бала! Шундый яхшы кешенең үз улы түгеллегенә үкенү хисе сыманрак нәрсә күңелен телеп үтте. Нигә бу минем улым түгел икән. Нигә минем улым да шундый яхшы күңелле түгел икән?! Әнинең буыннары тотмый башлаган иде, Хадичә карчыкка китереп дәваладык. Аның улларының кайтып күренгәне дә юк. Буының тотмау түгел, үлеп китсән дә каберенә кайтып туфрак салучы табылмас.

* * *

Ул да бермәлне аяксыз калган иде... Кышның ямьле бер көнендә малларын карарга дип абзарга чыккан иде Фатыйма, бер дигән атлап барган жиреннән кинәт нәрсәгәдер абынып китте дә мәтәлләп барып төште. Тиз генә торып китмәкче булган иде, аягына баса алмады, бөтен булмышын чиксез авырту телеп үтте. «Алла-алла-алла...—дип ыңгырашты ул, жиргә бөгелеп төшкән хәлендә ике кулы белән уң балтырын тотып.—Ниләр генә булды икән аяккаема...» Нәрсәгә абынганын чамаларга тырышып тирәягына күз йөгертеп алды, тик абынырлык әйбер күренмәде. Авыртуга абынганмын инде, дип уйлады ул. Тагын дүрт аяклап басарга тырышты. Авырту бетмәде, шулай да ул егылмыйча кала алды. Бертын хәл жыеп торды. Монда торып булмый иде, дүрт аяклап булса да өйгә керергә кирәк. Әмма шул рәвешле атларга тырышу белән, ялгыш уң аягына таянды да, авыртуга чыдый алмыйча, тагын барып төште. Беркадәр һушсыз ятты... Аллакаем сакласын инде. Берәрсе күрсә, Фатыйма исерек дип тә уйлар әле... Ләкин карчык урыныннан кузгалырлык көч тапмады. Жир салкын иде. Үзенең чарасызлыгынны тоюдан дөнья да шыксыз булып тоелды. Суык аның бөтен күзәнәкләренә үтеп керде. Үлеп тә китәрсең әле шулай көтмәгәндә... Ул инде яшәрен яшәгән, үлем артык куркыныч булып тоелмады. Ләкин... Фатыйманың тамагына төер тыгылды. Менә шулай... Бер ялгызың... Абзарда... Тирес арасында... Ул монда үләргә жыенмый иде. Монда үләргә ярамый. Инәләре абзарда үлеп ятса, улларым адәм күзенә ничек күренерләр?! Алла сакласын! Өйгә керергә кирәк. Шушы уйлар белән ул тагын дүрт аяклап басты. Уң аягына таянмаска тырышып, башта

кулларын, аннан сул аягын алга шудырды. Ул инде яшь, көчле кеше түгел, болай атлау бөтен хәлен ала, өстәвенә, ун аягындагы авырту селкенгән саен сулкылдап, көчле әрнү дулкыны булып йөрәгенә бәрә иде. Абзар эченнән ишек алдына чыкканчы Фатыйма шыбыр тиргә батты. Ихатага чыккач, берәрсе күренмәсме дип алан-йолан каранып торды. «Һәй! Берәрегез юкмы! Килегез әле! Аягымны авырттырдым бит!»—дип сөрәнләп тә карады. Ахырда башын иеп тынып калды. Күрүче дә, ишетүче дә юк...Тамагына янә төер килеп тыгылды. Күзләреннән яшь атылып чыкты. Җан әрнүе белән авырту онытылып торды. Ул тагын алга омтылды. Шайтан алгыры! Бияләй дә кимәгән булган идем. Күгәрчен тәпие сыман булып күренләнгән кулларын күрүгә бөтен тәне белән калтыранып куйды. Болай торырга ярамый. Кулларым туңачак...Ул тагын беркадәр җир үтте дә бармакларының әрнүенә чыдый алмыйча, туктап калды. Әрнү туктамады. Фатыйма өреп җылытырга теләп, кулларын авызына китерде һәм тигезлеген җуеп йөзе белән карга капланды. Салкын каты кар битләрен сыдырып алды. Ул егылып китте. Аста калган уң аягы чыдап булмаслык булып әрнеде. Кабахәтләр! Нигә мине шулай интектерәсез инде!..—диде ул кемне сүккәнен үзе дә анлап җитәлмичә.—Ерткыч түгел лә сез... Сез бит адәм балалары... Сез юньле булсагыз, мин болай итеп йөрер идеммени!.. Мин бит сезне... мин бит... Анын сүзләре елауга әверелде. Күнелендәге бөтен әрнүләре, бөтен сызланулары ташкын булып тышка томырылды. Ул ярсып елады. Ул ярсып урыныннан купты. Йөрәген телгән ялкынны да, сөякләренә кадәр үтеп кергән салкынны да җинәргә тырышып, җан ярсуы белән алга шуышты... Төн уртасында идәндә уянып киткәндә, ул үзенең ничек итеп өйгә кергәнен хәтерләми иде. Ул моны соныннан да исенә төшерә алмады. Ул бары тик тәмуг газаплары аша узганын гына хәтерли иде.

Ул өч көн буена аяксыз ятты. Өстәвенә, салкын да тидергән иде. Өч көн буена тамагына бер ризык әзерләп каба алмады. Хәтта хәҗәтен дә көч-хәл белән шуышып барып, ишек төбендә генә үтәде. Искә төшерсән, бүген дә тәннәр чемердәп китә... Һәм өч көн буена Хатмулланың кайтып, үзе белән теге дөньяга алып китүен теләп ялварды. Бу көннәрдә анын өчен үлемнән дә зуррак бәхет юктыр сыман иде. Һәм бер көнне ишек шакыдылар. «Хатмуллам кайтты!—дигән уй ялтлап китте анын башында,—Аллага шөкер, Хатмуллам кайтты!» Тик шундук әлеге уенын дөрес түгеллеген анлады. Хатмулла ишек шакып тормас иде.

—Кер, улым, кер!..—дип кычкырды ул, тик тавышы үзеннән ерак китмәде.—Керегез, балакайларым.

Шулай да аны ишеттеләр бугай. Ишек ачылды. Идән уртасына шуышып килеп җиткән Фатыйма ишек төбендәге тасны берәр нәрсә белән каплап куярга өлгерә алмавы өчен гарьләнеп куйды. Ләкин керүченең кем икәнен күрүгә үк кояштай балкып китте.

—Кайттынмы, балакаем!—дип анын аяк астына ташланды ул, һәм хәлсез учлары белән үкчәсен кочаклап еларга кереште.—Ничә еллар буе көттем бит инде... Кайчагында исән икәненә дә шикләнеп куя идем... Балакаем!.. Менә, чирләп киттем әле...

Керүче аны кочакларга ашыкмады. Ул акрын гына карчык янына чүгәләде дә башыннан сыйпап алды. Һәм талгын гына анын башын күтәрде. Фатыйма күз яшьләре аша елмаеп улына карады.

—Балакаем... Син ничек үзгәргәнсен...

Озаграк караган саен улынын никадәр нык үзгәргәнен төшенде. Кинәт анын йөзендәге елмаю катып калды. Күзләрен ачып-йомып алды. Һәм бөтен йөзен курку ялмады.

—Китмә...—дип әрнеп пышылдады ул.—Китмә, улым...

—Китмим, Фатыйма апа...—дип башыннан сыйпады аны керүче.—Беркая да китмим... Тик син тынычлан, яме...

—Фатыйма апа...—дип пышылдады карчык бу сүзне үлчәп карагандай.—Фатыйма апа...

Һәм анын күз алдындагы йөз акрын гына күрше Рәмзилгә әверелде. Бу анын улы түгел иде.

Һәм карчык һушын җуйды. Соңыннан, айга якын больницада ятканда, ул төшендә гел шушы мизгелне күрде. Улының аякларын кочаклап: «Китмә балам! Беркая да китмә!»—дип шатлыктан елый да, күзләрем талганчы карап калыйм әле дип башын күтәрсә, күрше Рәмзил булып чыга...

* * *

—Мин сине көткән идем,—диде Хәдичә карчык.—Әлбәттә, иртәрәк килүеңне теләгән идем. Әмма хәзер соң инде. Минем соңгы минутларым якынлаша. Тавышланма!

Нәрсәдер әйтеп карышырга теләгән Фатыйманы шулай кискен бүлдерде дә бер мәлгә тын калды. Бу тынлык мәңгегә сузылгандыр төсле тоелды.

—Минем соңгы минутларым якынлаша,—дип кабатлады ул тагын.—Балаларына куркыныч яный. Сиңа да бик ашыгырга кирәк... Аларны кисәтергә... Мин сиңа үз көчемнең бер өлешен калдырам... Хуш...

Фатыйма карчык нидер әйтмәкче иде, әмма өлгерә алмый калды. Кинәт менәрләгән яшен бергә килеп чәкәшкәндәй көчле нур пәйда булды да аны кайдадыр алып ыргытты. Бөтен тәнен чиксез әрнетеп ялкын көйдерде. Фатыйма карчык үзен ниндидер тар көпшә аша узгандай хис итте. Аны бер үк вакытта рәхимсез бер гайрәт белән кысалар да, тартып-сузалар да иде. Әлеге коточкыч газап ничек кинәт башланган булса, шулай ук юкка да чыкты. Газабы югалды, әмма тормыш тиз генә кире кайтмады. Чынбарлыктагы дөнья ниндидер куе томанга төренеп озак кына читтә адашып йөрде. Шуннан соң гына мизгел саен көчәя барып, томан аша сыек нур үтә башлады, бераздан тормышның шау-шулары ишетелде.

* * *

Хәдичә карчык янына баруы бушка китмәде. Балаларына куркыныч янавын, һәм аларны кисәтергә кирәген белә ич. Хәзер ул аларны эзләп юлга кузгалырга тиеш. Ярый әле теге хатның күчермәсен үз вакытында ясатып алган. Анда адресы булмый калмас. Шул адрес белән юлга кузгалырга.

Шуларны уйлап та өлгермәде, үзенә табан атлаган Зөһрәне күреп елмаеп җибәрде. Әмма хатынның Фатыйма карчык турында хәбәрендә дә юк иде. Ул күзләрен әле унга, әле сулга йөгертеп, тирә-яктагы йортларга караган булып, Фатыйманы таптый язып узып китте. Моңа карчыкның бик ачуы чыкты. Ул дәшми генә узып китә алмады:

—Бик хәтәр нәрсә икәнсең!—диде ул, тавышына бөтен әрнүен салырга тырышып.—Күзенне тондырып, тапап та узарсың әле... Бәреп ексаң, борылып та карамассың...

Хатын кинәт туктап калды да тавыш хуҗасын эзләде. Карчыкны күргәч, гаепле елмаеп куйды һәм аның янына атлады:

—Апа, зинһар, гафу итегез инде... Эзли торгач, чистый күзем тонды... Берүк, гафу итә күрегез. Мин сезне рәнҗетергә теләмәгән идем.

—Нәрсә, тагын эчеп йөримө әллә?

—Юк...

—Инде дә эчсә, ояты булмас, юньсезнең... Нәрсә юллыйсың соң болай пыр тузып?

—Юк, апа, сез мине кем беләндер бутыйсыз бугай...

Фатыйма карчык бик тозлап-борычлап нәрсәдер әйтмәкче булып Зөһрәгә караган иде, кинәт аның күз төбен абайлап телен тешләде. Кичә Зөһрәнең күз төбе кара янган иде. Бу хатынның бернәрсәсе дә юк. Житмәсә, кулында юл сумкасы да бар икән. Шайтан алгыры! Бу юлы чынлап та үзе буталган шул! Карале, малай. Шул тиклем дә охшаш кешеләр булыр икән!

—Әллә апамны беләсезме? Зөһрәне?!

Фатыйма карчык ык-мык итеп калды. Берни дә әйтә алмады, бары тик ризалык белдереп, баш кына какты.

—Мин шуларның йортын эзләп йөрим бит!

—Ә мин шул йортта торам,—диде Фатыйма карчык шаян шелтә белән.—Ә син мине тапап китә яздың...

—Гафу итегез инде...

—Зыян юк... Зөһрә шулай кыланып узып бара дип ачуланган идем. Ә син йорт эзлисен, имеш...—Һәм ул үз тапкырлыгына үзе сөенеп өстәп куйды.—Йортларны да кешеләргә карап эзләргә кирәк, кызым.

—Сез апамнар белән бер йортта яшисезме?

—Әйе. Әйдә, минем арттан.—Фатыйма карчык тулай торак ягына атлады.—Мин Фатыйма карчык булам. Синең исемен ничек соң?

—Ләйлә,—дип елмайды хатын.—Без Зөһрә белән игезәкләр. Ул берничә минутка алдарак туган. Күптән күрешкәнебез юк иде инде...

—Хәзер туганнар бер-берсе белән бик аралашмый шул,—диде Фатыйма карчык, битәрләгәндәй итеп.—Әллә нишләде халык...

—Юк, без хат алышып торабыз. Бары тик соңгы арада гына... Мин авылга киткәч кенә еш күрешми башладык.

—Тормыш итүең авылдамени?—Фатыйма карчыкның бу соравы «Кайсы авылдан соң син? Безнең яктан түгелме:»—дигәндәйрәк килеп чыкты.

—Тормыш дип...—Ләйлә монсу елмайды.—Укытучы булып барган идем бер авылга... Хәзер нәрсә?!. Мәктәпне яптылар, яратып йөргән кешем шәһәргә китте...

—Син шунын артыннан килгәнсеңдер әле?—Бу сорау башка кеше авызыннан тупаслык сыманрак янгырар иде. Тик Фатыйма карчык аны әллә нинди бер ягымлылык белән, хатынның бу адымын хуплагандай итеп әйтте.—Мәхәббәт йөртәдер сине.

—Юк. Ул бөтенләй башка шәһәрдә. Уфада. Бер хатынга йортка кергән инде. Ә мин... Авылда ямь калмады. Монда берәр жиргә урнашып булмасмы диебрәк килгән идем.

—Урнашырсын әле. Эше дә, яшәр урыны да табылыр. Казан—зур шәһәр.

Ләйләнең шулай ихлас итеп сөйләшүе Фатыйма карчыкка бик ошады. Ул ана канат куярлык сүзләр әйтергә теләде. Тик шуннан да артыгын өсти алмады. Тиздән алар тулай торакка килеп тә життеләр.

—Рәхмәт инде сезгә, Фатыйма апа,—диде Ләйлә.—Минем кайда тукталганны беләсез. Кирәгем тиярлек булса, эндәшегез. Рәхәтләнеп ярдәмләшермен.

—Үзенә рәхмәт, кызым, яхшы сүзең өчен...—дип елмайды карчык һәм үзенең дә бүлмәсен әйтте.—Зөһрә, бәлки, эштәдер әле ул. Ишекләре бикле булса, интегеп торма. Мина төш. Бүлмәне исеңдә калдырдыңмы?

Фатыйма карчык өенә кереп чәй эчәргә дә өлгермәде, ишек тукылдаттылар.

—Керегез. Ачык,—диде Фатыйма карчык икенче чынаякка чәй ясап. Ул керүченен кем икәнлеген чамалый иде. Зөһрәләр әле эштәдер.—Ләйлә, кызым, синме?

—Мин әле, Фатыйма апа.

Кинәт карчыкның башында бер уй ялтырап китте. Фатыйма Ләйләгә сынаулы караш ташлады.

—Нәрсә булды, Фатыйма апа?

—Булмады, кызым... Мин юлга җыена идем... Юк-юк, синең керүең вакытсыз булмады... Киресенчә... Син... син бит эш юллап, монда яшәргә дип килгән кеше инде...

—Әйе.

—Әзер урының юктыр бит? Фәләненче числодан эш башларга дип көтеп тормыйлардыр?

—Юк инде. Әллә?.. Әллә сезнең берәр тәкъдимегез бармы?

—Юк, кызым... Эш турында сүзем юк... Мин башка нәрсә тәкъдим итәсе идем...—Фатыйма карчык бертын сүзсез торды.—Мин юлга җыенам. Карт кешемен бит инде. Әллә иптәш булып барасыңмы, балам?

—Кайда барырга уйлыйсыз соң?

—Э-э-э... Кайда икәнен дә бик төгәл генә белмим әле. Башта Ленинградка инде. Аннан күз күргән якка. Юлдаш булып бара алсаң, бик яхшы булыр иде. Исән-имин урап кайтсам, бурычлы булып калмас идем, кызым.

—Кайчан кузгалырга дисез соң, Фатыйма апа?

## 4. Утрау

* * *

—Син мине гаеплисеңме?—дип пышылдады Ольга.

—Юк, кадерлем. Син барсын да дөрес эшләгәнсең.

—Юк... Мин дөрес эшләмәдем... Мин капчык авызын бәйләргә оныттым. Ә баскычның яртысына җиткәч, аның ауганлыгын күрдем. Костюмның бер очы капчык авызыннан чыгып, ак нур булып ялтырап тора иде. Ләкин мин кире борылырга курыктым. Куркудан котырынган кешеләр сизеп калыр да, мине өрәк дип уйлап үтереп ташларлар сыман тоелды.

Андрей Николаевич аны кочаклап алды.

—Бер нәрсәне мәңге онытма, кадерлем. Безнең эштә хаталану гөнаһ түгел, ә хатаңны яшерү гөнаһ. Капчык турында син төшү белән миңа әйтергә тиеш идең.—Андрей Николаевич хатынны үзенә кысты.—Ярый, барсы да үтте инде. Без нәрсәдер уйлап табарга тырышырбыз. Синең белән.

—Мин куркам...—дип пышылдады Ольга.—Әлеге кешеләр ничектер күңелемә якын була башлады. Ә без аларны кайгыга салырга тиешбез.

—Син ул хакта уйлама. Бу бәндәләрнең барсы да газапка лаек. Хәзер менә нәрсә мөһим: Роман. Ул безнең сөйләшүне ишеткән булырга тиеш. Һәрхәлдә, Өрәк белән мәҗараны без оештырганны ул яхшы белә. Аның урынында булсаң, син нәрсә эшләр идең?

* * *

—Леон һаман күренми...—диде Лена сүзне бөтенләй икенчегә борып.—Бөтен дөньяны өрәк куркытканда нишләп йөри икән...

Хәмит елмаеп куйды. Дәшмәде.

—Кызлар кырындадыр...—диде Ләйсән, үзенең дә әле Роберт белән түгеллегенә үкенеп.—Тагын кайда булсын.

—Шул маржа дип, өрәк кулына эләкмәсен...

—Гашыйкларга өрәк кагылмый ул,—дип елмайды Хәмит.—Кайтыр әле.

Һәм кинәт катып калды. Аның Ленасы да кайчандыр әнисе әйткән сүзләрне кабатлый түгелме соң?! Тагын шул «маржа»... Ә Ләис... Әтисенең язмышын кабатламаса, татарда кыз беткәнмени инде ана! Ярый, башын

югалтып кына куймасын инде. Һәм колагында әнисенең сүзләре яңгырап китте: «Авылда уникe ир маржага өйләнде... син уночeнчесе буласың...» Һәм күз алдында Аннаның сыны чагылып узды. Ул, кайсыдыр ягы белән, Ләисне караткан әлеге кызга охшагандыр сыман иде...

—Ул кыз маржа түгел,—диде Ләйсән, ниндидер яңалык ачкан сыман.—Ул саф татар кызы.

—Нәрсә?!—Хәмитнең тавышы шатлыклы иде.—Нәрсә дисең?

Лена ана сәерсенеп карап куйды да берни дә дәшмәде.

—Айгөл—татар кызы,—дип кабатлады Ләйсән.

—Шулайдыр инде...—Ленаның кинәт кәефе үзгәрде.—Бөтен кешегә дә американнар житмидер...

—Роберт та татар егете,—диде Ләйсән, әнисенең чәнчелеп торуына тамчы да үпкәләмичә.—Татар күп ул, барсына да житә...

Хәмит кычкырып көлеп жибәрде. Ләйсәнгә ул рәхмәтле иде. Аның көлүе Ленага тагы да авыррак булып ишетелде.

—Житте!—дип тавышын күтәрде ул.—Бала-чагаланып тормагыз. Гомергә әти була белмәдең. Юньле кешенең кызлары атасы янында егет сөйләп тормый ул.

Хәмит аны кочаклап алды.

—Сөйләсеннәр, жаным... Безне ярatканга шулай бит ул...

Лена бер мәлгә генә киреләнеп торды да иренә сыенды.

—Юкка гына өйдән чыгып киттек әле,—диде аннан соң үзенең кәефсезлеген акларга теләгәндәй.—Бер рәхәт күргән юк...

—Булыр әле рәхәте дә...—Хәмит аны юатырга тырышты.—Ожмах утравы вәгъдә иттеләр бит...

—Үтә инде гомер шул вәгъдәләргә ышанып.—Лена моңсу елмайды.—Өйдә генә яткан булсак.

—Монда да кызык, ләбаса...—Ләйсән тагы нидер әйтмәкче булган иде, Роберт турында сүз башланырыннан кыенсынып, тукталып калды.

—Теге өрәкне әйтәм, мин аны чынлап та әллә ничә куллы итеп күрдем... Әгәр ул чыннан да теге Кали алиһә өрәге булса... Ә Ләис һаман юк...

—Кайдадыр шушында гына инде алар.—Хәмит хатынын ныграк кысты.—Чыгып эндәшсән, хәзер килеп житәрләр.

—Чакырыйммы соң?—диде Ләйсән. Ул әнисенең бәхетеннән аз гына көнләшә иде.

—Юк, ашыкмый тор,—диде Хәмит һәм хатынының сораулы карашын сизгәндәй булып өстәп куйды.—Үзе керер әле. Ашыктырмыйк. Күп вакыт үтмәде бит.

—Нишләп мондый урында өрәк булырга тиеш соң ул?—диде Лена үзалдына сөйләнгәндәй.—Утрауның тарихын беләсе иде. Әллә Андрей Николаевичка барып киләбезме? Аның белмәгән нәрсәсе юк бит.

—Ташландык утрау бит бу.—Хәмит аны тынычландырырга тели иде.—Адәм аягы сирәк баса торган урын. Мондый жирдә кешенең күзенә әллә нәрсәләр күренергә мөмкин инде. Житмәсә, юл буена куркыныч вакыйгалар турында сөйләшеп килдек...

—Син нәрсә?!—Лена аның куенынннан арынды.—Өрәк чынлыкта юк иде. Ул безнең күзгә генә күренде дип әйтмәкчесеңме?

—Алай да булырга мөмкин...— Хәмит елмаюын яшерергә тырышты.

—Ул бөтенебезнең дә күзенә күренде бит...

—Ә мин күрмәдем,—диде Ләйсән.—Мин кешеләрнең үрле-кырлы сикерүеннән генә курыктым.

—Мин дә күрмәдем.—Хәмит елмайгандай итте.—Мин синең кычкыруыңны гына ишетеп чыктым. Ул вакытта өрәк юк иде.

—Ә мин күрдем.—Лена үз сүзләренә үзе ышанырга тырышкандай иде.—Мин күрдем. Өрәк бар иде. Хатын-кыз өрәге. Аның бөтен гәүдәсеннән тирә-якка яктылык тарала иде.

—Бәлки, аны бер син генә күргәнсеңдер...

Ләйсән пырхылдап куйды.

—Нәрсә көлеп торасың...—Лена Ләйсәнгә борылды.—Мине ялган сөйли дип уйлыйсыңмы әллә?! Яки, акылдан шашкан дип...

—Юк,—Хәмит тынычландырырга ашыкты.—Аны синнән башка да күрүчеләр булган. Без бит коридорда кычкырган тавыш ишеттек. Син ин беренче булып шунда ташландың. Һәм бераздан куркып кычкырып җибәрдең. Өрәкне синнән башка да күрүчеләр булган. Ләкин аны барыбыз да күрмәдек.

Бер мәлгә тын калдылар.

—Ул өрәк беркемгә дә зыян китермәде,—диде Лена бераздан.—Ул бары тик күренеп кенә узды. Үзенең барлыгын сиздерергә теләгәндәй. Әгәр өрәк кешеләрнең күзенә күренә икән, ул нәрсәдер әйтергә, кисәтергә тели. Шулай булмаса, ул бөтенләй күренмәс иде. Ә бу өрәк ни әйтергә теләде соң? «Икенче катта мин яшим, анда якын барасы булмагыз»—дияргә теләмәгәндер бит инде. Ә бәлки, ул безнең икенче катка менүебезне теләгәндер? Кайчандыр икенче катта ниндидер фаҗига булгандыр да, өрәк безгә шул хакта хәбәр итәргә телидер.

—Ярый, юк белән баш катырмыйк, Лена...—диде Хәмит һәм үзенең ник авызын ачуына үкенеп куйды.

—Нишләп юк белән баш катыру булсын. Безнең ике балабыз бар. Һәм иртәгә таң атканчы монда торасыбыз бар. Әгәр теплоход килеп җитми икән, бәлки, озаграк та торырга туры килер.

—Барсы да тәртиптә булыр, Лена...

—Булмый. Әгәр без өрәкнең ни өчен килүен, аңа нәрсә кирәген ачыкламыйбыз икән, бер нәрсә дә тәртиптә булалмый.

—Бөтен өмет синдә инде,—диде Хәмит ягымлы тавыш белән.—Минем «әлифба»дан соң китап укыганым юк.

Ләйсән көлеп җибәрде.

—Ә үзең мине тирги-тирги укыта идең. Беренче сыйныфларда. «Өчле» дә алганым булмады, имеш...

—Минем чынлап та «өчле» алганым булмады,—дип елмайды Хәмит.—Гел «икеле» генә куялар иде. Шаяртам, әлбәттә. Ләкин син миннән яхшырак укырга тиеш. Гомумән, балалар бездән яхшырак яшәргә тиешләр. Шулай булмаса, тормышның мәгънәсе югала. Әгәр син юкка чыгасың икән, димәк, әниең белән безнең гомер әрәмгә узган.

—Ярый, ярый, әти, аңлашылды. Без сезнең гомерегезне әрәм итмәскә тырышырбыз...

—Бу бик матур утрау,—дип үз уйларын дәвам итте Лена. Ул ата белән кызны ишетмәде дә шикелле.—Шушы утрауда кемдер бик матур йорт салып куйган. Ләкин ни сәбәптәндер, аны ташлап китәргә мәҗбүр булган. Мондый урынны, мондый йортны бер дә юктан гына ташландык хәлгә калдырмыйлар. Нәрсәдер булган монда. Ниндидер коточкыч хәл булган. Һәм өрәк безгә шул хакта сөйләргә телидер.

—Алай булмаска да мөмкин,—дип каршы төште Хәмит.—Мондый утрауда йорт салу өчен дә, килеп-китеп йөрү өчен дә зур акча кирәк. Димәк, моны төзеткән кеше бик бай булган. Заманында ул монда дуслары белән дә, үзе генә дә килеп ял итәргә яраткандыр. Ләкин бер мәлне ул ярлыга калган. Акчасы ни сәбәптәндер җилгә очкан һәм утрауга килеп йөрерлек рәте калмаган. Болай да булырга мөмкин.

—Ләкин ярлылана башлавын сизү белән ул әфәнде бу утраудагы йортын нindидер бай дустына сатар иде,—диде Лена иренен шул сүзен генә көткәндәй.—Бу бәләкәй нәрсә түгел. Зур гына акча китерердәй әйбер.

—Икенче төрле дә булырга мөмкин.— Хәмит тә бирешергә теләмәде.—Йорт хуҗасы картаеп үлеп китә. Ә балалары өчен бу утрау бернигә дә кирәк түгел. Сатарлар иде, акчалары житеш. Монда килеп йөрергә вакытлары да, теләкләре дә юк. Һәм утрау онытыла башлый, әкренләп кенә ул ташландык хәлгә килә.

—Алай булуы да мөмкин, әлбәттә. Ләкин өрәк?! Аны нәрсә белән аңлатасың?

—Элек-электән үк: «Ташландык йортларга җен ияләшә»,—дип сөйләгәннәр... Монда нindидер өрәкнең барлыкка килүе өчен фаҗига булу мөһим түгел. Хәтта безнең авыл очындагы Гайшә карчыкның өендә дә җеннәр бар икән диләр иде. Карчык үзе үлгәч, өй биш ел буе хуҗасыз торган. Биш ел буена анда адәм аягы басмаган. Ә төннәрен тәрәзәләре яктырып-сүнеп ала торган булган. Хәтта электр утын аерып куйгач та бу хәл дәвам иткән. Гайшә карчык диндар кортка иде. Аның йортында нindидер канкоеш, фаҗига булганын беркем дә хәтерләми. Шулай булгач, бу утрауны да фаҗига оясы дип карау дөрес булмый. Өрәк булсын өчен фаҗига гына кирәк түгел.

—Шулайдыр,—дип елмайды Лена.—Ләкин ул йорттагы җеннәрне беркем дә күрмәгән, шулай бит?

—Күргән кеше бар димиләр иде...

—Бу бары тик кешеләр сөйләве генә. Гайбәтнең бер төре. Һәм ул әлеге очрак белән берничек тә уртак була алмый. Минем укыганым бар. Өрәкләр бары тик фаҗига булган урында гына барлыкка килә. Хәтта алай да түгел, озак еллар буенча кешеләрнең теленнән төшми сөйләнерлек тетрәндергеч фаҗига булган җирдә генә. Әлеге фаҗига еллар үтү белән онытылмас легендага әверелә. Һәм ул көннән көнгә, елдан елга сөйләнелеп килә. Шул рәвешле әлеге вакыйгада катнашучыларның энергетик образы тулылана бара. Һәм шушы урынга эләккән һәрбер кеше, күнел тынычлыгын җую белән аларны күрергә мөмкин.

—Ә тиз онытылган фаҗигалар урынында өрәкләр булмыймы?

—Юк. Булмый. Өрәк—ул үткәннәрнең энергетик образы.

—Үткәннәрнеке генәме?

—Белмим. «Кешегә көн дә тиле дип торсаң, ул чынлап та исәрләнергә мөмкин»,—диләр бит. Кешенең көчле хис-тойгылары да өрәккә әйләнеп кемнеңдер күзенә күренергә мөмкин. Әйтик, әгәр син гомер буена матур йорт төзергә хыялланасың икән, ул йорт синең күзеңә күренә башларга мөмкин. Яки башкаларга күренергә, әйтик, мина. Хәтта алай гына да түгел, ул йортны син чынлап та төзергә мөмкинсең.

—Йорт төзергә?—дип елмайды Хәмит.

—Юк, йортны мисал итеп кенә алдым.—Лена аның шаяртуын аңламады.—Әйтик, синең кемгәдер бик хәтерең калган. Ул кеше сине чиксез рәнҗеткән. Һәм син аны берничек тә гафу итә алмыйсың. Гафу итәргә теләсәң дә. Акылың белән сабыр итсәң дә, күнелең белән аны шул гамәле өчен җәзаларга телисең. Һәм еллар буена шулай дәвам итә. Син хәтта үзең бу турыда уйламыйсың да. Бары тик аңастың гына теге кешегә җәза сорый. Шул җәзаны күз алдына китерә. Һәм еллар үтү белән синдәге җәзалау теләге өрәккә әйләнергә мөмкин. Өрәккә әйләнеп теге кешене җәзаларга. Син, әлбәттә, бу хакта берни дә белмәячәксең.

—Аңлап җитмәдем,—диде Хәмит.—Әйтик, мин сиңа бик рәнҗеп, кыйнап ташларга телим икән, минем шушы теләгем өрәккә әйләнеп, сине кыйный башлаячакмыни?

—Нәкъ шулай. Кешенең һәрбер уе, һәрбер теләге—ул энергия. Әгәр ул еллар буена кайдадыр тупланып, бикләнеп, кысылып килә икән, унайлы вакыт җитү белән, читлекне бәреп чыгарга һәм үзаллы тормыш белән яши башларга сәләтле.

—Ничек инде?..

—Машинанның камерасын күз алдына китер. Син ана һава тутырасын. Һава—ул энергия. Һава тутырган саен камера кабара. Ә син туктамыйсын, син тутыруынны дәвам итәсен. Һәм бер мәлне камера шартлый. Анын эчендәге энергия инде беркемгә дә буйсынмый. Ул иреккә чыга.

—Ул иреккә чыга да таралып бетә...

—Әйе. Һава таралып бетә. Ләкин шул һава урынында син ниндидер бер эшкә юнәлтелгән энергияне күз алдына китер. Ул һаваның һәр молекуласы, һәр атомы бер якка юнәлтелгән дип уйла. Мондый очракта ул таралмый, ә тыелгысыз бер көч булып хәрәкәт итә башлый.

—Карале, Лена...—диде Хәмит елмая биребрәк.—Ә син боларга үзең ышанасынмы?

—Минем ышану-ышанмау монда мөһим түгел. Китапта шулай язылган. Ә аны җитди тикшеренүләр нәтиҗәсендә язганнар. Хәтта без бернәрсәгә дә ышанмасак та хәл үзгәрми.

—Ләкин өрәкләрнең изге ниятлесе дә була. Сыер бозаулаганын хәбәр итүчеләр, мәсәлән...—Хәмит кинәт төртелеп калды. Анын күз алдына теге вакытта абзар артында булган хәл килеп басты. Ләйлә хәзер кайларда йөри икән? Авыл ирләре белән буталышканның икенче көнендә үк авылдан чыгып киткән, дигәннәр иде. Ләкин бу хакта уйларын ерак җибәрмәскә тырышты. Лена андагы үзгәрешне, әлбәттә, сизмәде. Анын үз уйлары иде.

—Изге өрәкләр дә була. Ләкин алар да бер дә юктан гына барлыкка килмиләр. Изге өрәкләр дә ниндидер куркыныч хакында хәбәр итү максатында күзгә күренәләр. Димәк, өрәк бар икән, сине нинди дә булса куркыныч хәл сагалый. Без әлеге өрәкнең ни теләгәнен ачыкларга тиешбез.

Ләйсән, гадәттә, әнисенең белдеклелегенә көлемсерәп кенә карый иде. Тик бу юлы аны җитди кабул итте. Әнисенең белеме анда ихтирам да, курку да уятты. Сөйләгәннәре хак булса, авыз ерып торырлык нәрсә түгел икән шул. Ә Ләис...

—Ләис никтер һаман кайтмый...—дип куйды ул.—Хәтсез генә вакыт үтте бит инде.

—Хәзер карап киләм...—диде Хәмит.—Ерак түгелләр...

—Юк, Хәмит.—Лenaның тавышы җитди иде.—Мин үзем чакырам аны. Өрәк күренсә, ни өчен килүен дә ачыкларга тырышырмын. Ә сез монда торып торыгыз.

—Ләкин...

—Берәр нәрсә булса, мин кычкырырмын,—дип елмайды Лена.—Уяу бул.

* * *

Анна салкын суда чылатылган тастымалны караватта яткан иренең башына урады да анын янына утырды.

—Һаман авыртамы? Эх, шул өрәкне...—диде ул ни әйтергә белмичә.— Өрәк күренмәгән булса...

—Юк,—дип бүлдерде Михаил.—Өрәк кенә гаепле түгел... Хәтта өрәк монда бөтенләй дә гаепле түгел. Эш утрауның үзендә. Мин моны беренче кат аяк басу белән тойдым.

—Нәрсә?..

—Әйе, бу утрауда ниндидер сер бар... Ул безне яратмый... Ул безнең китүне тели...

—Жаным...—Анна иренең башыннан сыйпады.—Бәлки, тагын дару эчеп карарсың?..

—Эчтем бит инде...

—Йокы даруы. Бәлки, тынычлап йоклап алсаң...

—Анна!.. Син мине сантыйлана башлаган дип уйламыйсыңдыр бит?!.

—Юк, кадерлем, юк.

—Бернинди дару да ярдәм итмәячәк. Эчкән даруларны санап кара. Мин күптән тынычланып, йоклап китәргә, һич югында авыртудан котылырга тиеш идем инде.

Анна дәшмәде. Иренең сүзләрендә хаклык бар иде.

—Менә шул... Даруларның бер файдасы да тимәячәк... Эш утрауның үзендә. Бу утрау безне яратмый. Ул безне күралмый. Ул безне куа. Һәм без тиз арада моннан китәргә тиешбез. Әгәр китмибез икән, барыбыз да һәлак булачакбыз.

—Ләкин...

—Юк, кадерлем... Хәер, син миңа ышанмыйсың...

—Ышанам, жаным... Тик син тынычлан гына...

—Ярый...—Михаил бер мәлгә тынып калды.—Ярый... Мин тыныч...

—Соңгы вакытта син тормышыңны бөтенләй диярлек үзгәрттең. Киеренке уйлар эчендә яшәдең. Сиңа ял итәргә кирәк, кадерлем.

Анна хаклы иде. Бәлки, чынлап та акылына көч тә килә башлагандыр. Михаил үзен кулга алырга, тынычланырга, йоклап китәргә тырышты. Аннаның куллары назлы да, шифалы да иде. Бераздан ир хатынының назлы бармаклары тәэсирендә чынлап та тынычланып калды. Бөтен тәне изрәп киткәндәй тоелды. Ул ниндидер рәхәт дулкыннарда талгын гына бәвелә иде. Тирә-якта тик яктылык кына, назлы җилләр чәчләреннән сыйпый. Баш очында ак болытлар ага. Кошлар сайрый, яфракларның серле шыбырдавы ишетелә. Рәхәт. Кинәт ул җилнең көчәя баруын тойды. Җил көчәю белән яфракларның шыбырдавы да ыграк ишетелә башлады һәм тоташ гүләүгә әверелде. Михаил күзләрен ачты. Баш очындагы ак болытлар юк иде инде. Бөтен тирә-якны каплап кара томан килә иде. Томан бар дөньяны каплап алды да, кинәт таралып җиргә төшеп китте. Аның эзләреннән төрле төстәге түгәрәкләр генә калды. Ул түгәрәкләр кинәйгәннән киңәя барып, зәңгәрсу төскә керде һәм бераздан зур суга әверелде. Су бөтен тирә-якны ялмап алды. Бөтен дөнья тик судан гына тора иде. Ләкин кинәт Михаил шул су уртасындагы кечкенә утрауны күреп калды. Күрде дә дертләп китте. Бу утрау аңа таныш иде. Шултиклем таныш. Утрау, әлбәттә, матур иде. Матур иде... Монда адәм кулы кагылган нәрсәләр сирәктер кебек иде. Шуның белән ул җир шарының яшь чагын хәтерләтә сыман иде. Җир шарының... Яшь чагын... Малай чагын... Ындыр артында бәбкәләр саклап йөргән малай чагын... Һәм әнисенең сүзләре яңгырап китә: «Улым!.. Ашарга әзер. Кайт!» Утрау үзе дә ерактан караганда ярымтүгәрәк рәвешендә... Ул бөтен булмышы белән сине үзеннән себереп ташларга тели. Ләкин моңа көче җитми һәм сабыр итеп түзәргә була... Әмма аның түзүе вакытлыча гына, ул түзми, ул сабыр итми, ул бары тик сине куып төшерерлек корал эзли. Һәм таба... Утрау ниндидер кодрәтне суырып ала. Ул тылсымлы чишмәдән су эчкәндәй, ниндидер чыганактан көч ала. Һәм коточкыч бер ерткычка әверелә. Ләкин ул ерткычлыгын сиңа күрсәтми әле. Ул сине яхшылык белән куарга тырыша. Һәм утрау уртасында томаннан яралган карчык пәйда була. Карчык. Бу карчык шултиклем таныш... Бу карчыкны аның кайдадыр күргәне бар... Тик кем икәнен генә хәтерли алмый.

—Кем син?

Карчык дәшми. Михаил тагын сорый:

—Кем син?

—Фәрештә,—дип елмая карчык, тешсез авызын кулы белән каплап.—Син беләсең мине... Хәтерләп кара әле. Мин онытмадым. Ә син? Син дә онытырга тиеш түгел идең... Син мине онытмаска тиеш идең... Син онытырга тиеш түгел идең...

—Мин сине белмим,—дип кычкыра Михаил курку катыш нәфрәт белән.—Кем син? Нигә әйтмисең? Мин сине кайдан белергә тиеш?

—Кил әле якынрак,—ди карчык, күзләрен майландырып.—Кил, мин сиңа кемлегемне әйтәм.

Михаил курка. Ул якын килергә теләми. Ләкин аның бик беләсе килә. Һәм ул карчыкка терәлеп үк баса.

—Йә, кем син?

Карчык кинәт елмаеп җибәрә. Аның иреннәре акрын гына ерыла... Ерыла һәм ерылудан туктамый... Иреннәре колагына җитә... Җилкәсенә... Киң ачылган авызында тирес кортлары күренә... анда бары тик кортлар гына мыжгып тора... Төрле төстәге кортлар... Һәм Михаил ул кортларның нәрсә эшләгәнен дә күрә. Алар кемнеңдер йөрәген кимерәләр. Вак-вак кына кабып. Ашыкмыйча гына. Һәм бер мәлгә Михаилны күреп, кимерүләреннән туктап, башларын күтәрәләр. Берсе күз кысып ала. Һәм Михаилның коты алынуын күреп, кычкырып көләргә тотына.

—Кем син?—дип сорый Михаил.—Кем син?

—Мин—синең гомерең,—ди корт һәм тагы да котсызрак итеп көләргә тотына, аңа башкалары кушыла. Һәм бөтен тирә-якта бары тик бер генә аваз яңгырап тора:

—Мин—синең гомерең!

—Мин... Ха-ха-ха!

—Синең!.. Ха-ха-ха!

—Гомерең!.. Ха-ха-ха!

—Китегез! Югалыгыз!—дип кычкыра Михаил.—Минем сезнең белән бер уртаклыгым да юк! Китегез! Югалыгыз!

Ләкин тегеләр аны ишетергә дә теләми. Һәм Михаилга ташланалар. Ир аларны өстеннән кагарга тырышып чәбәләнә. Әмма җитешә алмый. Кортлар хәзер аны сырып ала. Тешләүләреннән җан әрни.

—Михаил! Җаным!—дип кычкыра кортларның берсе.—Тынычлан, кадерлем! Тынычлан!

Ләкин ир тынычланырга теләми. Ул белә, аз гына тынычланып калдынмы, кортлар сине кимереп бетерәчәк.

—Тынычлан, җаным!..—Һәм кемдер аның яңагына суга. Михаилның күзеннән утлар күренә. Һәм шушы утлар ярдәм итә, кортлар яна башлый. Бераздан ул кортлардан тик көл генә кала. Ә теге тавыш һаман ишетелә.—Михаил, кадерлем, нәрсә булды синең белән!

Михаил күзләрен ачты. Анна елар чиккә җитеп аның өстенә иелгән иде.

—Кадерлем, син саташтың...—диде ул.—Син нык саташтың...

—Юк, җаным...—Михаил ни әйтергә белми иде.—Рәхмәт сиңа!..

—Бердәнберем... Мин сине шундый яратам...

—Мин дә...—Михаил тулысынча уянды.—Ә бәләкәч ни хәлдә?

—Ул йоклый...

—Уятмадыммы?

—Юк, син кычкырмадың... Бары тик чәбәләнден генә... Өстеңнән нииндидер кортларны куган кебек... Мин сине яратам, җаным. Мә су эчеп ал.

—Анна... Мин... Беләм...—Михаил кинәт сүзсез калды. Бер хәрәкәт тә ясамады. Хәтта тын да алмагандай тоелды. Анна бертын куркып күзәтте дә аның сулышын, йөрәк тибешен тыңлады. Ир тигез сулап йоклый иде. Анна да тынычланыбрак калгандай булды. Кинәт күрше караватта яткан бала тынгысызлана башлады. Анна аның янына күчте...

* * *

—Мин бер нәрсәне аңлый алмыйм,—Айгөлнең тавышында калтырану юкка чыккан иде инде.—Ни өчен кирәк икән соң бу аларга? Карап торуга, бик шаян кеше дә түгелләр бит инде. Үзен Андрей Николаевич дип, атасының исемен әйтеп таныштырган җитди адәм. Һәм кинәт...

Радик башын чайкап кына куйды:

—Белмим.

—Балаларның җәйге ял йортында шундый хәл булса, мин аптырамас та идем.—Айгөл капчык авызын ачып, тагы өрәк киеменә үрелде.—Әмма Андрей Николаевич һәм Ольга...

—Бәлки, алар да бик шук кешеләрдер,—дип елмайды Радик.—Теплоходта да ул күңелсез булмасын дип гел әкият сөйләп килде. Менә монда да нинди мажара уйлап тапканнар. Әгәр алар булмаса, без йокымсырап килер идек тә, бүлмәләребезгә кереп урнашкач, тагы йокыга чумар идек. Ә болай... Соңыннан көлешеп сөйләрлек истәлекләр кала. Ә Андрей Николаевич—ил гизгән адәм, вакытны ничек кызыклы итеп үткәрергә белә.

—Әти...—Айгөл өрәк киемен тартып чыгарды.—Син чынлап та шулай уйлыйсыңмы?

Радик дәшмәде. Ул, әлбәттә, болай уйламый иде. Икенче катта, өрәк күлмәге салынган капчыкны табалмагач, Андрей белән Ольганың ничек талашканын ул ишеткән иде.

—Бәлки, мин дә коридордан бер әйләнеп керермен?—дип елмайды кыз, күлмәкне өстенә ябынып.—Карале, ничек килешеп тора.

—Җитәр...—Радик кызына карады да куркып китте.—Сал ул күлмәкне. Әллә нинди зәхмәтле нәрсә булыр...

Айгөл күлмәкне рәтләп киде дә төймәләрен каптырып бетергәч, кулларын алга сузды:

—Мин—өрәк! Мин сезне өркетергә килдем!...

—Җитәр,—дип кабатлады Радик.—Котымны аласың...

Айгөл кеткелдәп куйды да ишеккә юнәлде.

—Мин сезне...

Шундый салкын тавыш белән пышылдаган җиреннән ул кинәт туктап калды. Бүлмә ишеге ачылып китте. Аннан нindидер хатын-кыз шәүләсе килеп керде дә бер мизгелгә генә катып калды.

—Әнкәй!—дип пышылдады керүче үз күзләренә үзе ышанырга теләмәгәндәй.—Аллакаем!

Һәм кинәт кычкырып җибәрде. Радик болай да берәрсе килеп кермәсен дибрәк шүрли иде. Ул шундук һушына килде һәм коты алынган хатынның авызын учлары белән томалады. Тавыш ишетелмәде.

—Лена, зинһар өчен тынычланыгыз һәм кычкырмагыз,—дип пышылдады ул хатынның колагына.—Тавыш куптарып башкаларны куркытырга кирәкми. Мин сезгә хәзер барсын да аңлатам.

Көтелмәгән хәлдән үзе дә куркуга төшкән Айгөл хатынның күз алдында ук өрәк күлмәген салып ташлады. Моны күргән Лененың күзләре мангаена менде.

—Коридорда күренгән өрәк барыбызны да куркуга салгач, мин икенче катка мендем,—диде Радик, кулларын һаман хатынның авызыннан

алмыйча.—Һәм баскыч төбендәге капчык авызыннан чыгып, ялтырап яткан менә шушы костюмны күрдем. Бу гадидән дә гади кием генә. Сез курыкмыйсызмы инде?

Хатын баш какты. Радик аны җибәрде.

—Безне, димәк, кеше куркыткан?—диде Лена.—Димәк, өрәк юк?

—Һәрхәлдә, безне куркыткан нәрсә өрәк түгел. Ә шушы киемнәрне кигән хатын.

—Кем соң ул?—Лена шикле карашларын Айгөлгә төбәде.—Кем ул безне куркытучы?

—Ольга.

—Кем?!

—Хәтерендәме, алар Андрей Николаевич белән икенче катка менделәр? Алар анда өрәк эзләмәделәр, ә менә шушы киемне эзләделәр...

—Ә ни өчен мин сезгә ышанырга тиеш?

—Белмим. Ләкин мин дөп-дөресен сөйлим.

—Мин сезгә ышанмыйм,—диде Лена, ишеккә атлап.—Ышанмыйм.

Ул ишек тоткасына үрелде дә кинәт туктап калды. Нәрсәнедер исенә төшерергә теләгәндәй уйланып торды. Аннан соң Айгөлгә төбәлде.

—Туктагыз әле... Ә минем улым кайда?—диде ул, үзалдына сөйләнгәндәй һәм бераздан Айгөлгә эндәште.—Сез бергә түгел идегезмени?

—Юк, кешеләр бүлмәгә таралышканда ул да кереп китте...—Хәзер Айгөл аптырап калды.—Туктагыз әле... Ләис өйдә түгелмени?

—Ләис?—Лена татарчага күчте.—Юк, ул өйгә кермәде. Ләйсән аны синең белән диде.

—Туктагыз әле...—Радик та татарчага күчте.—Сезнең улыгыз... Ә Айгөл бит күптән инде... Бәлки, улыгыз башка җирдә йөридер? Хәер, ул кайда йөрергә тиеш?!.

—Ә нигә сез аны шундук эзләргә чыкмадыгыз?—диде Айгөл ачуын яшерергә дә теләмичә.—Без аерылышканга хәтсез вакыт үтте бит инде.

—Мин аны синең яныңдадыр дип уйладым,—диде Лена аның кәефенә бөтенләй дә игътибар итмичә.—Егетләрне кызлар яныннан әниләре барып алмый ич...

—Гафу итегез...—Айгөлнең тавышы калтыранды.—Ләкин кайда йөри икән соң ул?

—Белмим...—Лена инде чыгарга борылган иде. Кинәт ул туктап калды.—Ә бәлки, ул чынлап та монда булгандыр?

Беркем дә дәшмәде.

—Юк, монда кермәде,—диде Радик бераздан.—Кермәде.

—Аны эзләргә кирәк.

—Бәлки, кирәкмидер дә?!.—дип Айгөлгә төбәлде Лена.—Бәлки... Мин сезгә ышанмыйм. Әле өрәк... Әле кеше югала...

Ул кинәт кузгалып чыгып китте. Шапылдап ябылган ишек тавышы Ленаның хөкем карары сыман тоелды. Кыска, көчле, аяусыз. Аның артында бүлмәдә урнашкан тынлык та кырыс хөкемдар төсле иде. «Минем улымның югалуына сез гаепле. Ничек кенә акланырга тырышсагыз да мин сезгә ышанмыйм»,—дип әйтә шикелле иде ул тынлык.

Тынлык озакка сузылды.

Бераздан Айгөл өрәк киемен кире капчыкка тыгып куйды да ишек төбендәге почмакка ыргытты. Радик су алып эчте. Аннан соң тәрәзәне ачып җибәрде. Бертын тышка карап торды. Колак төбендә черки безелди башлагач, ишек төбенә карап алды да тәрәзәне япты. Бәлки, капчыкны шуннан атып бәрергә генәдер? Ләкин бу котылу юлы түгел иде. Әгәр Ләис чынлап та югалган икән, димәк, коточкыч хәлләр башланган дигән сүз.

Айгөлне күз уныннан ычкындырырга ярамый. Ләис урынына аның кызы да югалырга мөмкин иде бит. Хәер... Бәлки, берәр жирдә нәрсәдер эзләнеп кенә йөридер. Радик үзе дә бер мәлгә юкка чыгып торды бит... Кинәт ул американлылар хакында исенә төшерде. Кичтән бирле күренгәннәре юк. Алар кайда икән? Бәлки, алар да...

—Әти, Ләисне эзләргә кирәк...

—Әйе, кызым...

Тагын тынлык урнашты. Бераздан Радик ишеккә атлады.

—Син кайда, әти?

—Хәзер керәм, кызым... Хәзер...

—Мин куркам...

—Курыкма. Мин озак тормыйм. Американнарга гына күз салып чыгам.

—Озак торма...

Әтисе чыгып киткәч, бер мәлгә генә бүлмәне шом басты. Күзгә күренмәс куркыныч бөтен тәнеңне кысып аладыр, сулышларыңа уралып эченә үтеп керәдер сыман тоелды. Ләкин бу халәт озакка бармады. Кинәт Айгөл һушына килде һәм аның аңында бары тик бер генә уй дулады. Ләис юкка чыккан! Әлбәттә, егет, бәлки, кайдадыр тоткарланып кына торадыр. Алай да булуы бар. Әмма Айгөлнең күңеле моңа ышанмады. Ләисне күрмичә, аның куркыныч хәлдә түгеллегенә ышана алмый иде ул. Хәзер дөньяның бөтен котсызлыклары да артка чигенде. Ләисне югалту афәте янында алар бик кечкенә иде.

Кыз коридорга атлады.

*Ахыры киләсе санда*

---

*«Казан утлары»на – 90*

**«Безнең юл»**



Журналыбыз «Безнең юл» исеме белән 1922-1930 елларда дөнья күрә.

Журнал чыгаруда җаваплы кешеләр:

1922 елның 1-7 саннарында җаваплы мөхәррир — Гасыйм Мансуров. 8-9 саныннан 1924 елның 12 санынача — мәсьүл (җаваплы — ред) мөхәррир — Мидхәт Бурундуков.

1925 елның 1-5 саннарында — редакцион коллегия; 6 санда — редакцион коллегия рәисе Галимҗан Ибраһимов, 7-12 саннарында — редакцион коллегия. 1926 елның 1-9 саннарында — редакцион коллегия, 10 саныннан — 1928 елның 2 санынача — редактор: коллегия.

1928 елның 3-4 саннарында редактор — редколлегия: Гомәр Галиев, Шәриф Камал, Гомәр Толымбайский, Хәсән Туфан, Габдрахман Сәгъди (5 санында редколлегия исемлегендә Х.Туфан юк), 11-12 саннарында журнал гарәп һәм латин имласында чыга.

1929 елның 1-8 саннарында редколлегия исемлеге — шул ук. 9нчы саныннан 1930 елның 3нче санына кадәр — редактор: редколлегия.



Салисә
Гәрәева

# МОҢНАРДАЙ ТАШЫЙ КҮҢЕЛЕМ

## Мин бу җирдә калам

**Мин бу жирдә мәңгелеккә калам,
Аерылса да тәнем:
Чөнки монда җаным чәчәк атты,
Тойды тормыш ямен!..**

**Ташларында эзем, юлларында.
Суларында агам.
Җилләрендә чәчем җилфердәтәм,
Утларында янам.**

**Мин бу җирдә мәңгелеккә калам, —
Әбәт яшәр өчен.
Килер буыннарга үз телемдә
Сөеп дәшәр өчен!**

**Мин бу җиргә бакый чит-ят түгел,
Аерылса да тәнем:
Мин тулаем эчтем җаным белән
Бөек Урал ямен!..**

## Кояш тотылганда

*2009 елның 22 июлендә кояш
тулаем тотылды. Аны Ай каплады.*

**Искәртүме, әллә кисәтүме? —
Ай каплады Кояш табагын.
Шомлану һәм курку тоеп, кинәт
Кысылды да калды тамагым.**

---

Салисә ГӘРӘЕВА – *шагыйрә; «Уралым», «Тау сукмагы», «Йолдыз яңгырлары» һ.б. китаплар авторы. Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Һ.Такташ исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Тынды Дөнья. Караңгылык төште.
Исеп куйды җилнең кискене.
Кеше кебек, курку–шомланудан
Сискәнгәндер Җирем–мескенем.

Алты минут алты сәгать кебек
Бик озын һәм шомлы тоелды,
Кояш йөзен кап–карага манып.
Каралып, Ай аңа сыенды!

Тәңгәл килде ике алтын табак:
Йөзгә–йөз һәм күзгә–күз алар!
Галәмнәрдә, Җирне тетрәндереп.
Кара–каршы сыенып торалар...

Борынгыдан Кояш, Ай тотылу
Җир галәмен сала куркуга:
Галәмдәге Бөек Бердәнбер Көч
Җиргә карап торган күк була!

Нәрсә юрый?Ниләр вәгъдә итә?
Соңгысымы әллә гасырның?!
Хыял, өмет, дәртләр–теләкләрнең
Ашкынуын тыеп, басылдым.

Ике мең ел үткәч, бәлки, Кояш
Ае белән кабат тотылыр?
Барып җитәрбезме? Җир–Анабыз
Афәтләрдән ничек котылыр?!

## Тарихтан нәгърә

Шигърият — Тарихтан нәгърә,
Язмышлар чагылышы.
Ул — акылсыз сәясәтнең
Ватанга кагылышы...

Ул — сугыш, талау, ярлылык,
Түрәләрнең ялганы.
Бу юлы да — элеккечә:
Ничә кабат алдады!..

Шигърият — Табигать өне,
Тансык ел фасыллары;
Ул — йөрәктә урын алган
Бердәнбер сөйгән ярым.

Ул — мәчет манарасында
Балкыган алтын урак!
Ул — Ватан! Мин Илгә кайтам,
Ерак юлларны урап!..

Җил уйнаткан пәрдәләр ул,
Китаплар — киштәдәге;
Бүген дә...Галәмнән иңгән
Моңнарны ишетәм әле!..

Ул — баламның елмаюы,
Халкымның нурлы йөзе!
Шигърият — Илаһи сер ул,
Моңнар чишмәсе — үзем!..

## Яңгыр яуганда

Тансык була яңгыр корылыктан
Ярылганда туфрак, көйгәндә.
(Бу кадәр дә сөенечле булмас
Сөйгән белән кавышу сөйгәнгә!)

Агачларым талгын рәхәтлектә,
Зифа буен гөлләр игәннәр:

Гүя алар тансык тамчыларга,
Оялышып, «рәхмәт» дигәннәр!

Тамчыларны җыям учларыма, —
Бармак арасыннан су ага...
Гомеребез дә Галәм өчен — тамчы,
Охшап тора аккан суларга.

Бие, яңгыр!
Ян, ялтыра, яшен!
Күк күкрәсен, болыт үтәли.
Җылы яңгыр, тансык җәйге яңгыр
Күңелләрне ача, иркәли.

Яшен уза болыт үтәли!

## Камыш

Кара башлы яшел камыш,
Кыяк чыжлаган тавыш.
Камышлар пышылдый кебек:
—Исмә, Җил! Очма, Сагыш!..
Камыш чыжлаган тавыш...

Кыяклар яшел иде дә,
Тирбәлеп яшим, диде.
Камышлар бирде тавышын:
—Дулкынга дәшим! — диде.
Кыяклар яшел иде...

Болгана су, кага дулкын.
Ява яңгыр. Су салкын.
Җилдә чайкалган камышның
Сагышы җанга якын
Яңгыр ява, су салкын!..

Кара башлы яшел камыш.
Үрдәк кычкырган тавыш,
Моңнардан ташый күңелем, —
Кагыла күрмә ялгыш!

...Исмә, Җил! Очма, Сагыш!..
Үрдәк кычкырган тавыш...

## Ислам дуслыкка илтә

Явызлык, коллык дөньясы
Ислам динен сытмакчы.
Әһле исламны чүктереп,
Аның йөзен ертмакчы.

Комсызлык, масаю, канга
Сусаулар йөртә аны.
Ә Ислам дине дуслыкка
Илтә бөтен дөньяны!

Без — гаделлек мөритләре,
Эчебез–тышыбыз пакь.
...Кем белән син?
Кыйблаларны
Турылап, җилкенер чак!..

## Җәй сүрелә...

Җәй сүрелә.
Бушап калды ярлар.
Комнар кеше эзен сагына.
Торкылдашып,
Торна төркемнәре
Күл өстеннән читкә агыла...

Шиңә үлән.
Гөлләр орлык коя.
Авырая дулкын күлләрдә.
Безгә кала
Дулкын белән бергә
Җиргә имин көзләр теләргә.

Алда көзләр,
Язлар чират тора
Фасыллар һәм илләр алдында.
Киләчәгем —
Томан артларында,
Үткәннәрем истә, аңымда.

Көз сарыга мана үләнне,
Без көтәбез язлар килгәнне...

## Дәртем утлы

Ак канатлы
Илһам фәрештәсе
Иңде минем өйгә:
Ят аһәңнәр иңде аның белән,
Аңлашылмас көйләр!..

Борчып җанны, сүзләр кайнадылар,
Юл эзләде фикер!
Йөрәк әйтте:
—Парнас түбәсенә М
ен, Пегаска сикер!..

Дәртем утлы.
Шул тау түбәләрен,
Ах, бер күрсәм иде!
Гади, тыйнак татар сүзләренә
Тылсым үрсәм иде!..



Илүсә
Нәбиуллина

# БОРЫЛЫШ

ХИКӘЯ

Әле яңа гына көн башлануга да карамастан, тышта көннең кай вакыты икәнен дә чамаларлык түгел. Болытлар бөтен күк йөзен каплап алган. Кояш күптән баткандыр да, ул бүтән калыкмас кебек. Өскә салкын яңгыр ява. Җир инде сеңдерә алган кадәр суны күптән сеңдергән, хәзер су асфальт буйлап, ашыкмый гына, юлда очраган чүп-чарны да ияртеп, каядыр ага. Бу шыксыз вә юеш, ямьсез көндә урамга чыгарга мәҗбүр булган адәм балалары салкыннан күшегеп, муеннарын якаларына яшереп, бераз иелә төшеп, ашыга-ашыга үз юллары һәм мәшәкатьләре белән каядыр атлыйлар.

Яңгырлы көн дә табигать мизгеле.

Салкынмы, җылымы, язмы, көзме – тормыш барыбер дәвам итә.

Газиз Камалов менә инде кайчаннан бирле тәрәзә янында баскан килеш. Зал тәрәзәсе каршында гына автобус тукталышы. Панорама зур һәм андагы күренеш-вакыйгалар гел алышынып кына тора. Кемдер автобуска житешергә дип йөгерә; житешә алмый, кулларын һавада бутый-бутый автобус йөртүчене тирги; кемдер төшеп кала, кемдер утырып китә. Газиз исә үзен урамдагы кешеләрдән бәхетлерәк хис итеп, тышка карап, уйланып тора. Аңа рәхәт, бер җиргә барасы да, яңгырга чыланып күшегәсе дә юк. Фатир эче тыныч, җылы. Өч бүлмәгә дә ял көннәрендә генә була торган тәмле ис таралган. Аның фатир дип аталган илендә иминлек.

Ә тышта салкын яңгыр ява.

Көзге салкын яңгыр, кемгәдер ачулангандай, тәрәзәгә бәрә. Әйтерсең лә тышта калган юлчы җылы фатирга кертүенне үтенә. Шык, шык.. Юк, Газизләрнең тәрәзәсенә яңгыр астында калган юлчы берничек тә шакый алмый, алар биш катлы йортның өченче катында яши.

Тәрәзә каршында йорт биеклегендә тирәкләр үсеп утыра, алар җил көченә түзә алмыйча бөгелә, агачларның ботаклары тәрәзәгә кадәр килеп җитә, коелып бетә алмаган яфраклар тәрәзәгә бәрелә. Җанны күңелсез уйлар били

---

Илүсә НӘБИУЛЛИНА – *прозаик; «Миләш тәме», «Җанкаем», «Бәхет утравы», «Кояш булэк итәм» дигән китаплар авторы. Әлмәттә яши.*

башлаганчы дип, Газиз тәрәзә яныннан тизрәк китү ягын карады.

Яңгыр шыбырдаганы җанга тия, эре тамчылар калай тәрәзә төбенә шулкадәр каты килеп төшә ки, ул гел башка сугып торган кебек шакылдый: тып та тып, тып та тып. Юк, салкын яңгыр тамчылары гына күңелне суыта алмас.

Фатир эчендәге рәхәтлек, пешкән ит, кызган май, камыр исе бөтен дөньяны оныттырырлык. Көне буе газ өстендә һәм мичендә нидер пешеренгәч, фатир эче тәмам җылынган. Һавада бәйрәм һәм шатлык тулы ис. Менә шул тәмле ис күңелне төшенкелеккә бирелүдән саклый, борын эчләрен кытыклап, җанны иркәли. Әлеге рәхәтлекне, ләззәтне тыштагы салкын яңгыр, җил генә бетерерлекме соң...

Бүген ял көне булгач, Газизнең хатыны Зөлфия иртәдән бирле кухня тирәсендә бөтерелә. Иртән коймаклап чәй эчергән иде, менә хәзер бөтен фатир эчен бәлеш исе тутырды. Оныклар белән балалар килер дип аерата нык тырыша ул. Газиз тыштагы гарасатны күзәтә-күзәтә хатынының җылы кухняга тизрәк бәлеш ашарга чакырганын көтә.

Тамак тәмугка кертә, дисәләр дә, әлеге сүзләр хәзерге яшь буын өчен әйтелмәгән. Хәзерге яшьләр башка. Әлеге әйтемне кайбер яшьләр аңлап та бетермәс. Хәзер яшьләрнең тамаклары тук, өсләре бөтен, сугышны һәм ачлыкны алар китаптан укып, кинодан карап кына беләләр.

Мондый төксе көндә балалар бәлеш дип җылы фатирларыннан чыкмаячаклар. Шулай да өмет дигән нәрсә бар әле. Газиз, балалар киләсе чаттан күзен алмый. Зөлфия дә үз ягында, иренә сиздермәскә тырышып, әледән-әле урам якка күз ташлый, өметләнә, болай да атна буе вакыт юкны сылтау итеп, телефоннан гына шалтыратып хәл белешәләр. Чакырмыйча гына, ял көне дип, хәл белергә килсәләр була бит инде. Әниләренең дә, әтиләренең дә күңелләре булыр иде. Шул-шул: ана күңеле балада, баланыкы —далада, дип белмичә әйтмәгәннәр.

Чама белән бәлеш инде пешкән булырга тиеш. Зөлфия һаман кухнясында нindidер эш тапкан булып кайнаша, вакытны суза. Бәлеш янына аның тагын әллә никадәрле тәмле ризыгы була. Тәмле-татлылар оныклар өчен.

Уй кем өстеннән хакимлек итә? Ямьсез уй, билгеле инде, вакыты күп булган һәм эшсез кешене баса. Газизнең дә бүген вакыты күп, эше дә юк. Шәһәр фатиры эшләп үскән авыл малаен да көннәр буе сузылып диванда ятарга өйрәтте. Ике-өч көнгә бер чүп түгүне, атнага бер тапкыр, ял көнендә, тузан суыртуны исәпкә алмаганда, Газизнең эше юк иде. Бүген дә менә шулай.

Газиз үзе әтиле килеш ятим үсте. Ике абыйсы сугышка кадәр туып калганнар. Ул әтиләре сугыштан әйләнеп кайткач туган бала. Әйе, Газиз сугыштан кайткан яралгы. Сугыштан соң туган бала булса да, ул ятим үсте. Менә шунысы бигрәк йөрәкне өзгәли дә. Әтиең яу кырында ятып калса бәлки ана яшәү җиңелерәк тә булган булыр иде.

Ана яшь ярым булганда әтиләре авылга килгән яшь фельдшер кыз белән авылдан чыгып киткән. Шул китүдән ул кайтып күренмәгән дә. Исәнме, юкмы икәнен дә белүче юк. Авылда әтиләренең туганнары да калмаган. Әнисе, аларның әбиләре булган карчык, улын сугыштан көтеп ала алмыйча, Җиңү көннәре якынлашканда гына гүр иясе булган. Әтисенең, өч малаен исәпкә алмагач, авылга сагынып кайтып күрер кешесе юк иде.

Абыйлары ничектер, Газиз исә әтиләре сугышта үлеп калган балалардан көнләшеп үсте. Аларга фронтовик балаларына дигән ярдәм дә, һич югы җылы сүз генә дә эләкмәде. Тамаклары икмәккә түгел, бәрәңгегә дә туймаган көннәре күп булды. Ике абыйсының канаты астында үскәч, башка малайлар ятим дип бик кага алмадылар алуын. Шулай да ятимлекнең ачысын аны

ятимнәр генә белә. Ятимлек дигән зәхмәт синең йөзеңә чыга. Ул синең атлап йөрешеңдә, үз-үзеңне тотышыңда, сөйләшүеңдә була. Ятимлекне син юып та, икенче кием киеп тә бетерә алмыйсың. Ул синең җиде кат тиреңөстенә сигезенчесе булып, ябешеп йөри.

Сугыштан соңгы авыр еллар. Газиз үзен белә башлаган иде инде. Ниндидер бәйрәм уңаеннан әниләре чуен бәлеше пешерде.

Бәлеш пешерергә оннары да юк иде. Әниләре кемнәндер бурычка кечкенә генә кисәк ит алып кайтты. Шөкер, егерме сутый бакчада бәрәңге уңа иде. Ул елны да бәрәңге уңды. Язга таба бәрәңге санаулы булса да, көз-кыш аның саны-исәбе булмый. Күп итеп бәрәңге турадылар. Ит белән суган да кушып, чуенны мичкә тыккач, өй эченә түзеп булмастай тәмле ис таралды. Вакыт үтми генә. Әллә соң миче сүрән булганмы? Нигә соң шулкадәр озак пешә ул бәлеш? Малайларның баш миен әнә шундыйрак сораулар бораулый.

Ә әниләренең йөзе кояш кебек балкый, бит алмалары кызарып тора, яшәреп, тагын да матурланып киткән. Ул мич белән өстәл арасында очынып кына йөри. Тәмле ризык пешеренүе, аны әтиләре белән яшәгән сугышка кадәр имин, мул елларга алып кайткандыр. Шушы мизгелләрдә генә булса да иренең хыянәтен онытып торгандыр. Мәхәббәттән туган улларына тәмле ризык ашата алуына куангандыр.

Әтиләренең өч малайны калдырып яшь хатынга чыгып киткәненә дә инде байтак. Тормышның авырлыгын, корсакның гел буш булуын сөйләп бетерерлек кенә түгел. Уйласа, Газизнең хәзер дә күзләренә яшь килә. Чуен бәлеше тәмле булгандыр. Аны ашаганнары ул кадәр хәтердә дә калмаган, әмма пешкәнен көтеп торуы йөрәккә үк уелган.

Газиз кухня ягына колак сала-сала залда утыра. Вакытны бераз булса да алдамакчы булып, телевизорны кабызды. Анда да балачак хатирәләрен оныттырырлык бернәрсә дә юк. Кайсы гына каналга борсаң да йә сугыш, йә шәрә кызлар.

Хатыны Зөлфия гел көтмәгәндә эндәште. Ул залга килеп чыкты да:

—Газиз, Зарифҗанның хәлен белгәнең бармы? —дип сорап, сискәнеп китәргә һәм бүгенгегә кайтырга мәҗбүр итте.

— Нигә алай дип сорап куйдың әле?

—Теге атнада ук урамда Наташаны очраткан идем, Зариф авырып ята, хәле бик авыр, диде.

—Нәрсә булган? Хәлен барып белү түгел, бу араларда гына шалтыратканым да юк.

—Шалтырат, нигә шалтыратмыйсың соң?

—Соң... Теге бит... Вакыт...

—Вакыт, имеш, вакытыңа ни булган? Көннәр буе телевизор каршыннан китмисең. Шалтыратып, кешенең хәлен белергә ярты минут вакыт җитә.

—Җитә, —дип килеште Газиз хатыны белән.

—Зарифҗан бит ул синең иң якын дустың, алай гына да түгел, авылдашың.

—Дустым, —дип кабатлады Газиз янә хатыны артыннан. Үзен үтә гаепле хис итте. Болай авыз эчендә ботка пешерүе үзенә дә ошамады. Ни әйтергә дә белмичә хатынына карап тора башлады.

—Нигә миңа шулай карап торасың?—диде Зөлфия, бераз үртәлеп.

—Наташадан сорамадыңмы, Зарифҗанга ни булган соң?

—Сорамадым. Авырый дигәч, авырыйдыр. Ни булганын, бар, үзең белеш.

Хатыны: «Мин белгән кадәрен сиңа әйттем, калганы синең эш», дигән кебек кулларын җәеп, иңсәләрен сикертте дә, ирен беренче сыйныфта,

дәресен әзерләп килмәгән баланы тиргәгән кебек унайсыз хәлдә калдырып, тагын кухняга юл тотты.

Гомергә булмаган хәл. Газизгә генә шулай тоелдымы, хатыны аның белән бик кискен-коры сөйләште. «Балалар килмәгән ачуны миннән ала», — дип, Газиз хатынына чын-чынлап үпкәләп куйды. Шулай үз-үзен бераз юатты.

Газиз дә, Зарифҗан да авылдан еракта, Казан каласында ук, бер институтта укыдылар. Икесенә дә, өйләнгәч, бер шәһәрдә эшләргә насыйп булды. Дөрес, Газиз башта юллама белән шәһәрдән еракта, авылда эшләде. Шулай да аларның сукмаклары озак вакытларга аерылмады, гел кисешеп торды.

Нужа дигән авыр арбаны тартып барганда Зарифҗандай кеше булу үзе бәхет иде. Тормыш үзе әчеле мунча булса, аның арбасы ай-һай авыр бит. Әле тәгәрмәчен берәр жиргә килеп төртелә, әле камыт бавы өзелә, әле тәртән сына. Менә шул вакытта ышанычлы ныклы дус кирәк тә инде. Зарифҗан шундыйлардан иде.

Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк гомер итәргә...

Авылдашларга эш буенча да гел аралашып яшәргә туры килде. Бер тирәдәрәк өйләнешкәч, яшь гаиләләр буларак та уртаклыклар күп иде. Ирләре авылдашлар булгач, хатыннар да тиз танышып, дуслашып киттеләр, балалар да бергәрәк үсте.

—Ярый, бүген барып кайтырмын. Барыбер өйдә утырасы килми, менә бераз янгыр гына туктый төшсен, —диде Газиз, ниһаять исенә килеп.

Аның сүзен ишетүче булмады. Бу вакытка хатыны залдан күптән чыгып киткән, кухняда бәлеше белән мәш килә иде, шуна иренең әйткәнен ишетмәде дә.

—Чыкты, уйларымны бүлде. Тет итеп тиргәде дә, чыгып та китте, хатын-кыз димәсән, хәтере калыр... —дип үзалдына сөйләнде Газиз.

Аның хатынына булган үпкәсе бетмәгән иде әле.

—Белермен. Бүген үк барырмын да, барысын да белешеп кайтырмын, —Газиз тиз генә тынычлана алмады.

Ә янгыр аны үртәгән кебек отыры көчәя бара. Жил тәрәзә төбендәге, балкон өстенә каплаган калайларны йолкып шыгырдый, ыңгыраша. Коеп яуган салкын янгыр да, жил дә түгел, нәкъ менә шушы калай тавышы күнелгә шом сала, тыштагы хәлләрне берничә тапкыр көчәйтеп өркетә.

Менә шушы тавышларга колак сала-сала, тыштагы хәлләрне күзәтә-күзәтә тәмам туеп, Газиз инде ничәнче тапкыр кухняга сәяхәт кылды. Бәлеш ашарга утыртучы юк. Бу —нindидер тәмле ис белән газаплау ысулы. Ул хатынын да анлый, аның балаларга кайнар бәлеш ашатасы килә. Ә алар йә киноги китkәннәрдер, йә дусларына кунакка, аларның әниләре белән әтиләре гамьнәрендә дә юк. Яшьлек ул бер генә. Аның өчен начар һава торышы да, салкын жил дә, янгыр да киртә түгел.

Балалар килмәделәр. Ярый әле шалтыратып нindидер базада ял итүләрен әйттеләр. Көтеп-көтеп тә ни килен белән малай, ни кияү белән кыз күренмәгәч, бәлеш ашарга утырдылар. Табын янында сүз ялганып китмәде. Хатыны балаларны, оныкларын уйлады, ә Газизнең уйлары аны кабат-кабат Зарифҗанга алып кайтты.

Ул көнне Газиз якташы янына соң гына, янгыр туктагач, өйләрдә ут алынгач кына барды. Инде тышта каранғы булуга да карамастан, якташы өйдә үзе генә булып чыкты. Зарифҗан дусты фатир ишеген ыңгыраша-

ыңгыраша килеп ачты да, кул биреп исәнләшкәч, ыңгыраша-ыңгыраша янә урынына барып ятты. Хәле авыр булуы хактыр, күрәсең. Ачык йөзле, кин күңелле Зарифҗан җитди сәбәпсез кунакны болай каршы алмас. Бүген хәл гел башкача. Фатирда үлем тынлыгы. Салкын. Тәмле ризык түгел, гомумән, нидер пешкәне сизелми.

Почмактагы тәре бүген аерата тасраеп, чекрәеп Газизгә карап торган шикелле тоелды. Тәрене килгән саен күрсә дә, ана тыныч кына карый алмый ул. Караган саен тәне буйлап салкынлык йөгерә, бала йоннары кабара. Наташа үз динен тота, аны яхшы белә һәм төгәл үти. Ул бөтен йола-бәйрәмнәрне җиренә җиткереп башкара.

Хуҗаның төсе качкан. Сүзе дә бакый дөнья тирәсендә генә. Тәмам үләргә җыенып беткән.

Зарифҗан Газиздән ике яшькә генә олы. Икесе дә пенсия яшенә якынаеп киләләр. Пенсиягә чыккач кешенең икенче сулышы ачыла, яңа тормыш башлый диләр. Зарифҗанга карагач моңа бер генә дә ышанасы килми. Күңеле тәмам төшеп беткән авылдашының.

—Табиб чакырттыңмы соң?

—Чакырттым.

—Больничный алдыңмы соң?

—Алдым.

Сүз ялганып китә алмады. Газиз: «Хәлең ничек соң?», «Дарулар эчәсеңме, файдасы тияме?» кебегрәк берничә дежур сорау бирде, авылдашы исә ыңгыраша-ыңгыраша гына җавап кайтарды.

Наташа өйдә юк иде. Кая булыр ул. Вакыт та соң бит инде. Газиз килгәннән бирле үзен борчыган сорауны бирәсе итте:

—Наташа үзе кая соң ?

Зарифҗанның йөзе чытылды. Ул лимон капкандагы кебек авызларын кыйшайтып, әче итеп елмайды. Кысылган иреннәре арасыннан гына берничә сүз сытып чыгарды:

—Аның кайда икәне билгеле инде.

—Миңа билгеле түгел.

—Кара шәлен ябына да, чиркәвенә чыгып китә...

—Алай...

—Көн дә шулай. Соңгы вакытларда бигрәк диңгә бирелде, өйдә торганы да юк.

Газиз авыру кеше белән килешеп, аның сүзләрен җөпләп кенә утырасы урында:

—Соң аның да үләсе бар инде! – дип әйтеп салмасынмы, югыйсә алай уйламаган иде бит, Наташаның өйдә булмаганын хупламаган иде.

—Анысы шулай инде, – дигән булды авылдашы, аның дусты әйткән сүзләрдән тәмам кәефе төште.

—Һәр кешегә үз дине, әнә бит синең дә «Аятел-көрси»ең янында гына ята.

«Телем – дошманым», —дип, Газиз ул сүзләрне шунда ук ник әйткәненә үкенде.

Чир белән бетерешкән, ялгызлыктан гаҗиз булган дусты эндәшмәде. Ул, дөрес сүзгә җавап юк, дигәндәй кулларын гына җәйде дә, башын селкеп куйды. Караңгы йөзе тагын да ныграк караңгыланды.

Алай әйтергә кирәк түгел иде. Сүз үрчетә, бәхәсләшә торган чакмыни. Болай да күңеле төшкән авыру кешегә шулай дип кем әйтә инде. Җүләр баш. Авылдашының күңелен күтәрердәй, һич югында юатырдай, авыруын оныттырырдай сүз табарга иде бит.

Ике арада урнашкан авыр салкын тынлыкны нинди генә сүз әйтеп тә

жылытырлык түгел иде инде. Ни китәргә, ни тагын бераз утырырга белмичә, Газиз бераз аптырап торды да, кайтырга кузгалды. Ах-ух килеп, кешене түгел, үз-үзен дә сөйми яткан Зарифҗан кунагын үгетләп тормады.

—Ярый, мин китим инде, — дип, Газиз урыныннан калкыну белән, ул да урынынан торды, ишеккә кадәр озата килде.

Чыгып китәргә ишек тоткасына тотынгач кына Газиз үзе алып килгән, кергәч тә ишек төбендәге тумбочка өстенә куйган букчасын күрде.

—Бәй, онытып та торам икән. Зөлфия бит сиңа тәм-том төяп җибәрде. Син ярата торган тозлы кыяр, помидор, кәбестә. Авызыңа тәм керер. Бәлеш суынгандыр инде, анысын җылытып ашарсың.

—Нигә шул кадәр күп алып килдең. Әле гел юньләп ашаганым юк. Рәхмәт инде. Зөлфиягә дә рәхмәтемне җиткерерсең.

—Җиткерермен.

—Хәл белүең өчен рәхмәт.

—Наташага сәлам әйтерсең.

—Әйтермен, әйтермен.

Бер төшкән кәеф күчтәнәчләрне тапшырганда да, урамга чыккач та күтәрелмәде.

Җил тынган, яңгыр туктаган. Подъезд ишегеннән чыгу белән кичке салкын һава Газизнең күлмәк, плащ якасыннан муенына кереп тулды. Күңелсез уйларына бирелгән ирне салкын һава да айныта алмады.

Юл буе ул үзенең турысын әйтә торган гадәтен, кирәк чакта телен тыеп кала белмәвен тиргәп кайтты. Хәл белергә барды, янәсе, кешенең авырткан җиренә кагылып, җәрәхәтен яңартты. Тьфү.

Һәрнәрсә, һәр гамәлең өчен түләргә кирәк диюләре шушы микәнни?

Зарифҗан әнисенең хәер-фатихасыннан башка өйләнде. Аның рус кызына өйләнәсен ишеткән әнисе: «Марҗа киленне өемә кертәсем юк», —дип пыр тузды. Шулай әнисе бик каты торгач, Зарифҗан өйләнүнең беренче елларында авылга да кайтмады. Улының әлеге эшенә рәнҗегән әнисе дә аларга килмәде. Зарифҗан хатыны белән, балалары туып, шактый вакыт узгач кына әнисе янына кайтты. Вакыт узгач, әнисе күрәчәге белән килеште, ләкин киленне үз итмәде. Наташа да Зарифҗанның әнисе өчен егылып китмәде. Ул кемгә кияүгә чыкканын белсә дә, санлашырга теләмәде. Утыз елга телне түгел, һич югы «әни» дигән сүзне генә дә өйрәнмәде.

Зарифҗанның Наташаны ярату көчле идеме, белмим. Ул хатыны кылган гамәлләргә бер генә дә сүз әйтмәде. Наташа ни эшләсе килсә, шуны кыланды. Балалар тугач та аларны чиркәүгә алып барып чукындырды. Муеннарына тәре тагып куйды. Әни кешегә ни әйтерсең, аның да үз дине. Боларга каршы Зарифҗан ни ак, ни кара дип бер сүз дә әйтмәде. Зарифҗанның әнисе генә: «Шул балаларны кочагыма алып ярата да алмыйм, иң элек күзем муеннарындагы тәрегә төшә дә, тәнем эсселе-суыклы булып китә», —дип сөйләп йөрде. Әниләре татарча белмәгәч, өйдә татарча сөйләшмәгәч, балалар да татар фамилияле урыс кызы белән урыс малае булып үсте. Аларга рус теле — ана теле булды. Яшьрәк чакта мондый гына вак-төяккә Зарифҗан да игътибар итмәде. Ә ул игътибар иткәндә соң иде инде.

Кеше язмышына читтән карап торганда гына шулай акыл өйрәтергә була. Газиз үзе дә, Ходайның рәхмәте белән генә, Зарифҗан хөкемендә кала язды. Ярый әле бәхеткә юлында фәрештәдәй изге җан очрады. Бер авылда эшләгәндә фатир хуҗасы Мария апа ана вакытында төпле киңәшен биреп өлгерде.

Газиз —солдат хезмәтләрен үтеп, институт тулай торагында биш ел торып, тәмам шомарган, югары белемле егет, күрше районга, урыс авылына

эшкә билгеләнде. Авылның да ниндие әле. Шәһәрдән ерак, юлы-ние юк. Авыл кешеләре өйгә кертелгән су, газ турында әле хыялланмыйлар да. Шушы кечкенә авылда фатир хуҗасының сыер абзарыннан аз гына зуррак клуб бар. Авыл яшьләре, Газиз кебек юллама белән эшкә билгеләнүчеләр, эч пошканда шунда җыелышалар. Кышкы төннәр ел кадәр озын тоела. Күңелсез. Шул күңелсез бушлыкны тутыру өчен кемдер шешә белән дуслаша, үзенчә озын төннәрне кыскарта. Авылда самогон ише шайтан суы эчәргә генә түгел, батып үләргә дә житәрлек иде.

Газизнең килеп, авылда эшли башлавына бер ел тула дигәндә, зур үзгәрешләр булып куя язды.

Кышкы көннәр, озын төннәр артта калып, жир йөзенә ямьле яз, аның артыннан чәчәкле жәй килде. Су буена урнашкан кечкенә авыл шомырт, жиләк, чәчәк исенә күмелде. Табигатьнең искиткеч матур чагы. Яшь жилкенчәкнең генә түгел, чәчләренә чал кергәннәрнең дә хәмер эчмичә исерә торган вакытлары житте.

Көн тиз уза. Чөнки Зариф көндезләрен эштә.

Кичләрен кая барырга белми каңгырып йөргәндә, авылга шәһәрдән бик чибәр кунак кызы кайтты. Ул кызның матурлыгын ничекләр генә итеп аңлатсаң да күз алдына китерү мөмкин түгел, аның үзен күрергә кирәк иде.

Кунак кызы авылдагы «культурный» укытучы кызларга да охшамаган. Ул үзгә. Кәнсә тирәсендә чуалган, чиста киенеп йөргән укымышлы кызлардан да аерылып тора. Фермада эшләүче авыл кызлары белән бөтенләй чагыштырырлык түгел. Ул —башка. Ул —күктән ингән фәрештә кебек. Аны хәзер телевизорлардан күрсәтелә торган «модельләр» белән генә чагыштырып була. Үзе зифа буйлы, үзенең килмәгән жире юк. Модельләрнең аларның күкрәк турлары тип-тигез, такта кебек. Ә бу Люба-Любовьның күкрәкләре ике алма, тал чыбыгыдай нечкә биле менә-менә өзелеп китәр кебек. Ул чәчләре болыт кебек куе-бөдрә. Ул күзләр, ул кашлар дисеңме. Кыскасы, гүзәлләрнең гүзәле инде.

Ак куллары аның шикәр кебек,
Бит очлары таңдай кызарган.
Якын килсәң, янып китәр кебек...

Юк, аның матурлыгын әйтеп бетереп мактардай шагыйрь әле тумаган. Андый матурлыкны мәңгеләштерердәй рәссам да юк. Авылда булган бөтен ир-ат, шул исәптән Газиз дә кунак кызына бердәй гашыйк булдылар.

Сез инде: «Яратканга —ямьсез, ачыкканга —тәмсез булмас, гашыйк булганга гына ир-ат күзенә шулай матур күренгәндер» — диярсез. Юк-юк, алай уйлап ялгыша күрмәгез. Бу гашыйк Газизнең генә түгел, бөтен авыл халкы фикере. Хәтта Газиз фатирда торучы хужа ханым да аны мактамый түзә алмады: «Бигрәкләр дә матур кыз инде, мона кадәр минем мондый матурлыкны күргәнем юк иде әле», —диде. Ә Газизнең фатир хужасы юкбарга гына тел чайкый торган кеше түгел.

Мария ханым яшь кыз килеш, хатыны үлеп дүрт бала белән тол калган кешегә кияүгә чыккан. Берсеннән-берсе кечкенә шул балаларны аякка бастырган. Үзенең укырга, белем алырга хыялы да булган. Табигать биргән йөгерек уе, сәләте булса да укырга китмәгән. Яшь гомерен шул ятимнәргә багышлаган, аларны үстереп, барысын да кеше итеп тараткан, ирен жирләгән. Хәзер ялгызы гына алты почмаклы йортта тора. Ялгыз гомер матуррак узсын дип өйдәш кертә. Газиз аның чираттагы өйдәше иде. Алар бергәләп көзне, озын кышны уздырдылар. Никадәрле китап укыдылар, ниләр турында гына сөйләшеп бетермәделәр. Акыллы хатыннардан иде

Мария ханым. Кайбер бәхәсләрдә югары белемле Газиз дә Мария апасының үзеннән акыллырак булуын танып, артка чигенә иде.

Дөрес, балалары аны онытмыйлар, сирәк булса да кайталар, посылкалар да җибәргәләп торалар, акча да салалар. Ләкин ул балаларга гына ышанып, аларның ярдәменә генә карап тормый. Үзе колхоз эшенә дә чыга, сорап килгән кешеләргә кулмәген, бишмәтен дә тегә, шәл дә бәйләп сата, кыскасы, бер генә минут та тик утырмый. Укымаган китабы, карамаган киносы юк. Авылга кино-концерт килсә, берсен дә калдырмый. Авыл китапханәсендәге китапларны күптән укып бетергән, районга барган кешегә китап алып кайтырга куша. Өйдәге китап киштәсе сыгылып тора. Менә шундый алдынгы карашлы, укымышлы ханым ул.

Сүз бит шәһәрдән кайткан чибәр кунак кызы турында иде. Менә шул кунак кызына бер көнне кинодан соң Газиз, бөтен кыюлыгын җыеп, сүз катты. Риза булмас, озата кайтырга ясаган тәкъдимемне кире кагар дигән иде. Какмады. Нәкъ шагыйрь әйткәнчә килеп чыкты:

Юри генә: «Киттек», —дигән идем,
Харап була яздым мин, егет.
Ул култыклап алгач, бу йөрәгем,
Өзелеп төшеп китте җу-у-у итеп.

Газиз, үз бәхетенә үзе ышана алмыйча, кунак кызы янәшәсеннән атлый. Куллар да артыкка чыкты. Аларны кесәгә тыксаң да мәзәк кебек, селкеп баруы да матур түгел.

Беренче озатып кайтуда искитәрлек әйбер булмаса да Газиз бәхетле иде. Ул мәхәббәт дигән дингезгә төшеп батты. Хәзер ул мәхәббәттән исергән, башларын югалткан, кысага сыймаган әллә нинди гамәлләр кылган кешеләрне аңлый. Үзе дә тиле кешедәй гел елмаеп йөри. Бәхете-шатлыгы белән уртаклашасы, аны бөтен кеше ишетерлек итеп кычкырасы килә.

«Мин Любаны яратам».

«Мин дөньяның иң матур кызын яратам.»

Кычкырып әйтмәсә дә, эчендәге Мине әнә шулай шәрран яра аның. «Мин Любаны яратам...»

Шул кичтән Газизнең күнелендә ике яз хакимлек итә башлады. Көн белән төн ялганды. Көне буе Любаны гына уйлап йөри. Аны уйлап уянып китә, аны уйлап эшли, аны уйлап йокларга ята.

Таң аттырганчы, сулыш алырга да куркып, аның янында утыра. Бар да татлы төш сыман гына. Тирән итеп сулыш алса, уянып китәр дә, янындагы фәрештә юкка чыгар, ә ул шыксыз чынбарлыкта калыр сыман. Дөньядагы иң матур кыз аныкы. Аннан бәхетлерәк кеше юк. Шундый матур кыз үзенә игътибар итте бит, дигән кайнар уй гел баш миен пешереп-көйдереп тора. Бәхет күкрәк читлегенә генә сыешмый.

Хәзер Газиз өчен бөтен нәрсә Люба белән бәйле иде. Ул киләчәккә планнарын да Люба белән бәйләп кора. Люба белән аннан туган матур-матур балаларны күз алдына китерә. Яраткан хатыны белән шәһәр урамыннан барганда ир-егетләрнең каерылып-каерылып аның Любасына караганнарын тоя. Күкрәк турындагы йөрәк буласы урындагы рәхәтлекне әйтеп аңлатырлык кына түгел. Кыскасы, Газиз бәхеттә, әкият дөньясында яши, хыял дулкынында тирбәлә.

Ул бәхетле. Ул бик бәхетле. Ул чиксез бәхетле.

Үзендә фатирда торучы егеттәге үзгәрешләрне хуҗа ханым да сизми калмады. Авылда сер яшереп буламы инде. Анда син уч төбендәге кебек. Эшләр тирәнгә китә башлаганчы дигәндер инде, хуҗабикә ханым бер көнне клубка барырга җыенып йөргән егетне каршына утыртты.

—Улым, утыр әле, мин сиңа бер сүз әйтәм, —диде ул.

—Ярар, Мария апа.

—Син утыр, утыр. Озак тотмам, китәрсең клубыңа.

Газиз сүзнең үз файдасына бармаслыгын чамалаудан куырылып китте, нидер сизенеп шомланып куйды. Шулай да урындык алып Мария апа каршына утырды. Ул аңа әниедәй якын, аның сүзен тыңларга кирәк.

—Тыңлыйм, Мария апа.

—Синең кунак кызы белән эшләрең ничек соң?

Җавабының үтә мәгънәсез икәнен белә торып, Газиз каушаудан ахрысы, сорауга сорау белән җавап бирде.

—Нинди кунак кызы?

Мария апа аның бу ахмак соравын ишетмәгәндәй колак яныннан уздырып җибәрде.

Газиз үзенең кызарганын сизде, бит алмалары, ике колагы ут булып янарга тотынды. Ул барысын да белә. Әйтәм бит, авыл халкыннан нидер яшерәм димә инде син. Ни булганны түгел, ни буласын да алдан белеп торалар. Боргаланудан файда юк. Мария апа каршында бигрәк тә алай эшләргә ярамый. Дөресен сөйләп бирергә кирәк.

—Яратам мин аны. Өйләнергә уйлыйм. Ул да мине ярата, кияүгә чыгарга каршы түгел.

—Шулай дип уйлаган идем аны...

Хуҗа ханым озак кына эндәшми утырды. Ул өйдәш егетне рәнҗетмичә генә ышандырырлык сүзләр эзләде ахрысы. Әйтәм бит, үтә акыллы, хикмәтле хатын иде ул.

Газиз күзләрен фатир хуҗасыннан ала алмыйча сихерләнгәндәй утыра бирде. Нинди хөкем чыгарыр икән. Эчтәге бәләкәй шайтан: «Кешене тыңла, үзеңчә эшлә», —дип акыл да сата башлады. Мария апа сүзләрен үлчәп кенә тезеп китте:

—Улым, Люба матур кыз, аңа гашыйк булмый мөмкин түгел.

—Матур гына түгел, бик матур...

Мария апа янә аның сүзләрен ишетмәгәндәй, бәлки уй-фикере чуалмасын диптер, сүзен дәвам итте.

— Мин әби булсам да аны очратканда күз тимәсен дия-дия, сакланып кына сокланып карыйм, бәхете генә булсын берүк. Син дә яратмаслык егет түгел. Буең-сының бар, укыган, акыллы егетсең. Сүз дә юк, бик пар килгәнсез. Тик... Үзеңнең сөйләвең буенча, әниегез бер ялгызы өч малай үстергән.

—Әйе, безне әни берьялгызы үстерде.

—Җиңел булмагандыр. Авырлыгын, ялгыз килеш малайларны аякка бастыруның ни икәнен үзе генә белә торгандыр. Сезне үстергәч, аякка бастыргач тормышы көйләнер дип планнар коргандыр. Кызлары булмагач, киленнәрен әллә ничә тапкыр күз алдына китергәндер. Бу эшенә синең әниең ничек карар соң? Бу хакта уйладыңмы?

—Юк, уйламадым.

—Уйламагансыңдыр шул.

—«Ана күңеле – балада, баланыкы – далада,» —дип, Газиз кайдандыр ишетеп калган әйтемне китереп, сүзне уенга борырга тырышты.

—Татар авылына, бер авыз сүз дә русча белмәгән әниең янына маржа килен алып кайтуың турында уйладыңмы?

—Юк, ул кадәресен уйлап бетермәдем әле.

—Юктыр шул, улым, яшь чакта ул кайнар башлы буласың, айларга, елларга план корып куймыйсың.

—Кая инде ул елларга план кору, Мария апа, күрдем дә гашыйк булдым.

Менә шул.

—Бу хәлләргә әниең ничек карар?

—Белмим.

—Ә аны кем белергә тиеш соң?

—Миндер инде

—Син шул. Гомерен сезгә багышлаган әниегез турында да уйларга кирәк.

—Әни мине аңлар дип уйлыйм.

—Сүз дә юк, әниең сине аңларга тырышыр. Акыллы егет бит син. Унсигез яшьлек кайнар башлы чагын узган. Бөтен нәрсәне уйлап эш итәргә кирәк, улым. Әниең йөрәге белән аңласа да, күңеле белән килененнән кабул итәрме?

—Анысын белмим, Мария апа...

—И, бала, бала, белмисең шул...

Газиз авыз эченнән ботка пешерде. Фатир хуҗасы сүзен дәвам итте:

—Билгеле, ана баласының теләгенә каршы килә алмас, бик теләсәң, синең бәхетең өчен фатихасын да бирер, тик... Тик ...

Мария апа тагын озак кына тын торды. Ул гашыйк кайнар башны үпкәләтмичә генә суытырдай төпле сүзләр эзләде. Юк, ул сүз эзләп тормый иде, сүзләренә төпле дәлилләр китерде.

—Улым, уйла әле. Өйләнерсең, балаларың да булыр. Бәлки син чыннан да хатыннан уңарсың. Люба яхшы тормыш иптәше дә булыр, син аны, ул сине яратып та яшәрсез. Бер көн килер. Юктан гына тавыш чыгар. Син өзелеп яраткан кешең сиңа: «Татарин», —дияр. Менә шул сүзне син гафу итә алмассың. Бәхет белән тулып торган тормыш касәгез әнә шул бер сүздән чатнап китәр. Тормыш касәсе чатнарга күп кирәкми ул. Ә чатнаган касәдә су тормый...

Фатир хуҗасы тынып калды. Өй эче тып-тын. Мич аралыгында чикерткә генә үзенең җырын суза. Аның ике әңгәмәдәш хәлендә эше юк. Чатнаган касәдә су тормый...

Газизнең күңелендә буран купты. Уйлардан башы тубал булды. Акыл белән йөрәк гел килешә алмады. Берсе Мария апа яклы, икенчесе аны тыңламаска кушты. Әнә шул күңелдәге каршылыклы уйлары, буран белән клубка чыгып китте. Клубка барып җитмәде, кырт борылып, су буена төшеп китте. Уйлары белән таң аттырды.

Любасы аны бу кичтә көтеп ала алмады.

Көн артыннан көн уза торды. Кайнар башы бераз гына суына төште. Салкын акыл белән Мария апаның сүзләрен кинокадрларын әйләндергән кебек кат-кат әйләндерде. Уйлаган саен аның хаклыгына инана барды.

Ә йөрәкнең бирешәсе килмәде. Ул һаман «Люба» дип янды. Йөрәгенең ничек януын, аның ничек авыртуын сүз белән генә аңлатырлык түгел иде. Вакыт – дәва. Әнә шул дәвалы вакыт узган саен, йөрәктәге авырту кимер кимүен. Ләкин иң авыр берничә көнне уздырасы бар иде.

Салкын акыл һәм Мария апаның теге бер сүзе кайнар йөрәкне җиңде. Егеттәге үзгәрешләрне Люба да сизде. Сулып, ябыгып китте. Ябыгу аңа тагын да ныграк гүзәллек өстәде.

«Якын килсәң, янып китәр кебек...», дип кабатлап йөрде Газиз үзалдына. Бөтен көчен җыеп, Люба белән аңлашты. Ул көнне алар яктыргач кына аерылыштылар.

Йөзләренә таңның алсу төсе кунган, шикәр кебек ак йөзле Любаша аерылышуны үзенчә кичерде. Газиз үзенчә. Икесенә дә авыр иде.

Газиз башта кыз алдында үзен гаепле дә, гөнаһлы да тойды. Тора-бара бу хисләр дә тоныкланды. Аларны вакыт тузаны каплады. Оныттырды.

Мария апанын бер сүзе тормышын үзгәртергә мәҗбүр итте. Бер сүз уй агышын гына түгел, тормыш агышын икенче якка борып җибәрде. Әнә шул бер сүз тормышка яңача карарга мәҗбүр итте. Борылыш. Әйтергә кирәк, вакытлы борылыш. Гомерләр узгач андый борылышны ясау авыр булыр иде.

Шул вакыйгадан соң Газиз эшкә үзләренең ягына кайтты. Чираттагы елларда, атна арасында да гел авылда күренә башлады.

Чибәрләр үзләренең авылында да бар икән. Авыл кызына өйләнде. Аның белән өч дистә ел яшәп, бер генә көн, бер генә минутка да үкенгәне булмады. Зөлфия менә дигән хатын, әнисенә менә дигән килен, балаларга менә дигән әни булды.

Әгәр Любага өйләнгән булсам... дигән уй элегрәк башына еш килде. Үкенер иде микән? Үзе егылган — еламас, дип яшәр идеме? Белгесез.

Зарифҗан дустының тормышына караган саен ул Мария апасына рәхмәт укыды.

Бер сүз. Тормышны аягыннан башына куярдай, язгы ташкын кебек ургылып аккан суны борырдай бер сүз...

***

...Бүген көн бөтенләй башка. Давыл узган, дөнья тынган. Көз димәссең, күк йөзе чиста, анда бер генә болыт әсәре дә юк. Тирә-юньдә көчле җил, буран һәм гарасатлардан соң гына була торган тынлык. Кичә җиргә ятардай булып бөгелгән агачлар бүген тып-тын, үз дәрәҗәләрен белеп, мәгърур гына басып торалар. Көчле җил агачлардагы соңгы яфракларны йолкып алып, әллә кайларга очырып киткән. Бүген исә кояш та: «Кичә минем көн түгел иде, гафу итегез инде, чыга алмадым, менә бүген мин сезнеке... — дигән кебек елмаеп, күк йөзен балкытып тора.

Кояш чыккач җир нурга күмелгән. Өй түбәләрендәге кошлар да чыркылдашмый, бер-берсе белән чукышмый тыныч кына җылы нурларга коенып утыра. Урамда йөрүчеләрнең дә бүген аяк атлауларына кадәр үзгә. Житез, дәртле атлыйлар. Кешеләрнең йөзләре якты, бит алмаларында әллә күктәге кояш нурлары уйный, әллә үзләре матур көнгә карап елмаялар.

Кара инде, кичә нинди иде дә, бүген көн нинди. Күңел дигәнең дә шулай бит. Менә генә сыкрап әрнеп тора, икенче караганда якты көн кебек балкып китә. Узган көн сыкрап-сыктап торган күңелен бүген кызы белән оныгы басты да куйды. Иртән-иртүк кызы шалтыратып: «Әтием, хәлең ничек, әнием ни хәлдә?» — дип балдан татлы теле белән җанымны иркәләде. Оныгы исә: «Бабаем, сине бик сагындым», — дип, күгәрчендәй гөрләп, күңеленә май якты. Тәүлеккә якын шомландырып торган күңелендәге теге кара болыт таралды да китте.



Әхмәт
Гадел

# ҖИЛ ИСӘ, ЕЛЛАР ҮТӘ...

## Сөй!

**Әй, кардәш, җитте замана,
оеш та укмаш.
Туганлык дигән табында
Гөрләш, җый, уртлаш.
Йөрмә нәфрәт, ачу җыеп,
хурлау кирәкми.
Явызлык, гайбәт, әшәкелек
ашый йөрәкне.
Тиң күр үзеңдәй татарны,
бертуганың ит.
Елмаеп йөрсә дә сиңа,
Читтән килгән – чит!
Күршеңә тел–теш тидермә,
сүз әйтмә хурлап.
Оныт үпкә, рәнҗешеңне,
исәнләш зурлап.
Әй, татар, сөй бер–береңне,
Йортың, халкың сөй.
Мәхәббәттән генә туа
йөрәкләрдә көй.
Сиңа иң җитмәгән нәрсә,
юк, акча түгел!
Бел, кардәш, сиңа кирәге
бүген — киң күңел.
Күңелдәге кояш кына
җылыта җанны.
Сөй, татар, санла тиңеңне –
җылыт җиһанны!**

Әхмәт ГАДЕЛ (1942) – *шагыйрь, язучы-публицист; «Йолдызлы чат», «Рух бәйрәме», «Еракта, томаннар артында...» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

## Мин синнән ваз кичмәмен!

Көннәрен һәм төннәрен без бергә идек, җаным,
Язгы былбыллар кебек канатында таңнарның.
Һичкем аера алмас төсле бер-беребездән,
Кояшлы иде безнең татлы шат төнебез дә.

Мондый хәл булыр диеп һич уйламадым, җаным,
Төнем төн түгел минем, караңгыланды таңым.
Мәхәббәткә чик булмас, сөюем сине эзләр,
Биек күкләргә менеп, дөньяга бага күзләр.

Мин синнән ваз кичмәмен, син – күземнең нурысың,
Тормышымның иң матур һәм иң олы җыры син!
Син мине яшәтәсең, бирәсең көчле канат,
Гүя миңа дәшәсең: эзлә, тап, ярат, ярат!

Еракта син, яр, хәзер, йолдызлар сыман ерак,
Еракта син, яр, хәзер, аерды явыз фирак.
Әмма сине табармын, һич сүрелми өметем,
Без бергә булсак кына бу дөнья булыр бөтен!

## Көз. Урман. Уйлар.

Көз алтын яфрак яудыра,
Җир — сары, күкләр зәңгәр...
Йөрәк яна да яндыра...
Көз килә безгә мәгәр...
Кемгә көз, ә кемгә әле
Көз җиләндә яз уйный:
Тормышның рәхәт бер мәле:
Назлана, күңел туймый.
Чәчәкләрнең сагышын да
Күрми яшьлекнең күзе.
Тормышның шат агышында
Алтын балыктай үзе.
Ә яфраклар җилдә оча,
Коена яңгырларда.
Алтын көз дөньяны коча,
Иртәнге кырауларда!
Көзнең моңлы бәйрәмендә
Күрдем тормыш балкышын:
Биек күктә торналарның
Канатлары алкышын.

## Яшьлектә сөйгән яр

Тау башыннан кул изәмәс,
Җилфердәтмәс яулыгын.
Хатлар да язып белешмәс,
Ничек, диеп, саулыгың.

Ул калган илләр бик ерак,
Кул түгел, караш җитмәс.
Тик күңелдә сыны тора,
Хәтеремнән һич китмәс.

**Йә, булмаса болыт булып**
**Очамы ул күкләрдә?!**
**Кайлардан канат табарга,**
**Ничек кайтыйм үткәнгә?!**

***

**Җилләр исә, еллар үтә**
**Бу гаҗәеп дөньяда.**
**Әле генә иде иртә,**
**Җирдә көн, кояш яна...**

**Әле генә бакчаларда**
**Шаулап атты гөл-чәчәк.**
**Үзгәрделәр акчалар да**
**Һәм дә бөтен киләчәк.**

**Үзгәрделәр... Ил үзгәрде...**
**Танымаслык күршеләр.**
**Һәм кызарды, кем бүзәрде -**
**Үргә ашты... төштеләр...**

**Тик табигать үзгәрмәдең;**
**Шул ук кич, шул ук иртә...**
**Килә язлар гүзәлләнеп,**
**Җил исә, еллар үтә...**

***

**Сөюдән зур бер Аллаһ.**
**Раббене сөю - олуг,**
**Машаллаһ йә машаллаһ!**
**Янма мин ярың өчен,**
**Калдыр аһ-зарың көчен.**
**Үз-үзеңне талама**
**Йә бер Раббем, йә, Алла!**
**Дөньяның матурлыгы,**
**Хәләлнең татлылыгы,**
**Ярыңның батырлыгы**
**Аллаһтан! Йә, бер Аллаһ!**
**Дөрес, мәхәббәт - көмеш,**
**Алтыннан кыйммәт, имеш,**
**Төн үбеш, таңда күреш,**
**Шул була сөю, имеш!...**
**Әмма кулымны тот та,**
**Раббене син онытма.**
**Габитлектә - коллыкта**
**Зикер ит Бер Олугны.**
**Сөям сүзен исеңә**
**Төшерсәң, килсен Аллаһ.**
**Ул халәттә кимсенмә,**
**Зарланма, итмә аң-ваһ.**
**Икәү дисәң, без өчәү:**
**Уяу караш гел бага.**
**Сөю дигән сүздән соң,**
**Урын калсын догага!**
**Чөнки олуг мәхәббәт**
**Бүләк ерак гарештән.**
**Безнең гашыйк булулар**
**Аллаһ тәкъдире эштер!**

**Редакциядән:**
*Бу айда шагыйрь үзенең 70 яшьлеген билгеләп үтә. Юбилее белән ихлас котлыйбыз, исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Ибраһим
Биектаулы

# МОҢСУ МИЗГЕЛЛӘР

## Булмады....

**Чыкмады миннән сәүдәгәр,
түрә, текә хөкемдар...
эзләмәдем уылдыклар,
тукландым алда ни бар...**

**Булды кыяр-кыймас кына,
мөнбәрләргә менгәнем.
Сөйләгәнем шигырь булды,
гайре сүз сөйләмәдем.**

**Хакыйкать эзләү гамәлем
гавам тапты файдасыз.
Яшәдем аптырамышта,
бәргәләнеп мәгънәсез.**

**Оныттым сихри моңнарны –
кыргыйландым... Йә, ярар!
Әнә, Кояш чыгып килә ...
Менә, хәзер... елмаям!**

## Мөселманнар

**Җиргә Иман гүзәллеге иңсен өчен,
мәҗүсилек-наданлыкка чик куярга
Аллаһ бирде үз әмерен Рәсүленә –
ышанычлы сөйгән колы Мөхәммәдкә...**

**Шул көннәрдән
мөселманнар күңеленә
саф нур чәчә гарәп иле, шәһри Мәккә...
Бу изге җир лаек чиксез мәхәббәткә –
адәмнәргә юл яктырта киләчәккә.**

Ибраһим БИЕКТАУЛЫ (1937) – *шагыйрь, публицист; «Бәйрәм белән!», «Җирдән җиде җиһанга», «Галәм серләре» һ.б. китаплар авторы. Ижау шәһәрендә яши.*

**Мөселманнар — сабыр халык, фида җаннар —**
**Матурлыкны, Тынычлыкны яхшы аңлар!**
**Кем акыллы — үткер күздән дөнья багар —**
**Мөселманда ышанычлы дусны табар!**

**Ир гомере — ел гомере — фасылларда.**
**Корьән сүзе — Аллаһ сүзе — гасырларда...**

***

**Язмыш, тапшыр бүләгеңне!**
**Гайре күтәр ара юк —**
**көймә комда... Сәгать сонда**
**кузгатырлык чара юк...**
**Гомер буе: «Булыр!», — дисең.**
**Күңел... бүген ымсына!**
**Беләм, мине хәзерлисең**
**югалту кайгысына...**

***

**Мондагы яр — анда яр микән,**
**хур кызлары миңа пар микән?**

**Бу таңнарның моңлы әтәчләре**
**теге дөньяларда бар микән?**
**Сандугачлар — нинди гөлдә икән,**
**сайраулары — нинди телдә икән?**

**Бармы анда сырхау, ютәлләү,**
**суган-борыч үскән түтәлләр?**
**Мөмкин булса тормыш күтәргә,**
**ризалашам бүген китәргә!..**

## Көзге урман

**Урманда — соңгы тантана...**
**Күк тәбрикли-гөрелди,**
**өрәңгеләр кызарына,**
**сары усак дерелди,**
**биеккә — тылсымлы күккә**
**зәңгәр көй күтәрелә,**
**күбәләктәй гүзәл яфрак**
**вальста бөтерелә...**

***

**Әгәр яныгызда**
**җыерчыклы арган чырай**
**пәйда булса, чирканмагыз!**

**Шатлыкны аз күргән,**
**мул хәсрәт кичергән,**
**мең көйгән, мең янган**
**адәм йөзе шундый була —**
**минем йөзем — атам йөзе,**
**бабам йөзе халкым йөзе...**

***

**Юк! Һичкайчан!**
**Инде кире кайтмас**
**Балачагым,**
**Туган йортым ишегалды,**
**Кояш җылысында**
**мине изрәткән**
**мамык түшәк өсте...**
**Инде ишетә алмам газиз**
**Әнием тавышын:**
**– Улым, кер, аш пеште!.**

***

**«Аһ!» — дип әйтсәм,**
**яндырырмын Галәмне...**
**Дәшми калсам, беркем**
**белмәс хәлемне...**

## Күләгәләр

**Бәрелешеп — очкын чыгармый.**
**Кояш чыкса — туа.**
**Кояш батса — үлә.**
**Хәрәкәтне — кабатлый,**
**авазны — юк....**

## Гомер

**Ни әйтсәң дә, гомер — мизгел.**
**Кадерен бел дә илһамлан.**
**Ни чәчсәң — шуны урырсың.**
**Гомерең — үстергән алмаң...**

## Бәхет

**Бәхет — кыюга бирелер,**
**юаштан — ерак йөрер...**
**Усаллар да, мескеннәр дә —**
**Аллаһ өчен — барыбер...**
**Көрәшче җан, бәхет саклап,**
**утлар–суларга керер...**

## Акыл

**Акыл белән яшәүчегә**
**ике фикер кадерле:**
**«Бал», — диеп агу кабудан**
**ач торуың хәерле;**
**Яманны күршең итүдән —**
**ялгызлыгың хәерле.**

**Редакциядән:**
*Бу айда шагыйрь үзенең 75 яшьлеген билгеләп үтә. Юбилее белән ихлас котлыйбыз, исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

Вакыйф
Нуриев

# КАЗАН КҮРКӘСЕ

ХИКӘЯ

*КПСС Үзәк Комитетының генеральный секретаре Брежнев белән КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Табеев Мәскәүдә Кызыл мәйданда йөриләр икән. Очраган һәр кеше: «Исәнмесез, Фикрәт Әхмәтҗанович», — дип, Табеевка сәлам бирә.*

*— Как так, — ди Брежнев, йөзенә ризасызлык билгеләре чыгарып, — совет халкы синең белән исәнләшә, ә минем белән исәнләшми-и-и.*

*— Болар бит — минем якташлар. Казаннан болар, дорогой и многоуважаемый Леонид Ильич! Мәскәүгә ит алырга килгәннәр, — ди Табеев.*

*Брежневның йөзе яктырып китә:*

*— Ит алырга! Мәскәүгә! — Кадерлебез авызларын чапылдатып пауза ясый. — Дөрес эшлиләр! Совет кешесенең өстәлендә барысы да булырга тиеш!*

(Халык арасында йөргән мәзәк.)

## Мисбахның Мәскәүгә юл алуы һәм...

Казан вокзалы. Үзе озын, үзе яшел, үзеннән колбаса исе килеп торган «Татарстан» поезды. Хәзер ул Мәскәүгә китәчәк. Мисбах та китә. СССР кадәр СССРнын башкаласына «дифицит» күркә ите алырга бара. Хатыны озата. «Мәскәүдә тегене ал, моны ал», — дип иренең колак итен ашый. Сүз арасында: «И яратам да инде шушы шпал исен», — дип вагон астына карап куя. «Алай бик яраткач, бер шпалны өйгә алып кайт та, кочаклап йокла», — ди ире.

Чү! Поезд кузгала түгелме?! Состав ит урлаган һәм шушы караклыгын яшерергә маташкан мәче кебек акрын гына шуа башлады. Мисбах ошбу сәфәренә зур өметләр баглаган хатынына тамбордан кул болгады.

Һай ул Мәскәүгә китүләр. Һай ул Мәскәүгә озатулар!.. Ире хатынын озатса, әле бер хәл. Хатын-кызнын ирен озатуы... Кырыкмаса кырык тапкыр әйтелгән сүзләр перронда кабат яңгырады: «Кара аны, балакларыңны җыеп йөр, авыл гыйбады булма. Күркәсе кечкенә булса, икене ал. Миңа сапожки кара. Очраса, икене ал. Берсен сатарбыз. Кызга колготкиларны бер-ике

размерга зурракны ал. Капчунный колбаса очраса, күбрәк ал. Рәсәйский сыр ал. Чәй эчәргә Мәскәуский карамель ал. Акчанны югалтма! Трусиктан алганынны кеше күрмәсен. Сосиски кирәген онытма!»

Горур поезд белән янәшә чабып барган күп сүзле хатын тагын нидер әйтмәкче иде, перрондагы эскәмиягә килеп бәрелде. Ул арада әле Казаннын, әле Мәскәүнең ыгы-зыгысыннан туйган «Татарстан» хут алып өлгерде. Поезд китте. «Күркә», «колбаса», «сосиски» дигән җан авазлары гамьсез Маркиз утраулары, тәкәббер Ослан таулары ягына очты. Казансу күперенә кереп барган озын поезд ерактан караганда үзе дә сосискига охшаган иде.

Күркә итендә күптән нәфесе бар иде Мисбахның. Үзенең дә авылдагы кушаматы — «Күркә». Үзе — Күркә, үзенең күркә ите ашаганы юк. Ул кушамат, белмим, каян чыккандыр? Аның башы гәүдәгә дөрес куелмаган. Онытылган, күрәсең. Эскертбаш. Андый озын баш булса да, шул күркә, тавык, казда гына инде. Баш өстәлдәге күркә йомыркасы кебек яткан килеш калса да, Ходай Тәгалә, компенсация диптер инде, чибәрлекне биргән тагын үзенә. Күз, авыз, борын өчен мәйдан да бик кечкенә калган югыйсә. Шул кечкенә кишәрлекне дә тип-тигез итеп ике өлешкә бүлгән. Бер өлешен кызганмый-нитми маңгайга бирергә җөрьәт иткән. Күз, борын, авызга материал бик аз калды инде дип куркып тормаган. Тегеләре дә матур гына кереп урнашкан. Дөрес, күзләре Чыңгызханныкы кебек кысык инде кысыгын, аның каравы борын шәп. Төз, туры. Барысы да үзенә килешеп тора.

Поезд чаба. Хуш, Казан! Хуш, Бишбалта! Мисбах тәрәзәгә карап әйтеп куйды:

> Сау бул инде, хуш, бәхил бул, и минем торган җирем,
> «Заначка»ны хатын тапса дип, борчылып йөргән җирем.

Купега керде.

— Сәлам, юлдашлар! Мисбах булам. Кушаматым — «Томшык».

Күр әле син аны ә, «Күркә» дими, «Томшык», ди. Хәер, алар авылында кош-корт кушаматы белән йөрүче бихисап: тавык, әтәч, ата каз, чеби бар. Бар тагын карга, чыпчык, күке, козгын, торна. Хәзер аларның барысын да «Томшык» дип кенә йөртәләр. Киләчәктә бу галәмәтне колакка ятышсыз «глобализация», «оптимизация» дигән төшенчәләр белән атарлар. Тагын әллә ниләр уйлап чыгарырлар.

Купедагы юлдашларның икесе — өлкән яшьтәге бер агай белән аның кияве, егерме биш-утыз яшьләр тирәсендәге бер озын, ябык егет — шулай ук ит алырга баручылар булып чыкты. Елтырап торган күзләрен әле унга әле сулга тәгәрәтеп утырган юка иренле, юка чәчле, аның каравы калын тавышлы кыз гына тамак кайгыртып йөрүчегә охшамаган. Иткә дипломат тотып бармыйлар бит инде.

Мисбах кылын тартып карарга булды:

— Башкалада ни йомыш?

— Мин укыйм анда.

— Кайда?

— КПСС Үзәк Комитеты каршындагы академиянең аспирантурасында-а-а.

Мисбах өнсез калды. Ләкин үзен бик тиз кулга алды.

— Укып буламы соң?

— Экзамен бирергә барам. Биреп булырмы, юкмы?

— Бирә алмасаң, Якуб абыйга әйтербез. Шалтыратыр.

— Кем соң ул — Якуб абый?

— Полководец, генерал. 90 яшьтә. Мәскәүнең үзәгендә Цекә йортында яши. Дер калтырап торалар аның алдында. Андропов мәрхүм генеральный булгач ин әүвәл үзе янына киңәшкә аны чакыртты.

— Син ул бабайны каян беләсен соң?

— Дуслар без аның белән.

Ах бу Мисбахны, «дуслар» дигән була. Берничә ел элек Мәскәүгә барганда Казаннан Якуб Чанышевка дип бер китап биреп җибәргәннәр иде, шуны кертеп чыкканда күрдем, дими. Чанышевның күптән түгел генә мәрхүм булганын да белми. Хәер, берәрсе укырга керергә җыенса — университетта Мисбахның таныш доценты бар. Берәрсе армиягә китә башласа — Татвоенкоматта таныш прапорщигы бар. Берәрсенен (җәйнен эссе көнендә) тамагы кипсә — Казандагы сыра заводында таныш «завсклад»ы бар. Әнә шулай сайрый-сайрый авылдашларынын кесәсеннән байтак сыйланды инде ул. Ярдәме генә тимәде. Авыл халкы ышана. Ышанмый да булмый, егетнең башы эшли. Әдәбиятны үлеп ярата. Тукайга мөкиббән. Мәктәпне тәмамлагач, университетка татар теле бүлегенә укырга керде бит ул. Беркем ярдәм итмәде. Тик укымады гына. Беренче курста ук ташлады. Армиягә китте. Кайтты. Эшкә урнашты. Балалар бакчасына. Шунда завхоз да, электрик та, столяр да, ишегалдын себерүче дә. Купедаш аспирант кыз исә Казандагы автохуҗалыкларның берсендә партоешма секретаре урынбасары икән. «Компарттуташ» дип уйлап куйды Мисбах эчтән генә.

## Мисбахның купедагы туташның котын алуы һәм...

«Ярый хуш, батты кояш, йокларга яттык кич белән,
Купе эче тулган туташның хушбуй исе белән.»

Өске шүрлеккә менеп яткан Мисбах бу шигырьне Компарттуташ юынырга чыгып киткәч укыды. Билетка язылган урынына караганда ул аста ятарга тиеш иде. Ятагын кызга бирде. Аспирант кереп яткач, ул барысына да тыныч йокы теләде. Теләвен теләде, тик йокы тыныч булмады.

Мисбахның төн уртасында торып пес итеп керә торган гадәте бар. Бүген дә торды. Чыкты. Керде. Ул кергәндә поезд туктап тора иде. Кинәт кузгалып китте. Өске шүрлеккә менәргә дип кулларын сузган Мисбах, состав кузгалган шәпкә, тигезлекне югалтып, суга корсагы белән чумган кеше кебек, Компарттуташ өстенә килеп капланды. Тегесе йөрәк өзгеч тавыш белән кычкырып җибәрде. Кычкырмассын, йоклап ятканда сина шулай ташлансыннар әле. Бөтен вагон уянды. Проводница йөгереп килеп житте. Мисбах күмәче көлгә төшкән хәлдә калды.

Иртән исә һәркем үз эше белән мәшгуль иде. Мисбахның купедашлары гына төнге мажараларны искә төшереп бер көлешеп алдылар. Компарттуташ та эчен тотып көлде. Иртәнге чәйне эчкәндә ул «амбразура»сын каплаган Мисбахка якынрак килде, отыры терәлеп үк диярлек утырды.

Поезд СССРның башкаласына килеп житте. Саумы, Мәскәү! Купедан чыкканда Мисбах, Тукайга ияреп, юлдашларына тагын бер-ике шигъри юл әйтеп алды:

«Тор, шәкерт! Життек Мәскәүгә, алдымызда бит Мәскәү.
Мондадыр безнең влачнын тузлары, Горбачлары;
Әйдәгез, рәхим итегез, и сез Казан ачлары.»

«Сез мине академгородокка кадәр озатып куясыздыр ич инде», — диде Компарттуташ вагоннан чыкканда һәм Мисбахка шактый калын күренгән күн сумкасын тоттырды, дипломатын үзе алды. Күндәм Томшык теләр-теләмәс кенә аспиранткага иярде. Ник ияргәненә сонынннан үкенде үкенүен.

Метрода, бу кыздан аерылып калмыйм тагын дип, халык дингезендә этешеп-төртешеп шабыр тиргә батуы бер хәл. Компарт туташ парикмахерскийга кереп чәчен күпертеп чыгарга булды. Анда чират. Сәгать ярым көттеләр. Туташка нәрсә, ул сайравын белә. Академ-шәһәрчекне мактый. «Җанын ни тели, буфетларында шул бар», — ди. — Сыр, колбаса, балык, икра, кофе... Ит тә бар, күркә дә бар. Теләсәң, күгәрчен сөтен дә табып була. Коммунизм утравы, короче говоря. Шулай булырга тиеш. Партия җитәкчеләре әйбәт яшәргә тиеш. Бүген нинди генә проблема туса да, аны хәл итү юлын Коммунистлар партиясе күрсәтә бит!»

Парикмахерскийдан чыккач, Компарттуташ Мисбахка «Минем прическа матурмы? Ник мактамыйсың? Макта инде!» — дип кадалды. Аннары маникюр, педикюрга керәсе итте. Анда чират юк дисезме?! Томшыкның сабырлыгы төкәнде. Аның күркә аласы һәм поездга өлгерәсе бар бит әле. «Бу тирәдә телеграф бар микән? Миңа срочно эшкә шалтыратып алырга кирәк», — дигән булып, Компарттуташ яныннан очты.

## Мисбахның күркә алуы һәм...

И рәхмәт инде, Мәскәү! Мисбахны бик тиз күркәле иттең бит. Үзе теләгән кошны «Арбат» гастрономыннан «тотты» ул. Дөрес, бер сәгать чамасы чират торырга туры килде килүен. Бер сәгать Мәскәү өчен нәрсә ул?! Кошы шәп. Ул түшләре дисеңме, ул ботлары дисеңме! Нәфесне ымсындырыпмы ымсындыра. Казан күркәсе булып чыкты бит әле җитмәсә! Кибетчеләр үзләре әйтеп тора, аларга итне Татариядән китерәләр икән. Хәер, Мисбахның ишеткәне бар, Казан янындагы кайсыдыр бер кошчылык фабрикасында күркәләрне Мәскәү өчен махсус үстерәләр, имеш. Мисбахның Казаннан икәнен белгәч, әй тотындылар мактарга: «Татарларның ите бик тәмле була, — диләр. «Мал симертү рәтен, кош-корт үстерү җаен белә татарлар», — диләр. «Әйе, татарда мал салам ашап, кибәк төчкерми, тик ит үзенә генә эләкми, күзгә кырып салырга да калдырмыйлар», — диде Мисбах, кемгәдер үпкәләгән сыман рәвеш чыгарып.

Күркә алу шатлыгыннан күнеле, һәмәй кошы тоткандай, мәтәлчек аткан Томшык Мәскәүнең иң биек йортлары тезелеп киткән Калинин проспектыннан атлады. Кая барганын ул үзе дә белми иде әле...

## Мисбахның Рейганны каршы алуы һәм...

Көтмәгәндә-уйламаганда Мисбах Кремльгә килеп чыкты. Анда халык, анда халык... Кремльгә керү юлының ике ягына кечкенә кетәклеккә шыплап кунаклаган чебеш кебек тулганнар. Рейган килгән икән бит. Хәзер аэропорт юлында. Ул һәм аны озатып баручы картеж менә-менә шушы минутларда монда булырга, Кремльгә шушыннан кереп китәргә тиеш икән. Мисбахмы соң мондый тарихи форсатны кулдан ычкындыручы. «Мин Америка Президенты Рональд Рейганны күрдем!» — дип гомер буена сөйләп йөриячәк. Авылдашлары алдында мактаначак. Әнә, авылда сыңар аяклы Даут бабай бар иде. «Ул Ленинны күргән», — диләр иде аның турында. Шуның аркасында гел дәрәҗәле йөрде. Ул Ленинны күргән! Бетте китте... Аның ике сугышта катнашуын, шунда аягын калдыруын телгә алган кеше дә юк.

Майның соңгы көннәре. Карашын җәйгә төбәгән кояш кыздырыпмы-кыздыра. Чү! Ни булды? Халык ташкыны, җим сипкән хуҗабикә янына чапкан күркә, тавык-чебеш кебек, чаба башлады. Дәррәү булып Кызыл Мәйданга килеп керде һәм ГУМ янындагы урамның ике ягын камап алды. Рейган менә шушыннан үтеп, Кремльгә Спасс башнясы астыннан керәчәк икән. Хәлбуки, Мисбах халыктан калмады.

Күз алмасын арлы-бирле очыртып, янып-пешеп тагын күпме басып торганнардыр, кызыл йөзле, кызыл борынлы бер мент зур канәгатьләнү хисе белән әйтеп куйды: «Юкка көтәсез. Рейган Кремльдә инде!»
Шуннан халык нишләде дисезме?

## Мисбахның Мәскәү Кремлен алуы һәм...

Кемнеңдер: «Алга, Кремльгә!» дип кычкыруы булды, халык армиясе Кызыл Мәйданны тутырып, Спасс башнясына таба чаба башлады. Чебеш эләктерергә йөргән козгынга ташланган кош кебек Кремльгә ябырылдылар. Әгәр шунда солдатлар, хәрбиләр башняның ике якка ачылып торган, калын имән борысларыннан эшләнгән капкасын ябып өлгермәсәләр, белмим, бу һөҗүмнең ахыры ни белән беткән булыр иде икән. Белмим, бу бөек Кремльнең бу биек капкасы кайчан шулай ябылды икән? Мәскәүгә немец-фашист илбасарлары һөҗүм иткәндә дә ябылды микән әле?!
Кремльгә иң беренче килеп типкән кешеләрнең берсе ярсулы Мисбах өчен исә СССР капкасы ябылуның ахыры болай булды. Затлы кәчтүм кигән, кара галстук таккан ике шәп-зәһәр егет кызыл кенәгәләрен вәкарь белән чыгарып күрсәттеләр дә, аны үзләре белән алып киттеләр. Кояш төшми торган тар гына урамдагы бернинди язуы-ние булмаган бер соры йортка алып керделәр. Шыр ялангач салкынча бүлмәдә — сынар өстәл дә берничә урындык. Мисбахка утырырга ымладылар. Үзләре әүвәл Томшыкның паспортын карадылар. Татар икәнен белгәч, «Менә тагын бер Чыңгызхан!», — дип көлеп куйды берсе. Аннары Мәскәүгә килүенең максатын сорадылар. Мисбах: «Күркә итенә килдем», — дигәч, күзләренә гаҗәпләнү билгеләре чыгарып, карашып куйдылар.
— Рейганны күрәсем килгән иде, — диде Мисбах, тегеләрнең чираттагы соравын көтеп тормыйча. — Аннан сорыйсы нәрсә бар иде.
— Ни сорамакчы иден?
— Америкада күркә ите ашыйлар микән?
— Ашыйлар. Сез җаваптан канәгатьме?
— Рейган үзе күркә итен ярата микән?
— Күркә итен кем яратмый?! Тик менә күркә алырга килгән кешенең Кремльне алырга йөрүе гаҗәп.
— Күркәне алдым инде мин. «Арбат»тан алдым. Менә, чегы да бар. Тукта, күркә кайда соң әле минем? Ах, шайтан алгыры, онытылып калган бит. Бая аяк астына куеп торган идем. Күркәм калган! Кәчтүм дә калган. Ах, бетте баш!
— Ярый, бар тап тизрәк күркәнне! — диделәр тегеләр, чекны бик җентекләп караганнан соң.
Мисбах паспортын алды да чыгып очты.
Бая басып торган җиргә дә очып килде.
Тик күркәдән җилләр искән иде...

## Мисбахның авыртмас башка тимер таяк алуы һәм...

Мәскәү дигәч тә, сез Мәскәүдә, Москвада, Маскальдә күркә ите тулып ята дип уйлыйсызмы? Ята пычагым... Мисбах әлеге дә баягы «Арбат»ка килеп карады — күркә юк. «Елисеевский»га кереп карады — күркә юк. Кая кереп, кайдан чыкмады — күркә юк. Юк күркә. Юк инде, юк...
Мисбах уйга батты: «Их, Рейган, Рейган! Кызык иттең син мине, иптәш Рейган. Хәер, нинди иптәш инде син. Син — капиталист. Мин — бер коробка, ягъни бер «кап ит ал ич». Иптәш булмаган Рейган. Мин күркә

алырга килгән көнне генә килми торсаң ни була иде соң?! Син бит «любой» вакытта килә ала идең. Үзең СССРны «явызлык империясе» дип сүккән буласың, үзең кунакка килгәнсең. Хәер килгәнсең икән, йөр инде Кремльдә. Шул Кремльдән чыга алмассың инде син. Мисбах ялгыша. Ул күркә таба алмыйча тәмам интегеп, гаҗиз булып Мәскәүдәге Казан вокзалына кайтып ауганда, Рейган Кызыл Мәйданга чыгып халык белән сөйләшеп йөрде.

«Кайтып ауганда» дигән булам. Кая ауды соң ул? Вокзал тулы халык. Утырырга урын юк. Мисбах подвалга, саклау камераларына төшә торган баскычка чүмәште. Кәеф юк. Күңелне бушатырга кеше юк. Хет эчмәсәм җанны җылытып торырга башы чабылган, йоны йолкынган шул күркә булсын иде. Юк шул...

«Эчмәсәм, күркә дә юк эч, тик икәү без: уй да мин»

Күпме утырырга була шулай мәэюс булып. Тукта әле, Мисбах, син — Мәскәү кадәр Мәскәүгә килгән кеше. Урамга чыгып, бераз йөреп кер. Мәскәүне кара.

Мисбах чыкканда караңгы иде инде. Көн сүрелә төшкән. Җылы, җилсез кич. Хәер, монда көн ни, төн ни. Кеше йөреп тора, вокзал яны кайнап тора. Әнә, сукбайлар. Тимер-бетон багана төбендәге тимер-бетон плитәгә утырганнар да, кичке ашны ашыйлар. Табыннары куе күренә. Хәтта кара икра да бар бугай. Чү! Аяк астында яшел төстәге капрон сумка аунап ята. Аның янында кәчтүм. Мисбах кәчтүменә охшаган. Сумкадан күркә боты чыгып тора түгелме?! Бәй, Мисбах сумкасы ич бу! Казан күркәсе ич бу!

Мисбах йөгереп килде дә, сумкага ташланды.

— Болар минеке! — диде ул кистереп. — Көндез Рейганны каршы алганда Кызыл Мәйданда онытып калдырганмын. Табуыгыз өчен рәхмәт!

Мисбах күркәне алды да китте. Бомжлар ягыннан каршы дәшүче дә, каршы чыгучы да булмады.

Менә бит, Ходайның рәхмәте, табылды бит күркә, табылды! Кешегә сөйләсәң — кеше ышанмас. Дистә миллион халык яшәгән шәһәрдә югалткан әйбереңне табу — печән кибәненнән энә табу белән бер. Мисбах сөенеченнән рәхмәт укыды: «Рәхмәт сиңа, күркә. Табылуың өчен рәхмәт. Миңа иптәш булганың өчен рәхмәт, якташ!»

Күркәдән күте кибән булган Томшык татлы сөенеченнән нишләргә белмәде.

## Мисбахның тагын бер туташның котын алуы һәм...

Күркә табылуын табылды. Тик менә Казанга кайтып булмый бит әле. Билет юк. Бүген юк та юк инде. Иртәгә, берсекөнгә китәсе поездларга да юк бит әле. Күркәсен саклык камерасына куйсын да кибетләргә йөрсен, хатыны алырга кушкан әйберләрне алсын, диярсез. Кибеткә йөрүчеме соң инде ул — Мисбах. Аңа күркәдән башка берни кирәкми. Болай кайта алмый ятса, күркәсе дә исләнәчәк бит әле. Вокзалның эчпошыргыч, сару кайнаткыч ыгы-зыгысыннан тәмам туйган Мисбах кадерле күркәсен саклык камерасына япты. «Күркәм сабырлык бирсен сиңа, күркәм!» — диде ул һәм... кунакханә эзләп китте.

Кунакханәне ул иртәгесен кичен генә тапты. Анысы да паспортының эченә кызыл акча салып биргәч кенә насыйп булды. Кунакханә димәсәң хәтере калыр, Мәскәүнең үзәгендә булса да ни суыткычы (күркәне кая куярга?), ни телевизоры юк. Ишегенә дә берни язылмаган. Башкасы булмаса да, телефоны бар, душы бар. Тагын, беләсезме, нәрсә бар? Бай табын. Коньяк, виски, ул шәрабның ниндиләре генә юк. Икраны кашыклап аша.

Ачылганы да, ачылмаганы да бар. Тагын әллә нинди нәмәстәкәйләр. Бирәү булса, боларга күрмәгәндәй ташланыр иде. Мисбах берсенә дә кагылмады. Габдулла Тукайның «Су анасы»н исенә төшерде:

«Йә иясе юк! — дип, вискиларга тими башладым.»

Йокларга ятар алдыннан Мисбах кичке Мәскәүне карап, бер йөреп керәсе итте. Күркә исләнер дип борчылды борчылуын, аның каравы бүген кунар урын бар. Күпме йөрергә була су аударган түнтәктәй, җил аударган колмактай. Читтән килгән кеше Мәскәүдә кая барсын — Кызыл Мәйданга бара инде. Мисбах та шунда юл тотты. Килеп җитүе булды, ГУМның яктылык төшмәгән почмагында көтмәгәндә-уйламаганда бер кыз пәйда булды.

— Ай, куркыттыгыз, котны алдыгыз, — диде ул Мисбахка көр тавыш белән.

Кыз шәп. Маңгаен каплаган, җилкәләренә агып төшкән туры, сары чәч, борыны — Кремль очында, иреннәре — мавзолей. Турыпочмаклы. Ботлары озын. Нәкъ Спасс манарасы кебек басып тора. Исеме — Наташа. Мисбах үзен «Бах» дип кенә таныштырды. Бу сары баш сүзгә юмарт булып чыкты. Тормышның кыйммәт булуыннан, акча җиткерә алмавыннан зарланды. «Әллә панельгә чыгып ятасы инде», — дип тә ычкындырды. Мисбах аны кызганды. Ресторанга алып кереп сыйламакчы иде, тик үзсүзле хатыны эшне харап итеп куйган булып чыкты. Иртәгә Мәскәүгә китәсе диган көнне төн утырып ире киясе чәчәкле трусикның эчке ягына кесә текте ул. Акчаны да шунда тегеп куйды. Югалмасын, урлатмасын, имеш. Акыллы диген инде син ул хатынны. Акча дип Мәскәү чибәре алдында трусик актарып торып булмый бит инде. Кәшилүктә бераз акча бар барын. Житмәсә, нишләрсең? Бу иркә кошның ресторанда ниләргә заказ бирдертәсен кем белә?

Мисбахның аяклары үзеннән-үзе кунакханәгә таба атлады. Чибәркәй дә күндәм булып чыкты, һич карусыз аңа иярде.

Кайттылар. Төнге кунак кайтуга өстендәге хөлләләрен салып ташлады. Шорты белән майкадан гына калды. Сары чәчкә сары майка бигрәк килешеп тора. Майка нәрсә ул? Кошы шәп! Ул түшләре, ул ботлары... Вәйт күркә бу! Рәхмәт инде Мәскәүгә! Күз кыздырырлык күркәләрне биреп кенә тора Мисбахка.

Кызыкай кайту белән табынга ташланды. Авызына икра тутырды, тавыкны сүтеп бетерде, өстәлдәге бөтен ризыкны козгын кебек чукып чыкты. Әледән-әле шампан, шәраб уртлап куйгалады. Мисбах әле һаман ризыкка тимәде, берни дә ашамады. Ашау кайгысымыни?! Мәскәүнең бер диган чибәре куенына кереп бара. Әнә ул кулларын суза, муеннарга урала, эскертбашны сыпыра. Мисбах күзен йомып рәхәт чигә. Кемгә эләккән әле мондый бәхет?! Мисбахның Казаннан икәнен белгәч, кунак кыз гозерен дә ирештерде:

— Сездә сәүдә институты, йә булмаса сәүдә техникумы юкмы?

— Нишләп булмасын. Бар!

— Мине шунда заочно укырга кертә алмыйсыңмы? Мәскәүдә кереп булмый.

— Нет проблем! Минем анда дус профессорым бар.

— Мин килгәндә миңа торырга урын да табасыңмы?

— Нон проблем! Ярты Казан — минем кулда.

Бәй, бөтенләе белән Мисбахныкы икән бит бу кыз. Мәскәү кошы гына түгел, Казан кошы да булачак бу.

Казан күркәсе!

Утны сүндереп ятаргадыр инде.

«Душка кереп чыгыйк, — диде кыз. — Бар, башта син кер. Сабының бармы? Булса, жәлләмә, әйбәтләп юын».

Сабын да бар, шампунь да бар. Томшык ак күбеккә батып юынды. Фырт кына чыкты.

Чыкса...

Бүлмәнең өсте аска килгән. Идәндә Мисбахның буш кәшилүге аунап ята.

Төнге кош чыгып очкан. Бар, йөгер, тот!.. Тотарсын тазның толымыннан.

Рәхмәт инде хатынына, акчасын трусигына тегеп куймаган булса... Мисбах бер тиенсез калачак иде. Хәзергә ул акчасыз калмады — өнсез калды.

## Мисбахның хәтәр әмер алуы һәм...

Номерда телефон шалтырады. Мисбах трубканы алырга белмәде, алмаска белмәде. Аңа шалтыратмыйлар ич. Томшыкның монда яшәп ятуын эт тә белми. Шулай да тыңлап карарга булды.

— Бахмы?

— Әйе, Бах. Тоист Мисбах.

— Бах, без синдә күпме акча барын беләбез. Башың ике булмаса, син аны безгә бирергә тиеш. Моның өчен аны каядыр китереп куярга тиеш. Кая куясың? Уйла! Биш минуттан шалтыратабыз.

Мисбахның хәле китте. Баш миен куркыныч уйлар телгәләде. «Кем бу? Миндә акча барын каян белә? Бүлмәсендәге телефонның номерын Мисбах үзе дә белми. Теге белә. Кичәге төн кошы — Сары чәч эше түгел микән? Тәгаен, шул визитның нәтиҗәсе бу. Шул Наташа маташа. Алай дисәң, ул төнге күбәләк: «Кызык иттем бу Донжуанны, сукыр тиенсез калдырып киттем», — дип уйларга тиеш бит. Мул табынны күреп: «Акчасы күптер. Яшергәндер», — дип уйлады микән? Теге сукбай-бомжлар эше түгел микән бу? Күркәнең хуҗасы табылу ошамаган боларга, күрәсең. Күзәтеп йөргәннәр. Исемне каян белделәр икән? Әллә инде Казанда ук артыннан бастырып чыктылармы? Их, Мисбах, Мисбах. Бах! Ба-бах. Каптың бит. Хәзер инде хатының белән икегез тырмашып-чәрәшеп җыйган акчаны кая илтеп куясыңны уйла. Башың җәлме, малың җәлме?!

Телефон.

— Алло!

— Ә-ә-ә-әлү. Казан вокзалында, Саклык камерасында булыр акча. Камераның номерын һәм кодны кайткач ә-ә-әйтермен, — диде Мисбах тавышының калтыранганын сиздермәскә тырышып.

— Ике сәгать вакыт сиңа. Шалтыратырбыз. Акчаны куеп кайткан бул! Кара әле, ишетсен колагың, фокус күрсәтергә җыенма тагын. Башыңны сакла!

Фокус дигәннән, Томшык бармагын өзеп, колагын сикертеп, чәчләрен үрә торгызып күрсәтә ала. Бу бандитлар шуны да беләләр хәтта.

Трусик кесәсе сүтелде. Мисбах вокзалга килде. Акчаны тизрәк куярга да кайтып әйтергә. Тизрәк котылырга бу җүнсез, хәерсез бәндә-бәдбәхетләрдән. Тик менә буш урын юк, ә вакыт бара. Мисбах нишләсен — күркәсе яткан таныш камераны ачарга булды. Берочтан «якташының» хәлен дә беләчәк. Ачты. Шунда ук ифрат сизгер борынына тынчыган ис килеп бәрелде. Хәле шәптән түгел күркәнең. Болай булса, исләнергә-бозылырга мөмкин. Ярый, хәзергә әле аның кайгысы юк. Ул кайтырга билет алырлык һәм азмаз тамагына капкалап йөрерлек кенә акча калдырды... Кәгазьгә төрелгән шәмәхә егермебишлек, яшькелт иллелекләр күркә астына кереп ятты. Төптөгәл ике сәгатьтән соң шалтыраган телефонның чәнечкеле трубкасына әмернең үтәлүен әйтте.

Кичкә таба шомлы телефон янә шалтырады. «Уф! Котылдым бу бәладән!» — дип үз-үзен тынычландырып утырган Мисбах бу юлы трубканы чиркангыч бандитлардан жылы сүз өмет итеп күтәрде.

— Әлү!

— Син, Бах, скрипач! Без сиңа әйттек бит, «без фокуса», дидек. Ә син... Тагын безне кәкре каенга терәмәкче булдыңмы? Бу юлы кемнең муенын сыздың? Кемнең башын тыгып куйдың анда? Шуның исенә ментлар килер дә безне эләктерерләр дип уйладыңмы? Белеп тор, ул адәм башын камерадан үзенә чыгарырга туры килмәгәе. Хәзергә син җиңдең: бер — ноль белән. Ну бу исәп бик тиз үзгәрергә мөмкин. Онытма! Онытма җирдә без барын!

«Капрон сумкада яткан симез күркә куркыткан бит боларны. Исе үк котларын алган. Вәйт әкәмәт!» — Томшык тирләгән кулындагы шомлы, кайнар трубканы куярга да онытып ни көләргә, ни еларга белмичә катып калды.

Белмим, бу котелмәгән борчу-хәсрәттән башы тораташ булган Мисбах тагын ниләр уйлап бетергән булыр иде, кичкырын кунакханә бүлмәсенә, артына ут төрткәннәрмени, атылып-бәрелеп бер карачутыр егет килеп керде:

— Мин бу бүлмәдә яшәдем. Хәзер срочно китәргә кирәк. Бик кадерле әйберем калган. Шуны алырга кердем. Аннан башка мин — кулсыз-аяксыз. — Ул җәһәт кенә өстәл тартмасын ачты, аннан җәлт кенә тузган карталар тартып чыгарды, аларны, җәлт кенә, «пыр» иттереп, бер кулыннан икенче кулына очырып алды.

— Син Бах түгелме? — диде Мисбах, таныш кешесен күргәндәй.

— Әйе, Бах. «Скрипач». Мине каян беләсең?

— Телефоннан сорадылар! — дигән булды Томшык берни булмагандай.

— Аңлашылды. Миңа монда озак тоткарланырга ярамый. Чаптым мин. Син мине күрмәдең, яме. Пока!

— Ә шешәләрең, коньякларың, бу икралар...

— Сиңа калдырам.

Бах-скрипач чыгып киткәч, Томшык үз-үзен сүкте: «Их, Мисбах, Мисбах! Көн буена пүчтәк хәсрәт белән йөргәнсең икән бит. Үзе теләп елан авызына килеп кергән чебен бит син. Мөнә кемнән акча сораганнар бит ул бандитлар». Мисбах үз-үзен әрләсә дә, яшь әтәч, сырты кабарган күркә кебек өзлексез чукып торган бу вакыйгаларның мондый борылыш алуына, хәтәр табышмакның чишелүенә бик шат иде.

Ул арада бүлмәгә, җыештыручымы, идән юучымы, администратормы, чурт белсен, бер хатын килеп керде һәм өстәлдәге шәп шешәләрне, затлы деликатесларны капчыгына тутырып алып чыгып та китте.

Мисбах бер сүз дә әйтә алмый, ашарга-эчәргә сораган күркә чебие кебек, авызын ачып калды.

## Мисбахның кайтырга билет алуы һәм...

Йа Хода, Мисбахны мәгънәсез эш-гамәләрдән, монарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән борчу-михнәтләрдән, хәсрәт-газаплардан да азат итәр көнең бар икән. Менә хәзер фырт-кәпери егет үз кадерен үзе белеп вокзалга киләчәк, дәрәҗәле кеше рәвешендә перронга чыгачак, проводникка вәкарь белән билетын сузачак һәм әйтәчәк:

«Әйдә, чап, поезд, Казанга! Менә билетым: мә-мә-мә!»

Аннары йөзенә битарафлык, гамьсезлек билгеләре чыгарып, тыныч кына вагонга узачак. Узарсың, бар. Тыныч кына. Саклык камерасының ишеген ачуга, «Күркәнең исе бар шул бераз» дигән уй аны борчуга салды. Шулай да,

акчаны бандитлардан саклап калган Казан күркәсенә рәхмәте чиксез иде.

Ул Мәскәүнең сару кайнаткыч вакыйгаларыннан, кысыр хәсрәтләреннән арынып, якташ күркәсе салынган капрон сумкасын тотып, йөзенә әлләкем рәвеше керткән булып перронга чыкты.

Чыкса...

— Мисбах!

Кем кычкыра дисәң, Компарттуташ икән.

— Ай Мисбах! Һай Мисбах! Каян килеп чыктың?! Ходай бардыр ул...

— Үзең — коммунист. Үзең Ходайга ышанасың. Нинди парторг инде син?!

— Минем бу әйберләр белән пром-м-блема!

— «Проблеман»ны коммунистлар партиясе хәл итмимени?

— Ай, Мисбах. Булыш, пажалысты. Әйберләремне вагонга күтәреп бар!

Компарттуташның «әйберләр» дигәне, әллә ниткән сумка-мумка, сетка-метка, пакет-макетлардан торган чуар тау. Мисбах шуны кузгатырга, вагонга кертеп утыртырга тиеш.

Бу «тау»ны вокзалга Компарттуташның сабакташ егетләре көтүләре белән алып төшкәннәр. Төшкәннәр дә, Тукай әкиятендәге су эзләп киткән бүреләр кебек, поездга «посадка» игълан ителгәнче кайсы — морожныйга, кайсы сырага дигән булып, берәм-берәм сыпырганнар.

КПСС Үзәк Комитеты каршындагы академия — «коммунизм утравы» буфетларыннан азык-төлекне чумырып, комсызланып алган Компарттуташ кулыннан Мисбах берничек тә ычкына алмаячак иде.

Тауны ташыды.

Ташый-ташый иза чикте.

Соңгы «рейста» Мисбахның портреты менә болайрак иде: ике кулда — бик күп әйбер, ике җилкәдә — аллы-артлы асылган бик күп әйбер. Барысы да — Компарттуташ малы. Үзенең ялгыз күркә салынган бердәнбер сумкасын Томшык теше белән күтәргән иде. Менә шулай, Мисбах, өйрәтә сине бу дөнья, бу тормыш. Теләсә — күркә, теләсә овчарка итә.

Компарттуташны ташый-ташый эт булган Томшыкның үз вагонына кереп, үз урынына килеп утыруы булды, поезд кузгалып та китте. Аның «Хуш, Мәскәү», дип әйтерлек тә хәле калмаган иде. Хәл ана Гусь хрустальная станциясенә җиткәч кенә керде. Шунда аның башында бер идея дә туды. Ис керә башлаган күркәне вагонда тоту, гомумән, өйгә алып кайту әйбәт түгел. Атарга кул бармый. Ул аны урамга алып чыгып, вагон астына бәйләп куячак. Кайтсын шунда атына-атына. Хәлбуки, ул Казанга хәтле кайтып җитә алмаячак, сумканың бавы киселеп, юлда төшеп калачак. Калсын! Үзе төшеп кала бит. Ни дисәң дә үз кулың белән ташлау түгел. Күркә, газиз туган ягына кайтып җитә алмаса да, рәнҗемәс, шөт.

Поезд туктап торган кечкенә генә бер тоңык станциядә бичара күркә салынган сумка вагон астында асылынып тора иде инде.

Ул Арзамас тирәсендә үк төшеп калды бугай әле. Көн сәкедә йоклап яткан Мисбах поезд бер көйгә генә барганда вагон астында нәрсәнеңдер шалтор-шолтыр килүенә сискәнеп уянып китте.

— Хуш, күркә! Бәхил бул!

Тик Мисбах иртәрәк бәхилләшкән булып чыкты. Казанга кайтып төшкәч, вагон астына иелеп караса, күндәм күркәсе сабыр гына асылынып тора инде.

Мисбах сөенде.

Их, күркәм, исән-саумыни син?! Мин сине бит...

Томшык сумканы җәт кенә чишеп алды һәм әйтеп куйды:

«И Казан! Сиңа кайттым ит сәфәреннән туеп тагын да мин.»

Тик Мисбах күркәне барыбер өйгә алып кайтасы итмәде. Тимер юл аша Идел ягына чыккач бер чүплек бар. Күркә белән ул шунда хушлашырга булды. Мисбах тимер юл аша салынган күпер баскычыннан менеп барганда автохуҗалыкның бер көтү ир-атлары «проблемалы» Компарттуташны вагоннан бушатып калдылар.

Чүплекне Томшык тиз тапты.

— Күркәм, матурым, калдырам мин сине. Ачуланма, өйгә алып кертә алмыйм. Хатыннан оят. Шул бер күркәне дә исләндермичә алып кайта алмадыңмыни, дияр. Сүз дә юк, шәп күркә син. Син мине Кремль янында килеп бәйләнгән кызыл Кенәгәле Гайрәтле Бәндәләрдән коткарып калдың. Акчамны башкисәр бандитлардан саклап калдың. Күркәмлекнең күрке син, күркәм! Чын татар күркәсе! Яратам мин сине. Башың киселгән булса да яратам. Хәер, кемнең генә башы киселмәгән татар тарихында. Милләтебезне дә, халкыбызны да әнә шул газиз башлары киселгәннәр коткарып-саклап калган. Татарларны далага-җәһәннәмгә олактырырга теләгән Сталин, каһарман Җәлил һәм җәлилчеләрнең батырлыгы турында ишеткәч, уеннан кире кайткан.

Чүплек контейнеры буш булса да, Мисбах кошны анда томырырга җөрьәт итмәде. Ул аны сумкасы-ние белән ипләп кенә бер кырыйга куйды да башын иеп өенә кереп китте.

## Мисбахның хатыныннан уклау алуы һәм...

Мәскәү кадәр Мәскәүдән ике кулын селтәп кайткан ирен хатыны ничек каршы алды дисезме? Әлбәттә инде, колач җәеп түгел. Сәфәрдән калган акчаларны санап утырганда Мисбахның кесәсеннән килеп чыккан «записка»ны күргәч, кулына уклау эләктерде һәм иренең эскертбашына берне кундырып та алды. Мәктүптә болай дип язылган иде: «Мисбах! Булышуың өчен рәхмәт! Мәскәү күчтәнәчләре белән чәй эчәргә кил. Минем язуны берәүгә дә укытма.» Шунда ук телефон номерлары. «Күр әле бу Компарттуташны! — дип уйлады Томшык. — Ни арада язган моны, ни арада кесәгә тыгып куйган. Язуны укытма, имеш. Укытырмын мин сина арт... партсабагыңны!»

Өйдә җәнҗал кызганнан-кыза барды.

Чү! Ишек шакыдылар. Ачсалар, чәчләре тузгыган кечкенә бер кыз белән авыз-борыны буялып беткән кечкенә бер малай басып тора. Кулларында — күркә салынган сумка!

— Бу сезнеке бит. Сез аны бая онытып калдырдыгыз.

Әле генә ирен каезлап торган хатын сумканы эләктерде.

— Бәй, күркә бит бу. И-и-и тапмадым дип торган була бит әле. Ялганчы! Менә бит - алып кайткансың!

— Бераз гына исләнә башлаган ул.

— И-и-и картым!.. Мин — ничә еллар ашханәдә эшләүче повар — итнең мондыен гына күрмәгәнме сон?! Моннан мин сиңа бер дигән деликатес пешереп бирәм.

Хатын аптырап басып торган, гомер буена ризыкка нәзберек булган ирен кочаклап алды, аның өйдән пыранлаткан вакытта гәүдәсе чыгып та, озын вә аркылы булу аркасында ишеккә кысылып кала торган эскертбашын сыпырып куйды..

Бүлмәгә вагон астында поезд тәгәрмәчләренең өзлексез тыкылдавын тынлап кайткан галиҗәнап күркәдән Мисбахның хатыны тансыклаган шпал исе таралды.

# КӘРИМИЗМНАР

- *Безнең капитализм — ул СССРдан калган розеткага Еврoштепсель төртеп маташу кебегрәк...*
- *Дәшми калу — үч алуның бер төре.*
- *Этләр өрә торыр — барс йөри торыр.*
- *Урысмы син — докажи, татармы син — покажи ...паспортыңны.*
- *Мин-минле автор язудан туктаса донос жанрына күчә.*
- *Ир кеше тәрәзә уя, хатын-кыз пәрдә кора.*
- *Хатын-кыз тудыручы, ир-ат күмүче...*
- *Яратмаган кеше белән яшәү — ялгызлыкның бер төре.*
- *Рәхәт булган җирдә хәтәр бар.*
- *Диагноз: хроник шымчы.*
- *Бүгенге дантесларга пушкин җиткерер хәл юк.*
- *Алманың хакын ашагач сорама.*
- *Ялкау байдан ярлы туар.*
- *«Туксан тугызлы» килеш тә йөзгә җитте.*
- *Иманын укыттылар, укыттылар да имтихан алдылар.*
- *Кәрлә патшага бил бөгүе кыен.*
- *Яшь җитәкче үзе китә, олайганы — сугыш игълан итә.*
- *Ак йортта таң атканда — Кремльдә караңгы төшә.*
- *Көч беткәч уйнарга ярый.*
- *Саулык артыннан куып бик күп авырулар «бахилла»шты.*
- *Ауган агачка тукран да кунмый.*
- *Хатыны әйтә: кунып кит, ди.*
- *Нихәл, дип сорасаң — йөткерә башлый.*
- *Күп белсәң — тиз картайтырсың.*
- *Татар үлгәннән соң да өч көн яши ала.*
- *Чиратың якынайган саен дус-ишләр күбәя.*
- *Ришвәт акчалары озынайгач конвертлар да зурайды.*
- *Син гафу ит, мин икейөзле кешеләргә генә «Сез» дип дәшәм...*
- *Залга тамашачы җыюлары авырлашты: ярлының акчасы юк, байлар өйдә мөлкәт саклап ята.*
- *Йолдызлар фаразы кушканча кавышу: алтмыш яшьлек Сарык утыз биш яшьлек Бозауны йортка керткән.*
- *Реклама: Батулланың егерме томлыгын укып чыккан кешегә Әмир Мәхмүдовның дүрт томлыгын бүләк итәбез!*
- *Дөньяның фанилыгы — киткән кеше урынына яхшырагы килгәне юк әле...*
- *Зур Хуҗа килгәч, кечкенә хуҗалар Хуҗа Насретдинга әверелә.*

**Камил КӘРИМОВ**



Язучы Шәриф Камал үзенең эш бүлмәсендә укучы яшьләр белән бергә. 1939 ел.



Рәссам, сынчы Бакый Урманче (1897-1990).
1981 елда төшерелгән фоторәсем.



Язучы Алмаз Гыймадиев һәм шагыйрь Вахит Галиев Шәйхи Маннур һәйкәле янында. Мамадыш. 2001 ел.



«Казан утлары» журналында озак еллар эшләгән каләмдәшебез Рашат Низамиев. 1985 ел.



Нәкый Исәнбәт, Михаил Луконин, Мөҗәһит Вәлиев (КПСС өлкә комитеты секретаре), Мостай Кәрим. Тукайның 90 еллык юбилее көннәрендә. Арча районының Яңа Кырлай авылы. 1976 ел.

Туфан
Миңнуллин

# ҮЗГӘРҮ

ҮЗЕМ ТУРЫНДА ҮЗЕМ

## Милләт

Минем яши-яши нык үзгәрүем милләт мәсьәләсендәдер. Милләтнең ни икәнен, нәрсә аңлатканын, нигә кирәклеген аңламаган малайдан милләтемнең үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында уйланып, борчылып, хәлемнән килгәнчә аны яшәтер өчен көрәшүче кешегә әверелдем. Милләт мәсьәләсендә әле дә күп нәрсәне аңлап бетерә алмыйм. Кайчакларда уйлап-уйлап торам да, нигә адәм баласы үз милләте өчен җан ата, кем булсаң да барыбер түгелмени дип уйлап куям. Нигә татар дип өзгәләнәм, урыс булдың ни, чуаш, кытай, чукча булдың ни, яки берсе дә булмадың ди, кеше генә булып калдың ди — шуннан ни үзгәрә? Күрәсең, үз милләтеңә тартылу ул Ходай тарафыннан җаныңа салынган хикмәттер. Югыйсә дөньядагы бөтен хатын-кызлар да әйбәт, ә менә әни кадерлерәк, бөтен ирләр дә яхшы, әти якынрак. Бер караганда ни аермасы бар? Тууга ук ияр дә кит берәрсенә. Юк шул — кан җибәрми, инстинкт рөхсәт итми. Адәм баласында гына түгел, хайваннарда да кан күзәнәкләренең берлеге, фән теле белән әйткәндә, геннар берлеге саклана. Анда да бүреләрнең үз өере, антилопаларның үз көтүе.

Сабый чакта милләт дигәнең шул әти белән әниең, абый-апаларың, апа-сеңелләреңдер инде. Үсә төшкән саен дөнья киңәя бара; туганнарыңның күп икәнен аңлаталар. Нәсел дигән сүз барлыгын беләсең. Хәтерлим әле, бала чакта бүрәнә өстендә утырган агайлар кемнең кемгә кайсы яктан туган икәнлекләрен тикшерәләр иде. Нәтиҗәдә авылыбызның бөтен кешеләре бер-берсенә туган булып чыкты. Хатыйп абый гына чит, чөнки ул Салтыктан килеп безнең авылга Саимә апага йортка кергән. Ләкин бераз утыргач, аның да ят түгеллеге ачыкланды. Кемдер Салтык кызына өйләнгән, кайсыдыр Салтык егетенә кияүгә чыккан. Бара-тора тирә-як авылларның да туганнар икәнлеге беленде. Барысында да бер канның кушылмалары бар икән ләбаса. Әйе, милләт шулдыр инде ул. Шуңа да татар татарга, урыс урыска якындыр. Хәер, анда да күпме кан кушылган. Анысы туганлыкның кешелек дөньясы дип аталуына барып тоташадыр. Әлегә кешелек милләтләргә бүленеп яши, милләт, димәк, туганлыкның иң якын формасы. Шушы уйланулардан чыгып, минем татар булуым минем каныма салынган, шуңа күрә мин шул татар дигән кавемгә тартыламдыр дигән нәтиҗәгә киләм — һәм:

*Агай-эне ак мыек,*
*Бер-беребезне какмыек,*
*Каккан-суккан чакларда да*
*Бер-беребезне яклыек, —*

дигән уй белән яшимдер.

*Дәвамы. Башы узган санда.*

Милләтнең ни икәнлеген аңларга миңа гомерем буена тормыш өйрәтте. Мин туган районда урыс авыллары күп иде, районның үзәге — Кама Тамагында — гел урыслар гына яши иде. Беренче булып, әлбәттә, урысның без түгеллеген аңладым. Чөнки безнеңчә сөйләшмиләр, киемнәре дә, ашаган ризыклары да үзгә. Тора-бара безнеңчә сөйләшмәүнең сәбәбе аңлашылды — алар башка халык, урыс дип аталган халык икән. Мәктәптә ул халыкның бөек икәнлеген укыттылар. Аны безгә үзебезнең апалар өйрәттеләр. Укытучы әйткәч, аның дөреслегенә без шикләнмәдек. Тик менә ул бөек халыкның телен өйрәнү генә ачуны китерде. Алар сүзен дөрес әйтмәсәң дә, дөрес язмасаң да «2»ле куялар. Шул чактадыр, күрәсең, урыс булу теләге күңелгә кереп оялагандыр. Бераз вакыт үткәч, дөньяда урыслардан башка да кешеләр яшәгәнен белдек. Безнең районда мукшы авыллары бар иде. Баштарак аларны нигә мукшы дип йөрткәннәре аңлашылмады, чөнки алар безнеңчә сөйләшәләр иде. Чуаш дигән халык та бар икәнлеген Галимулланың Хисмәт исемле бабасы аша белдем. Аның кушаматы Чымырчуат иде. Чымырчуат чуаш сүзе булып чыкты, яңгыр ява дигәнне аңлата икән. Галимулланың бабасы чуашлар белән бергә эшләгән икән.

Дөнья киңәйгән саен, анда төрле телдә сөйләшүче күп халыклар, ягъни милләтләр барлыгы ачыкланды. Алар дус яшиләр икәнлеген укыттылар. Бик үк дус булмаганнарын тормыш күрсәтте. Аларга мин «халыклар дуслыгы» бүлегендә киңрәк итеп тукталдым.

Әйткәнемчә, бүген мин — милләтче татар. Бүген инде минем беркем дә буласым килми. Бабайлардан күчә-күчә килгән кан ныграк уйный. Күп тапкырлар әйттем, яздым, тагын да кабатлыйм: бу татарлыгым бүтән халыкларны кешегә санамаудан түгел, менә шул халыклар арасында татарым да барлыгын һәм аның беркемнән дә ким түгеллеген аңлауда һәм аны озаграк яшәтергә теләүдә, яшәвемнең мәгънәсе кемдер булып түгел, татар булып яшәвемдә һәм туганлык канын бездән соң килгәннәрнең тамырына аз булса да салып калдыруда. Башка милләтләр белән кан кушылуының кая алып баруын белми үстем мин. Күрше рус авылларындагы маржа кызлары кызыктыра иде. Чибәрләр иде. Аларга өйләнү хыялы мин һәм минем кебекләрне күп ялгышлар ясарга этәрде. Ни кызганыч, безгә аны ныклап төшендерүче булмады. Кан тарта дигән сүзнең мәгънәсен аңлап бетермәдек шул. Хәзер дә бик күпләр аңлап бетерми. Ә кан чыннан да тарта икән. Әнә шул төрле милләт канының кушылганнан соң да тарткалашуы безнең милләт файдасына булып чыкмады. Без җиңелгәннән җиңелә барабыз. Уйландыра. Бу бүлек — шул уйлануларның бер өлеше.

Без милли мәсьәләне күтәргәндә кайбер шовинист «теоретиклар» бүтән илләрне мисалга китереп, алар моделен безгә такмакчылар. Мәсәлән, дөньяның бик күп милләтләре җыелып яшәгән Америка Кушма Штатларын мисалга китерәләр. Имештер, анда милли проблемаларны бездәге кайбер милләтчеләр кебек кабыргасы белән куймыйлар, кискен бәхәсләрсез генә яши бирәләр. Ләкин шунысын әйтергә «оныталар» — Американы «ачучылар» андагы төп халыкны (индеецларны) кырып бетереп «татулыкка» ирешәләр. Россиядә дә милли мәсьәләне шулай чишәргә тырышалар. Бөтен милләтләрне руслаштырып, проблемасыз бер милләтне генә калдырырга әллә нинди мәкерле планнар коралар. Ләкин еш кына каршылыкларга очрыйлар. Чөнки Россия территориясенең күптин-күп өлеше борын-борыннан шунда төпләнеп яшәгән милләтләрдән тора. Күзе туймаган агрессив хакимнәр рус халкын туктаусыз өстереп, тыныч холыклы халыкларның сугышырга өйрәнмәгәнлегеннән файдаланып, күп җирләрне яулап алганнар да, «исконные русские земли» ясаганнар. Һәм оятсызларча башта көчләп чукындырырга тотынып, аннары телләреннән яздырып, урыс ясарга керешәләр. Гасырлар буе шушы сәясәтне дәүләт күләмендә алып барып, әйтергә кирәк, уңышларга да ирешәләр. Аз санлы милләтләрне ашап бетерә баралар. Ашау сүзен адәм аңламаслык сүзләр белән бизиләр: ассимилияция, толерантлык, глобализация... Көчлерәк милләтләр үзләрен саклар өчен көрәшәләр. Шул көрәшүчеләр арасында союздаш республика исемен алып, аннан соң империя мәкерләреннән котылган милләтләр дә бар. Без татарлар читлектә калдык.

Нишләргә? Борынгы мәдәнияте булган, тарих сәхифәләрендә зур урын

алып торган милләтне ничек сакларга? Бүген безнең төп проблемабыз шуннан гыйбарәт. Мин үзгәрә-үзгәрә шуны аңлар дәрәҗәгә килеп җиттем шикелле һәм, хәлемнән килгәнчә, милләтемнең исән калуы өчен көрәшәм. Һәм, Ходайның биргәненә шөкер, көрәштәшләрем без сукранганча ук аз түгел. Көрәшнең формалары күп төрле. Көсәккә каршы көсәк күтәрү акылсызлыктыр. Чөнки Россия көсәге һаман да әле саллы һәм рәхимсез. Ул мөстәкыйльлеккә омтылучыларны вәхшиләрчә дөмбәсли. Чеченнар омтылып караганнар иде, пыран-заран китерделәр. Күрәсең, көрәшнең бүтән алымнарын эзләргәдер. Минемчә, безгә бердәнбер юл — милләтнең милли аңын тәрбияләргә, камилләштерергә, үстерергә кирәктер. Телебезне, гореф-гадәтләребезне, динебезне саклауның механизмын эшләү һәм хәрәкәткә китерү зарурдыр.

Ә бит ул механизм булган. Өстенә нинди албасты килгәнен чамалап, милләтебез йомылган, үз эченә качкан. Агрессия максатына хезмәт итүче чит гореф-гадәтләрне, чит мәдәниятне кертмәгән, аларның нинди йогышлы чир икәнен белгән. Ләкин, ни кызганыч, без тиз ышанучан халык, сәүдә өлкәсендә хәйләкәрлек күрсәтсәк тә, сәясәттә тиз алданабыз. Аның иң ачык мисалы: Октябрь революциясен хуплап каршы алып, Гражданнар сугышында большевикларны яклап сугышып, Россиядә совет власте урнашуына куанып алдандык. Чөнки большевиклар безгә дәүләтчелек вәгъдә итте, үзбилгеләнү хокукын бирү турында сөйләде. Һәм дәүләт бирде дә сыман. Автономия генә булса да, шуңа сөендек. Киләчәктә мөстәкыйль булу турында хыялландык. Һәм алдандык. Россиядә империянең исеме һәм формасы гына үзгәрде. Һәм без шул империянең хокуксыз халкы гына булып калдык. Әгәр дә ышанмыйча үз кабыгыбызда йомылып яши бирсәк, бәлки бу хәлгә үк төшмәгән булыр идек. Хәер, кем белә, Сталин ул кабыкны рәхимсез көсәге белән бәреп ваткан да булыр иде. Чөнки яулап алучыларның сәясәтен дәвам итүчеләр милләтләрнең «үз кабыгына бикләнү һәм аның зарары» дигән нәрсә уйлап тапканнар иде инде. Бүген без үз кабыгыбызга бикләнүдән бөкәйдән курыккан кебек куркабыз һәм әкрен-әкрен читләр кабыгына кереп бикләнеп юкка чыга барабыз. Без бүген ияреп кенә йөрүче милләткә әйләндек шикелле.

Хәтта безне берләштереп торган Ислам дине мәсьәләсендә дә башкалар итәгенә тотынып баручы сабыйларны хәтерләтәбез. Заманында Гарәбстан, Иран кебек көчле илләрнең көчле дин белгечләре белән бергә-бер торып бәхәсләшә алган Курсавилар, Мәрҗаниләр юлыннан тайпыла башладык. Асылда урыс тәрбиясе алган, туган телен югалткан яшьләребез Гарәбстанга барып ислам диненең татарга ят юнәлешләрен алып кайталар. Мәчетләребезгә, телебез сакчылары булган гыйбадәтханәләребезгә безне бетерергә көйләнгән рус телен алып керәләр.

Без толерантлык дигән сүзне бүтәннәргә хезмәт итү дип кенә аңлыйбыз. Искиткеч гүзәл, сыннарына килешеп, ятышып торган, гасырлар буе буыннан-буынга күчеп камилләшкән милли киемнәребезне башта Европага ияреп салып ташладык, хәзер инде дини булуыбызны гарәп балахоннарына төренеп исбатламакчыбыз. Белмим, Европа ишәге булырга теләмичә, гарәп сарыгы булуның ни өстенлеге бардыр. Ходайга баш оруның бердәнбер урыны итеп бары тик хаҗ кылуны гына санап, халыкның бүтән изге урыннарында дога кылуын хәрәм санаучылар пәйда булды. Минем өчен кагъбә ничек изге булса, төрки бабаларыбыз җирләнгән урыннар да изге. Ходайга табынырга кирәк, әмма ул Гарәбстанда гына пропискада тормый, кодрәте минем җиремә дә таралган.

Мин милләт белән динне аерып карамыйм. Кайсысына өстенлек бирергә дә белмим. Кайвакытта уйлап-уйлап йөрим дә, борынгыдан килгән телебезнең, гореф-гадәтләребезнең юылып юкка чыга баруын күреп, үлчәүнең авыр башы милләттәдер дим; кайвакытта исә динебез безне саклап калган урыннар белән очрашып, үлчәүнең угы дин ягына авыша. Совет заманында театр белән Литвага гастрольгә барган идек. Шунда «Кырык татар» дип аталган авылда булдык. Телләре инде татарныкы түгел, исемнәренә карап, безнең нәселдән икәнлекләрен чамалап була, ә диннәре — ислам дине. Зиратларында кабер ташларына гарәп язуы белән чокып язылган дога сүзләре. Һәм алар үзләрен татар дип саныйлар. Ләкин, ни кызганыч, алдарак әйткәнемчә, алар инде барыбер чын

татар түгел, югалып баручы, читләр мәдәниятенә хезмәт итүче кавем генә.

Үзгәрелә. Югыйсә миңа үскән чакта милләтең ни, чуртың ни иде. Татар сүзе комачаулый да иде. Антоновка авылына салам башлы чибәр-чибәр маржа кызларын кочаклап булмасмы дип баргач, «уйди, татарин» сүзен ишетү хурлык иде. Урыс малае буласы килгән чаклар була иде. Үзеңнән көлгәнне күреп тору авыр бит ул. Урыс бездән көлсә, без дә үз чиратыбызда үзебез түбән дип санаучы милләтләрдән көлә идек. Бәлки, көлүебездә явызлык булмагандыр, әмма аның төбендә мыскыл итү, түбәнсетү ята иде. Әле дә оялып искә ала торган бер вакыйганы сөйләмичә булдыра алмыйм. Бервакыт бер авыл мәктәбенең укытучылары белән мари авылына бардык. Кыш көне иде, җылынып чыгарга дип «җылыткыч» алдык та шуны «салып кую» өчен бер мари өенә кердек. Минем юлдашларым киез итекләрендәге карны да какмыйча (итекләрне салу юк та юк инде) түргә уздылар. Мин сап-сары итеп юылган идәнне күреп, киез итекләрне салмыйча булдыра алмадым. Шунда бер яшь укытучы: «Салма итегеңне, Туфан абый, мари өе ич бу», — димәсенме. Соңыннан беленде: өй хуҗалары татарча аңлыйлар иде. Алар караңгы чырай күрсәтмәскә тырыштылар, әлбәттә, ләкин миңа карашлары икенче төрле иде. Ягымлы иде. Аның каравы, авыл кибетендә ишетмәгәнемне ишеттем. Сатучы гаҗәеп чибәр мари кызы иде. Аның күзләренә карадым да тораташ булып катып калдым. Шундый да серле күзләр! (Андый серле күзләр фин-угыр халыкларында еш очрый). Карап торам сүз әйтергә дә кыймыйча кибетче кызның күзләренә. Түзмәдем: «Нинди серле күзләр! Урман күле кебек!» — дидем. Мари кызы нәфрәтле карашын миңа төбәп, урысчалап: «Чево напялился, проклятый татарин!», — димәсенме. Оятымнан җир тишегенә кереп китәрдәй булдым. Бу — Россиядәге милли сәясәтнең гариплеген күрсәтүче факт.

Әллә Россиядә генә түгел, бөтен Җир шарында да үзен өстен санаучыларның түбән дип санаучылардан шаярып та, мыскыллап та көлүе табигый хәл микән? Куркыныч нәрсә, бу хакта уйлыйсы да килми хәтта. Мин акылым белән дә, күңелем белән дә җир өстендәге бөтен халыклар да бертигез дип санаучы. Ходай адәм балаларын тигез итеп яраткан, аларга бер кояшны бүләк иткән. Кемнәрдер шул кояшны приватизацияләргә җыена. Коточкыч вәхшилек. Гомумән, Россия дигән илдә бер милләтнең икенчесен хурлавы — кабул ителгән норма. Һәр милләтнең аны мыскыл итә торган кушаматы бар иде. Аларны хәтта искә аласым да килми.

Бер уңайдан яһүд халкы турында да берничә сүз әйтмичә түзә алмыйм. Россиядә тәртипнең булмавын рус милләтчеләре яһүдләрнең яшерен сәясәтеннән күрәләр. Без дә үз чиратыбызда ул халык турында рәтле сүз әйтмибез. Бөтен «этлек»не алардан күрәбез. Минем бу фикер белән килешәсем килми. Мисаллар бар. Безне Мәскәүдә театр училищесында барысы да диярлек яһүд милләтеннән булган педагоглар укытты. Бездән артист һәм кеше ясар өчен шундый тырыштылар ки, аларны гаепләп сүз әйтергә телем бармый. Мин аларның һәрберсенә рәхмәтле. Дөньяга күзем алар ярдәмендә ачыла башлады минем. Әйе, яһүдләр — Россиянең эчке сәясәтен җитәкләүче халык. Шуңадыр безнең аларга дәгъваларыбыз бар. Әмма Рәсәй халкы ялкау, куркак, эшлексез булганга алар гаепleme? Алардан өйрәнәсе урынга без аларны сүгәбез. Татарның да рус милләтчеләренә ияреп яһүдләрне сүгеп йөрүе — безнең булдыксыз милләткә әйләнә баруыбыз галәмәте. Яһүдләр, мәсәлән, безнең кебек яһүд теле нигә кирәк ул дип ахмак сүз сөйләп йөрмиләр, үз-үзләрен, бер-берсен яклый беләләр. Шулай булмаса, әллә кайчан юкка чыккан булырлар иде. Алардан үрнәк алырга кирәк безгә.

Игътибар итсәк, яһүдләр турында мәзәкләр (анекдотлар) күп. Ләкин аларның берсендә дә, һәрхәлдә мин белгәннәрендә, яһүдне мыскыл иткән сүзләр юк. Чөнки ул анекдотларның авторлары яһүдләр үзләре. Алар үзләреннән көлсәләр дә, матур итеп көлә беләләр. Ә безнең анекдотларда без кем? Искә төшерәсем килмәсә дә, гыйбрәт өчен берничәсен язмыйча булдыра алмыйм.

Төрле халык вәкилләре, үлгәч, оҗмахка керергә чират торалар икән. Оҗмахка кертүче фәрештә чираттагыларның кайсы халыктан булуларын сорап тора икән. Урыс булганнарга:

— Кер әйдә, пумушнигым булырсың, — дип әйтә икән.

— Чуашың, — диючегә:
— Кер, табак-савыт юарсың, — дия икән.
— Керәшен, — дигәннәренә:
— Бизәвсәкеве керәсең, — дип әйтә ди.
— Татарың, — дисәләр:
— Кит, ботыңнан тотып атармын, — дип кычкыра икән.

Теге дөньяда тәмугта гөнаһлы бәндәләрне казаннарга салып кайнаталар икән. Бөтен казаннарның да капкачлары бар, татарлар кайнаган казанның гына капкачы юк ди.

— Нигә алай? — дип сораучыларга тәмуг башлыгы:

— Башка казаннарны ачсак, анда кайнаучыларның чыгып качулары ихтимал, ә татарларның берәрсе казаннан чыгып качарга уйласа, бүтәннәре аны ботыннан сөйрәп төшерә, — ди икән.

Мәйданда бер багана тора икән. Анда: «Баганаың башына менүчегә ни теләсә, шул нәрсә бирелә», дигән язу ябыштырылган икән. Бер төркем татар шул язуны укыганнар да:

— Әйдә, меник, үзебезгә ирек сорыйк, — дигәннәр. Аерым-аерым менәргә тырышканнар, булдыра алмаганнар — шуып төшәләр икән. Шунда берсе:

— Әйдә, болай эшлик, беребез җилкәсенә беребез басып меник, — дигән.

Шулай эшләгәч, бер татар багана башында аркылы менеп таякка утырган. Астагылар:

— Сора, әйдә, irekне, сора, — диләр икән.

Өстәгесе исә:

— Вон отсюда, гололобые татары, — дигән.

Бу куркыныч мәзәкләрне кем уйлап чыгаргандыр, белмим, әмма анда без мескен һәм әшәкеләр итеп сурәтләнгән.

Боларны ишеткәч, элек мин көлә идем, хәзер сөйләсәләр, җен ачуларым чыга. Чөнки теләсәләр ничек кимсетергә тырышсалар да, без мескен халык түгел.

Минем кәефемне кырган тагын бер нәрсә бар — без үткәннәр турында сөйләгәндә мактанып: «Патшаларның кучерлары арасында татарлар да булган, Ленин да үзенә шофер итеп татарны сайлаган, чөнки без ышанычлы халык, дибез. Ышанычлыдыр шул. Рәсәйне Рәсәй итеп саклар өчен татар күпме кан түккән һәм түгә. Тик шуның бәрабәренә ни алган? Ышанычны аклаган өчен аңа ни бирәләр? Телен кисәләр. Аны бетерү өчен әллә ниләр кыланалар. Әйе, Рәсәй рәхмәтле ил түгел.

Тел кисү дигәннән, бер гыйбрәтле вакыйга. Бервакыт башкорт шагыйре Мостай Кәрим: «Мәскәү белән Казан арасындагы мөнәсәбәтләрнең киеренкелеге аңлашыла, чөнки сезне Мәскәү яулап алган, ә без башкортлар — үзебез кушылдык. Безнең мөнәсәбәтләр элек-электән дустанә», — диде. «Дустанә булгач, нигә соң Пугачев восстаниесе вакытында Мәскәүгә каршы чыктыгыз? Нигә ул вакытта башкортларның телләрен, колакларын кистеләр?» — дигән идем, сүзем Мостай агага ошамады, янымнан күчеп утырды. Саграк булыйм бу татар милләтчесеннән, дип уйлады булса кирәк.

«Милләтче» дигән төшенчә озак еллар, минем аңлавымча, яман сүз иде. «Татар милләтчеләре» дигәнне ишеткәндә аны әйтүчеләр ягындарак идем. Милләтне яклаучыларның кискен чыгышларын тыңлаганда, нигә кирәк инде куертырга, диебрәк тыңлый идем. Ул мәсьәләдә күзем ачыла башлау 80 нче елларга туры киләдер. Мәскәүдә ике еллык Югары әдәби курсларда укыган чак. Анда СССРда яшәүче төрле милләт язучылары белемнәрен ныгыта, әдәби осталыкларын камилләштерә иде. Шунда еш кына милли мәсьәләләрдә бәхәс куба иде. Хәтеремдә әле, бер рус язучысы үз халкын бөтен халыкларга да мәдәният алып килүче халык дип әйткәч, без шагыйрь Зөлфәт белән аңа каршы чыктык: «Мисаллар китереп дәлилләә», — дидек. Үзенчә дәлилләр китергән булып маташканда бер сүз әйтеп тегене дәшмәс иттек. «Без бит сезнең кызларыгызны, хатыннарыгызны ыштан кияргә өйрәттек», — дидек. Шунда Ленинградтан Михаил Глинка исемле шагыйрь, башта безнең сүздән тәмләп

көлде дә: «Когда мы были цивилизованным народом, вы, татары, еще как птицы летали», — диде. «Может быть, — дидек, — но мы в данный момент говорили о русских и татарах, о евреях не говорили», — дидек. Чөнки Глинканың еврей милләтеннән икәнен белә идек. Шунда рус халкының «Где татарин прошел, там еврею делать нечего» дигән мәкален дә исенә төшердек.

Безнең курсларның секретаре — Нина Аверьяновна Маликова — мөлаем ханым иде. Шуңа мин бервакыт: «Нина Аверьяновна, не замечайте наши прогулы, мы же с вами одной крови», — дидем. «Как так?» — ди. «Ваша фамилия татарская, значит, ваши предки татары», — дидем. Ул гаҗәпләнде. «Ладно, спрошу у мужа, это его фамилия», — диде. Сораганмыдыр, белмим, әмма очрашкан саен: «Ну как, мой пропускающий лекции татарин», — дип елмая иде. Сөйкемле ханым иде шул.

Бу милләтчелегем минем аңлап эшләгән гамәлем булмагандыр әле, инстинкт — кандагы татарлыкның уянуы гына булгандыр. «Шовинист» дигән сүзнең теоретик яктан ни икәнен белсәм дә, аның мәкерле аслын аңлап бетермәгәнмен, аерым кешеләрнең җитешсезлеге дип кенә кабул иткәнмен. Әйе, Россиядә яшь буынны шовинистик рухта тәрбияләү, урыслаштыру — дәүләт югарылыгында хупланылган сәясәт. Ул иң әүвәл мәктәпкә беренче тапкыр аяк баскан балалар аңына сеңдерелә. Мәктәптә генә түгел, балалар бакчасында да балалар кулына бирелгән рәсемле китапларда урыслар бик әйбәт, бөек халык итеп сурәтләнә, татар исә «поганый». Мин кызымны беренче класска алып бардым, ул шул көнне «мин татар булмыйм» дип кайтты. Анда аны, кысыграк күзле булгангадыр инде, балалар бакчасыннан килгәннәр «дочь Чингизхана, поганая татарка», дигәннәр. Татарның поганый түгеллеген аңлатырга шактый тырышырга туры килде миңа. «Кызым, мин бик начармы?» дигән соравыма ул: «Син бик яхшы», — диде. «Мин бит татар», — дигәч кенә азрак акылга килде. Икенче бер мисал. Бер мәктәпкә очрашуга бардым. Сәхнәдә милли киемнәр кигән кызлар татар биюен бииләр. Залда минем янәшәмдә ике кызый утыра. 8-9 яшьләрендә. Шунда берсе икенчесенә әйтә: «Смотри, Гузелька, татарочки танцуют», — ди. «А вы кто?» — дип сорыйм болардан. «Не знаем», — диләр. Югыйсә берсе Гүзәл, икенчесе Алсу исемлеләр.

Милләтчелек бары тик шовинизм булган җирдә генә начар юнәлеш алганына төшендем мин. Милләт мәсьәләсендә арттырып җибәрүчеләр бездә бар инде ул. Татар икәнлегем белән горурланам, диләр кайберәүләр, шулай дип шигырьләр язалар. Мин горурланмыйм. Нигә горурланырга ди? Ул бит аягың-кулың барлыгы белән горурланган шикелле инде. Минем девизым: «Татар дөньядагы бер халыктан да ким түгел, һәм, әлбәттә, артык та түгел». Минем җир йөзендә татар булып яшәргә тулы хакым бар. Кемдер Ходай биргән шушы хокукны чикли икән — ул минем дошманым. Бетте-китте — вәссәлам. Мин җир өстендәге бер генә халыкны да күпсенмим, аның ничек яшәвенә тыкшынмыйм, минемчә яшәргә кыстамыйм.

Кан кушылуы турында әйткән идем инде. Әйе, катнаш никахларны өнәмим. Монда мәсьәлә кайсы милләтнең әйбәт яки начарлыгыннан тормый. Милләтләр төрле булгач, тәрбия ысуллары да төрле, шуларны бәрелештерү кирәкмидер дип саныйм. Абстракт милләтне кабул итмим. Чөнки ул җирдәге төрлелекне бетерү хисабына оеша торган төссез гавәм. Космополитизм минем өчен ят. Җир өсте төрле төстәге чәчәкләр, агачлар булуы белән гүзәл, хайваннар дөньясы арысланнан алып сукыр тычканына хәтлесе белән матур, кешеләр төрле-төрле телдә сөйләшүләре, төрлечә яшәүләре, төрле кыяфәттә булулары белән кадерле.

Глобальләштерүне, ягъни мәсәлән, милләтләрнең берләшеп, буталышып бетүен табигый процесс дип аңлатырга тырышучы галимнәр барлыкка килде. Янәсе, бүгенге дөньяда кешеләр күп аралаша, ә аралашыр өчен бер-береңне аңларга кирәк, аңлашыр өчен бер тел булуы зарури, диләр. Аралашканда кешеләр бер-берсенең гореф-гадәтләрен, яшәү рәвешләрен дә алалар, үзләштерәләр, диләр. Нәтиҗәдә, аз санлы милләтләр үз асылларын югалтып, юкка чыгалар, диләр. Чөнки алар глобальләштерүгә каршы тора алмыйлар, диләр. Ни кызганыч, ул процесс бара, инде җир өстендәге аз санлы күп

милләтләр югалып, җирнең матурлыгы, бизәге дә кимеде. Ләкин бу процесс табигый түгел. Ходай халыкларны төрле-төрле итеп яраткан, кемнәрдер югалырга тиеш дип планлаштырылган булса, яратып та тормаган булыр иде. Димәк, глобальләштерү теориясе уйдырма. Ул агрессив дәүләтләрнең (бәлки, халыкларныңдыр да) бүтәннәрне йотуын аклар өчен уйлап чыгарылган. Россия Дәүләт Думасының 309нчы законны чыгарып, рус булмаган халыкларны үз телләрендә укытуны тыюы табигый процессмы әллә? Бу — вәхшиләр законы, рус булмаган милләтләрне ашау законы, бу — каннибализмга тиң закон.

«Ашау» Россиядә генә түгел, төрле формаларда бүтән агрессив дәүләтләрдә дә бара. Татарларны ашау дәүләтчелегебезне югалткан көннән башланды һәм бүген фаҗига төсен алды. Фаҗигагә тарыса, адәм баласы эчендәге кулланылмый яткан ресурсларын эшкә җигә. Халыклар да шулай. Һәрхәлдә, шулай булырга тиеш. Без еш кына үзебезне берләшә алмауда гаеплибез. Татарны татар үзе бетерә, дибез. Бу гаепләүдә, бәлки, күпмедер дөреслек бардыр. Әмма бу безнең халыкка гына хас сыйфат түгел. Күп халыклар үзара ыгы-зыгы килеп яшиләр. Шул исәптән, рус халкы да ул сыйфаттан азат түгел. Аны Россия дәүләте берләштереп, җыеп тота. Без дә, өстебезгә афәт килсә, бер-беребезгә якынаябыз. Халык бит өстенә дошман килгәндә берләшә. Безне бу инде каршылык күрсәтергә сәләтсез, таркалып беткән халык дип уйлаучылар, 90нчы елларда безнең бердәм җыелып алуыбызны күреп, шүрләп калдылар. Кайвакытта мин болай дип тә уйлап куям: безне әзрәк кысалар, ныклабрак кыссыннар иде, ул чакта, бәлки, өстебезгә ябырылучы афәтнең килеп җиткәнен, башыбызны кисәргә күтәргән балтаның йөзен абайлап, саклану чараларын күрер идек, гамьсезлектән айнып идек. Айнысак, Тукай әйткән гафләт йокысыннан уянсак, нидер эшли алыр идек. Бармы безнең милләтнең эчке, йокымсырап яткан ресурслары? Мин бар әле дип саныйм. Мин узган юл милләт белән бергә узылган. Әгәр мин үзгәрә-үзгәрә миллилекнең адәм баласы өчен кадерле нәрсә икәнен аңлый башлаганмын икән, бүтәннәрдә дә үзгәрешләр булган диган сүз. Әйткәнемчә, безнең милләт аны туксанынчы елларда исбатлап күрсәтте инде. Ул елларда күп ихтыяр көче сарыф итеп арып, бүген бераз ял итә икән, учакларда ут әле сүнмәгән. Ялкын булып күтәрелергә әзер тора дип уйлыйм. Һәрхәлдә, ышанасым килә. Дөнья күләмендә булмаса да, Россия күләмендә үзебезне саклап калырлык потенциал куәтебез бар. Бу — безнең тарихыбыз, борынгыдан килгән мәдәниятебез, безнең җаннарыбызда яшәгән дәүләтчелек идеясе. Кайчандыр дәүләт тоткан халык барыбер шуны кайтару турында уйлый. Әгәр дә без милләт буларак җир йөзеннән югалабыз икән, рус шовинистлары хыялланмасын, алар да безнең белән бергә югалачаклар. Хәер, рус үзе дә бара инде, имгәтелгән теле генә калып барып, русскоязычный халыкка әйләнә. Юкка гынамыни Россия гражданнарының милләтен «россиянин» дип кенә атарга тәкъдим итүче акыллы башлар барлыкка килде. Алар рус түгелләр. Кем икәнлекләрен үзләре генә белә.

Кыскасы, гомернең калган өлешендә дә уйланыр нәрсәләр җитәрлек. Баш өстенә Явыз Иван күтәргән балта әкрен-әкрен аска төшә. Без дүрт гасыр ярым төрле юллар табып, аңардан тайпылырга тырыштык, бәлки, ул балтаны алырлар дип рус хөкүмәтенә ярарга тырыштык, җайлаштык. Әмма балта һаман якынлаша, күпләребез аны күрми, яки күрергә теләми, яки кемгәдер барыбер. Корсак белән уйлаучыларга кем тәлинкәсен яласалар да ярый. Ләкин җаны булганнарга көрәшне туктатырга ярамый. Ахыргача көрәшергә кирәк. Онытмыйк, фашистлар Мәскәү янына ук килеп җиткәннәр иде, көч табылды бит.

Безне бүген төрле шиваләргә аерып таркатырга тырышалар. Үзебез дә без болгар, без фәлән диеп йә саташып, йә провокациягә бирелеп, таркатырга теләүчеләргә ярдәм итәбез. Әмма мин кемнәргәдер ияреп, татарымны яманларга теләмим. Кайвакыт күңел әрнеп, милләтем хакында авыр сүзләр әйтсәм дә, татарны тулаем хурлап, ул сатлык, ул фәлән-төгән дип ярлык тагарга алынмыйм. Әйе, үз вакытында ул янәшәсендә нинди дошман булуын һәм аның көчле икәнен абайлап өлгермәде, җиңелүгә дучар булды. Акылына килгәндә соң иде инде. Шулай да, 450 елдан артык албасты астында яшәп тә үз-үзен саклап кала алды. Инде өметсезлеккә бирелгән вакытта, җаен туры

китереп, мәйданнарга чыгып, үзенең азау тешен күрсәтте. Без әле, Аллага шөкер, исән.

Бер гыйбрәтле вакыйга сөйләп алыйм әле. Авыл зиратында бер бабайга кабер казыйбыз. Ләхет алганда астан бер авылдашым мине чакыра: «Карале, Туфан, бу тамырга, ди, кая төшеп җиткән бу билчән тамыры, — ди. — Ул тамырны кызу да суга алмый, салкын да өшетә алмый», — ди. Мин шунда татар милләте турында уйлап куйдым. Тирәндә безнең тамырыбыз, аны юкка чыгару җиңел түгел. Уяу булырга гына кирәк — кабер казып, кисә күрмәсеннәр.

Мин татар булып тудым, татар булып үстем, үскәндә саташкан чаклар да булгандыр (без бит өстән әйтелгәннәргә ышанучан халык), әмма барыбер татар булып калдым. Бу дөньядан да татар булып китәргә язсын.

## Патшалар

Мин патша дигән сүзне китаплардан гына укып беләм. Шулай да Россияне идарә итүчеләрнең барысын — Совнарком башлыгын да, генераль секретарьларны, президентларны да патша дип атарга булдым. Россиягә патша дигән сүз килешеп тора. Император дигәне дә телгә ятышлы. Россия хакиме, кем дип аталса да, патша кебек чикләнмәгән власть иясе. Әгәр Россия, бүгенгедәй артка чигенә-чигенә, 17нче елдан арткарак китсә, бөтен исемнәр дә шул вакыттагыча үзгәртелсә, милиция полициягә әйләнгән кебек, «президент» исеме дә «царь»га әверелүе бик ихтимал.

Мин үзем, башкалар кебек үк, түрәләрдән дә кадерлерәк адәми зат юк дип үстем. (Әнием дә бит: «Мәскәүдә биш ел укып, колхоз председателе дә була алмадың», — дигән иде). Ә патша — иң зур түрә.

Кайсы патша минем үзгәрүемә тәэсир ясады икән? Барысының да аз-маз өлеше бардыр. Әлбәттә инде, мин үскәндә, мин җитлеккәндә идарә иткәннәрнең йогынтысы күбрәк булгандыр. Мәгълүм ки, безнең буынны «халыклар атасы» бөек Сталин үстергән, ләкин барыбер Лениннан башларгадыр. Ул бит безнең бабабыз иде. Туган телебездән башка икенче телебез Ленин бабай дип ачылды. Юк, Ленинга чаклы булган кайбер патшаларны искә алып үтмичә булмастыр. Без укыган тарихтагы патшалар бит алар. Ә без укыган тарих безне күп нәрсәләргә «өйрәтте», аннан соң күп нәрсәләргә күзебезне дә ачты.

Сүзне шуннан башлыйм әле: Россия белән беркайчан да чын урыс идарә итмәгән. Соңгылары турында өздереп әйтә алмыйм. Татар тарихында иң начар исемне алганы, билгеле инде, Иван Грозный. Элек Грозный дигән сүзгә әллә ни әһәмият итми идем. Безгә бит аны Россияне яклаучы итеп укыттылар. Кемнән яклаган Иван Грозный Россияне? Әлбәттә, дошманнардан. Россия өчен бөтен илләр, бөтен халыклар да дошман булган бит. Россия үзе генә тәти булган. Шул тәти Иванны без тәти итеп өйрәндек. Грозныйлыгы да мактауга лаек кушамат тоелды безгә. Хәтта Казанны яулап алуы да безнең өчен прогрессив күренеш иде. «Грозный» сүзен без татарчага тәрҗемә итми генә укыдык. Тәрҗемә итә башлагач, әшәке исем икән Грозный. Тәти Иваныбыз Явыз икән ләбаса. Ул татарга гына түгел, урысның үзенә дә күп явызлыклар кылган самодур булган икән. Үзгәрдеме мөнәсәбәтем бер Россия патшасына? Үзгәрде. Беренче Петр да безнең өчен Россияне чәчәк аттырган, Европага тәрәзә ачкан бөек Патша иде. Аңа багышланган киноларны карап сокландык. Укый-укый беленде — ул илбасар икән ич. Татарларны чукындыру өчен иң нык тырышкан адәми зат икән. Чукынырга теләмәгән татарлардан лашман ясап, үзәкләренә үткән. Анна Ивановна дигән патшабикә булган. Ул Россиядә бөтен җинаятьчеләргә дә үлем җәзасын бетергән диләр. Үлем җәзасы бары тик корал ясаган татарларга гына калган. Татар авылларында тимерчеләр итеп бары тик урысларны гына куйганнар. Әйтәм аны мин белә башлаганда да татар авылларында тимерчеләр урыслар иде. Кыскасы, Россиядә бер генә патша да татарны яратмаган. Кызыклы факт — татарны җеннәре сөймәсә дә, күбесенең каннарында татар өлеше бар, үзләренең кучерлары арасында да татарлар күп булган. Күрәсең, бүтәннәр ышанычлы булмаган. Әйе, хезмәт итәргә дигәндә ышанычлы, тугры халык шул без — хуҗаларыбызны эт кебек саклыйбыз. Бу фикергә килү дә — минем үзгәрүем нәтиҗәсе.

Россия патшаларыннан фрау Екатерина гына татар тарихына матур исем белән, «Әби патша» булып кереп калган. Татарны тупас көч белән буйсындырып булмаганны аңлап, аңа азмы-күпме ирек биргән. Бутаннәр җимерттергән мәчетләр урынына яңаларын салырга рөхсәт иткән. Шуның өчен ул немкага хөрмәт безнең халыкта саклана һәм, билгеле инде, мин дә, шул халыкның улы буларак, Әби патшага тел-теш тидерәсем килми. Революциягә кадәр булган патшалар турында сүземне туктатып, Ленинга күчик. Чөнки без аның оеткысында тәрбияләнгән буын. Октябряттан алып коммунистлар партиясе әгъзасы булып җиткәнче Ленин мәктәбен узган кешеләр. Без гомеребезнең тәүге елларын Ленин бабай оныклары булып башладык. Октябрят чакта моңа чын-чынлап ышана идек, горурлана идек. Тизрәк пионер яшенә җитү төп максат булгандыр. Пионер чакта да оныклар идек әле. Комсомолга керер алдыннан, белмим, арабыздан кемдер күңелдә шик тудырды: «Ленин бабайның үз оныклары булмаган икән, шуңа күрә безне аныкы иткәннәр», — диде. Кем булды икән ул «контр», төгәл исемен хәтерләмим. Шул малай бугай инде без хор белән

*Ленин бабай маңгай чәчен*
*Ал тасма белән үргән,*

дип җырлаганнан соң, коткы таратты. «Ленин бабайның маңгай чәче булмаган, ул пеләш булган, менә рәсеменә карагыз», — дип, класс түрендә эленеп торган портретка күрсәтте. Укытучылар ишетмәгәндер инде, әйтүчегә дә, тыңлаучыларга да эләккән булыр иде юкса. Хәер, мондый сүзләр генә безнең Ленин бабайга булган мәхәббәтне киметә алмады. Миңа ул гомерем буена маяк булды. Гомерем буена дим, чөнки бүгенге көнгә хәтле, бөтен яктан да булмаса да, ул минем өчен мактауга лаек шәхес. Мәңгелеккә дип килгән монархияне, самодержавиене пыран-заран китерү өчен белем дә, акыл да, ныклы ышанычка ия булу да кирәк. Китап киштәсендә Ленин томнары тезелеп киткән. 55 том. Шуларның шактые Ленинның үз кулы белән язылган хезмәтләр. Аларны бит аңа бүгенге референт кебекләр язып бирмәгән. Укый белгән кешегә аннан күп нәрсәләрне аңларга була. «Россия — халыклар төрмәсе» дигән сүзләре үзе генә дә ни тора. Ленинга мәхәббәт миңа әтинең аңа мөнәсәбәтеннән дә күчкәндер. Әти аны һәрвакыт күккә чөеп мактый иде. Аның сәбәбе дә бар — әти бала чактан ятим калган, аны Ленин төзегән җәмгыять кеше иткән. Ленин заманында кылынган явызлыклар турында укып белгәч, миңа аны аңлау бик кыен булды. Ленинның катнашы юктыр ул эшләргә дип уйладым. Ләкин, нишләтәсең, документларда Ленин имзасы тора. Бигрәк тә дин әһелләрен эзәрлекләве күңелне рәнҗетте.

Ленин шәхесе турында бүген дә уйланам. Хәтта аның Казан чоры турында пьеса язу теләге әле дә сүнмәгән. Минем уемча, Ленин чыннан да дөньяны камил, кешеләрне бәхетле итәргә теләүчеләрнең берседер. Теләгенә ирешә алмавын күргәч, аптырап-югалып калгандыр. Бәхетле булырга теләмәгән кешеләрне кыйнап, үтереп бәхетле итәргә алынгандыр. Бу кешеләрнең бәхетле булырга теләмәвен диннән эзләгәндер. Нишләтәсең, кешене кыйнап оҗмахка кертеп булмый шул. Әмма барыбер Ленинны явыз итеп күрәсем килми. Ул бөтен кешелек дөньясы турында фикер йөртеп, аерым кешеләрне, хәтта аерым халыкларны да күрмәгән. Татарлар арасында күпме яшәп, ул халык, аның тарихы, язмышы турында бер язмасы юк. Кешелек дөньясын бәхетле итү өчен аерым кешеләрне корбан итү аңа җинаять тоелмаган. Бу, минемчә, аның төп ялгышы. Без бүген тырыша-тырыша аны сүгәбез, кылган гамәлләреннән җинаять эзлибез. Ә үзебез нишлибез? Илнең бөтенлеген саклыйбыз дигән изге нияттән күпме кешеләрнең башына җитәбез. Бу җинаять түгелмени? Кеше үтерү нинди генә максаттан эшләнсә дә, хупланырга тиеш түгел. Үзе биргән гомерне үзе алырга бер Ходайның гына хакы бар. Мин хәтта иң явыз җинаятьчегә дә үлем карары чыгармау ягында. Аның өчен гомерлек төрмәгә ябу җәзасы бар. Ленинны бәлки яшь буыннан оныттырырлар, ләкин ленинизм яшәячәк.

Патшалар, деспотизм булган илдә яңа Лениннар да туып торачак. Бу — тормыш законы. Ленинга карашым нинди үзгәреш кичерде дисәм, ул миңа бик тә тәти бабайдан дөньяны камилләштерергә азапланган фаҗигале, әмма

шактый ук рәхимсез бөек шәхескә әйләнде.

Ленинны Сталин дигән патша алыштырды. Менә ул чыннан да чикләнмәгән властька ия явыз патша иде. Дөрес, аның явызлыгын соңрак белдек. Бала чакта исә ул безне җитәкләп коммунизмга алып баручы сөйкемле бабай иде. «Ленин байрагы астында, бөек Сталин җитәкчелегендә алга — коммунизмга!» дигән лозунг кайда гына эленеп тормый иде. Сталин турында да без иң матур җырлар җырладык.

*Мылтык атарга оста мин,*
*Бик күп тордым постта мин.*
*Җитәкчебез — компартия,*
*Юлбашчыбыз Сталин.*
*Җырларга да оста мин,*
*Биергә дә оста мин;*
*Җырлап, биергә өйрәтте*
*Юлбашчыбыз Сталин.*

Хәтта Сталинның татар телендә кушаматы да ягымлы иде — Мыек бабай. Сталин исеме безнең күңелләргә нык сеңдерелгән иде. Әле дә хәтеремдә, урамда тузан сибешеп йөргәндә кайсыдыр Фәннурга катырак суккан иде, Фәннур: «Сталин бабайга әйтәм мин сине», — дип, сугучының котын алды. Авыл Советы бинасында Сталинның бик матур портреты эленеп тора иде. Пыяла эчендә. Сөрткәндә җыештыручы апаның кулыннан портрет ычкынып китеп, пыяласы ватыла. Пыяла ватыгы Сталинның битен яралый. Шуның өчен апаны алып китәләр. Хәтердә, апаны чын күңелдән гаепләделәр. Сталин кадәр Сталинны җәрәхәтләп кара әле син.

Сталин үлгәч, еладым мин. Дөнья җимерелер төсле тоелды. Югыйсә миңа 18 яшь иде бит инде. Сталин турында кәфер сүзне беренче тапкыр Казакъстанда, чирәм җирләр эшкәртеп йөргәндә ишеттем. Безнең Баймәгамбәт исемендәге совхоз Каенды күл (Каенлы күл) авылы җирендә урнашкан иде. Ул авылда казакълар белән бергә илләреннән куылган ингушлар, Кырым татарлары да яши иде. Инде Сталин үлгән булса да, аларга хыянәтчеләр дип карыйлар иде. Имештер, алар фашистларны ипи-тоз белән каршы алганнар. Бер ингуш гаиләсенә барып йөри идем, аларның минем яшьтәге уллары бар иде. Шунда бер тапкыр чәй эчеп утырганда йорт хуҗасы Сталинны әшәке сүз белән атады. Котларым очты. Мәскәүдә театр училищесында укыганда бер төркем яңа укырга килгән студентларның татарча сөйләшкәнен тыңлап тордым. Кемнәр икән бу дип кызыксындым. Игътибар белән тыңласам, сөйләшүләре татарча ук түгел икән, охшаган гына икән. Алар балкарлар булып чыкты. Үземнең татар икәнлегемне әйткәч: «Ай, явыз адәм», — дип китеп бардылар. Соңыннан аңлашылды: алар илләреннән куылган халык икән. Ә аларны өйләреннән куып чыгарып, машиналарга төяп озатучы солдатларның барысы диярлек татарлар, башкортлар булган. Мондый кабахәт, мәкерле эшне сталинчылар эшләгән. Туганнар туганнарын мәсхәрәләп өйләреннән сөйрәп чыгарып атканнар. Мин, әлбәттә, моны белми идем.

Тора-бара Сталинның явызлыклары ачыла башлады. Сталин вакытында Сталин алдында биеп торган Хрущев партия пленумында чыгыш ясап, Сталинны эт итеп сүкте. Аның сүзләренә ышанып җитмәдем, мин ни өчендер үлгән кешедән үч ала дип уйладым. Сталинның явызлыгын ачкан фактлар бер-бер артлы пәйда булгач, ышанмаска мөмкин түгел иде инде. 37нче еллар фаҗигасе Сталинга нәфрәт уятты. Бүген ул минем өчен — кабахәт кеше. Кемнәрдер аны акларга тырыша икән, аларны мин мазохистлар дип атыйм. Мондый явызлыкны акларга ярамый. Бүгенге коммунистларның Сталин исемен күтәреп йөрүләрен аңламыйм. Әле газетадан укыдым, Пензада, имеш, Сталинга һәйкәл куярга җыеналар икән. Нәрсә инде бу? Сталинның кем икәнен белерлек тә акыллары юк микәнни? Сталин ул җәллад, палач. Урыста «злой гений» дигән төшенчә бар. Сталин ул. Имештер, Сталин артта калган Россияне алдынгы илләр рәтенә чыгарган. Ничек чыгарган соң? Беломорканалны кемнәр

төзегән? Сталин тоткыннары. Магнитогорскины кемнәр салган? Илләреннән куылган авыл кешеләре. Бервакыт Магнитогорск төзелешендә бетон изү буенча дөнья рекорды куйган бригада турында пьеса язарга ниятләдем. Шуның өчен материал тупларга керештем. Магнитогорскида яшәүчеләр белән бәйләнешкә кердем. Рекорд куйгач ниләр булды дигән соравыма: «Столовыйга алып барып, туйганчы ашаттылар», — диделәр. Аптырап калдым. Шул гына булды микән зурлаулары, дип уйладым. Рекорд куючылар — Магнитогорскига сөрелгән татарлар. Алар коточкыч шартларда яшәгәннәр. Боларны белгәч, пьеса язу теләге кочәйде. Ләкин ул әсәр рекорд куючыларны мактап, аларга дан җырлау түгел иде. Тик ничек язарга белмәдем, дөресрәге, курыктым. Куйдырмасалар да, язарга кирәк иде. Ходай кичерә күрсен. Кайсы гына «бөек төзелеш»не алма, анда бер гаепсезгә хөкем ителгән Россия кешеләре.

Сталин, имеш, Бөек Ватан сугышында җиңгән. Әаның башлануында Сталинның катнашы булмаганмы? Гитлер белән икәүләп дөньяны бүлешергә җыенган кеше ул түгелме? Әгәр дә бүгенге коммунистлар үзләренә теләктәшләр табарга, үзләре тирәсенә яшьләрне тупларга телиләр икән, Сталинны тарих чүплегендә калдырырга тиешләр. Һәм, өстәвенә, партия исеменнән дөнья алдында гаепләрен танып, куылган, үтерелгән, изелгән кешеләрдән, халыклардан гафу үтенергә тиешләр. Чөнки коммунистик җәмгыять, әкият булса да, матур әкият, ә Сталин — шул әкияттәге коммунизм идеясен юкка чыгарган явыз көч; иң куркынычы — ул совет кешеләреннән шымчылар, доносчылар, икейөзле куркаклар тәрбияләде. Тарих алдында иң зур гаебе аның, бәлки, шулдыр. Бүген мин кайдан килгән Сталинга һәм аның ише Гитлерга, Пол Потка, Пиночет кебекләргә бу явызлык дип уйланам. Иблис токымыннандыр алар дип тә уйлыйм. Котчыккыч нәтиҗәгә килгән чакларым да була. Бәлки, Сталинны Рәсәй менталитеты тудыргандыр. Рәсәй халкы каты куллы патшаларны ярата бит. Явыз Иванны, кешеләрне меңләп кырган Петр патшаны мактап телдән төшермиләр. Бәлки, бу илгә, бу халыкка Сталиннар кирәктер? Кыйналудан тәм табучы халыклар яшидер Россиядә? Аллам сакласын. Явызлыкны яклау — явызлар һәм мескеннәр шөгыле.

Хрущев килгәндә мин уңны сулдан аера башлаучы егет кисәге идем инде. Ул елларда Мәскәүдә укыдым, анда төрле сүзләр тыңларга өйрәндем. Дөньяга, Россиядәге сәяси тормышка сукырларча бәя бирүче түгел идем инде. «Нигә алай?» дигән сорауны үземә үзем еш бирә идем дә, җавабын эзли идем. Хрущев килгән заманны «оттепель» дип атый башладылар. Аның мәгънәсен дә аңларлык дәрәҗәдә идем. Димәк, Россиядә җан өшеткеч каты, зәмһәрир суыклары булган һәм инде ул бераз чигенеп, әз-мәз җылына башлаганбыз. Сүз, әлбәттә, деспотизмнан демократиягә күчә башлауны аңлата иде. Театр училищесында укып йөргәндә һәрвакыт дөньяны үз кучәрләрендә әйләндерергә тырышкан яһүд егетләре берәр почмакка җыелып, сәясәт турында фикер алышалар иде. Мин алар арасында буталып, сөйләшкәннәрен тыңлый идем. Күрәсең, аларга тыңлый белүчеләр кирәк булгандыр, мине араларыннан кумадылар. Мин анда беренче тапкыр Хрущев турында анекдот ишеттем. Хәтерләмим инде ул анекдотны, сөйләүчеләр көлештеләр, мин көләргә курыктым. Куркытылган халыкның баласы бит, нишләтәсең. Шулай да Мәскәүдән кайтканда патшаларның да әллә кем түгеллегенә ышанган кеше идем. Хрущев турында анекдотларны үзем дә сөйли идем. Бигрәк тә кукурузга кагылышлылары безгә якын иде. Мин генә түгел, авылыбыз такмакчысы Мәрфуга апа да:

*Кукурузның ботагын*
*Йөгерә-йөгерә утадым;*
*Ашыйсың килсә, ашарсың*
*Хрущевның ........, —*

дип җырлаудан курыкмый башлаган заман килде. Хрущевның БМО мөнбәреннән ботинкасын салып селкүе дә безгә ошады. «Свой парин» инде, үзебезнеке. Ләкин бу үзебезнеке булып уйнаган патшаның чын йөзе ачылды. Аның заманында милли мәктәпләр ябыла башлады. Аны «ата-аналар теләге» дигән ялган белән akладылар. Хәтта республикадагы бердәнбер диярлек

татар газетасы «Социалистик Татарстан»ны да дубляж итеп, ягъни мәсәлән, урысчадан тәрҗемә итеп кенә калдырырга маташтылар. Димәк, Сталин да эшләмәгән астыртын явызлыкны Хрущев эшләде, һәм ул явызлык бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Мин Хрущевны кайсыдыр бер язмамда надан дип атаган идем. Күрәсең, ул милли мәсьәләдә бик үк надан булмаган. Ленин әйткән халыклар төрмәсенең мәкерле надзирателе булган. Һәм ул төрмә урыстан башка халыкларны ябып тотарга көйләнә башлаган. Надан булса, аның милли сәясәтен бүгенгеләр өлге итеп алмаслар иде.

Хрущевның икенче бер этлеге колхозларны берләштереп, перспективасыз авыллар ясавы булгандыр. Авыллар шул чорда тарала башлады. Безнең милләткә бу экономик, социаль яктан гына һөҗүм түгел, безнең милли мәдәниятебезгә күсәк белән ору иде. Чөнки безнең мәдәниятебезнең чишмә башы авылларда иде. Чишмә корый башлады.

Хрущевны төп башына утырткан Брежнев минем өчен яхшы да булмады, начар да булмады. Ни өчендер мин аны Патша булып утырырлык зур шәхес дип кабул итә алмадым. Картайган чагында ул көлке объектына әйләнде. Ләкин усал итеп көлми идек үзеннән. Куркыныч та түгел иде бугай ул. Янында утыручы Сусловлар куркыныч иде. Леонид Ильич белән алар идарә иттеләр диган фикер калды миндә. Мәкерле кеше түгел иде бугай ул. Ул чакта без көлеп, Кремльне «Картлар йорты» дип атадык, «сисиматически» дип, Брежнев булып сөйләштек. «Чирәм җир», «Кече җир» романнарын бүтәннәр язып биргәнен белә идек. Шул романнар өчен Ленин премиясе алуыннан да көлдек кенә. Түше тулы «Алтын йолдыз»лары, орденнары да ачуны китермәде, күбрәк көләсене генә китерде. Хәерле булсын инде, Россия патшалары арасында андый чудаклар да булган. Алар Россия тарихында төп рольне уйнамаганнар. Тик мин бер нәрсәне аңлап бетермим, бүген Брежнев шәхесенә артык игътибар бирелә. Телевидениедә ничәмә-ничә фильм күрсәтелде әнә. Күрәсең, бүгенгеләр өчен Россия тарихында Брежневның әһәмиятле урыны бардыр. Ленин Россиянең астын-өскә китерде — ул феномен һәръяклап өйрәнелергә тиеш, Сталин миллионнарның башына җитте, шулар арасында «Яшәсен Сталин!» дип үлүчеләр дә булды — бу тиранияңең тамырлары кайда? — ул да туктаусыз өйрәнелергә тиеш, Хрущевның уптым илаһи шәхес культы дигән төшенчәнең Россия тарихында очраклы түгеллеген фаш итүе шулай ук игътибарга лаек. Ә Брежнев? Хәерле булсын.

Брежневтан соң хакимияткә Черненконы китерделәр. Кемгә кирәк булгандыр аның кандидатурасы, белмим. Минем өчен ул кызганыч бер бабай иде. Аның турында, ялгышмасам, анекдот та сөйләмәдек — аңа да лаек түгел иде бугай ул. Әмма ул патшалык иткәндә минем белән истерикага якын бер тетрәнү булып алды. СССР Югары Советына сайлау вакытында Черненконы кандидат буларак телевидениедән күрсәттеләр. Минемчә, аны табуттан торгызып кына күрсәтеп алдылар, аңарда тере кеше кыяфәте юк иде. Шунда минем белән әллә ни булды — бугазыма төер килеп тыгылды, елыйсы да, көләсе дә килгән кебек. Туктаусыз «бөек держава» дип шаулаган илнең мескенлеген күрүдән туган халәт иде бу. Шундый патша да идарә итә алырлык ил нинди дә, аның халкы кем? Без, «бөек держава» дип кычкыручылар, барыбыз да шыр чыккан тиләләр икәнлеген күреп җан әрнеде. Күрәсең, бу фаҗигале кәмит уены өстәгеләрдән кемнәрнедер уйландыргандыр, хакимияткә КГБ килде.

Властька Андроповның килүе, хәтерлим әле, күпләрдә Россиянең киләчәгенә өмет уятты. Күчәрдән ычкынып барган Россиягә тәртип кертер дип өметләнделәр. Ләкин ул да әллә ни кыра алмады. Айный алмаган Рәсәй кешеләрен айнытырга, эшлисе килмәгәннәрне мәҗбүри эшләтергә тырышты, әмма көче җитмәде. Күрәсең, гасырлар буе канга кереп оялаган гадәтләрне КГБ методы белән генә туктатып булмыйдыр. Гомумән, кешене тупас көч кулланып тәрбияләп була микән? Эчкән кеше кыйнасаң да эчә, эшләмәгәне әллә нишләтсәң дә эшләми — эшләгән булып кылана гына — нәкъ колларча яшәү инде бу. Кешене кеше итәр өчен аны иң әүвәл коллык психологиясеннән дәваларга кирәктер. Бездә исә кешедән кол ясау сәясәте дәүләтнең идарә итү системасын тәшкил итә иде.

Горбачев Россиягә «перестройка» дигән сүз алып килде. Нияте изге булгандыр. Ләкин Россиядә «перестройка», «реформа» дигән нәрсәләр «демократия» сүзе

кебек үк сүз уйнату гына. Аңа әле, бәлки, патшалар гына да гаепле түгелдер. Бик азга канәгать булып яшәргә күнеккән халык бит без. Кайчан, кемнәр безне шулай яшәргә өйрәткәндер, белеп тә булмый. Бәлки, ул Россиянең бертуктаусыз сугышуыннан киләдер. Сугыш вакытында рәхәт тормыш турында уйламыйсың бит. Без сугыш булмаганда сугышка әзерләнәбез — анда да каешларны кысыбрак яшәргә кирәк. Ә Горбачев «перестройка» дигән сүз әйтеп, безне каушатып калдырды. Нәрсә соң ул перестройка? Аның ни өчен кирәклеген аңламадык. Ул бит йоклаган кешене типкәләп уяткан кебек. Син куркудан сикереп торасың да, кая барырга, нишләргә икәнен йокы аралаш белмисең. Россия хакимиятендә иң тапкыр афоризмнар атасы Черномырдин әйтмешли, «хотели как лучше, получилось как всегда». Шуңа күрә Горбачев күрергә теләгән үзгәртеп кору булмады бу. Шулай да, ул сүз телгә кереп калды. Икенче төрлерәк яшәргә омтылу кешегә хас сыйфат шул. Горбачевның «Сухой закон» кертергә тырышуы да йөзем плантацияләрен кисеп юкка чыгару гына булды. Чөнки сәрхушлык урыс кешесенең яшәү рәвешенә әйләнгән, аны үзгәртү мөмкин түгел хәлдер. Урыс һәм аннан үрнәк алырга өйрәнеп җиткән башка халыклар эчмичә яшәүне күз алдына да китерә алмыйлар. Алар өчен эчү — тугарылып күңел ачу гына түгел, кайгы-хәсрәтләрне, тормыш авырлыкларын онытып тору ысулы да.

Кыскасы, Горбачев бездән кеше ясарга омтылып карады, ә без аңардан көлдек. Һәм тарихта да ул буш хыяллар авторы гына булып калырдыр. Бүген СССРның таркалуын да Горбачев белән Ельциннан күрәләр. Югыйсә, СССРны кан коюларсыз гына таркатканнары өчен, аларга рәхмәт әйтергә кирәк. Ул таркалыр хәлгә килеп җиткән иде инде. СССР республикалар союзы дип аталса да, анда союз, ягъни мәсәлән, берлек юк иде. Ул юкә бау бәйләп куелган халыклар «Союзы» иде. Ирек турында сүз ишетелүгә үк, Союздаш республикалар СССРдан качу юлын эзләргә тотындылар. Горбачев шул процессны йөз меңләгән корбаннарсыз гына үткәрде. Һәр империя таралырга тиешлеген тарих фәне күптән раслаган бит инде. Горбачевны мин система корбаны дип саныйм һәм аңа хөрмәт белән карыйм.

Россия тарихында Ельцин да истә калырлык фигура. Горбачев белән власть бүлешә алмасалар да, алар асылда бер юнәлештә фикер йөртүчеләр. Аерма шунда гына: Горбачев Ельцинга караганда йомшаграк күңелле һәм тәвәккәллеге җитмәгән патша. Ельцин исә — каты куллы. Рәсәй халкы Ельциннан исерек дип көләргә яратса, каты куллылыгы өчен хөрмәт итте. Россия халкы кыйналырга яраткан халык бит инде ул. Ләкин Ельцин, каты куллы булса да, халыкны кыйнау ягында түгел иде сыман. Рәсәй халкының азга да канәгать булу менталитетын яхшы үзләштергәнгә, ул халыкны кыйнауның бик мәкерле ысулын уйлап тапты. Россияне акчалы кешеләрдән талатырга кереште. Әй таладылар да соң илне. Әле дә талыйлар. Нигә таламаска, халык бит дәшми, ул мазохист — кыйналудан тәм таба. Бик аз вакыт эчендә олигархларның барлыкка килүе һәм бик тиз үрчүе талануга күнеккән халыклар яшәгән илдә генә була ала.

Ельцинның рус булмаган милләтләр хуплаган ягы — безнең хәлне аңларга тырышуы булгандыр. «Руслардан башка Россияне тәшкил иткән башка халыклар да бар, нигә алар үз илләрендә хокуксыз булырга тиеш?» дигән сорау, бәлки, аның күңелендә тугандыр. Шуны аңларга ояты җиткәндер. Руслаштыру сәясәтенең иң тупас формаларыннан ваз кичеп, хәйләле юлларын эзләгәндер. Аның: «Суверенитетны йота алган кадәр алыгыз», — диюендә, әлбәттә, безгә мөстәкыйль яшәргә рөхсәт итү ятмый, күпмедер дәрәҗәдә безне мыскыл итүче ирония ята. Янәсе, сез йота алмаячаксыз, сез нихәтле әтәчләнсәгез дә, Россия империясенә каршы тора алмаячаксыз. СССР халык депутаты чагымда Мәскәү Кремленең Съездлар сарае фойесында Жириновскийның журналистлар алдында җикеренүен тыңларга туры килде. Ул СССР составындагы республикаларның мөстәкыйль яшәргә сәләтсез икәнлекләрен сөйләде дә: «Казахстан, например, никогда не был государством, там было дикое поле, мы не завоевывали эти земли, только освоили», — диде. Шунда кемдер: «У татар было государство, его тоже не завоевывали?» — дип сорагач, «Да, это ханство нам мешало, мы завоевали его. Если татары сегодня шумят, надо было в свое время защищать свое государство, сейчас нечего рыпаться», — диде. Мондый

фикер Ельцин өчен дә ят дип уйламыйм, чөнки Жириновский ул патшалык иткән чакта канат җәйде. (Бүген дә ул Россия җитәкчеләренең хөрмәтле кешесе булып кала бирә. Чөнки ул — аларның күңел түрендәге уйны кычкырып әйтеп бирүче). Һәрхәлдә, Ельцинга минем татар буларак мөнәсәбәтем бик үк начар түгел. Ә икътисад мәсьәләсендә аны гаеплиләр икән, анда дөреслек бар. Тик шунысы да мәгълүм: Россиядә кем генә патшалык итсә дә, рәтле тормыш булмаган, булмады һәм булмастыр да кебек. Россия менталитетының асылында мең еллар буе берни дә алышынмый, патшалар гына алышынып тора.

Бүгенгеләр турында сүз әйтмим, чөнки бу — сәясәткә турыдан-туры катнашу була. Аларына киләчәктә бәя бирүчеләр табылыр.

Рәсәй патшаларыннан башка үзебезнең патшалар да бар иде бит әле. Ходай күпсенмәсен, хәзер дә бар. Алар турында да әйтәсе фикерләрем, әлбәттә, юк түгел. Ләкин алар минем үзгәрүемә йогынты ясадылар микән? Ясаганнар. Болгар дәүләте, Алтын Урданың җимерелүендә, Казан ханлыгының яулап алынуында ханнарның да гаебе булгандыр. «Нигә алай?» дигән сорауны мин үземә бирәм дә, тарих китапларына мөрәҗәгать итәм, уйланам. Жириновский сүзләре искә төшеп, тетрәнеп куям. Элек мин бу турыда уйланмый идем шикелле. Ә инде Мәскәү яулап алганнан соң без патшаларсыз (ханнарсыз) калганбыз. Ленин бүләк иткән автономия вакытындагылар хакында ни әйтәсең? Алар минем өчен һәрвакыт Мәскәү куйган чиновниклар булды. Шәхсән үземә начарлыклары тимәде. Шуннан арысын әйтә алмыйм. Ельцин биргән иректән соң азмы-күпме мөстәкыйльлек булды булуын, хәзер барысы да үз урынына кайтты. Хәерле булсын. Берсен дә гаепләргә җыенмыйм, хокукы чикләнгән хакимияттән әллә ни таләп итеп булмый.

Мин әлеге фикерне бүтәннәр белән сөйләшкәндә дә әйтәм. Минем белән килешмәүчеләр күп. Без Мәскәүнең Россиядә милләтләрнең уянуларын күреп, каушап калуыннан файдаланмадык, булган мөмкинлекләрне кулдан ычкындырдык, диләр. «Мәскәү каушап калмады, ул безнең белән уйнап кына алды», дим. «Без ул уеннан да файдаланырга тиеш идек, тулы мөстәкыйльлеккә ирешмәсәк тә, дәүләтчелегебезнең кайбер элементларын ныгытып өлгерә ала идек», диләр. Мисал итеп латин графикасына кире кайту, милли университет ачу һәм тагын башка эшләнергә тиешле бурычларыбызны китерәләр. Әйе, бу мәсьәләдә килешмичә мөмкин түгел. Латин графикасына күчеп өлгерә идек без. Аңа без әзер идек. Милли университет ачарга да тулы мөмкинлекләр бар иде. Ләкин эш эшлисе урынга мәгънәсез бәхәсләр оештырып вакытны уздырдык. Мәскәү, бу гамәлебезне ошатып бетермәсә дә, турыдан-туры басым ясарлык хәлдә түгел иде. Безнең тәвәккәллегебез җитмәде. Теге яки бу эшне башкарырга теләмәгәндә проблемадан бик оста итеп качу ысулын кулландык. Юк, булмый, дип кистереп әйтмичә генә җаваплылыктан качып, һәртөрле «объектив» сәбәпләр эзләп, сылтаулар табып, аларны дәлилләп маташып вакытны сузып, мәсьәләнең актуальлеген югалтырга остардык. Латин графикасына кайту мәсьәләсе җитәкчеләр алдында кискен итеп куелгач, галимәр арасында махсус дискуссияләр оештырылды. Галимнәр исә, гадәттәгечә, кайбер хәрефләргә койрык өстәргәме-юкмы дигән буш, мәгънәсез бәхәсләргә чумып, хакимияткә ярдәм иттеләр. Кем белә, бәлки, аларга шулай вакытны сузарга киңәш иткәннәрдер.

Университет белән дә шулай. Милли кадрлар җитешми, концепциясе эшләнмәгән, бина юк дигән сылтаулар табылды. Югыйсә барысы да бар иде, теләк һәм тәвәккәллек кенә кирәк иде. 1552 елда Казанны яклаучыларга һәйкәл кую турында нинди генә матур сүзләр сөйләнмәде. Карап торырга барысы да бик җайлы барган кебек иде. Президент та, башкалар да, әйе, һәйкәл кирәклеген таныдылар. Әзерлек тә башланды сыман. Комиссия дә төзелде. Һәйкәл өчен урын да табылды кебек. Һәйкәл проектына конкурс та игълан ителде. Һәйкәл кирәк дип дәгъва кылучылар, көрәшүчеләр тынычланыбрак көттеләр. Һәм бүгенгә хәтле сабыр гына көтәләр. Һәйкәлне куймау гаҗәеп зур осталык белән киләчәккә кичектерелде. Куймыйбыз дип әзеп әйтүче дә юк, һәйкәл дә юк. Сәясәт шундый буладыр инде ул. Кыскасы, халык мәйданнарга чыгып хакын даулавы вакытлыча җилкенеп алу гына булып калды.

Мин тагын бер кат кабатлыйм: милли сәясәттә күсәк белән эш итүче Россия

хакимияте белән мөнәсәбәтләрдә безнең җитәкчеләргә җиңел түгел. Әмма җитәкләргә алынгач, идарә итү осталыгын күрсәткәндә тәвәккәлрәк булу да зарурдыр. Милләт өчен эшлисе эшләребез бик күп, боларны аңлау һәм эшләү өчен беренче чиратта җитәкчеләр җаваплы. Без аларга ышаныч белдереп, өметләр белән яшибез, алар шуны онытмасыннар иде. Россия тәхетенә кем генә утырса да, нинди генә реформалар үткәрсәләр дә, безнең файдага булмаячак. Үз көнебезне үзебез күрергә өйрәнсәк, үз язмышыбызны бүтәннәр кулына тапшырмасак, үзебезне сакларлык милли аңыбызны булдыруга ирешсәк кенә исән калачакбыз.

## Икътисад, көнкүреш

Кешене кеше буларак ике терәү терәп тора: берсе аның — рух, икенчесе — материя. Шуларның берсе какшаса, кеше егыла. Мин рухка кагылышлы мәсьәләләргә кагыла бардым, ә менә матди яктан ничек яшәвем миңа үзгәреш ясаганмы, юкмы икәнлегенә аерым тукталмадым. Мөгаен, кирәктер.

Мәктәпләрдә очрашулар вакытында балалар еш кына: «Сез бала чагыгызда кем булырга хыяллана идегез?» — дигән сорауны бирәләр. «Туйганчы ашау турында хыяллана идем» — дигәч, көләләр. Ә бит көлке түгел. Чыннан да шулай иде ич. Безнең балачак сугыш вакытына туры килде. Ачлыкның соңгы чикләренә җиткән көннәр булды. Ашамаган үлән калмады. Шөкер, үләксә ашау көненә җиткермәде әни. Без сугыш кайчан бетәр икән дә, кайчан туйганчы ашарбыз икән дип хыялландык. Май, октябрь бәйрәмнәрендә мәктәптә аш пешереп сыйланганга, әлеге бәйрәмнәр бүген дә күңелгә якын.

Сугыш бетте. Җиңү шатлыгыннан ашыйсы килүне дә онытып тордык. Әмма озакламый корсакның бушлыгы үзен белдерде. Әтиләре кайтмаган балаларны әйтеп тә тормыйм, без әтиләр дә ачыктык. Хәтердә, 46нчымы, 47нчеме елда, әти өйгә районнан килгән вәкилне алып кайтты. Бер чәкүшкә аракылары бар иде шикелле. Ләкин закуска табылмады. Вәкил әнине саранлыкта гаепләмәкче иде дә, әни: «Әнә, балаларым ач утыра», — дип кычкырды. Әти, колхозда хисапчы булып эшләсә дә, үтә намуслы кеше иде, урлашуның ни икәнен белмәде, ә хезмәт хакына бирелгән бер капчык арышны көз көне үк ашап бетергән идек. Эшләгәнгә бирмәсәләр дә, колхозчыдан нинди генә салым түләттермәделәр. Бервакыт, налогын түләмәгәч, районнан килгән вәкил белән авыл Советы председателе Кадыйр бабайларга недоимка өчен әйберләрен алырга керәләр, әмма алып чыгарлык нәрсә тапмыйлар. Шунда Кадыйр бабай, шыр ялангач утырган малае Каюмны күрсәтеп: «Алып китегез шуны, фәлән нәрсәсе хөкүмәткә булыр», — дигән. Шул сүз өчен озак йөрттеләр шикелле үзен.

Мин, авыл малае буларак, авылдагы кискен үзгәрешләргә кагылмый китә алмыйм. Андагы бертуктаусыз үзгәртүләр мине дә үзгәрткәннәрдер. Мин туганчы ук башланган коллективлаштыру мин үсеп җиткәндә «чәчәк атып», мин олыгайганда таркалды. Колхозны таркату авылларны таркатуга китерде. Чөнки колхоз булып яшәргә өйрәтелгән, шуңа җайлашкан авыл кешесе судан ярга чыгарып ыргытылган балык хәлендә калды. Кызык бит — башта колхозга җыеп крәстиянне таладылар, аннан колхозны талап крәстиянне ыштансыз калдырдылар. Ә бит, бактың исә, колхозларны төзегәндә аның киләчәге булмаячагын авыл кешеләре белгәннәр. Галимулла абый Шакиров сөйләде: «Безнең әти колхозга озак кермәгән. Аны көн саен авыл Советына чакыртып эшкәрткәннәр, кеше хезмәтеннән файдаланмаса да, кулак дигән исем такканнар. «Колхозга каршы контр» дип тә атаганнар. «Юк, мин контр түгел, дигән әти, мин колхоз яклы. Мин үзем кебек эш эшли белгән кешеләр белән колхоз төзергә телим. Җыен әтрәк-әләм, хөрәсән белән колхоз төзеп ачтан үләсем килми», — дигән.

Надирның сүзләре: «Безнең авылда колхоз төзелгәч, председатель сайларга җыелыш җыйганнар. Кемне сайлыйбыз, дигәнгә кемдер Шәрәфи абзыйны күрсәткән. Ул арба тәгәрмәче ясаучы оста булган, тирә-якта аның исемен белгәннәр. Оста булгач, тормышы да җитеш булган. Җыелышта, ул кулак, кулакны сайламыйбыз, дип каршы чыкканнар. Икенче берәүне тәкъдим иткәннәр. Ул шулай ук хәлле кеше икән — башында каракүл бүрек, өстендә төлке тун, аягында Кукмараның чигүле киез итеге. Аны да браковать

иткәннәр. Нәтиҗәдә авылның иң хәерче, иң бетәшкән, иң ялкау кешесен сайлап куйганнар. Үзен-үзе дә ашата алмаган бәндәдән нинди председатель чыксын ди. Гомер гомергә мантый алмаган колхоз».

Әйе, колхоз авыл кешесенең тормышын җиңеләйтү өчен төзелмәгән шул, крәстиянне милкеннән мәхрүм итеп талар өчен төзелгән. Колхозны кычкыртып таладылар. Яңа уңыш өлгерүгә үк колхозның ашлыгын кырып-себереп алып бетерәләр иде. Һәм бу «дәүләт алдындагы изге бурычны үтәү» дип атала иде. Колхоз таланды, колхоз аша халык таланды. Колхоз авыл кешесен урларга өйрәтте. Чөнки эшләгәнен бирмиләр иде. Болар бар да минем күз алдымда үтте. Мин дә ачыктым, мин дә урларга өйрәндем. Әни өйрәтте. Төнлә безне уятып басудан колхоз саламын урларга алып бара иде. Бүген авылны бетерүнең яңа юлларын эзлиләр һәм таптылар да шикелле инде. Колхоз чагында, формаль булса да, җир колхозчыга дәүләт тарафыннан чикләүсез арендага бирелгән булса, хәзер ул латифундистлар милкенә күчә бара. Яңа төр бариннар һәм яңа төр крепостнойлар барлыкка килде.

Гаҗәеп халык яши Россиядә — аны берничә тапкыр җыеп талады Рәсәйдәге хакимият — халык дәшми. Үзара зарланган була да, шуның белән бетә. Түзәрлек чамасы калмагач, большевиклар вәгъдәсенә ышанып, революциядә катнашты, Гражданнар сугышында кырылды, ләкин таланудан котыла алмады. Ничәмә дистә еллар инде мин «бөек держава» сүзен ишетәм. Нәрсәсе белән бөек икәнен аңлатып бирүче юк. Хәерче халык бөек була ала микәнни? Берничә ел элек Разил Вәлиев белән Берлин урамында йөргәндә, урамнардагы тәртипне, төзеклекне күреп, Разил: «Да, безнең әтиләр урнаштырып киткән монда тәртипне», — диде. Җиңелгән ил рәхәтләнеп яши, җиңүчеләр һаман хәерче. Бу икътисади серне аңлап та, аңлатып та булмый. Россия территориясенең астында һәм өстендә табигый байлыкның чиге-чамасы юк, халкы исә һаман хәерче. «Кто виноват?», «Кому на Руси жить хорошо?» дигән сораулар күп, җавап юк. Әллә бу Алла каргаган урын микән, дип тә уйлап куям кайчакта. Россия патшаларына җир җитмәде, бүген дә җитми, тик җирдән дә кадерсез нәрсә юк бу илдә.

Тамак кайгысы мине гомер буе озата барды. Кайчак туйганчы ашасам да ач идем. Ачлык тук чагымда да эзәрлекләде. Запаска дип он, ярма, токмачише әйберләрне күп итеп алып куя идек, алар бозылгач, чыгарып ташлый идек. Ашый-ашый симерешеп бетсәк тә ач булдык, булганда туйганчы тыгынып калыйк дигән нәрсәнең нәтиҗәсе иде бу. Чөнки иртәгегә ышаныч юк иде.

70нче елларда бөтен ризыкны Мәскәүдән ташыдык. Татарстан тавык үстерә, йомыркасы белән түшкәсе Мәскәүдә, сыер асрый — мае Мәскәүдә. Итне әйтеп тә торасы юк. 1976 ел. Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укып йөргән чак. Казанга алып кайтырга дип иткә чират торам. Чират — дилбегә буе. Бер генә тапкыр тору җитми, кулга 2 кило гына бирәләр. Мәскәү хатыннары безне яратмыйлар. «Понаехали тут»,— дип чырайларын сыталар. Торам чиратта. Менә берзаман чират барудан туктады. Эш шунда икән, чираты җиткән бер авыл мужигы итне озак сайлый, күбрәк һәм сөяксезрәк ит алырга теләп, сатучы белән бәхәсләшә. Сатучы моны сүгә-сүгә куа. Теге китми. Чираттагы хатыннар тавыш куптардылар:

— Эй, мужик, не задерживай очередь, — диләр.

— А ну-ка, оцепитесь от меня, — ди мужик, — Смотрите на мясо, там Ярославское клеймо, на родину везу, — ди.

Милиция чакырдылар. Милиция ул чакта вазифасын төгәл үти иде, мужикны алып чыгып киттеләр, мужик үз сүзен әйтә-әйтә китте:

— Сволочи, нажрались тут в Москве, — диде.

Москва, белгәнебезчә, бөек мәмләкәтнең башкаласы.

Икенче бер очрак. Монысы Казанда. Бервакыт ит ашыйсы килә башлады. Бер җирдә дә юк. Кибеттә юк та юк инде, базарда да юк. Акча да бар югыйсә. Аптырагач, ресторанга кердем, анда да итле ризык юк. Дүрт-биш ресторанга кердем, берсендә дә юк. Ахыр чиктә бер ресторанга кереп ботка алып ашадым да, лыкынганчы аракы эчтем. Өйгә кайтышлый юл буе сүгенеп кайттым. Бөтенесенә дә эләкте: Мәскәү Кремлендә утыручыларга да, Казандагыларга да. Ярый әле милиция очрамады, юкса күрсәтәләр иде Кремльдә кемнәр утырганын.

Ничәмә дистә еллар буе съездларда чәчәк атуыбыз турында сөйлиләр — халык көлә генә. Яшьләр өчен берничә шул чорлар анекдоты да язып әле. Берәүгә табышмак әйтәләр икән. «Мчится как бешеный, мясом обвешанный. Нәрсә ул? Җавабы — «Татарстан» поезды Мәскәүдән кайтып килә... Берәү дусларына кунакка килә. Ә тегеләрнең ишекләре бикле. «Болар йә өйдә юк, йә бикләнеп итле аш ашыйлар», — ди кунак. Бу 80 нче еллар хакында. Ярый, туксанынчы еллар җитте. Кинәт кенә Мәскәүдә азык-төлек бетте. Ни хикмәттер, бездә бар. Мәскәү халкы бездән ташый башлады бит. Шул чакны мин вокзалга төшеп, тегеләрнең азык-төлек төягән сумкалар сөйрәүләрен рәхәтләнеп күзәткән идем. Күңелемдә «белегез безнең теге чаклардагы хәлне» дигән коточкыч бер куану иде. Югыйсә Мәскәү халкының ни гаебе бар анда, илең шундый булгач.

Хәзер кибетләрдә дә, базарда да ризык тулып ята, халыкның аны алырга акчасы юк. Халык тагын ач. Минем, тамагым тук кебек, әмма, хәерчеләрне күргәч, ризыкның тәме бетә. Йөрәкләрен, күзләрен май басканнар да бар бу илдә, алар җае чыкканнан файдаланып урлап җыйган акчаларына тыгыналар. 2011 ел. Ә Тукай 1906 елда «Сорыкортлар»га дигән шигырен яза. Ни аерма?

Монда үзгәрәсең килмәсә дә үзгәрәсең. Минем һәр тиенем эшләп табылган, шулай да гомер буе шушы ил өчен бөкреләрен чыгарып эшләгәннәрнең ни хәлдә яшәгәннәрен күрәм дә, адәм рәтле яшәгәнемә оялып куям. Минем дә иртәгәге көнгә ышанычым юк, картлык көнемә дип җыеп куйган акчамны күрәлә талап алдылар. Халык түгел, хөкүмәт талады. Бөек держава дип сөйләнүчеләр.

Мин бу сүзләрне халык алдында яхшы күренер өчен дә, хакимияттә утыручыларны сүгәр өчен дә язмыйм. Шушы илдә туып, шушы илдә үсеп, шушы яшькә җиткән кешенең уйланулары гына бу. Мин әлеге илдә яхшы тормыш булачагына ышанмыйм инде. Такташ «Коммунизм кыры күренә», дип язды заманында. Юри, шаярып-көлеп язгандыр ул. Әллә, кайчандыр мин коммунизм булуына өметләнеп алданган кебек, алданды микән?

Мин Рәсәй кешесенең тамак хәерчелеге турында гына яздым. Ә тормышның башка яклары? Әйтик, торак мәсьәләсе. Ул өлкәгә кереп батсам, чыга алмамдыр. Бүген кайберәүләр салам түбәле Россияне бай иде дип расламакчы булалар. Имештер, Патша Россиясендә халыклар яхшы гомер кичергәннәр. Шул замандагы авылларның рәсемнәре сакланган бит югыйсә, карасыннар иде. Бүген, әлбәттә, алай ук түгел. Ләкин заманы да бүтән бит. Башка илләр белән чагыштырганда... Юк, бүтән бу турыда язмыйм. Мин бу илнең, нинди генә җәмгыятьтә яшәсә дә, рәтле булмаячагына ышанган кеше. Дәлилләрем — үткәнем һәм хәзергем. Минем дәлилләрем җитмәсә, бүтәннәр өсти ала. Газеталарда «Онытасым юк» рубрикасында минем яшьтәгеләрнең истәлекләре басыла. Ничаклы истәлек укыдым — берсендә дә тормышның матурлыгы, рәхәтлеге турындагысы юк. Бу илдә яшәүнең әмәлен дә таптым шикелле мин. Киләчәктә булыр дигән буш хыял белән үз-үземне алдамыйм, ярый инде, моннан кайтышрак та булуы мөмкин бит дип, үземне-үзем тынычландырам. Ни өчендер, хакимияттә утыручыларга да ачуым юк кебек, дөньясы шундый булгач, шулай буладыр инде дип уйлап куйгалыйм. Бездә генә түгел, бүтән илләрдә дә хакимият башына тираннар килеп китә. Аларны, түзәр чама калмагач, алып ыргыталар, хәтта үлем җәзасына да хөкем иткәлиләр. Халык, котылдык дип уйлап, бераз тынычлангач, икенче бер тиран килеп, алдагысыннан да артык кылана. Россия белән дә шулай. Бер явыздан котылып алганда икенчесе, икенчесе булмаса, өченчесе килеп «халыклар төрмәсе» ясый. Ләкин мин дөньясы шундый дип аңа кул селтәп, төшенкелеккә бирелеп изелеп яшәргә риза булу ягында түгел. Җан иреге, халыклар иреге өчен туктаусыз көрәшергә кирәк.

## Иҗат

Ул сүзнең мәгънәсе бик киң. Фәлсәфәгә үк кереп китеп уйлансаң, яшәү үзе иҗаттыр. Бөтен эшнең, гамәлнең асылында иҗат ята. Хәтта тәмле итеп ашарга пешерү дә, матур итеп киенә белү дә иҗат. Иҗатсыз яшәгән кеше — буш кеше. Мин инде иҗатның бөтен юнәлешләренә кереп тормыйм, үземнең яшәешемә турыдан-туры кагылган иҗат тирәсендә генә йөрермен. Ә минем яшәвемнең

төп мәгънәсе ул — әдәби иҗат. Мин, әлбәттә, эшләгән бүтән эшләремә дә иҗат дип карыйм. Кызыксыз эшне кирәк булганга гына, мәҗбүри генә эшлим. Мәсәлән, җир казу миңа кызык түгел (хәер, кемгә кызык икән ул). Ләкин кирәк чаклары була. Яшелчәләр, җимеш агачлары, чәчәкләр үстерергә яратам. Чөнки монда иҗат бар. Ә аларны үстерү өчен җирдә казынырга кирәк. Кеше казып биргән җирдә үстерүнең шулай ук кызыгы әллә ни түгел.

Миндә әдәби иҗатка омтылыш кайчан башланды икән? Күрәсең, туганда ук миңа ул күәс салынган булгандыр. Әти шигырьләр яза иде. Аның бу гамәлен әни ошатып бетермәсә дә, яза иде. Хәер, әни ягында да иҗатка омтылучылар бар иде. Аның өлкән абыйсы Гатаулла (авылча итеп әйтсәк, Гата) күргәнен, ишеткәнен арттырып, кеше кызыксынып тыңларлык итеп сөйли белә иде. «Җыен юк-барны Гата абый уйлап чыгара», диләр иде аның турында. Ә минем иҗат юлы такмаклар чыгарудан башлангандыр. Такмаклар — татар халкының борынгыдан килгән авыз иҗаты жанры. Урыс та ул яктан бездән калышмый. Аларда такмак «частушки» дип атала. Бу бик гади аңлашыла, чөнки урысның иң кимендә яртысы татардан чыккан.

Без егетлеккә дәгъва кылып борынлап килгәндә кышкы кичләрне бер әрсенең көндез яккан җылы мунчасына җыелып, «күңел ача» идек. Клуб та бар иде авылда, ләкин мунчада кызыграк иде. Өстәвенә, анда җылы, ә клубта салкын. Мунчада безне тыючы, узына башласак куып чыгаручы завклуб юк. Сам патша, сам хәҗәен. Әкиятләр сөйлибез, борынга кызлар исе керә башлаган — аларның гайбәтен сатабыз, кызлар белән нишләп булганын фаразлыйбыз. Һәм алар турында такмаклар чыгарабыз. Аларны кәгазьгә язып, иртәгесен мәктәптә кызлар партасына куябыз. Тагын да бераз үсә төшкәч, аулак өйләргә кич утырырга йөри башладык. Анда да такмаксыз булмый. Кара-каршы такмак әйтешү дә бар иде әле ул заманда. Хәзер ул җуелды.Такмак чыгаруда мин беренчеләр рәтендә булдым шикелле. Ничектер үзеннән-үзе килеп чыга иде ул. Моны экспромт дип атыйлар. Экспромт кына булмагандыр ул, көндезләрен кичке «җыен»га әзерләнеп, такмаклар чыгарганым һәм аларны язып та куйганым хәтердә. Кызганыч, аларның күбесе инде онытылган. Мәсәлән,

*Әй, аузың зур, аузың зур,*
*Аузыңны нишләтергә?*
*Бер ягына пич чыгарып,*
*Канюшный эшләтергә, —*

дигәне истә. Кайсыдыр кызга аталып чыгарылгандыр инде ул. Кем булды икән ул олы авызлы кызыбыз? Ә менә бу такмакның адресаты билгеле.

*Сездә бүген ничәсе,*
*Бездә бүген кичәсе.*
*Ике түстаган аш ашаган*
*Айтуган Хәдичәсе.*

Хәдичә апа бездән өлкән иде. Күрәсең, бу такмак өлкән егетләрнең заказы белән язылгандыр. Мәктәптә иҗат итәр өчен мөмкинлекләр бар иде. Чөнки стена газетасы чыга һәм анда, әлбәттә, шигырь дә булырга тиеш. Өстәвенә, укытучы апа кайчакларда күргәнеңне шигырь итеп язып килергә куша. Кушылган «өйгә эш»не үтәп килгәнем дә хәтердә калган. Күргән нәрсә күп була бит ул бала чакта. Әмма барысы да шигырьгә сыеп бетми. Кайсыларын язуы кызык түгел. Көн дә ашый торган бәрәңге турында ничек инде шигырь язасың? Минем өчен кызыклы факт табылды. Безнең өй күл буенда гына. Ә анда бакалар. Кайвакытта алар күл кырыена чыгып чалкан яталар икән. Шул турыда яздым да куйдым:

*Күл буенда бакалар*
*Бот күтәреп яталар.*

Үз язганымнан үзем рәхәтләнеп көлдем. Тик укытучы апама гына бу ошамады.

«Бот күтәреп яту» аңа ямьсез тоелгандыр, ахры. Ә менә стена газетасы өчен язылган шигырь ошады укытучыга. Ул Пушкин турында иде. Ни өчен Пушкин — анысын хәтерләмим. Ул шигырь инде үзе дә хәтердә сакланмаган. Андагы «гүя» дигән сүз барлыгы гына истә. «Гүя» дип безнең авылда сөйләшмиләр, аны китаптан укып белгәнмендер инде. Гүя дигән сүз «шикелле», «кебек», «сыман» сүзләренең синонимы. Матур сүз. Сандугач шикелле дип әйтсәң дә дөрес, әмма гүя сандугач дисәң, грамытныерак килеп чыга сыман кебек шикелле. Шигырь теле купшылыкны кабул итә. Шуңа күрәдер, бүгенге яшь шагыйрьләр купшы итеп язарга яраталар. Купшылык кайчак аңлашылмас дәрәҗәгә җитеп, ачуны китерә башлый.

Егет булып җитешкәч, шигырь язу белән шөгыльләнгәнемне хәтерләмим. Күрәсең, үскән саен тормыш мәшәкатьләре күбәя төшкәндер, шигырь кайгысы булмагандыр. Шулай да тугызынчымы, унынчымы класста укыганда Сания исемле кызга күзем төшеп, аңа багышлап шигырь яздым бугай. Матур шигырь булгандыр. Тенеш авылы кызы Сания үзе дә чибәр иде шул. Яшьлек истәлеге булсын, аның турында бүген дә бер строфа язып куйыйм әле.

*Ялтыравык галош, ап-ак йон оекбаш —*
*Ничек шуңа күзең төшмәсен?*
*Тенеш кызыкае, хәтерлимсең микән*
*Каракүлнең якты чишмәсен?*

Юктыр, хәтерләмидер. Ул мине күзлек кигәнем өчен ошатмады. Җитмәсә, буем да ул чакта бәләкәй иде. Бәлки инде ул исән дә түгелдер. Тьфү, тьфү, әйттем исә кайттым, исән генә була күрсен.

Әдәби иҗатка тартылу мине Казан университетына алып килде. Татар теле бүлегенә имтиханнар тапшырдым. Үтмәдем. Немец теленнән «икеле» чәпәделәр. Дөрес эшләделәр — немец телен алты ел укысам да, белми идем.

Киттем Казакъстанга — чирәм җирләрне эшкәртергә. Әдәбият җырланасы җыр булып киләчәккә калды. Язмышым да минем әдәбият белән бәйләнергә тиешле булгандыр, чирәм җирләрне урап кайткач, тагын университетка керергә тырыштым, ләкин, бәхетемә күрә, Мәскәүдәге театр училищесына укырга китәргә туры килде. Монда инде рәхәтләндем шигырь язып. Чөнки бирегә иҗат атмосферасы иде. Минем кебек күңелендә иҗат ялкыны йөрткән егетләр бар иде. Мин язган шигырьләрне бергә җыеп, «Насыйбулла боткасы» дигән кульязма «китап» та чыгардык. Шигырь белән бергә драматургия дигән жанр барлыгын да белдек театр училищесында. Казанга училищены тәмамлап кайтканда минем бер чемодан шигырьләрем һәм «Азат» дигән бер пьесам да бар иде. Мин әле шигырь техникасын да, драматургия серләрен дә белмим, такмак чыгарган шикелле авылча гына сыпыртам. Миңа язуы кызык һәм рәхәт. Язучы өчен иң кирәкле нәрсә язуыңнан үзең тәм таба белүдер. Мин язарга тиеш дип интеккән кеше кулына каләм алмасын иде. «Иҗат газабы» дигән сүз бар барын. Ләкин ул газап татлы газап — мазохизмның бер формасыдыр. Шул «газап» булмаса, язып та булмыйдыр. Менә шул үзем сайлаган «газап» мине өстәл янына ешрак бәйләп куя иде.

Мин артистлыкка укыдым, театр штатында артист булып саналдым. Артистлык һөнәре дә иҗат. Үтә дә кызыклы, катлаулы иҗат. Син үзең булып калган хәлдә икенче бер кеше образына керә белергә тиешсең. Кайвакыт син уйнаган роль синең яшәү рәвешеңә, холкыңа, фикерләвеңә дә туры килми, әмма тамашачының синдә эше юк, ул спектакль карарга килгән, ул син уйнаган персонажның чын икәненә ышанырга тиеш. Ә кешене ышандыру өчен ихласлык кирәк. Миндә шундый осталык булдымы икән? Өздереп әйтә алмыйм. Осталыгымны күрсәтергә театрда миңа вакыт җитмәде, китәргә мәҗбүр иттеләр. Мин моны бик авыр кичердем. Мине драматургия коткарды. Анда да бит уйнарга кирәк. Ышанып уйнарга кирәк. Артист бер спектакльдә бер кеше булып уйнаса, драматург барлык персонаж өчен дә уйнарга мәҗбүр. Гаҗәеп кызыклы иҗат. Балаларның курчак уйнауларын күзәткәнем бар. Алар үз курчакларына үзләре күреп белгән кешеләрнең холкын, сөйләү манерасын

бирәләр. Пьеса язу да шул курчак уены бит инде. Шуны аңлый башладым мин яза-яза. Белгәнемне генә язарга тырыштым. Минем белгәнем — авыл, шунда яшәүчеләр, аларның уй-тойгылары, фикерләү формасы, җырлары, мәзәкләре, мәхәббәтләре, нәфрәтләре, сагышлары... Болар миңа сабый чагымнан ук каныма сеңгән иделәр. Пьесаларымда шулардан ерак китмәскә тырыштым. Заман сәясәтенә яраклашуның язучы өчен куркыныч нәрсә икәнен аңлап ук бетермәсәм дә, эчке бер сиземләү белән тойдым шикелле. Шул мине Рәсәйдәге сәяси үзгәрешләр афәтеннән коткарып калды. Әдәбиятның өйрәнү объекты кеше икәнлеген укып та белә идем инде. Бездән сәяси система партиянең ирешкән уңышлары, матур тормыш турында әсәрләр көтте, шуны аңыбызга сеңдерергә бөтен көчен куйды.

Язучыларны бергә җыеп эшкәрту өчен Язучылар берлеге оештырылды. Без аның әгъзалары идек. Язучыдан зур бер агрегатның винтигы ясау идеологиясе мин әдәбият бусагасын атлап кергәндә көчле иде әле. Ул идеологиягә буйсынмый яшәү бик кыен иде. Чыгымлаучыларны тәртә арасына кертүнең күп төрле ысуллары бар иде. Чыбыркы белән бергә прәннеге дә эләгә иде, билгеле. Мин инде аларны санап тормыйм. Һәрхәлдә, әдәбиятка килүче яшьләргә игътибар хәзергедән күпкә яхшырак иде. Без ташландык хәлдә түгел идек. Безгә күрсәтелгән игътибар өчен без иҗат ирегe белән түләргә мәҗбүр идек. Шулай да таш араларында үсәргә омтылган, хәтта өстенә җәелгән асфальтны да тишеп чыккан үлән-агачлар кебек, җан ирекка омтыла иде. Җәмгыятьтә кемнәрдер әйткәнен кабатлау белән канәгатьләнмичә, үз сүзеңне әйтергә тырышу инстинкты күңелләрдә яшәп килде. Без ул турыда аерым-аерым да, кайчакларда берничә язучы бергә мәҗлесләрдә җыелганда да уйлана, сөйләшә, фикер алыша идек. Бәхетемә күрә, мин инде иҗат тәҗрибәләре булган талантлы кешеләр арасына килеп эләктем. Илдар Юзеев, Аяз Гыйлаҗев, Шәүкәт Галиев, Альберт Яхиннар белән мәҗлестәш булып, күп нәрсәгә өйрәндем. Мин, бу кешеләргә рәхмәтле булсам да, берсен дә остазым дип санамыйм — әдәбиятта остазлык була алмыйдыр ул. Язарга берәүне дә өйрәтеп булмый. Хәреф танырга, җөмлә төзергә, нокта-өтерне кая куярга өйрәтеп була, ә әдәби әсәр язарга — юк. Хәер, бәлки, анысына өйрәтеп буладыр, ләкин ул өйрәтелгән язучы өйрәнчеклектән үлгәнче чыга алмыйдыр. Ул гомере буе остазын кабатлый гына торгандыр. Әдәбиятта үз йөзең, үз сүзең булмаса, исемең дә булмый. Кайвакытта мине бүгенге заманның Тинчурины дип атыйлар. Мин аны мине түбәнсетү дип кабул итәм. Тинчурин ул Тинчурин. Ул татар драматургиясенең йөзек кашы. Ул ничаклы бөек булса да, мин аны кабатлыйм икән, минем бәям базар көнне ике тиен. Тукаебыз бөек, әмма кемдер Тукай булырга азаплана икән, ул — мескен. Классиклар яшь язучыларга маяк булырга тиешләр. Алар яктысында, алар күрсәткән юлдан бару бары тик әдәбиятка олы итеп, үтә дә җаваплы шөгыль итеп карауда гына булырга тиештер. Калганы үзеңнән тора.

Мин санаганнар арасында Гариф абый Ахунов юк. Ул минем иҗади тормышыма соңрак килеп керде. Һәм һәрвакыт миңа хәер-хаһ булып мине үсендереп торды. Ул исемгә мин бу язмамда соңрак махсус тукталырмын әле. Минем иҗат юлымда очраган каләмдәшләрем турында әйтәсе сүзләрем бар. Уйлыйм әле менә — әйтергәме, юкмы. Чөнки ул сүзләрнең төрле булуы ихтимал. Аларны уңга-сулга селтәнмичә, үлгәннәрнең рухын рәнҗетмичә генә, исәннәрнең бәгыренә кагылмыйча гына ничек әйтергә? Уйларга кирәк. Мине үз араларына алып «эшкәрткән» язучылар, куркытылган булсалар да, мокытлык дәрәҗәсенә төшмәгәннәр иде. Фикерләрен кычкырып әйтмәсәләр дә, диссидент булмасалар да, без яшәгән җәмгыятьтәге ирексезлек турында яшерен-батырын сөйләшәләр иде. Аяз Гыйлаҗев исә уен кычкырып әйтүдән дә курыкмый иде. Хәтеремдә әле, бервакыт фашист концлагерьларындагы коточкыч шартлар турында сүз чыккач: «Сез әле совет концлагерьларын күрмәгән, күрсәгез, немец концлагерьлары балалар бакчасы гына булып күренер иде», — диде. Минем котым алынды шул сүзләрдән соң. Альберт Яхин үзенә генә хас алым белән миңа мәсәл жанрының ничек барлыкка килүен аңлатты. Болай диде: «Мәсәл ул сүз ирегe тыелган җәмгыятьтә фикереңне

яшереп әйтү өчен уйлап чыгарылган жанр. Безнең илдә мәсәл иң популяр жанр булырга тиеш иде Ләкин безнең мәсәлчеләр ул жанрның да дәрәҗәсен төшерделәр». Бу фикерен матбугатта бастырырга кыюлыгы җитмәсә дә (аңа моны рөхсәт итмәячәкләр иде), минем аңыма, күңелемә салып куйды. Илдар Юзеев миңа аеруча якын иде. Беренчедән, яше белән миннән әллә ни өлкән түгел, икенчедән, шигырьләрендәге җылылык күңелемә ятышлы иде. Шәүкәт Галиевтә авыл агаеның зирәклеге, һәр сүзен үлчәп сөйләве минем тотрыксыз холкымны аз-маз төзәтергә ярдәм итте. Аның миңа биргән бер киңәше өчен рәхмәтлемен. Чын язучы булам дисәң, гәҗит-журналга кереп эшләмә, ул язучының җелеген суыра торган эш. Мин аның сүзен тыңлап дөрес эшләдем. Язучыларның бүтәннәреннән дә нәрсәгәдер өйрәнгәнмендер инде. Язучылыгы чамалылардан да ничек язмаска икәне өйрәнелгәндер.

Заманалар үзгәргәч, кайбер язучылар совет, партия идеологиясенә каршы көрәшкән кыяфәт алдылар, үзләрен хакимият тарафыннан эзәрлекләнгән дип язып та чыктылар. Мин үзем, мәсәлән, Салих Баттталдан башка эзәрлекләнгән татар язучысын белмим. Кисәтелгәннәр бар иде, әмма эзәрлекләү ул икенчерәк нәрсә. Мине кисәтүче булмады кебек. Г.Камал театрында куелган «Миләүшәнең туган көне» спектаклен репертуардан алдылар. Сәбәбе идеологик хатага бәйле түгел иде шикелле. Ләкин әсәрнең төбендә әле яңа гына тормышка аяк баскан иҗат интеллигенциясенең бәргәләнүен сурәтләү иде. Бәлки, яшьләрнең үзләрен урап алган мохиттән ризасызлыгын сәхнәдән күрсәтү кемнеңдер кәефен кыргандыр. Ни булса булды, әлеге пьеса дөньяга Туфан Миңнуллин дигән яшь драматург туганлыгын теркәп куйды. Мин шул көннән иҗат эшенә җаваплы карый башлаганмындыр.

Хәтерлим әле, кайсыдыр гәҗиттә бер язучының мәкаләсе астына фамилиясе һәм дәрәҗәле исемнәре язылган иде. Без, яшь-җилкенчәк, шуны тикшереп утырдык. Шунда: «Мин беркайчан да язганнарым астына фамилиямнән башка нәрсә өстәмәячәкмен. Минем фамилия үзе дәрәҗәле исем булырга тиеш. Габдулла Тукайга нигә дәрәҗәле исем, Тукай диюгә үк кем икәнен беләләр», — дип әтәчләнгән идем. Мактанчыклык бар инде, нишләтәсең. Ләкин мактану мактану инде, аны акларга да кирәк бит әле. Гомер буе мин шул мактануны акларга тырыштым. Ирешә алганмынмы, анысын бүтәннәр бәяләсен, тик алдыма куйган максат-бурыч миңа шәләй-вәләй язарга ирек бирмәде.

Уңышсыз әсәрләрем бардыр, тик берсе дә халтура өчен язылмады. Югыйсә, тагын мактанам, пьеса кораштыру миңа бик җиңел. Мин аның серләренә төшендем шикелле. Гали Галияне ярата, Галиянең Вәлидә өмете, Вәли белән Гали дуслар — менә шуларны буташтырып, кайбер тамашачылар халтура икәнлеген сизмәслек тә итеп өч-дүрт көндә пьеса әвәләп куя аламдыр. Ләкин андый юл белән китүнең кая алып барасын белгәнгә, юлның авыррагын сайларга тырыштым. Хәер, әлләни авыр да түгел инде ул бер караганда. Әйтик, «Әлдермештән Әлмәндәр»не язуның ни авырлыгы булсын? Мин беләм бит андый Әлмәндәрләрне. Алар барысы да миңа таныш. Аларга кирәкмәгән идеологик бизәкләр такмыйча гына язарга кирәк. Мин ул пьесаны 12 көндә яздым. Каләм үзе яза, мин «ияреп» кенә барам. Нәтиҗәдә, килде-чыкты бөтенебезгә таныш Әлмәндәр. Гап-гади авыл карты. Безнең халкыбыз кебек. Эшли, яши, Әҗәл белән көрәшә. Анда мин уйлап чыгарган нәрсә — Әҗәлнең 1552 номерлы булуы. «Нигә аның номеры 1552 дип кызыксынучылар булгач, мин аны 1550гә төзәттем, дөресен әйткәндә, куйдырмаслар дип курыктым. Чөнки «Нигә 1550?» дип тә кызыксынучылар булды. Мәдәният министрлыгында Әлмәндәргә бизәк тагарга җыенучы табылды. «Кем соң ул Әлмәндәр, пьеса герое булырлык ни кылган?» — диде министр урынбасары. Һәм Әлмәндәрдән Социалистик Хезмәт Герое ясарга тәкъдим итте. Мин, әлбәттә, аны тыңламадым, Әлмәндәрнең кем икәнлеген күрсәтү өчен пьесага түбәндәге сүзләрне өстәдем:

Фәрештә: Әлмәндәр дә Әлмәндәр, дисең. Кем соң ул? Галимме? Искиткеч бер ачыш ясаганмы? Танылган җырчымы? Әллә берәр футболчымы, йә булмаса хоккейчымы? Кем? Нәрсә эшләгән?

Әҗәл: Берни эшләмәгән. Гап-гади кеше. Ләкин гомере буе яшәүнең кадерен, тәмен белеп яшәгән кеше. Иң авыр чакларда да тормыштан ямь таба

белгән, күңел көрлеген югалтмаган кеше. Ул — авылның шатлыгы, өмете».

Әлмәндәрнең кемлеген Әҗәл аңлатканда Фәрештә, әйткәннәренә өстәп, «Социалистик Хезмәт Героемы?» — дип тә сорый иде. Аны, министр урынбасарыннан көлү кебегрәк ишетелгәнгә, сызып ташладым.

Әлбәттә инде, пьесаларны язганда күргән-белгәннәрне генә теркәп баручы булу егетлек түгел. Язучыны теге яки бу әсәрне язарга этәрүче сәбәпләр була. Мин аларны гадәттә дүрткә бүләм. Беренчесе: сиңа ошаган, үрнәк була алырлык берәр шәхес турында бүтәннәргә сөйләү. Икенчесе: синең ачуыңны китерерлек әшәке бер җан турында башкаларга гыйбрәт булсын дип язу. Өченчесе: ишеткән, күргән кызыклы яки гыйбрәтле вакыйганы сөйләү. Дүртенчесе: уеңда йөрткән идея, фикерне башкалар белән уртаклашу.

Мәсәлән, бервакыт тормыш һәм хакимият тарафыннан кыйналган, үтерелгән шагыйрьләр турында уйланып йөргәндә «Үтерелгән шагыйрь исәннәреннән куркынычрак» дигән җөмлә туды. Шуны исбатлар өчен өч татар шагыйренең язмышы турында сәхнә әсәре язасым килде. Иң беренче итеп Муса Җәлил турында яздым. Ул публицистик драмага әлеге җөмләне керттем. Чыннан да, Җәлилнең үтерелүе шагыйрьне үлемсез итте. Һәм ул күпләр өчен куркыныч үлемсезлек. «Бик узынмагыз, тираннар, үтереп кенә котылдым дип уйламагыз, тарих каршында җавап бирәсегез бар», — дип кисәтү ул үлемсезлек. Шул сериядән икенче пьеса — Тукай турында. Анда да «Үтерелгән шагыйрь исәннәреннән куркынычрак» дигән сүзләр бар. Билгеле, Тукайны үлем җәзасына хөкем итмәгәннәр. Ә үтерелмәгән дип кем әйтә ала? Бу безгә барыбызга да кисәтү. Талантлы балаларын милләт сакларга тиеш, алар япь-яшь килеш дөнья белән хушлашырга тиеш түгелләр дигән кисәтү.

Пьесаның өченчесендә — шагыйрь Хәсән Туфан. Анда да теге җөмлә кабатлана. «Йә, нигә ирештегез, иптәш Сталиннар, Гулаглар төзеп, сез бүген каһәрләнүчеләр исемлегендә», дип әйтер өчен язылган пьеса иде ул.

Яши-яши, яза-яза язуымның төп темасын ачыкларга кирәк була башлады. Безгә әйттеләр ни турында язасын, әзер темалар бирделәр. Мәсәлән, КамАЗ төзегәндә, шул турыда язьгыз, диделәр. КамАЗның кирәклеген аңласак та, ничек итеп язарга икәнлеген күпләребез белмәде. Әдәбият объекты кеше кем ул төзелештә? Коммунизм төзүчеме, әллә колхозда изелүдән качып эшкә урнашучымы? КамАЗ төзибез дип кычкыручылар бар, бата-чума төзелештә эшләүчеләр бар. Кайсысы турында язарга? Миңа да обкомнан бөек төзелеш турында пьеса язарга тәкъдим иттеләр. Ничек итеп язарга белмәгәч, «КамАЗ грандиоз төзелеш, мин аны пьесама сыйдыра алмыйм», — дидем. Ул чакта мин «Ат карагы» дигән пьеса язган идем. Ат карагы турында яза, КамАЗ турында язарга теләми дип пьесамны куйдырмадылар.

Ни турында язарга кирәклекне ачыклый торгач, татар турында язарга кирәк дигән фикергә килдем. Аның турында без язмасак, кем язсын. Милләт темасы һәрвакыт актуаль тема. Халкыбыз яшәгәндә генә без, татар язучылары, яши алабыз, халкыбыз бетсә, без дә юкка чыгабыз. Бу — хакыйкать. Тукаебыз иҗатында да татар темасы үзәктә тора. Иҗатымның юнәлеше шуннан үзгәрә башлагандыр. Ни турында гына язсам да, уемда һәрвакыт татар тора. Әгәр пьесалардагы персонажлар арасында әйбәт булмаганнары бар икән, сурәтләгәндә көенәм, аларны яхшы итеп күрәсем килә. Язучының көндәлек дәфтәре булырга тиеш. Күргән, ишеткәннәрне хәтердә тотып бетереп булмый, көндәлеккә теркәп куясың. Әсәр язганда блокнотка күз салсаң, теркәп куйганнарның һәрвакыт кирәге чыга. Мин пьесалар язу белән бергә публицистика жанрында да эшлим. «Утырып уйлар уйладым» дигән исем белән инде дүрт китабым чыкты. Анда милләт язмышына багышланган бик күп язмалар бар.

«Утырып уйлар уйладым» дигәннән, проза жанрында хикәяләр дә язгалыйм. Чөнки драматургия теле белән сөйләп булмый торган вакыйгалар була. Проза язу миңа бик авыр бирелә. Сурәтләү чаралары таба алмыйм. Оста прозаиклар үз персонажларының төс-кыяфәтләрен, холык-фигыльләрен шундый оста итеп сурәтлиләр ки, мин сокланып укыйм. Ә үземнең кулымнан килми. Драма әсәрләре язганда персонаж сөйләше, үз-үзен тотышы аша гына аның эчке һәм

тышкы дөньясы сурәтләнә. Роман язып карарга күп кызыктым. Ләкин курыктым. Аннан соң, роман язарга түземлегем дә җитми. Пьесаны мин озак уйлап йөреп, бер утыруда яза алам, ә роман өчен күп утырырга кирәк.

Ә иң яраткан эшем — шигырь язу. Күрәсең, ул яшьлек мәхәббәте кебек күңелдә саклана торган нәрсәдер. Шигырь язудан башланды бит иҗатым. Җырлыйсы килеп тә җырланмый калган җыр кебек. Бәлки, җырлыйсы килеп тә җырлый алмаган дию дөресрәктер. Шигырьне әдәбиятның иң катлаулы жанры дип саныйм. Карап торырга бик җиңел кебек бит ул: алды-салды, тәхет-бәхет-ләхетләрдән рифма төзисең дә, бетте-китте, вәссәлам. Кайбер такмакчы шагыйрьләр шулай эшлиләр дә. Ә минә хисне, фикерне, җан сыкравын, күңел уйнавын, мәхәббәтне, нәфрәтне сүзләр белән аңлату һәм укучының да күңел кылларына кагыла белү ифрат авыр. Шигырьдә һәрбер сүз нәкъ үз урынында булырга тиеш. Ә мин барыбер шигырь язуымны ташламыйм. Ташлый алмыйм. Ләкин аларны бүтәннәргә күрсәтмим. Оялам. Шулай да шаярыбрак язган робагыйларны китап итеп чыгардым. Кызык өчен, шагыйрьлеккә дәгъва кылмыйча гына... Җенләнеп китәм дә, кайвакыт шуны робагый итеп язып куям. Соңыннан үзем укып карыйм да язганымны, кызык булып китә, мәгънәсе дә бар кебек тоела. Робагыйларымның берсен монда да күчереп куям әле. Ул минем үземә дә ошый, мин аны юбилей кичәсеннән макталып кайткач язган идем.

*Нигә кирәк яшәдем дип үкерү,*
*Ирештем дип, дөньяны ду китерү?*
*Бер уйласаң, безнең гомер нәрсә ул? —*
*Ярыктан чыгып чокырга сикерү.*

Шигырь язу миңа җиңел, аның өчен каләмдәшләр һәм укучылар алдында җавап тотасым юк. Ә пьесалар белән тамашачылар каршына чыгасы була. Тамашачы кабул итмәсә, мин ул пьесаны уйнап кына яздым дип акланып, котылып булмый. Шуңа күрә алдыма кәгазь салып, кулыма каләм алганчы язылачак пьеса турында озак уйлап йөрим, кайсыларын еллар буенча. «Әлдермештән Әлмәндәр»не тиз яздым, дидем. Әмма үлем һәм яшәү турында күпме уйлаганымны үзем дә белеп бетермим. Һәм кемнәр генә ул турыда уйламый. Гомумән, кеше һәм аның яшәве — бетмәс-төкәнмәс тема. Аны дөньяның бөтен язучылары да меңәр ел буе язып та бетерә алмыйлар.

Кем ул кеше? Берәү дә ул сорауга җавап таба алмый. Хәтта кеше үзе дә үзенең кем икәнен белми. Аны бары тик Ходай гына белә. Галәмнең чиксезлеген аңлап булмаган кебек, кешенең кем икәнлеген дә аңлый алмыйм. Һәм һәрвакыт шул сорауга җавап эзлим. Бөтен язганнарым да минем сораулар гына. Кайвакыт миңа: «Ул пьесаң белән ни әйтергә теләдең?» — дигән сорау бирәләр. Яратмыйм ул сорауны. Ни әйтергә теләгәнемне төгәл белсәм, язмаган булыр идем, дим. Язучы ул дөрес диагноз куеп, рецепт язып бирүче врач түгел. Ул үз алдына һәм укучылары алдына сорау куя да, бергәләп эзлик җавабын, ди. «Нигә алай?» «Нигә болай түгел?» «Ни өчен алай эшләдең, нигә болай эшләмәдең?» яки «Нигә болай килеп чыкты?» — кешене һәрвакыт уйландыра торган сораулар. Кереш сүземдә мин алар турында әйттем. Язучының җитлегә баруы гади сорауларга җавап эзләүдән башлап, катлаулы сорауларга җавап эзләүдән торадыр.

Бер мисал. Г.Камал театрында минем «Сөяркә» исемле пьесам куелды. Баштагы исеме «Гөнаһсыз гөнаһлылар» иде. Башкорт театрлары аны «Ярату гөнаһмы?» дигән исем белән куйды. Ул исемне алар үзләре уйлап таптылар, күрәсең, пьесаның эчтәлеге шул турыда икәнлеген белгәннәрдер. Әйе, ярату гөнаһмы, дигән сорау ифрат катлаулы. Аңа җавапны табу мөмкин түгелдер, тик шул сорау турында уйланырга гына мөмкиндер. Сүз бит мәхәббәт һәм тормыш чынбарлыгы турында бара. Мәхәббәт — кешедән кеше ясаган бөек хис. Акыл да кешене кеше иткән сыйфат. Алар еш кына бәрелешә. Бер үк кешедәге кайнар хис белән салкын акыл бәрелешкәндә кайсы якны сайларга? Гомер бит берәү генә һәм бик кыска — туйганчы (хәер, аңардан туеп була микән) яратып каласы килә. Шашып яратасы килә. Ә акыл әйтә: мәхәббәт ул

әйбәт нәрсә, кәнишне, ләкин аңа йөгән кирәк, ди, дулап китеп, сине харап итүе ихтимал, ди. Яраткан кешең белән кавышып, гаилә кысасына кергәнсең икән, тәртәдән чыгам дип тәртә сындыру ярамый һәм куркыныч, ди. Дәлилләп күп мисаллар китерә. Син, әлбәттә, килешәсең. Менә шунда ирләргә анабыз Хәва җенесеннән булган берәү яки хатын-кызларга атабыз Адәм затыннан булган берәү очрый да — дөньясын оныта. Нишләргә? Әхлак нормалары күзлегеннән караганда, әлбәттә, гаиләле булган килеш икенче берәүгә күз салу — бозыклык. Ләкин Ходай янәшәсендә Иблис бар. Иксез-чиксез Кодрәткә ия Ходай ни өчендер Иблискә җир йөзендә урын биргән. Шул Иблис котырта кешене, сөяркәле булуның гөнаһысы әллә ни зур түгел, ди. Сөяркә бит сөю сүзеннән алынган, ди. Әгәр син берәүне үлеп сөясең икән, ул бит кешегә хас сыйфат, ди. Ходай биргән бит сиңа сөю, ярату, мәхәббәт дигән бөек хисне, ди. Әнә ничаклы каршылыклар кешедә. Гаилә — җәмгыятьнең соткасы, шул тотка каерылмасын дип яки яратмаган, яки күңелең суынган кеше белән яшәү дә бит кеше өчен газап. Әнә шул каршылыклар тудырган сорауларга җавап эзләшергә дип язылды «Сөяркә». Җавабын таба алмадым. Һәм аны бер язучы да таба алмаячак. Ләкин сорау куелырга тиеш. Син язганны укыган яки караган кеше язганыңны үз тормышы, үз булмышы белән чагыштырып карап, уйланып, ниндидер нәтиҗәгә килергә тиештер. Сорауларга җавап эзли белмәү билгесезлеккә китерә, ә билгесезлек кеше өчен мәңгелек газап.

«Сөяркә»гә тукталуым акыл сатудан түгел, язучының үз алдына нинди сорау куярга тиешлеге турында уйлану гына. Ике икең дүрт икәнен бүтәннәргә аңлатырга тырышу язучы буларак сәләтсезлек галәмәте. Боларны мин ни өчен язаммы? Әлеге дә баягы язучы буларак формалашкан вакытта үткән юлыма борылып карау бу. Мин үземне бүген профессионал язучы дип саныйм. Ягъни минем профессиям — язу. Анкеталар тутырганда да мин үземне шулай дип атадым. Калганы — хезмәт итү генә. Әйтик, мин озак еллар төрле дәрәҗәдәге депутат булдым. Ул вазифаны намус белән башкарырга тырыштым. Әмма мин сәясәтче түгел. Сәясәтче була да алмыйм, теләмим дә. Язучылыкны бернигә дә алыштырмыйм. Иҗатыма сәясәт кертмәскә дә тырышам. (Хәер, алай дисәң, тормыш үзе сәясәт инде ул). Патшалар да, обком секретарьлары, президентлар да, караклар, урам себерүчеләр, бомжлар да минем өчен бары тик кешеләр генә.

Бервакыт татарның уңган-булган, йөрәкле кешесе Шәкүр карак турында пьеса язасым килде. «Нигә шундый батыр йөрәкле кеше караклык белән шөгыльләнгән?» дигән сорауга җавап эзләү иде теләгем. Шәкүр Рәхимовның тормышын өйрәнер өчен аның турында сөйләнгән легендаларны тыңладым, туган авылын күреп кайттым (авылында аны яманлап сөйләгән кеше табылмады), язылган истәлекләрне, әдәби язмаларны укыдым. Татарстан Югары судында Шәкүр һәм аның каракташларын хөкем иткән документлар сакланганын белә идем. Шуның белән танышырга теләп, Югары судка бардым. Мин мөрәҗәгать иткән Югары суд хезмәткәре: «Что же вы хотите писать о преступнике-конокраде?» — диде. «Он для вас преступник, для меня прежде всего человек», — дидем. Хезмәткәр миңа шикләнебрәк (юрист бит) карап торды да: «Ну что же, ищите в нем человека», — диде һәм суд бинасыннан чыкмыйча гына Шәкүр Рәхимовның кырык томлы эше белән танышырга рөхсәт бирде. Һәм танышу процессында берничә тапкыр: «Ну, нашли в нем человека?» — дип сорады. Әйе, Шәкүр каракның ничек итеп ат урлавы түгел (язучыга анысын да белергә кирәк), ә кеше буларак нигә шул юлны сайлавы кирәк язучы өчен. Һәм мин аны табарга тырыштым.

Язганнарым арасында әллә ни тирән фикер ятмаган комедияләр дә бар. Алары да кирәк әдәбиятта. Юмор әсәрләрендә персонажның холык-фигыле ачыграк, «күпертебрәк» сурәтләнә. Аларны укучы яки тамашачы да шулайрак карый. Язганыңда үз-үзен күрсә, рәхәтләнеп үзеннән көлә. Комедия жанрын җиңелчә жанрга саныйлар. Янәсе, кәмит кенә. Беренчедән, кәмит белән комедия арасында аерма бар, икенчедән, комедия язу драма язудан авыррак: кешене елатуы җиңел бит, көлдерүе, елмайтуы гына авыр.

Мин юлымда очрап, миңа җитлегергә ярдәм иткән кешеләрне искә алган

идем. Драматург өчен иң кирәкле кешеләрне — режиссерларны да искә алыйк. Мин һәрвакыт миңа яхшы режиссерлар «эләкте» дип язып килдем. Ходай миңа бик мәрхәмәтле булды. Драма әсәрләре әдәбият итеп каралсалар да, алар сәхнәдә генә чын бәяләрен ала. Дөрес, чын бәяне фикердәш талантлы режиссерларның хезмәте генә бирә ала. Иң югары сортлы бодай оныннан да адәм ашамаслык ризык пешереп булган кебек, яхшы пьесадан да начар спектакль әвәләп була. Миңа, бәхетемә каршы, андый режиссерлар туры килмәде. Беренче пьесамны куючы Сабир абый Өметбаевны мәңге онытмаячакмын. Мин аның турында инде язгаладым. Монда да кабатлыйм. Ул, Минзәлә театрының баш режиссеры, «Безнең авыл кешеләре» дигән пьесамны укып чыкты да, «куябыз», диде. Пьесаны артистларга кычкырып укыдым. Артистлар тыңлыйсы килмичә генә тыңладылар. Чөнки игътибарны җәлеп итәрлек нәрсә юк иде пьесада. (Аның шулай икәнен соңрак аңладым). Пьеса укылып беткәч, фикер алышулар башланды. Сүз алып сөйләүчеләр юк, «Нәрсә соң бу?» — дип сораучылар күп. Сабир абый барысын да сөйләргә мәҗбүр итә. Артистлар, Сабир абыйдан шүрләсәләр дә: «Бу әйбернең сәхнәгә куярлыгы юк», — дигән нәтиҗә ясадылар. Сабир абый, «куябыз», ди. Мин ниндидер оят эштә тотылган кеше сыман башны аска иеп утырам. Артистларга да ачуым чыга, миңа үчләре бар сыман тоела. Сабир абый һаман, «куябыз», ди. Пьесаның ни өчен куелачагын дәлилли: «Пьесада ике урында чын-чынлап күңелдән көлдерә торган ике эпизод бар. Әгәр дә без бер кичтә безнең спектакльне караган тамашачы — совет кешесен ике тапкыр чын күңелдән көлдерәбез икән, ул бөек нәрсә. Аның кәефе күтәрелә, эшен дә эш итеп эшли, яшисе килеп тә яши», — ди. Демагогиянең бу формасын бүген дә искә алып елмаям мин. Пьеса укылып, артистлар таралгач, Сабир абый: «Йә, ничек?» — дип сорый миннән. «Алар аңламадылар шикелле», — дигәнрәк сүз әйттем. «Аңладылар, бик яхшы аңладылар, — диде режиссер. — Ләкин барыбер куябыз. Син яшь кеше. Синең каләмең барлыгы сизелә. Син үз ялгышларыңны үзең сәхнәдән күрергә тиешсең, — диде. — Монысын куябыз, әмма тагын да шундый пьеса алып килсәң, театрдан типкәләп чыгарам», — диде. Куйды Сабир абый «Безнең авыл кешеләре»н. Премьера көнне «Синең кайда утырганыңны тамашачыларга әйтәм, тотып кыйнасалар, миңа үпкәләмә», — диде. Уйнадылар. Рәхмәт Сабир абыйга, минем кайда утырганымны тамашачыларга әйтмәде. Ә бу вакыйга миңа гомерлек сабак булды. Мин ул пьесаны бер генә җыентыгыма да кертмәдем. Хәтта үземдә кульязмасы да сакланмаган. Шундый сабак биргән Сабир абыйны ничек инде олылап, сагынып искә алмыйсың ди. Аның режиссер осталыгы турында кайберәүләрнең тискәре фикерләрен ишеткәч, мин теш-тырнагым белән аны якладым. Мәсьәлә шәхсән миндә генә түгел бит, яшь иҗат кешесенең киләчәген сизә белү сәләте теләсә кемгә бирелми. Йөрмә пешмәгән пьесаң белән буталып, дип куып чыгару күпләрнең канатын сындыра.

Әлеге пьеса уңаеннан тагын бер кешене искә аласым килә. Ул шул вакыттагы Мәдәният министры Рәхмәтуллин абый. Ул минем белән һәм минем кебек берничә автор белән язылачак пьесаларга договор төзеде. Аванска акча алдык. Соңыннан ишеттем, аңа әйткәннәр: «Язылмаган пьесаларга договор төзеп, акча түләп ашыкмаска иде. Әллә язалар әле алар, әллә юк, язганнарының да ничек буласы билгесез». Ул: «Әгәр дә без төзелгән ун договордан бер адәм рәтле пьеса алабыз икән, димәк, дөрес эшләгәнбез», — дигән. Чиновникларның да мондыйлары була. Аны да мин сагынып искә алам. Бүген инде сәхнәгә куелып, ел буе уйналган пьесаларыбызга гонорар ала алмыйбыз. Безгә дигән акчаны Макаревичлар алып бетерә. Заманында «Күчмә театр» исемен йөрткән (бүген К.Тинчурин исемендә) театрның баш режиссеры Равил абый Тумашев белән эшләү дә миңа драматург булырга бик ярдәм итте. Беренчедән, ул мине иҗат ритмында яшәтте. Бер пьесамны куйгач ук: «Тагын кайчан пьеса китерәсең?» — дип, тыкырдатып тора иде. Миңа «уңышлардан баш әйләнеп» шәләй-вәләй йөрергә вакыт калдырмый иде. Пьесаны спектакль иткәнче автор белән эшли белүче режиссер иде ул. Авторларга ялгышларын бик акыллы итеп күрсәтә белүче режиссер иде. (Туксан яше тулып килгән Равил абый исән-сау әле. Ходай аңа хәерле гомер озынлыгы бирсен). Мәсәлән, мин «Нигез ташлары»

дигән пьеса язып, Равил абыйга бирдем. Мин язган пьесада туган нигезләрен ташлап киткән бертуган ирләрнең әтиләре янына кайтып әверә килүләре сурәтләнгән иде. Ул әсәр язылган чакта авылның тарала башлаган вакыты иде. Мин авыл язмышы өчен борчылып язган идем аны. Равил абый, пьесаны укып чыккач: «Әлбәттә, син күтәргән проблема да җитди. Ләкин нигез ташлары турында сүз барганда синең персонажларыңның кешелек сыйфатлары әдәбият өчен мөһимрәк. Эш бит кешеләрнең кайда яшәвендә түгел, кем булуларында. Бу очракта, кеше буларак, синең геройларың аталарының нигез ташлары була алырлармы?» Бу киңәш пьесаның мәгънәсен тирәнәйтте, мин, әлбәттә, Равил абый белән килешеп, рәхмәтемне әйттем.

Гали Хөсәенов атлы режиссер бар иде. Без аның белән Казан телевидениесендә бергә эшләдек. Ул — режиссер, мин — редактор. Аннан икебез дә телевидениедән киттек. Ул Әлмәт театрында баш режиссер буларак минем иҗат белән һәрдаим кызыксынып торды. Ә «Ай булмаса, йолдыз бар» спектакле өчен аңа, миңа һәм гаҗәеп талантлы актриса Дамирә Кузаевага Тукай премиясе бирделәр. Театр сәнгатенең фанаты иде Гали абый Хөсәенов, авыр туфрагы җиңел булсын.

Марсель Сәлимҗанов. Бу исем минем иҗади язмышымда аерым бер урын алып торган зур шәхес. Г.Камал театрында баш режиссер булып утыз елдан артык эшләп, ул минем егермегә якын пьесамны сәхнәләштерде. Безне ни якынайтты икән? Без икебез ике төрле тәрбия алган кешеләр бит. Минем әти-әнием авыл кешеләре. (Әти Казанда туса да, гомере буе авылда яшәде. Тамырлары ук авылдан). Марсель — артистлар баласы, әби-бабайлары хәлле кешеләр. Марсель мине «аграрий» дип атый иде, мин җавап итеп аңа «асфальт малае» дигән кушамат тактым. Холыклар да төрлечә — мин бик тиз кабынып китүче шырпыккан, ул сүзен уйлап кына әйтүче шактый ук хәйләкәр кеше. Әмма аның хәйләкәрлеге мәкерле нияттән түгел, акыллылык галәмәте. Менә шушы ике кеше дистә еллар буе уртак тел табып, килешеп яшәдек-эшләдек. Күрәсең, безне берләштергән уртак сыйфат — театр сәнгатенә җитди, профессионал караштыр. Икебез дә беренче чиратта профессионализм күзлегеннән карый идек иҗатка. Театр безнең өчен хобби, ягъни мәсәлән, мавыгу гына түгел иде. Профессионал сәнгатьтә үзешчәнлек булырга тиеш түгел дип саный идек. Марсель Сәлимҗанов пьесаларга бәя биргәндә, аларны ике төргә бүлеп карый иде: әдәбиятлы һәм әдәбиятсыз пьесалар. Әгәр драма әсәре аерым әдәбият жанры булып театрда куелмаган килеш тә яши ала икән, димәк, ул әдәбиятлы пьеса, ә инде уйнап күрсәтүдән башка яши алмый икән, ул — әдәбиятсыз пьеса. Мин, мәсәлән, ул аерманы аңлап бетерә алмыйм, минем өчен драматургия бары тик әдәбиятның бер жанры гына. Марсель исә кайбер пьесаларны укып чыга да: «Куярга була, билгеле, ярыйсы гына спектакль дә чыгуы ихтимал, ләкин монда әдәбият юк», — дия иде. Минем язганнарны ул әдәбият дип кабул итте. Ялгышмасам, «Диләфрүзгә дүрт кияү»дә генә әдәбият юк, диде. Әмма аны да куйды, һәм спектакль Камал театрында озак еллар уйналды.

Марсель чын драматурглар итеп Кәрим Тинчурин белән Нәкый Исәнбәтне санады. «Мин өч драматургның язганнарын яратам», — дип ике классигыбыз арасына мине дә кертә иде. Мин язганнарны куйганда «Синдә крестьян логикасы, аңарга көлебрәк карарга була, әмма кабул итмәү мөмкин түгел», — ди торган иде. Марсель гаҗәеп эрудицияле, тирән белемле режиссер иде. Миңа белем җитешмәде, әле дә җитешми. Минем, Марсель әйтмешли, интуициям, ягъни сиземли, тоя белү сәләтем бар икән. Татарлар арасында иң көчле интуиция иясе дип ул Минтимер Шәймиевне саный иде. Аның үзендә дә белеме белән бергә интуиция дә көчле иде. Сәнгатьтә, әдәбиятта сиземли белү фикерләүдән көчле булырга тиеш, дия иде. Логик фикер йөртүче шагыйрьләрне шагыйрьгә санамый иде. Безнең бәхәскә кергән чакларыбыз сирәк булды. Миңа үз фикерен көчләп тагып, пьесаны төзәттереп интектерми иде, риза булмаган урыннары булса, «Туфанюга, бу җире әллә ничегрәк бит», дия иде дә, мин «әллә ничек»нең нәрсә икәнен эзләп табарга тырыша яки ул аңларлык итеп аңлата идем.

Марсельнең мине түбәнсеткәнен мин хәтерләмим. Бер тапкыр миңа авыр

тоелган сүз әйткән иде, соңыннан аңлаштык. Болай булды ул. «Йөрәк маем» дигән комедияне куйганда сәхнә бизәлешен икебез ике төрле күрдек. Мин күз алдыма китергәнчә, сәхнә яшеллек белән тулырга тиеш иде. Авыл бит. Өстәвенә, җәйге авыл. Матурлык. Марсель сәхнәне такта белән тутырды. Такта басмалар, фәлән-төгән. Мин аңа: «Син бит авылдан шәһәр паркы ясагансың», — дидем. Ул исә болай диде: «Сиңа, авыл мужигына, каен да тал кирәк инде. Авылыңнан башканы белмисең. Сәнгатьтә шартлылык дигән нәрсә бар. Авылның надан мужигы булып фикер йөртмә». Мин үзем өчен түгел, авыл мужигы өчен үпкәләдем. Әйткәләшеп киттек. Иҗатта бәхәсләшү табигый гадәт. Анда әзер формулалар юк. Әмма бәхәстә әдәп сакланырга тиешлеген онытып җибәргәнбез. Миңа бер режиссер: «Сиңа ышанмыйм», — дигән сүз әйтеп, үзеннән биздерде. Шуннан соң мин дә аның профессионаллыгына ышанмый башладым. Бер-береңә ышанмыйсың икән, театрда бергә иҗат итеп булмыйдыр. Хәер, театрда гына түгел, бөтен эштә дә шулайдыр ул.

Марсель белән тату эшләвебездән кайберәүләр гаеп тә эзләделәр шикелле. «Туфан Марсель Сәлимҗановка акча түләп тора икән шул, шуңа күрә Сәлимҗанов аның пьесаларын куя», — дигәнне ишеттергәннәре булды. Аллага шөкер, бер генә режиссер белән дә иҗаттан башка бернинди дә мөнәсәбәт булмады. Түләүле мөнәсәбәтләр иҗатның иң әче дошманы икәнен иҗат кешеләре бик яхшы беләдер. Иҗади мөнәсәбәтләрдә фикердәшлек булу — иң зарури таләп. Минем бүген дә режиссерлар арасында фикердәшләрем бар. Ләкин барыбер Марсельне сагынам. Ул мине иҗатта вакланмаска, арзан популярлыкка алданмаска, мактаганны күтәрә белергә өйрәтте. Марсель куярга теләмәгән пьесаларым да бар иде минем. Андый очракта: «Туфанюга, мин моны куймыйм, күңелемә ятмый, әгәр куючы булса, безнең театр сәхнәсендә, бер сүзем дә юк», — дия иде. «Адәм баласына ял кирәк» дигән пьесаны, мәсәлән, Празат абый Исәнбәт куйды. «Хушыгыз» белән дә шулай булды. Аны Марсель куярга теләмәгәч, Фәрит Бикчәнтәев куйды. Һәм әйбәт итеп куйды. Фәриткә мин «Шәҗәрә» өчен дә рәхмәтле.

Режиссерлар турында сүземне тәмамлап, язмышыма рәхмәт кенә әйтәм, бер генә режиссер да мин язганнарга йөз чөереп карамады. Минем гадәтем — пьеса күтәреп бер генә театрга да ялынып бармадым һәм бармаячакмын да. Мине куймыйлар икән, димәк, сәбәпләре бар: яки мин искергәнмен, яки татарлар арткарак тәгәрәгән — драма әсәрләренә таләпләр кими төшкән. «Яңа татар пьесасы» дигән конкурска килә башлаган пьесаларның беренче бүләккә лаек була алмавы да шуны күрсәтә шикелле. Бу конкурс турында да бернича сүз әйтим инде. Үтә дә кирәкле һәм вакытлы гамәл булды ул. Күпләргә каләменең көчен сынап карарга мөмкинлек бирде. Мин аның беренчесендә катнашырга теләмәдем. Чөнки шартлары белән килешеп бетмәдем. Анда урыс телендә язылган әсәрләр дә конкурста катнаша ала диелгән иде. Татар телендә язылмаган әсәрнең татар әдәбиятына катнашы юк дигән фикердә нык торам мин. Минем «ялгышымны» төзәтүчеләр дә бар. Заманында ике Ринат рус телендә язучы Диас Вәлиев татар язучысы дип исбатлаганда теш-тырнагым белән каршы тордым. Ходай хәерле кылсын. Нишләтәсең, татар булып туганыма мин гаепле түгел, татар булып үләчәгем — иман эше.

Конкурсның соңгыларында да катнашмадым. Көрәштә актив катнашуның бер чиге булырга тиеш дип саныйм. Минем яшьтә әдәбият, театр мәйданнарында ниләр, ничек эшләнгәнен читтәнрәк карап тору кызыклырак. Бер нәрсә сөендерә: драма әсәрләре язарга теләүчеләр арасында яшьләребез күренә. Димәк, театрның киләчәге өметле. Мин бу сүзләрне аксакал роленә кереп кыланып әйтмим. Сәбәбе гап-гади: әгәр язучыларыбыз бетеп, театрларыбыз авторларны урысча язучылар арасыннан эзләсә, шуларны тәрҗемә итеп, бу — татар драматургы дип мактанса, татар театры тора-бара «русскоязычный»га әйләнсә, минем дә кирәгем калмый. Барыбызны да: Галиәсгар Камалны, Мирхәйдәр Фәйзине дә, Кәрим Тинчурин белән Нәкый Исәнбәтне дә, мине дә, сине дә онытачаклар. Әнә бит урыс театрларында бүген урыс бетеп бара, «русскоязычный»лар гына. Әмма урыс үзе булмаса да, аның теле бар. Бездән ни калачак? Без бергә-бергә тотынышып эшләсәк кенә, киләчәк буын турында

кайгыртып кына гомеребезне озынайта алабыз. Ә минем әле, Муса Җәлил әйтмешли, бу дөньядан киткәч тә бераз яшисем килә. Шушы уңайдан кайбер татар театрларының «тамашачы кирәк театрны яшәтер өчен» дип урысча спектакль уйнаштыргалавын уйнашчылык белән маташу, татарга хыянәт итү дип саныйм һәм аларны каһәрлим.

Киләчәк турында уйлау белән бергә мин бүген дә үз тирәмдә булган драматурглар язганын аз гына да күпсенмәдем һәм күпсенмим. Көнчелек дигән әшәке хистәнерактарак йөрергә тырыштым. Әллә кайчан күңелемә киртләп куйдым: ни хәтле генә маташсам да, мин Аяз Гыйлаҗев, Шәриф Хөсәенов, Ризван Хәмит, соңрак Зөлфәт Хәким, Илгиз Зәйниев кебек яза алмыйм, алар да мин була алмыйлар, дидем һәм һаман да шул фикердә. Урын барыбызга да җитәрлек. Аларның әйбәт язуы да минем файдага. Мине алар һәрвакыт формада булырга мәҗбүр иттеләр һәм итәләр. Бу мәсьәләдә мин ярышуны кирәк дип саныйм. Сыйфат өчен ярыш безнең театрны да күтәрә бит.

Мине бервакыт Язучылар Союзы председателе иттеләр. Белмим, моның иҗатка кагылышы бармыдыр. Бардыр, мөгаен, чөнки мин председательлекне иҗат белән бутарга ярамаганлыгын күңелемә салып куйдым. Кайберәүләрнең председатель булмасалар да үз каләмдәшләре арасында олы хөрмәткә лаек икәнлекләрен күреп тордым. Хәсән Туфан, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттахлар, мәсәлән, пост биләмәсәләр дә, безнең өчен олы хөрмәткә лаек язучылар иде. Шуларны белеп, председательлектән файдаланмаска дигән сүз биргән идем. Сүземдә тордым шикелле. Председательлекнең миңа файдасы тимәде, ә менә зыяны тиде бугай. Аларның яшәү рәвешенә якынрак килеп, миңа белергә кирәкмәгән кайбер сыйфатларын күрдем. Әйе, аш бүлмәсендә әзерләнгән ризыкны яратып ашасаң да, аларны кемнәр ничек әзерләгәнен белмәү-күрмәү хәерлерәк шул. Председатель биш елга сайлана — мин ул срокны ничек үткәреп җибәрергә белмәдем. Котылганыма сөендем.

Минем турыда бүтән язучыларның кычкырып әйтми торган фикерләре булган кебек, минем дә каләмдәшләрем турында уңай һәм тискәре фикерләрем бар. Аларны монда язу үзем һәм кемнәрдер өчен кызык булачагын белсәм дә, тыелып калам әле. Кайберләре турында истәлекләрдә яздым язуын, алар китапларга да керделәр. Аларны кабатлауның, яңаларын өстәүнең хаҗәте юк. Әмма бер-икесе турында язып калдырасым килә. Язучылар арасында минем өнәп бетермәгән кешеләрем бар, аларның да мине өнәмәүчеләре бардыр. Моңа гаҗәпләнергә, гаепләргә кирәкмидер. Ходай барыбызны да төрле-төрле итеп яраткан. Язучылар арасында дошманым дип санарлыклары юк. Берәү дә юк, Аллага шөкер. Әйткәнемчә, икәү бар, ләкин алары да дошман түгел. Мин аларны кем дип атарга да белмим. Аларның берсе урыс телендә язучы Диас Вәлиев иде. Ул инде мәрхүм. Үлгәннәр турында начар сүз әйтергә ярамый диләр. Мин әйтәм. Чөнки әйтәсе сүзем аның үзенә, иҗатына кагылмый, ә аның чире турында булачак. Ул чир йогышлы чир, буыннардан-буыннарга күчеп, совет җәмгыятендә миллионнарның башына җиткән яман чир.

Бервакыт сенсацияләр әйтеп башкаларны гаҗәпкә калдырырга яраткан Аяз Гыйлаҗев әйтә: «Егетләр, мин гениаль бер пьеса укыдым. Ул урыс телендә язылган. Язучысы Диас Вәлиев дигән журналист», — ди. Шул гениаль пьесаны Аяз Марсель Сәлимҗановка укыткан. Марсель Аяз кебек ах-ух килә торган кеше түгел, «Куярга була, ләкин аның өстендә әле эшлисе бар», — дигән. Шуннан без Аяз җитәкчелегендә пьесаны эшләргә алындык. Аяз көндерде. Пьесаны Гариф абый Ахунов татарчага тәрҗемә итте. Без — Аяз, мин, Марсель — хәлебездән килгәнчә киңәшләр биреп, пьесаны тиешле кондициягә җиткердек. Гариф абый яхшылык эшләү йөзеннән, тәрҗемәче буларак үзен күрсәтмәде, гонорардан да баш тартты. Ягъни пьеса театрда татарча язылган әсәр буларак куелды. Театр афишасында яңа исем пәйда булды дип яздылар да. Ләкин аңа карап спектакльгә халык ябырылып йөрмәде. Шулай да Диас Вәлиевнең исеме ешрак ишетелә башлады. (Сизеләдер, мин аның пьесаларына бәя бирмим. Һәрхәлдә, алар игътибарга лаек иделәр). Вакыт уза торды, Диас Вәлиевне куя тордылар. Тик, әлеге дә баягы, тамашачы йөрмәде аның пьесаларына. Вәлиев исә тамашачы мине аңларга өлгермәгән, татар тамашачысы начар әсәрләрдә

тәрбияләнгән, дигән сүзләр ычкындыра башлады. Шунысы бар — Диас Вәлиев обкомның любимчигына әйләнде. КамАЗ турында пьеса да язгач, аны хәтта безгә үрнәк итә башладылар. Бер пьесасы Мәскәүдә куелгач, татар әдәбияты «всесоюзная арена»га чыкты дип шауладылар. Без дә куандык. Диас инде Аяз белән дә, Гариф абый белән дә (мине әйткән дә юк) өстән торып сөйләшә башлады. Аяз берәр сүз әйтсә, «Ты меня терроризируешь» дип кенә җиффәрә иде.

Көннәрдән бер көнне Диас Вәлиев хатынын ияртеп безгә килде. Хатыны Нәҗибә белән сөйләште, без кухняда драматургия турында фикер алыштык. Мин бераз салып та кайткан идем (Диас Вәлиев эчми иде). Сорый бу сүз арасында:

— Почему твои пьесы с успехом идут, а мои — нет?, — ди.

Мин таралып китеп, үз итеп, тотындым салган баштан моңа «гаебен» аңлатырга.

— Вся беда твоя в том, что у твоих пьес нет адресата, — дидем. — Для кого ты пишешь? Для абстрактного зрителя? А в театре реально мыслящий зритель. Они татары. Ты их не знаешь. Ты не знаешь, какую песню они поют в минуты высшей радости или страшного горя, — дидем. — В зрительном зале есть и русские, которые смотрят спектакль с наушниками. Ты их тоже не знаешь, — дидем. — Я тебе советую жить года два-три в глухой татарской деревне, научишься татарскому языку, слушать их песню», — дидем.

Сөйләдем дә сөйләдем моңа. Татар телен белмәвенең начарлыгы турында, әби-бабайларның телен онытуның гаеп эш икәнлеге турында да. Театрның драматургларга мөнәсәбәтен тәнкыйтьләдем. «Без, драматурглар, берләшергә тиеш», — дигән сүз дә ычкындырдым. Саубуллашып чыгып киттеләр болар.

Икенче көнне без Язучылар союзында очраштык. Мин күрешергә кулымны сузган идем, «Я тебе руку не подаю», — ди бу. Аптырап калдым: «Что случилось?» — дидем. «Ты — татарский националист», — ди. Мин шаярта бу дип уйлыйм. «Какой я националист?» — дип шаяртмакчы булам. Шуннан күрәм, бу чынлап икән. Гадәтемчә, мин ычкындым: «Первый раз в моей жизни мне не подают руку чтоб здороваться. Запомни, ты будешь искать мою руку, но не найдешь», — дидем дә, китеп бардым. Бер атна үтте микән, мине обкомга чакыралар. Диас Вәлиев донос язган. Доносны миңа укытмыйлар. 22 бит икәнен генә әйттеләр.Ниләр язылганы белән генә таныштыралар. Мин отъявленный националист икән, мин ниндидер шайка оештырырга җыенам икән, аны да шул шайкага керергә димлим икән. Милләтчеләр исемлегендә Гариф Ахунов та, Марсель Сәлимҗанов та бар. Ни өчендер Аяз Гыйлаҗев кына юк. (Аяздан шүрләгән, күрәсең). Донос уңаеннан миннән сораштыралар. Мин агарып каттым, ни әйтергә дә белмим. Андый чакта минем акланмыйча-нитмичә кәҗә тәкәсе шикелле керелә торган гадәтем бар, аяк терәп басам да, бер адым да атламыйм. «Нишлибез?» диләр. «Берни дә эшләмим, мин ул... мин ул...» Донос язучыга нинди исем тагарга белми тордым, авылча итеп «пакыч» дидем. Безнең авылда иң әшәке кешегә шулай диләр. Күрәсең, ул урысның «пакость» сүзеннән үзгәртелгән. Обком инструкторы Харис Әшрәфҗанов мине яхшы белә, шуңа күрә сакланып сөйләшә:

— Ярый, Туфан Абдуллович, икенче вакыт мондыйлар белән сүзегезне үлчәбрәк сөйләшегез, — диде дә, матур гына саубуллаштык.

Ике-өч көннән тагын Союзда очраштык Диас Вәлиев белән. Урыс телендә нинди сүгенү сүзен беләм, барысын да әйттем дә: «Ты ко мне, говенный доносчик, ближе чем на три метра не подходи, чтоб грязь твоя не прилипла, подойдешь, тебе в морду плюну», — дидем дә, китеп бардым. Ул дистанцияне саkладык без. Ул ничектер, мин сакладым, якын килсә, йөзенә төкерермен дә судтан башым чыкмас дип курыктым. Диасның әшәке исе гел пыскып торды. Рәис Беляев обкомга идеология секретаре булып килгәч, безне татуландырырга тырышты. «Сез доносчыны яклаучымыни, мин сезне хөрмәт итә идем, — дидем. — Минә күрерсез, ул сезнең өстән дә язачак әле», — дидем. Һәм шулай булып чыкты да — Беляев өстеннән дә ЦКга язды Вәлиев. Беляев бер очрашканда татарча ямьсез итеп сүгенде дә: «Тәки язды бит, сволочь»,

— диде. (Рәис Беляев, кызганыч, соңыннан да донос корбаны булды).

Ярый әле 37нче еллар түгел, безне җыеп атачаклар иде Вәлиев доносы буенча...

Дөньяда иң пычрак, иң кабахәт кеше донос язучы дип саныйм. Һәм исәннәрме, үлгәннәрме — беркайчан да аларны кешегә санамаячакмын.

«Миңа өч метр якын килмә», дип әйткән икенче бер язучының фамилиясен атап тормыйм. Ул донос язмады (молодец), тик китапларында мине пычратты. Анысына әллә ни исем китмәгән булыр иде, әлек ул, минем «талантыма сокланып», китабына автограф язган кеше. Мин аны бервакыт Башкортстанда очраткан идем, минем белән башкортча сөйләшә. «Нәрсә әле татар башың белән башкортча маталыйсың?» — дигәч, «Юк, агаем, мин башкорт», — дип әйткән иде ул. Минем бу кешегә карата, иҗатын кабул итсәм дә, ни начардан, ни яхшыдан сүз әйткәнем булмады. Бөеклек чире белән интегүче эгоист икәнлеген чамалаганга, читтәрәк торырга кирәк санадым... Кыскасы, мин аны яныма якын җибәрмим.

Үземне дә бик мактыйсым килми минем. Кемнәргәдер ошап җитми торган ягым бардыр, ахры. Нигә ошап бетмәгәнемне дә аңлап бетермим, югыйсә төзәлергә тырышыр идем. Минем яхшымыдыр, начармыдыр, бер гадәтем бар. Үзем нык хөрмәт иткәннәргә елыша алмыйм. Бәлки, шул сәбәпчедер. Мәсәлән, шагыйрь Сибгат Хәкимнең миңа салкын мөнәсәбәтен сизә идем. Ничаклы хөрмәт итсәм дә, Әмирхан абый Еники мине якын итмәде, Шәриф абый Хөсәеновтан мин җылы сүз өмет итеп тә ишетмәдем. Ә менә Хәсән Туфан мине ярата иде. Риза абый Ишморатның киң күңеллелеген күреп яшәдем. Гомәр ага Бәшировтан һәрвакыт җылы сүз ишеттем. Гариф абый Ахунов ярата иде үземне. Соңгы елларда аның белән уйнап алдылар. Шул уеннан чыга алмады Гариф абыкаем. Наиврак кеше иде шул. Аңламассың бу кеше дигән җан иясен. Шуны аңларга теләп язган булабыз инде, кем әйтмешли. Иҗат дөньясына кереп китеп, яза башладым да, чыга алмый интегәм. Сөйлисе, язып калдырасы сүзләрем күп. Мин бит үзем дә көтмәгән җирдән, стихияле рәвештә килеп кердем ул дөньяга. Ни эшләгәнемне аңлап эшләүче һәм язучы дигән исемне алган кеше.

Кайчакларда миңа китап сөючеләр «Кем ул язучы?» дигән сорауны бирәләр. Минем ул сорауга әзерләп куйган җавапларым бар.

1.Әйтик, юл буенда бер каен үсеп утыра. Шуның яныннан бер кеше үтеп бара. Каенга карап тора да: «Моны кисеп, турап куйсаң, бер куб метр утын чыгар иде», — ди. Икенче берәү узып бара. Каенның төз кәүсәсенә карап: «Ботаксыз урыннары күп икән, ничә балта сабы ясап булыр иде моңардан», — ди. Өченче берәү узып барышлый каенның ябалдашларына карый да: «Мунча себеркеләренә шәп икән », — ди. Дүртенче берәү каен янына тукталып, озак итеп аңа сокланып карап тора: «Сөбханалла! Яшел шәлен ябынып, ап-ак күлмәген киеп, күрегез минем чибәрлегемне дигән кыз кебек юл читенә чыгып баскан», — ди. Менә бу дүртенчесе язучы инде.

2.Әгәр дә берәү үзенә файдалы, бүтәннәргә зыянлы итеп ялганлый икән, ул жулик, мошенник. Әгәр дә үзенә зыянлы, бүтәннәргә файдалы итеп ялганласа, ул ахмак, дивана, тиле. Әгәр дә үзеңә дә, бүтәннәргә дә файдалы итеп ялганлый икән, ул — язучы. «Ялган» дигәнне мин фантазия мәгънәсендә кулланам, шулай әйткәндә сорау бирүчегә аңлашыларак төшә.

Яза-яза мин тагын бер нәрсәгә төшендем: акыллы фикер әйтәм дип көчәнергә кирәкми икән язучыга. Үзеңнән дә акыллырак булып булмый. Акыллырак булып маташсаң, укучы синең дурак икәнеңне тиз сизә. Гомумән, көчәнү адәм баласы өчен зарарлы нәрсә. Язу өчен көннең кай вакытын сайлау да әһәмиятледер. Кемнәрдер төнлә, кеше-кара йоклагач, тынычлап яза, мин исә организмның эшкә иң әзер чагын сайладым. Иртән утырып язам. Йокы туйган, баш ял иткән. Кайбер укучыларга боларны белү кызыктыр, шуңа күрә әйтәм. Язу процессы минем өчен гап-гади эш. Иҗат өстәл янына утырганчы башлана. Баш шәрифләренә нииндидер бер тема дип әйтикме, идея диикме, шул килеп керә дә, тынычлыгыңны ала. Йөртәсең шуны күңелеңдә, уеңда төрлечә әвәлисең, пьеса формасынамы, хикәяләү калыбынамы утыртасың. Иң рәхәте, иң кызыгы шул

чакта. Берәр чибәргә бер күрүдә гашыйк булып, шуны тагын очрату бәхетенә ирешү өчен планнар корган кебек. Кайвакыт корган планнарың язарга утыргач үзгәрә... Кайчак җитешсезлегеңне сәхнәдә күрәсең. Бервакыт карап утырам язганымны. Спектакльнең бер күренеше ошамый. Күрәм, гаеп режиссерда да, артистларда да түгел, үземдә. Шунда мин: «Болай язалармыни?!» — дип кычкырып җибәргәнемне сизми дә калдым.

Ярый, тагын бер-ике сүз әйтәм дә туктыйм. Язу минем өчен дәвалану чарасы да. Кешегә күңелен бушатып торырга кирәк. Югыйсә анда җыелган эмоцияләр аның психикасына тәэсир итеп, авыруга сабыштырырга мөмкиннәр. Ә ул күңелне кая бушатырга, кемгә сөйләп бушанырга? Ярый ла сине аңлап тыңлаучы булса. Ә менә ак кәгазь һәм кулыңдагы каләм сине тыңларга әзер. Рәхәтләнәсең аңа сөйләп серләреңне: шатлыкларыңны, кайгы-хәсрәтләреңне, борчулы уйларыңны. Кайберәүләр миңа эч пошудан зарланалар. Мин аларга шул турыда язарга киңәш итәм. Мин, гадәттә, язып бушанганнан соң рәхәтләнеп юләр сатып йөрим. Бервакыт Язучылар союзы коридорында болганып йөри идем, председателебез Ибраһим абый Гази үтеп бара. Мине туктатты да: «Син нәрсә, нишә күрсәң, лар-лар-лар — синең тавыш. Берәр җитди чагың бармы?» — ди. «Әгәр минем җитди чагымны күрәсегез килсә, минем эшләп утырган чагымны күрегез» — дидем. Ул миңа күзлеге астыннан озак итеп карап торды да: «Бар, үкер. Җавабың ошады», — диде.

Менә иҗат турында хәзергесе шулар. Үзгәрткәнме мине ул? Әлбәттә. Кайчак шүрлектә тезелеп торган китапларыма карыйм да, минекеләрме соң болар дип аптырап калам.

Кычкырып әйтәсем килмәгән бер нәрсә турында да язып куйыйм әле.

Дөньяда мода дигән нәрсә бар. Без аны күбрәк кием-салымга карата кулланабыз. Ләкин тормышның һәр тармагында мода бар. Хәтта сәясәттә дә — Россиядә кичә социализм модада булса, бүген — капитализм, кичә Сталин булса, бүген — Путин. Хәер, Сталин әле һаман да модадан төшеп калмый. Элек галифе белән френч киеп йөргәннәр бүген Сталин портретына табыналар. Сәнгатьтә мода аеруча үзен сиздерә: архитектура, сынлы сәнгать гел мода таләбен үти. Җыр сәнгатендә бүген модада — эстрада. Әдәбиятта мода үзен әлләни сиздерми кебек, әмма бу беренче карашка гына. Бактың исә, заман үзе модага этәргеч бирә. Элек, мәсәлән, пьесалар бишәр, аннары өчәр пәрдәле булса, бүген ике пәрдәдән арта алмый. Өч-дүрт сәгатькә сузылган спектакльне карап бетерергә түземлеге җитми бүгенге тамашачының, ул туктаусыз ашыгуга күнеккән. Кая ашыкканын үзе дә белми. Җырчыларга да мода бар, бүген модада — Салават, иртәгә аңардан үткенрәге табылыр. Язучыларга да мода юк түгел. Драматургиядә бервакыт модада Хәй Вахит иде, аннан соң мине төртеп чыгардылар, сизәм — мин инде, татарның казакие кебек, модадан төшеп барам. Мин моны ах-ух килмичә генә кабул иттем, һәртөрле мактауларны, атаклы дирижер Фоат Мансуров әйтмешли, матәм нотыкларына репетиция дип саныйм. Кырыгар ел буе мода тотып булмый, ул үзгәрергә тиеш. Мин драматург буларак элеккеге Туфан Миңнуллиннан һич кенә дә ким түгел, әмма тамашачыга бүтән кирәк. Ә тамашачыны ялыктырырга ярамый. Яңа тамашачыны элеккеләр белән ялыктыру, искеләрне карарга мәҗбүр итү — хатын-кызны көчләү белән бер. Үзгәрешләр кичерсә дә, мода вакыт-вакыт кабатланып та тора. Шуңа күрә модада «Ретро» дигән жанр бар. Кем белә, бәлки, Туфан Миңнуллин да «авылыгыздан тагын бер урап үтәрмен» дигән сыман бер урап үтәр. Анысы киләчәк эше. Бөтенләйгә югаласы килми бит, чорт вәзми.

*Дәвамы киләсе санда.*

# МӘДРӘСӘЛӘРЕБЕЗ — «ТАТАР АКАДЕМИЯЛӘРЕ»

XX гасыр башында татар гуманитар-филологик фәненә нигез салына һәм аның тизләтелгән үсеше күзәтелә. Янарыш хәрәкәтенең бер чагылышы булган әлеге күренештән 1920-30 елларда да уңышлы дәвам иттерелүе татар филологиясе фәненә үзләреннән ифрат зур өлеш керткән күренекле галимнәр Г.Ибраһимов, Г.Сәгъди, Г.Гобәйдуллин, Г.Рәхим, Г.Баттал, Җ.Вәлиди, Г.Нигъмәти, Г.Ходаяров, С.Атнагулов, В.Хангильдин, Г.Алпаров, Н.Хәким, Г.Нугайбәк, Г.Шәрәф, Х.Бәдигый һ.б. исеме белән тыгыз бәйле булып, аларны бүген зур горурлык белән телгә алабыз. Әлеге шәхесләрнең һәммәсе диярлек 1917 елгы октябрь инкыйлабына кадәр татар мәдрәсәләрендә белем-тәрбия алган һәм әлеге гамәл аларга яңа шартларда, совет чорында дөньяви милли мәдәниятне, фәнне, мәгарифне үстерү эшендә ярдәм иткән. Татар мәдрәсәләрендә бирелгән дини-рухи тәрбия һәм дөньяви белемнәрнең фәнни-мәдәни потенциалны тудыруда ничек катнашуы, әлеге галимнәребез хезмәтләрендә, эшчәнлекләрендә, иҗат мирасларында ни рәвешле урын алуы мәсьәләсе әле җитди тикшеренүләрне көтә. Укучылар игътибарына тәкъдим ителгән әлеге мәкаләдә без 1920-30 еллар татар филологиясе фәне үсешендә тирән эз калдырган күренекле галимнәр Галимҗан Ибраһимов, Галимҗан Нигъмәти, Җамал Вәлидиләрнең галим булып формалашуы һәм үсүендә алар укыган атаклы «Галия» һәм «Иж-Буби» мәдрәсәләренең ролен билгеләүне максат итеп куябыз.

Әлеге мәсьәләне исемнәре югарыда аталган өч филолог-галим шәхесе мисалында алып тикшерүебез очраклы түгел. Аларның тормыш һәм иҗат биографияләрендә, язмышларында үзара кисешкән уртак нокталар бар. Инкыйлабка кадәр татар мәдрәсәләрендә белем алып, Октябрьдән соңгы каршылыклы чорда фәнни-мәдәни һәм иҗтимагый мәйданда актив эшчәнлек алып барганнар, милли фәнне үстерүгә күп көч салып, татар филологиясе өлкәсендә зур галимнәр булып танылганнар. Ни кызганыч, татар фәнен үстерүгә зур хезмәт куйган әлеге фидакарь затларыбызның өчесе дә шәхес культы корбаны — 1930 елларның канлы «тегермәненә» тарттырылган, нахакка рәнҗетелеп, юк ителгән фаҗигале шәхесләр.

Г.Ибраһимов белән Г.Нигъмәтинең әдәби һәм фәнни биеклекләргә күтәрелүенең юл башы «Галия» мәдрәсәсенә барып тоташа, ә Җ.Вәлиди «Иж-Буби» мәдрәсәсендә белем ала. Г.Ибраһимов «Галия»дә 1906-1909 елларда укый, ә 1915-1917 елларда әлеге мәдрәсәдә укытучы булып эшли; Г.Нигъмәти исә әлеге мәдрәсәдә 1911-1917 елларда укый. Җ.Вәлидинең «Иж-Буби» мәдрәсәсендә укуы 1904-1911елларга туры килә.

XIX гасыр азагы — XX гасыр башларында Ижау ягындагы «Иж-Буби», Уфадагы «Галия», Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәләре статуслары белән чагыштырмача бердәй дәрәҗәдә торган, дини белем бирү белән бергә гимназия курсы буенча дөньяви предметлар укытуны да күздә тотып эшләгән җәдиди юнәлештәге яңа тип татар уку йортлары булганнар. Р.Әмирханов «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен чын мәгънәсендә Октябрьгә кадәрге чорның татар университеты дип атарга мөмкин дисә; А.Мәхмүтова «Буби» мәдрәсәсен шул чор рус-татар зыялылары даирәсендә «мөселманнар академиясе» дип йөрткәннәр дип яза, «Галия» мәдрәсәсен «халык университеты» тибындагы уку йорты дип бәяләүләр дә була. Г.Ибраһимов иҗатын өйрәнгән М.Хәсәнов «Галия» мәдрәсәсе турында «милли институт дәрәҗәсендәге мәшһүр уку йортларының берсе булган»дип яза.

Г.Ибраһимов, Г.Нигъмәти, Җ.Вәлидиләр укыган чордагы мәдрәсә программаларына

күз салсак, анда дини һәм дөньяви предметларның бердәй тигез дәрәҗәдә булуын күрәбез. Шәкертләргә төрле яклап системалы белем бирелгән. Гуманитар юнәлешкә караган предметлар саны гына да ике дистәдән артып китә. Мәдрәсәләрдә дини белем бирүдә мәгърифәтчел принциплар күздә тотылуын ассызыклап әйтергә кирәк. Үз вакытында Г.Утыз-Имәни «Мәгърифәтле булу — гыйлемле булу, гыйлемле булу — Коръәнне белү» дип аңлаткан. Шәкертләрдә дини предметларны укыту аша рухи бөтенлек тәрбияләнгән.

Мәдрәсәдә укыган чорда Г.Ибраһимов, Г.Нигъмәти, Ж.Вәлидиләргә дини белемнәр системасы аша рухи-әхлакый тәрбия бирелгән. Бу урында шуны да билгеләп үтик, 1920-1930 елларда актив эшчәнлек алып барган Ж.Вәлиди, Г.Нигъмәтиләрнең һәм шәхес, һәм галим буларак югары әхлак сыйфатларына ия булулары турында язалар икән, бу аларның табигый асылыннан тыш, мәдрәсәләрдә укып, дини тәрбия алулары, дин әхлагы нигезләрен үзләштерүләре белән бәйле булган. Мисал өчен, әдәбият тәнкыйтьчесе Г.Нигъмәтинең 1920-30 елларның катлаулы шартларында язучы-тәнкыйтьчеләрне төркемнәргә аермыйча, һәммәсенә хөрмәт белән каравын, әдәби судларда катнашып каләмдәшләрен кимсетмәвен, намуслы, кешелекле булып калуын искәртеп китәргә мөмкин.



*«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бинасы. Казан, Тукай урамы, 34нче йорт.*

«Галия» мәдрәсәсе укытучы кадрлар составының югары әзерлекле булуы белән аерылып торган. Бу мәдрәсәне нигезләүче Зыя Камали (Камалетдинов Пәрвазетдин Жамалетдин улы) үзе Каһирәдәге «Әль-Әзһәр» дини академиясен тәмамлаган зур гыйлем иясе, алдынгы карашлы кеше була. Мәдрәсәдә дин тәгълиматын, ислам фәлсәфәсен, этика фәннәрен укыта. Үз тирәсенә белемле, югары әзерлекле кадрларны туплый. «Галия» мәдрәсәсендә Багдад, Каһирә, Казан, Мәскәү университетларын, Төркия югары уку йортларын, Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган белгечләр укыткан. Г.Ибраһимов (татар теле һәм әдәбияты), Ә.Вәлиди (фәлсәфә), Г.Терегулов (психология), З.Кадыйри (гарәп, төрек телләре), Ф.Сәйфи-Казанлы (тарих), Г.Шинаси (педагогика, методика), Г.Фәезханов (математика), В.Клеменц (Варшава консерваториясе профессоры; музыка укытучысы) кебек күренекле шәхесләр белем биргән биредә. Алар укучыларында фикер һәм акыл сәләте, өйрәнелә торган предметларга карата иҗади мөнәсәбәт тәрбияләүгә һәм үстерүгә житди игътибар биргәннәр. Иң элек мәдрәсә житәкчесе, дин мөгаллиме Зыя Камали үзе укучыларында фикерләү сәләте уятырга тырышкан, лекцияләрен актуаль фәнни темаларга укыган. Хезмәтләре аша да («Ислам фәлсәфәсе» һ.б.) мөселманнарны фикерләү юлына этәрү максатын куйган. Чын исеме Пәрвазетдин булып, Зыя (зыя—гарәп сүзе: яктылык, нур, белем, мәгърифәт дигән мәгънәне аңлата) тәхәллүсен сайлау факты да бу кешенең үзен фәнгә, белемгә багышлавы турында ачык сөйли булса кирәк. Мәдрәсәдә шәкертләрнең фикри үсешенә этәргеч бирә торган мантыйк, мөназара (бәхәс) фәннәре укытылу факты турында да әйтеп китәргә кирәк. Шәкертләрне бәхәсле хәл тудыру һәм аны алып бару методикасына өйрәткәннәр. Бу исә булачак галим кеше өчен бик мөһим сыйфатларны тәрбияләүгә ярдәм иткән. 1920 елларда иҗат иткән татар галимнәренә фикер үткенлеге, фәнни хакыйкатькә ирешүдә бәхәс алымын кулланып эш итү сыйфатлары хас булган икән, моның очы әнә шул мәдрәсәләрдә алган белем һәм күнекмәләргә барып тоташа.

Тирән белемле Зыя Камалинең Г.Ибраһимовка тәэсире зур булган. 1915 елда «Галия»

мәдрәсәсе турындагы бер мәкаләсендә танылган әдип болай дип яза: «Мина ин беренче тәэсир итүче Шиһаб хәзрәт булса, икенчесе Зыя Камалидыр. Бу ике затка мин гакылымны азат кылу, фикеремә истикълал (бәйсезлек, иркенлек) бирү юлында мәнге бурычлымын. Болар минем фикри тәкаммелемнен (камилләшүемнен) үткән бер баскычында ин кирәкле мөәссир (тәэсир итүче) булдылар. Бер мин генә түгел, үзләренен үткәннәреннән хисап бирүче күп татар яшьләре дә моны икърар (тану) кыйлачаклар».

«Галия»дә укыганда ук Г.Ибраһимов фәнни ижат эше белән шөгыльләнә башлый. 1909 елда «Борынгы ислам мәдәнияте» дигән һәм шул ук чорда «Европа философы Декарт һәм анын нәсихәте» кебек беренче фәнни хезмәтләрен бастырып чыгара. Сонрак, мәдрәсәдә укыта башлагач, шәкертләр һәм мөгаллимнәр алдында тел-әдәбият мәсьәләләре буенча лекцияләр укый. Тел-әдәбият фәннәрен укыту тәҗрибәсенә таянып, методик характердагы хезмәтләрен яза. (1920 елларда аерым мәкаләләр яисә фәнни хезмәтләр рәвешендә бастырып та чыгара). Аларнын эчтәлегендә галимнен тел һәм әдәбият мәсьәләләрен анлатудагы фәнни концепциясе оешу эзлекле чагылыш таба. Аерым алганда, Г.Ибраһимов теге яки бу халыкнын теле, әдәбияты үсеше анын тарихи үсеше, шул халыкнын тормыш дәрәҗәсе, житештерү һәм рухи эшчәнлеге ихтыяжлары белән билгеләнүен яхшы анлаган.

1920-30 елларда Г.Ибраһимов житәкчелегендә татар галимнәре тел-әдәбият күренешләрен билгеле бер халык мәдәниятенен органик өлеше итеп карап, аларнын үсешен, яшәешен теге яки бу халыкнын милли үзенчәлекләре, ижтимагый-сәяси яшәү шартлары белән бәйләнештә өйрәнәләр. Шунысы игътибарга лаек, программаларда каралган предметларны укыту өчен мәдрәсә китапханәләрендә кирәкле әдәбият, уку әсбаплары тупланган була. Мәсәлән, «Галия» мәдрәсәсенен бай китапханәсендә дини, дөньяви әдәбият, татар, рус, гарәп, фарсы телләрендәге газета-журналлар, ислам нигезләре, гомуми тарих, психология, мантыйк һ.б. фәннәр буенча уку әсбаплары, Пушкин, Гоголь, Чехов, Горький кебек рус, Тукай, Рәмиев, Әмирхан, Гафури, Исхаки кебек татар әдәбияты вәкилләренен әсәрләре урын алган. Әлеге факторлар «Галия» мәдрәсәсе шәкертләренен (шул исәптән, Г.Ибраһимов, Г.Нигъмәтиләрнен дә) дөньяга карашын үстерүгә көчле тәэсир ясаган, аларнын фәнни мәнфәгатьләре формалашуга этәргеч биргән.

«Галия» мәдрәсәсендә укытканда Г.Ибраһимов әдәбият программасына дөнья классикасынын ин әйбәт үрнәкләрен тәрҗемә итеп кертүне көн тәртибенә чыгара. Һәм, әйтергә кирәк, алга таба фәнни ижат практикасында, кинкырлы эшчәнлегендә үзе дә Көнчыгыш, рус, Европа әдипләренен, фикер ияләренен әсәрләренә, хезмәтләренә кин таяна. «Безгә гакыл вә фикеребезне гомум бәни адәм офыгына таба юнәлдерергә — бәни адәм хәятенен борынгы заманнардан алып әдәбиятта ничек ингыйкас итә барганлыгы белән танышырга, кыскача әйткәндә, татар әдәбиятыннан үтеп, бөтендөнья әдәбиятынын тарихи агымнары белән дә танышырга лазем булачак. Киләчәк көнебезнен яктыруы өчен Гареб мәдәнияте белән файдалануыбыз никадәрле лазем булса, шул нисбәттә үк, безгә Шәрекънен үткәне белән дә азыкланырга тиештер», — дип яза ул 1915 елда бер мәкаләсендә. Г.Ибраһимовнын әлеге фикерләрен укучысы, фикердәше Г.Нигъмәти дә уртаклаша.

«Буби» мәдрәсәсенен уку-укыту программаларыннан чыгып сүз йөрткәндә, бу уку йортында да кин һәм төпле гуманитар белем бирелгән: фәлсәфә, мантыйк, метафизика, этика, Россия һәм Шәрекъ тарихы, гомуми тарих, ислам тарихы, риторика, шигырь төзелеше (гаруз), этика, рус, төрек, фарсы, гарәп, немец һәм француз телләре, рус, татар әдәбияты кебек фәннәр укытылган; дини тәгълиматны өйрәнүгә дә кин урын бирелгән. Ж.Вәлидинен укытучысы, «Буби» мәдрәсәсе мөгаллиме Габдулла Буби шәкертләрен Коръәннен камил мәгънәсенә төшенү өчен мөстәкыйль фикерләргә, уйларга, хакыйкатьне эзләү юлына өндәгән. Мәдрәсәдә ижади-эзләну эшенә зур игътибар бирелгән. Мәсәлән, шәкертләр катнашындагы кичәләрдә төрле темаларга докладлар, рефератлар укылган, газета материаллары буенча чыгышлар, аерым мәсьәләләрне тикшерүгә багышланган сөйләшү-бәхәсләр оештырылган. Болар шәкертләрнен танып-белүгә кызыксынуын үстергән. Биредә укыган Ж.Вәлидинен киләчәктә мәдәниятне яхшы белүче фән эшлеклесе, галим булып формалашуында әлеге чараларнын роле зур булган.

«Буби», »Галия», «Мөхәммәдия» мәдрәсәләренен уку-укыту программалары белән

рус гимназиясе, реальный училище, Казан татар укытучылар мәктәбе программалары арасында уртаклык күп. Шуна күрә Ж.Вәлидигә туганы С.Жәлал белән бергә «Буби»дан соң Казан Татар укытучылар мәктәбенә кереп уку артык кыенлыклар тудырмаган. «Буби»мәдрәсәсендә алган белемнәре Ж.Вәлидигә «Вакыт» газетасында, «Шура», «Аң» журналларында иҗтимагый һәм эстетик фикер үсешенә житди әлеш кертерлек күпсанлы мәкаләләр белән чыгыш ясау югарылыгына күтәрелергә юл ача. Алган белеме чорнын билгеле уку йортларыннан саналган «Хөсәения» мәдрәсәсендә татар теле һәм әдәбияты буенча мөгаллимлек итәргә мөмкинлек бирә.

Боларга өстәп шундый факт турында әйтеп китәргә мөмкин: Г.Нигъмәти «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, 1920 елларда укуын Мәскәүдә Дәүләт журналистика институтында дәвам итә, аннары Көнчыгыш хезмәт ияләре коммунистик университетында (КУТВ) укый. Бу уку йортларында ул танылган шәркыят белгечләре, совет галимнәре лекцияләрен тынлый. Гомумән, «Галия» мәдрәсәсе Г.Нигъмәтидә яна заман рус-Европа гыйлеме казанышларын кабул итү өчен унышлы жирлек әзерләү белән бергә, дәүләт, хөкүмәт, җәмәгать һәм фән, мәдәният, мәгариф оешмаларында, төрле җаваплы урыннарда эшчәнлеген унышлы алып барырга тулы мөмкинлек бирә. Ә инде «Мөхәммәдия», «Галия» мәдрәсәләрендә рус теле, тарих, Коръән нигезләре, Шәрекъ фәлсәфәсе кебек предметлар буенча алган белем Г.Гобәйдуллин, Г.Нигъмәти, Г.Толымбайларга Мәскәүдәге Кызыл профессура институтында укыганда (1920-1940 елларда вузлар өчен укытучылар, фәнни-тикшеренү учреждениеләре, партия, дәүләт органнары өчен фәнни хезмәткәрләр әзерләүче махсус уку йорты) әлеге вуз программасына кертелгән гуманитар фәннәр буенча курсларны унышлы үзләштерергә ярдәм иткән дип фаразлый алабыз.



*Бертуган Бубыйларның йорты һәм кызлар мәдрәсәсе (дарелмөгаллимат). Иж-Бубый авылы. 1908-1910 еллар.*

1926 елда Казанда Көнчыгыш педагогия институтында татар теле һәм мәдәнияте бүлеге оешкач, шунда татар теле, чагыштырма төрки-татар тел белеме, татар халык авыз иҗаты, татар халкы тарихы, татар әдәбияты, шәрекъ әдәбияты, методика курсларын укытканда Г.Гобәйдуллин, Г.Рәхим, Г.Нигъмәти, Ж.Вәлидиләр инкыйлабка кадәр татар мәдрәсәләрендә һәм сонрак совет югары уку йортларында алган тирән белемгә таянып эшлиләр. Шул рәвешле, алар үзләренен кинкырлы белемнәрен милли кадрлар әзерләү эшенә багышлыйлар.

XIX гасыр ахырында мәдрәсәләрдә татар теле укытыла башлау Ж.Вәлиди, Г.Сәгъди, Г.Ибраһимовларда татар-төрки тел гыйлеме белән кызыксынуны кузгаткан һәм алар алга таба фәнни эшчәнлекләрендә шул юнәлешне дә үстереп, тирәнәйтеп, алга таба тел галимнәре булып та танылалар. Мәсәлән, Ж.Вәлиди 1920 елларда Көнчыгыш педагогика институтынын татар бүлегендә татар телен укыткан, тел гыйлеме буенча дистәләрчә фәнни хезмәтләр язып чыгарган һәм аларнын күбесе студентлар өчен дәреслекләр сыйфатында кулланылган.

Ә инде татар әдәбияты дәресләрендә «Уку китабы» сыйфатында борынгы динн-әхлакый эчтәлекле хезмәтләрдән, татар фольклоры үрнәкләреннән, шәрекъ, XIX гасыр һәм XX гасыр башы татар әдипләренең әсәрләреннән туплап төзелгән хрестоматияләр файдаланылган. «Галия»дә татар әдәбиятыннан алган белеме Г.Нигъмәтигә 1920 еллар башында аны КХКУда, алга таба Көнчыгыш педагогия институтында югары дәрәҗәдә укыту мөмкинлеге биргән. Тел-әдәбият профессор-доцентлары Г.Сәгъди, Г.Гобәйдуллин, Г.Рәхим, Ж.Вәлидиләр хакында да шуны ук әйтергә мөмкин. Мәдрәсәдә укыганда өйрәнгән борынгы авторларнын дини-әхлакый эчтәлекле «Кыйссаи-Йосыф», «Бәдәвам», «Рисаләи Газизә», «Фәзаил-әшшөһүр», «Мөхәммәдия», «Бакырган»,

«Кисекбаш», «Кыйссасел-әнбия», «Алты бармак» һәм аннан соңгы чорларга караган татар авторларының әсәрләре, мәдрәсәләрдә әдәбият теориясе нигезләре буенча алган белемнәре әлеге галимнәргә татар әдәбияты, иҗтимагый һәм эстетик фикер тарихы буенча хезмәтләр язганда ышанычлы таяныч булып торган. Гарәп, фарсы, төрек, рус, немец, француз телләрен белү булачак татар филолог-галимнәренә Шәрекъ, рус-Европа чыганаклары белән турыдан-туры танышу мөмкинлеге биргән. Инде килеп, татар мәдрәсәләрендә киң планда тарих фәне укытылуны һәм алга таба бу фәннәрне Г.Газиз, Г.Рәхимнәрнең дөньяви югары уку йортларында тагын да кинәйтеп, тирәнәйтеп өйрәнүен, әлеге белемнәрен татар тарихы, тел, әдәбият тарихы буенча фәнни хезмәтләрен язганда куллануларын ассызыклап күрсәтү сорала.

Әдәбият галиме Г.Нигъмәти үз хезмәтләрендә эстетиканың, әдәбият теориясенең фәлсәфи нигезләрен аңлатканда, моңа хәтле мәдрәсәдә ислам тәгълиматын өйрәнү аша алган фәлсәфи гыйлемнәрен башка фәлсәфи системалар белән кушып файдалана. Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди, Г.Нигъмәтиләр мәдрәсәләрдә психология буенча алган белемнәрен алга таба тагы да кинәйтеп, тирәнәйтеп, 1920 елларга караган фәнни хезмәтләрендә иҗат психологиясе, язучы һәм укучы психологиясе мәсьәләләренең фәнни яктыртылышын тикшергәндә файдаланалар.

Шул рәвешле, дини мәдрәсәләрдә һәм югары уку йортларында белем алу Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди, Г.Нигъмәти, Г.Сәгъди, Г.Гобәйдуллин, Г.Рәхим кебек шәхесләргә мөселман һәм яңа заман мәдәниятен үзара бәйләү, Шәрекъ һәм рус-Европа әдәби-эстетик фикерен синтезлаштыру мөмкинлеге бирә. Нәтиҗәдә алар татар гуманитар фәне үсешенә зур өлеш кертерлек галимнәр булып тарих мәйданына чыгалар.

**Эльмира ГАЛИЕВА,**
*КФУ профессоры*

---

## *«Казан утлары»на – 90*

### «Безнең юл»

САДРИ ҖӘЛӘЛ

(1891-1943)



Язучы-прозаик, тәрҗемәче, публицист. «Дим буенда» исемле атаклы лирик-романтик повесть авторы. Репрессия корбаны. Күренекле тәнкыйтьче, әдәбият тарихчысы һәм тел галиме. Җамал Вәлиди – Садри Җәләлнең (Садретдин Хәйретдин улы Вәлидев) туганнан туган абыйсы, шулай ук репрессия корбаны.

С.Җәләл, үтә дә талантлы каләм әһеле буларак, 1919-1926 елларда Казанда нәшер ителгән барча газета-журнал редакцияләрендә, шул исәптән «Безнең юл» журналханәсендә дә әдәби хезмәткәр булып эшли. Әлеге мәртәбәле журналның беренче җаваплы редакторы Гасыйм Мансуров (1894-1955) аның шул чактагы журналистлык эшчәнлеге хакында түбәндәге юлларны язып калдырган: «...ул вакыттагы авыр шартлар эчендә журналга күп көч куючы, эшләүче – журналның беренче секретаре иптәш Садрый Җәләл булды. Аның бу хезмәте, әлбәттә, истән чыгарылмаска тиеш».

# СИКӘЛТӘЛЕ ЮЛЛАРДА

РӘФКАТЬ КӘРАМИГӘ 70 ЯШЬ

Юбилейларның, шөкер дип әйтик, булып торган көннәре. Берәүләр илле яше тулганын көтеп кенә торгандай, зур тамаша залларына укучысын җыеп, шаулатып, гөрләтеп бәйрәм ясый. Икенче берәүләр, бик зурдан купмыйча, ашыкмый-кабаланмый гына җитмеше-сиксәне җиткәнче бу турыда сүз катмый йөри. Андыйлар бәйрәм-тамашалардан бигрәк, матбугат битләрендә яисә башка чаралар аша үзенең иҗаты турында укучыларыннан, каләмдәшләреннән сүз-бәя ишетүне мөһимрәк саный. Хәер, ясарлыгың бар икән — ник ясамаска бәйрәменне, китапларың күп икән, әлеге форсаттан файдаланып, ник алар турында рәхәтләнеп сөйләшмәскә, күңелле гәп кормаска?!

Мәкаләдә сүзнең аерым әдип һәм әдәбият тирәсендә баруын аңлап, зирәк укучыларыбызның: «Әй, тагын гел мактаудан гына торган юбилей нотыгыдыр инде, тик андый төче мактаулардан гарык мин», — диюе дә мөмкин. Тик мөхтәрәм укучыбызга артык борчылмаска да була: беренчедән, әлеге мәкалә житди журнал битләрендә басыла, икенчедән, авторы да артык мактап, һуштан яздыручы тәнкыйтьчеләр исемлегенә керми бугай... Татар прозасы турындагы уйларыбыз да ярыйсы ук каршылыклы. Тәҗрибәле язучыларыбыз олыгаеп, гомер баскычларын атлап чыкканда күңелләрдә үзеннән-үзе шомлы уйлар да айкала башлый: әлеге әдипләргә алмашка кемнәр килә? Алар да шундый ук өметлеләрме? Эстафета таягын кулларыннан төшереп җибәрмәсләрме? Әле бит шунысы да бар: алмашчыларга гел кеше таягына карап кына йөрергәме?!

Әгәр дә укучы рөхсәт итсә, юбилярның иҗатына таянып, гомумән, әдәби барышыбыз турындагы фикерләр белән уртаклашу да мәслихәт булыр. Әлеге форсатны танылган прозачыбыз Рәфкать Кәрами бирә. Әлбәттә, юбилей уңае белән аның иҗатын «үтереп» мактарга кирәктер, бәлки. Истәлекле көн алдыннан андый мактауларга ул тулысынча лаек. Әмма бүгенге исәбем-бурычым бераз гына башкачарак: бу иҗатның төп хасиятләрен, үзенчәлекләрен, яңалыкларын эзләү һәм шуларның гомуми әдәби процесстагы роле, тоткан урыны, гомумән, прозабызның бүгенге хәле, кайбер проблемалары турында уйлану, фикер алышу.

Әйе, Р.Кәрами иҗаты мактауга да, объектив анализга да лаек. Ялгышмасам, тәнкыйть өлкәсендә бу иҗатны уртага куеп тикшергән хезмәтләрнең күптәннән күренгәне юк бугай. Бүгенге татар прозасында читкә сибелмичә, таралмыйча, аңлаешлырак итеп әйткәндә, тиз үзгәрүчән һәм безгә хәерсезрәк булып тоелган, әмма модадагы модернизм артыннан кумыйча, гел үз сукмагыннан барып, үзенә хас стильдә иҗат итүчеләр, сирәк булса да, бар әле. Р.Кәрами — әнә шундыйларның берсе. Каләме реаль тормышта була торган хәлләрне прозаның роман һәм повесть жанрлары аша чагылдыруны кулай күрә. Язганнары ышандыра, чөнки алар шул тормыш дип аталучы дәрьяның үзеннән, уртасыннан чумырып алынган.

Р.Кәрами күп яза, әмма әдәби тәнкыйть ул иҗат иткәннәрне тиз генә күреп алырга да, күтәреп куярга да ашыкмый. Моның сәбәпләре нидә икән соң? Әллә инде «традицион, реаль җирлектәге язмалар искерде, безне яңа әдәби чараларың белән

шаккатыр син», дип, тузга язмаганча кыланып, әдәби хәзинәдән йөз чөерүме яисә милләт әдәбияты тарафдарлары саналып йөрүчеләрнең сон чиккә житкән үшәнлек-ялкаулыгыннан килгән битарафлыкмы? Боларның берсе дә, беркемне дә бизәми, әмма әлеге күренеш бар, күбебезгә таныш, шуңа да күңелне борчый алар.

Р.Кәраминең үз укучылары барлыгына һәм аларның күп икәнлегенә шигебез юк. Ник дигәндә, классик традицияләр җирлегендә тәрбияләнеп үскән һәм балаларын да ата-бабадан килгән әхлакый җирлек рухында тәрбияләп үстергән укучылар катламы бүген яши әле. Һәм тагын да әһәмиятлесе, әнә шул әдәп-әхлак кагыйдәләрен күңелләрендә саклап, эш-гамәлләре белән раслап яшәячәк яшьләребез дә байтак әле тирәбездә.

Р.Кәрами (Кәрамиев Рәфкать Кәраметдин улы) — матур табигате белән җырларга кереп калган, сәнгать-әдәбият эшлеклеләре белән аты-даны таралган гүзәл Сарман ягыннан. Ул Рангазар авылында колхозчы гаиләсендә туып-үсә. Авылда җидееллык мәктәпне, аннары Алабуга мәдәният-агарту техникумын тәмамлагач, үз районында клуб мөдире, баянчы булып эшли. Алтмышынчы елларда Рәфкать Әлмәт якларына китеп, Чупай таш карьерында рәссам, аннары гади эшче, электрик һәм машинист ярдәмчесе булып эшли. Армия сафларына алынып, өч ел Хәрби диңгез флотының яр буе частьләрендә хезмәт итә.

1964-1977 елларда Р.Кәрами Казан органик синтез заводын коруда катнаша: башта электрик, соңыннан «Казаньхимстрой» трестының бишенче төзү идарәсендә профком рәисе була. 1970 елда ул, хезмәтеннән аерылмыйча, Казан дәүләт университетының тарих бүлеген тәмамлый. 1977-1979 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда укый. 1979-1993 елларда әдип Татарстан Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бюросында эшли. Татар халкы яшәгән күпсанлы төбәкләрдә булып, милли әдәбиятыбызны таратуга үзеннән зур өлеш кертә. 1993-2002 елларда Р.Кәрами Татар интеллектуаль милек агентлыгын житәкли — республикабызда әдәбият-сәнгать әһелләренең авторлык хокукларын яклауны җайга сала.

Әлеге биография белән танышучы Р.Кәраминең әдәби иҗат казанышларының бай тормыш тәҗрибәсенә нигезләнгәнлеген бик тиз күрә һәм бәяли ала. Ә ул әдәбиятыбызга менә инде 45 ел дәвамында хезмәт итә. Беренче әсәре («Дүрт кешелек каюта») 1967 елда укучысына барып ирешә. Ул арада башка повестьлары да («Кечкенә уйлар», «Капитан Хәкимов» һ.б.) укучының мәхәббәтен, киң әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын казанырга өлгерә. 1972 елда Р.Кәрами СССР Язучылар берлегенә кабул ителә.

Автор тормышның тирәнрәк катлауларына үтеп кергән саен, үзенең караш-фикерләрен ачык һәм кискен итеп әйтеп бирергә өйрәнә бара. Ул аңа чын бәхетнең акчага, байлыкка гына кайтып калмавын, моның өчен гаиләң, сине аңлаучы якын дусларың, яраткан эшең, үз мохитең булу зарур дип әйтергә тели. Әлеге фикерләр аеруча ачык булып әдипнең повестьларында чагылыш таба. Аларның иң уңышлыларын Р.Кәрами бер җыентыкка туплап, 1992 елда «Ындыр тулы кибән», ә 2004 елны «Мәхәббәт бураннары» исемнәре белән матбугатта бастырып чыгара. Минемчә, җыентык башына куелган икенче исем уңышлырак, чөнки ул бу повестьлардагы төп теманы тулырак иңләп ала һәм аларның җисеменә бик тә туры килеп тора. Әмма беренче исеме белән дә китап үз вакытында популярлык казанып өлгерә — бер дәвер ул китапханәләрдән иң еш алып укыла торган китапларның берсе булып танылa. «Дүрт кешелек каюта», «Кечкенә уйлар», «Сагышлы кояш», «Мәхәббәт бураннары», «Ындыр тулы кибән», «Капитан Хәкимов», «Йөрәгемне ут алган» повестьларында заман яшьләренең тормышы, хис-омтылышлары, мәхәббәт мөнәсәбәтләре, шатлык-сөенечләре, ялгыш-үкенечләре укучыларның күңелен җәлеп итә.

«Дүрт кешелек каюта» әсәрендә гади һәм гадәти генә вакыйга барышында (Иделдә туристлар теплоходында сәяхәт итү) автор Җәүдәт, Клара, Рәшит һәм Луиза кебек геройларының индивидуаль характер сыйфатларын ачарга өлгерә. «Сагышлы кояш» исемле повестьта әхлакый планда капма-каршы булган Фирдия белән Сәлим мисалында укучыга гыйбрәт алырлык хәлләр күрсәтелә. Ә «Капитан

Хәкимов» исемле күләмле повестьта әдип үз күргәннәренә, армия-флот тәҗрибәсенә таянып, гомерен туган илне саклауга багышлаган күркәм совет офицеры образын хезмәте һәм гаилә тормышы шартларында шактый тулы ачып сала.

Тормыштагы хаклык, мәхәббәттә ихласлык, сафлык, тугрылыкны олылаган шушы әсәрләр аша әдипнең төп идея-фикер юнәлешен, стиль башлангычын күреп була. Әлеге сыйфат-билге — нигездә, үз тормыш тәҗрибәннән чыгып, фәкать үзен белгәннәр һәм кичергәннәр, үзенә кагылышы булган нәрсәләр турында гына язу. Юк, бу һич тә үз башыннан узганнарны түкми-чәчми кабатлау, шул күренешләрнең күчермәсен булдыру дигән сүз түгел. Бу күргән-кичергәннәр кайчагында фикерне кузгату яисә әсәрнең сюжет җебен сузу өчен генә хезмәт итә торгандыр, әмма бер нәрсә бәхәссез, барысы да тормышның үзеннән килә, сурәтләрдә ясалмалылыкның эзе дә юк. Шуна күрә алар ышандыра һәм укучы да андый әсәрләрне, анда язылганнарны бик тиз үз итә, шул вакыйгалар, геройлар янәшәсендә яшәп ала. Шулай да бу урында бер искәрмә биреп үтәргә кирәктер: 1995 елда дөнья күргән «Каргышлы этаплар» романы югарыда әйтелгән үзенчәлеккә туры килеп бетми, автор үзенә шәхсән турыдан-туры кагылмаган шәхес культы репрессияләре турында яза. Хаксызга рәнҗетелгән якташларыбыз истәлегенә багышланган роман күпсанлы тарихи чыганаклар һәм документаль фактларга нигезләнеп эшләнгән. Бу юлы да әдип зур уңышка ирешә — 1999 елны әлеге әсәре өчен ТР Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясенә лаек була.

Р.Кәрами әсәрләрен укып, олылар да, яшьләр дә гыйбрәт, сабак һәм ләззәт ала. Шулай да, исемнәреннән үк күренгәнчә, әдип язганнарның күпчелеге яшүсмерләргә, тормыш юлына кереп баручыларга юнәлтелгән. Үзенең гомер бәйрәменә Р.Кәрами «Олы юл да сикәлтәле» трилогиясенен «Сөеп туймас чакларын» исемле икенче кисәген укучылар хөкеменә тапшыру белән килә. Әсәрнең баш герое Габделнур Гаделжанов образында бик күп татар ир-егетләре үз башларыннан кичергәннәрне, холык-тотышларына хас кайбер сыйфатларны күреп, танып алырлар әле диярга ныклы нигез бар. Бу бигрәк тә узган гасырда дөньяга килеп, совет заманының әчесен-төчесен татырга өлгергәннәргә, шулай ук демократия бөркәнчеген өстенә ябып, халыкны төрле юллар белән алдарга керешкәннәрнең шаһите булганнарга кагыла. Алардан яшьрәк укучылар катламы өчен дә роман-трилогия битләрендә бик күп гыйбрәтле хәлләр, фактлар, күренешләр бирелгән. Болар барысы да Габделнурның тормыш юлы, язмышы рәвешендә һәм бай әдәби чаралар ярдәмендә чагылдырыла. Әлеге геройның тормыш юлы үтә гыйбрәтле һәм катлаулы диярга тел әйләнми, әгәр дә шулай дисәк, бу дөрес булмас иде, мөгаен.

Р.Кәраминең герое — совет чорында ук туып, җәмгыятьтәге күптөрле үзгәрешләрне үз башыннан кичерүчеләрнең берсе. Габделнур тормышның төрле якларын күргән, аның сикәлтәле юлларын, борылышларын узган, кирәк җирдә ана көйләнгән, яраклашкан, әмма кыенлыклар алдында югалып калмаган кеше булып ачыла. Мондый образларны иҗат иткәндә татар әдипләре үз биографияләрендә булганнарны һичкайчан читләтеп үтмиләр. Моның шулай икәнлеген Вакыйф Нуруллин, Мәгъсүм Хуҗин, Әхсән Баян, Мөхәммәт Мәһдиев, Тәбриз Мөбарәков, Айдар Хәлим һәм тагын бик күпләрнең әсәрләре раслап тора. Әмма гомерләренең иң зур өлеше егерменче гасырның икенче яртысына туры килгән әдипләрне һәм шул чор кешеләре буларак сурәтләнгән геройларны янәшә куеп карасак, бер үк төрле түгел икәнлекләренә инанырбыз. Алар бер үк замана кешеләре. Ә язмыш сукмакларыннан һәркем үзенчә атлый. Әлеге аерымлык әдипләрнең образларны иҗат итү ысулында да чагыла. Мәсәлән, М.Мәһдиев шул мәгълүм чор хәлләрен үзе күргән, үзе кичергән икәнлеген яшермичә яза. Бәлки андый хәлләргә Р.Кәрами дә юлыккандыр. Әмма хикәяләүне ул автор, ягъни «мин» исеменнән алып бармый, төп вазифа геройга, әлеге трилогиядә Габделнурга йөкләнә.

Билгеле бер дәрәҗәдә Габделнурны гомумиләштерелгән образ дисән дә ярый. Аның тормыш юлында, характер чалымнарында, үз-үзен тотышында бик күпләргә хас уртаклыклар һәм охшаш сыйфатлар бар. Балачагы, яшьлек еллары авылда узу, аннан уку йортына килеп белем алуга тартылуы, армиягә китеп, флот гаскәрләренә эләгүе (монда да автор биографиясенең М.Мәһдиевнеке белән нык

охшашлыгы сизелә), аннан соң янадан туган ягына кайткач, яшьләргә хас гадәти мажараларга юлыгу — болар барысы да кызыклы, мавыктыргыч язылган. Сүз унаенда Р.Кәраминең теле шома, гади һәм халык сөйләменә хас хикмәтле гыйбарәләргә бай икәнлеген әйтмичә булмый.

Герой тормышта әлегә үз урынын тапмаган. Әмма ул аңа омтыла сыман. Габделнурның күңеле начарлыкта түгел — ул кешеләргә яхшылыклар эшләп, ярдәм иткәләп йөри. Бу таза, кыю егет гаделсезлекләр белән килешеп тормый. Башкаларны да, үз-үзен дә яклый белә. Кыскасы, аны заманның уңай герое дип тә санап булыр иде. Әмма төп нәтиҗәне ясарга әлегә ашыкмыйк. Габделнурның гаделсезлек белән килешмәүчәнлеге үзенә турыдан-туры кагылса гына сизелә. Ә болай ул әйләнә-тирәсендәге тормышның язылган һәм язылмаган тәртипләренә буйсынып, хәтта шулардан канәгать булып яши кебек. Әгәр шулай булмаганда, без аны заманның Дон Кихоты дип атар идек. Юк, ул донкихотлыктан бераз читтәрәк икән. Чөнки башка бик күпләр кебек, Габделнур әйләнә-тирәбезне басып алган башбаштаклык, явызлык, мәрхәмәтсезлек, икейөзлелек күренешләрен бер ялгызың гына бетереп, җиңеп булмаячагын яхшы аңлый һәм битараф калып, «артык нечкә тойгыларга бирелмичә, мәхәббәт учагында дөрләп янмыйча, гамьсез битарафлык белән, салдан аерылган ялгыз бүрәнә кебек, акрын гына тормыш агымында йөзеп бара». Әгәр дә бу метафораны чынбарлыкка күчерсәк, Габделнурның барыр юлы шактый ук сикәлтәле икәнлегенә юлыгабыз. Мәсьәлә бары шунда гына: героебыз бу арбага ябышып озак бара алырмы яисә юлның зуррак һәм көтелмәгәнрәк сикәлтәсе аны арбасыннан чөеп, олы юл читендәге канауга ыргытып калдырырмы? Минемчә, сюжеты озынгарак сузылган әсәрдә укучының дикъкатен нәкъ менә шушы фактор тотып тора кебек.

Романнар гадәттә күптармаклы булучан. Ә «Олы юл да сикәлтәле»дә сюжет бер генә сызык буенча үстерелә. Укучы бөтен роман буена Габделнурга ияреп йөри. Ә әсәр үзе, инде югарыда әйтеп үткәнебезчә, трилогия дип уйланылган. Димәк, герой биографиясендәге сюжет җебенең очы әлегә без укыганнар белән генә чикләнмичә, өченче кисәкнең ахырына ук китәчәк. Бу типтагы әсәрнең татар әдәбияты тарихында инде очраганы бар дип әйтсәк, хилафлык булмас. Заманында әсәренең үзәгендә бер герой торганга микән, Ибраһим Гази «Онытылмас еллар» трилогиясен повесть дип атаган иде. Замандашлары аны эпопея дип тә йөрттеләр.

Әлбәттә, мондый күләмле әсәрләрне иҗат итү әдипләрдән аерым бер төрле осталык, сәләт сорый. Р.Кәрами, моны яхшы аңлап, укучыны җәлеп итүнең үтемле чараларын эшкә җигә: вакыйгалар агышы күп төрле мәгълүматлар, истәлекләр, кызыклы хәлләр, хәтта мәзәкләр белән баетылып үстерелә. Әмма монда безнең соңгы еллар прозабызда бик нык тамыр җәеп килүче күренеш турында да әйтмичә үтеп китеп булмый — бу хәл бигрәк тә роман жанрына кагыла. Әдипләр берсеннән икенчесе уздырып, калын-калын әсәрләр язарга тырыша. Аларча, роман булгач, аның күләме, калынлыгы Коръән китабына якынлашсын. Кайберәүләр гомерләрен икешәр, өчәр, хәтта дүртәр томнан торган зур күләмле әсәрләр язуга багышлый. Багышлауларына каршы бер кәлимә сүз дә әйтә алмыйбыз. Тик мәсьәләне күләм белән генә хәл итеп булсачы?! Бу әсәрләрдә күләменә лаек яисә тәңгәлләшерлек тирән фикер, еллар, гасырлар агышын милләтебез язмышы, өмете, тәҗрибәсе, киләчәге белән бәйләү һәм боларны тарих көзгесенә куеп аңлату, фәлсәфи планда анализлау да булырга тиешлеге үзеннән-үзе сорала. Иншалла, бәлки андый әсәрләрне күрергә дә насыйп булыр. Әмма, кызганыч ки, мондый «кирпеч»ләрнең күбесендә әлеге фактор искә алып җиткерелми.

Әле бит жанр таләпләре дигән әйбер дә бар. Кайчандыр «яры-чите булмаган реализм» («реализм без берегов») дип башыбызны катырдылар. Хәзер инде бу шикле һәм мәгънәсез гыйбарәне романнарга да күчерәбезме?! Дөрес, бүген әдипләрнең байтагы әлеге терминнан гомумән читләшергә уйлый, ахрысы. Халкыбыз колагына ятышлы, борынгыдан ук килүче кайбер атамалар яңартыла: мәсәлән, кыйсса, бәян һ.б.лар — болар отышлы һәм бик матур атамалар. Әдәбият галимнәре бу терминнарның асылына тулысынча төшенеп, катгый жанр таләпләрен нигезләп әдипләр колагына җиткергәнче, аерым язучылар, шул атамаларның җиләс

күләгәсендә хозурланып, әле күп «шедеврлар» тудыра ала.

Аңлашыла булса кирәк, сүзебез әдәбиятта таралып килүче чир турында бара. Тормышта әдип үзе ни күргән, шуларның барысын да рәттән яисә вакыйга барган вакытларны аралаштырып теркәү — бу әле камил әдәби әсәр иҗат итү дигән сүз түгел. Мона омтылу әсәрнең сюжетына, композицион бөтенлегенә зыян салырга мөмкин. Кызганыч ки, моның мисалларын бүгенге татар прозасында бик еш очратып була.

Р.Кәрами иҗатыннан бөтенләй читкә китте бит бу, дип шелтәләүчеләр дә табылыр. Юк, бигүк читкә китмәдек. Биредә хөрмәтле юбилярыбыз колагына ишеттерерлек сүзләр дә яңгырады. Без Р.Кәраминең үз табышларын эзлибез — алар табылса, куанабыз. Әдәби бурычларны ул көнеленә якын герое аша чишәргә, башкарырга тырыша. Мондый геройны алданрак язылган «Очар кошлар белән янәшә» (1978-1985) романында да күргән идек. Анда да Гөлүс исемле татар егете тормыш казанының нәкъ уртасында кайный. Ул йөргән юлларда йөреп, аның мажараларын, хәлләрен бергә кичереп, укучы да байтак мәгълүмат ала. Бүген күп әдипләребез эшчеләр тормышы, хезмәт, производство мәсьәләләренә якын да килми, андый темалар укучыга нигә кирәк ул? дигән булып, аларны әйләнеп үтә. Р.Кәрами бу мәсьәләгә башкачарак карый һәм, минемчә, ялгышмый, чөнки бераз читкә тибәрелгән һәм кадерсезләнгән теманы яңарта, кешелек өчен материаль байлыкның бары тик хезмәт белән тудырылуын яхшы белә, моны аңлаучыларга үзенең җылы карашын белдерә.

Казандагы зур химия комбинаты төзелеше күренешләре романда зур осталык белән һәм төгәл сурәтләнә. Укучысын Казан каласында, аның урамнарында, бакчаларында йөрткәндә дә автор реальлеккә, төгәллеккә хилафлык китерми — ничек бар, шулай яза. Якташлары, замандашлары язылганнарны үз истәлекләре һәм күзәтүләре белән дә янәшә куеп, чагыштыра ала. Алардагы географик һәм тарихи дөреслекне танып алу белән әдип әсәрләренә ихтирам уянуга шикләнмәскә мөмкин. Чыннан да, Р.Кәрами әле дә татар әдәбиятындагы реалистик тармакны дәвам иттерүче прозаикларыбызның берсе булып кала бирә.

Без әдипнең күңеленә якын булган, бик тә яратып һәм иркенләп иҗат итә торган берничә теманы билгеләп алдык. Аларның берсе, әлбәттә, үзенең яшәү урыны — туган җиредәй якын күргән Казан шәһәре... Роман герое өчен дә илһам, шатлык һәм яшәү чыганагы булган кала менә ничек сурәтләнә: «И ямьле, нурлы шәһәр! Менә сиңа тагын бер яшь кеше килеп баш ия, үзенә сыеныр урын, әле берни дә эшли белмәгән, шулай да хезмәткә сусаган кулларына эш сорый. Кире какма аның үтенечен, фатиханны бир... Менә бераздан үсмернең сулышы тукталгандай булды — каршыда биек стеналы мәшһүр Кремль иде. Әнә кызыл кирпечтән салынган очлы башлы Сөембикә манарасы, ә арырак ап-ак Спасс башнясы. Менә кайчан аңа бу тарихи урыннарны күрергә насыйп булган икән!». Әнә шулай күпләргә таныш манзара романдагы яшь герой Гөлүс уйлары белән кушылып, янача җанлана, әсәрдәге шат, оптимистик рухны тагын да көчәйтеп җибәрә.

Р.Кәрами әсәрендә илебезнең иң гүзәл шәһәрләреннән тагын берсе турында мондый юллар бар: «Алар Ленинградта. Ул ни житте генә шәһәр түгел — революция бишеге, үзен мәңгелек данга күмгән «Аврора» крейсеры да шушында, тарихларга кереп калган Нева елгасы да аны аркылыга кисеп ага... Казан белән чагыштырганда аның йортлары да биегрәк, төрледән төрле орнаментлар белән чуарланган, кая карама гүзәл биналар, истәлекле урыннар...». Әлеге юлларны укыганда белгәннәрнең күңелендә истәлекләр яңара, ә белмәгәннәр күңелендә шул матур җирләрне күрәсе килү тойгылары уяна торгандыр, мөгаен.

Аерым урыннарда автор артыграк мавыгып китеп, укучы зиһенен тарихи, географик, этнографик мәгълүматлар белән ялыктыра башлый — үзенең саф әдәбият иҗатчысы булырга тиешлеген онытып җибәрә. Әгәр язучы үзенә таныш булган һәр фактны, мәгълүматны, кызык кебек тоелган һәр күренешне укучыга житкерү теләгенә бирелсә, әсәренә куелган төп әдәби-эстетик бурычларыннан читкә тайпылганлыгын сизми дә кала. Мәгълүмат никадәр мөһим тоелса да, аны әдипнең кыл иләгеннән иләп кенә төшерү зарурлыгын автор алга таба ешрак искә

алыр дигән өметтә калабыз.

Әлбәттә, Р.Кәраминең укучыга әйтәсе һәм әйтерлек сүзләре бик күп. Алар, нигездә, ике-өч өлкәгә карый, берсе — Россия армиясендәге хәлләр, икенчесе — эшчеләр тормышы. Һәр икесен ачканда әдип күргән-белгәннәренә таяна, үзе инанганча язарга тырыша. Шәхси тәҗрибәсенә нигезләнгән вакыйгаларны ихластан язу ысулы Р.Кәраминең иҗат үзенчәлеген һәм әдәби караш-юнәлешләрен аңларга да ярдәм итә. Армиянең бүгенге хәлен, уставта язылган һәм язылмаган тәртипләрен автор, реалистик әдәбиятка хас булганча, объектив рәвештә тасвирлый, кимчелекләрне һәм гаделсезлекләрне аяусыз фаш итә. Ул бу хәлләрне белеп, ышандырып яза. Шуның белән бергә, әдипнең сурәт-тасвирларында совет армиясендә, флот гаскәрләрендә үткәргән чорны, бергә солдат ашы, матрос шулпасы эчеп, илгә тугры хезмәт иткән иптәшләрен җылы һәм тирән хөрмәт белән сагынып искә алу романтикасы да сизелеп тора.

Әдипнең аеруча яратып сурәтли торган тагын бер өлкәсе — яшь кешенең мәхәббәт мажаралары. Үзенең бер китабын «Мәхәббәт бураннары» дип атавын югарыда искәрткән идек. «Олы юл да сикәлтәле», «Сөеп туймас чакларың» романнарының төп герое, әлегә гаилә кора алмаган Габделнурның мәхәббәт уеннары шактый мавыктыргыч итеп язылса да, ахыр чиктә ялыктыра башлый. Бу урында, миңа каршы төшеп, яшь укучыларның: «Без Р.Кәрами китапларын нәкъ шундый күренешләр күп булганга яратып укыйбыз инде», — диюләре ихтимал. Әлбәттә, алар да үзләренчә хаклы булырлар. Гомумән, мондый күренешләр шыплап тутырылган һәм шуңа ихтыяҗы булган укучыларның күңелен тагын да кытыклау өчен генә язылган әсәрләрнең күпчелеге илдә сексуаль революция башланган чорда — узган гасырның туксанынчы һәм яңа гасыр башында — иҗат ителгәнлеген искә төшерсәк, бу хакыйкать кырыс холыклы тәнкыйтьчеләр һәм аскетик табигатьле әдәбият белгечләренә дә аңлашыла төшәр. Андый күренешләрне Р.Кәраминең дә укучыны җәлеп итү чарасы итеп файдаланганлыгы күренә. Аянычлы ягы шунда: геройның мәхәббәттә «җиңүләрен» чагылдырган, ачыктан-ачык язылган әлеге хәл-вакыйгаларны яңа романнарына күпләп урнаштырып, хөрмәтле авторыбыз ялгыша булса кирәк. Тагын бер нәрсә онытылмасын иде, заманалар үзгәрә тора, бүген эротик эчтәлекле әдәбият һәркайда тулып ята һәм аның белән кабаттан очрашуны укучылар бик әһәмиятле проблема дип санамый бугай инде.

Шактый ук нәзакәтле күренешләрне Р.Кәрами матур итеп, күңелләрне иркәләрдәй сүзләр табып яза белә. Шуларның кайберләре авторның портрет белән эшләвендә дә сизелә. Бу фикерләребезне бер-ике генә мисал белән ныгытыйк: «Берничә адым атлагач, Сәлим, артына борылып, Фирдиянең биек үкчәле кара сапожкие белән шыгыр-шыгыр басып йөгерә-атлый барган җинел адымнарына, кара тун кисә дә, буеның зифалыгы сизелеп торган ыспай гәүдәсенә сокланып торды. Ә күз алдында аның кара тутлы уйчан йөзе. Башында кәҗә мамыгыннан бәйләнгән челтәрле ак яулык булгангамы, болай да кара кыйгач кашлары тагын да ныграк күзгә бәрелеп тора иде. Кечкенә түгәрәк йөзе мөлаем, күпереп торган калынча иреннәре, әйтерсең лә, үбешер өчен генә яралган... Сәлимнең күңел түрендә нидер сыкрап куйгандай булды, иңрәп сызлагандай йөрәге өзгәләнеп алды. Фирдиянең күп сөйләшмәве дә күңеленә хуш килгән иде егетнең. Ә сөйләшкәндә сүзләрен кызу-кызу әйтүе, елмайганда бөтен битенә нур сибелүе, хәтта сирәк кенә каш сирпеп алуларына кадәр егетнең күңеленә сеңеп калды... Их, кайсыдыр бер бәхетлесенә тап булачак бу сылу! Культурный, киенә белә, сүзгә оста. Үзе татар кызы. Авылга алып кайтып, өй ишеген каерып ачып, әнкәй, менә сиңа килен, дип шәрран ярып әйтсәң дә хур булырлык түгел бу...» («Сагышлы кояш»).

Татар хатын-кызларының мөлаем сурәтләре башка әсәрләрендә дә очрый. Шунысын да әйтик, гадәттә, сюжет барышында әлеге мөлаемлек раслана, ә ияләренең чын матурлыгы эш-гамәлләрендәге, холык-фигыльләрендәге күркәм сыйфатлары белән тагын да ныгытыла. «Капитан Хәкимов» повестенда Гөлсем исемле кызга авторның икенче бер герой Самат карашы аша бирелгән беренче бәясе дә нәкъ шундый булып чыга — алар матур, бәхетле тормыш корып җибәрәчәкләр: «Гөлсем кара итәк һәм зәңгәр джемпер киеп куйган. Ул аның нәзек, ябык гәүдәсен

тагын да жыйнаклатып, ыспайлатып тора, конгырт чәчләрен баш түбәсенә өеп, кинчә йөзенә килешле генә итеп зур прическа ясаган. Бит алмалары кызарып тора. Ләкин барыннан да бигрәк аның зур зәңгәр күзләре җәлеп итә иде. Башка берәүдә булса, ул күзләр ничектер артык зур, килешсез булыр иде сыман, ә менә Гөлсемнен елмаюлы йөзен алар тагын да ачып, яктыртып җибәрәләр. Ул күзләргә карап сокланмау мөмкин түгел иде» («Капитан Хәкимов»)

Р.Кәрами хикәяләр авторы буларак та укучыларга яхшы таныш. Аның чор рухына бәйле рәвештә замандашларыбызның күнел талпынышын тасвирлаган дистәләгән кече күләмле әсәрләре бар. Арада йөгерек, йомшак тел белән балаларга атап язылганнары да очрый. Язучы үзен юмор һәм сатирага корылган хикәяләр остасы итеп тә танытты. Хикәяләренең байтагы рус, әзәрбайҗан, кыргыз, хакас, казакъ, мари, мордва, башкорт, чуваш телләренә тәрҗемә ителде.

Әдипнен проза өлкәсендәге эшчәнлегенә багышланган бу мәкаләдә сәнгатьнең башка тармакларындагы күпкырлы эшчәнлегенә кагыла алмадык. Ә бит Р.Кәрами музыкага, монга, театр сәнгатенә җаны-тәне белән бирелгән кеше. Үзе махсус рәвештә халык каршында концертлар куеп йөрмәгәнлектән, күпләр аның яхшы баянчы икәнлеген дә белми торгандыр. Ә игътибарлы укучы әдип прозасында җырмоннарнын шактый сибелгәнлеген тиз күреп алгандыр. Р.Кәрами шигырьләренә байтак җырлар иҗат ителгән. Мәсәлән, композиторлар Әнвәр Бакиров, Риф Гатауллин көй язган «Авылым таннары», «Синен күзләр», «Яна Болгар» кебек җырларны гына искә төшерик.

Узган гасырнын сиксәненче елларында әдип драматургия белән дә мавыгып ала: бер-бер артлы «Агачыннан ерак төшми», «Яратуың чынмы?», «Кунак кызы», «Гаепле табылыр ул», «Шома егетләр», «Хатларынны көтәм, улкаем» дигән пьесалары языла. Аларнын кайберләре профессиональ театр сәхнәләренә дә менә.

Р.Кәрами үзенең гомер көзен зур уңышлар, үз теленә күчереп әйтсәк, ындыр тулы иҗат кибәннәре белән каршылый. Аның көз дигәнен дә картаю мәгънәсендә түгел, әнә шул кибәннәрне җыештырып йөрү вакыты дип кенә аңларга кирәктер. Очлыйсы кибәннәре байтак булырга тиеш әле. Бүген әдипнең яшьләрчә дәртләнеп, илһамланып иҗат итеп йөргән көннәре...

Үзенең иҗат ындырына барганда Р.Кәрами төрле-төрле сукмаклар сайларга ярата. Аның геройлары да тормышнын катлаулы, кыен юлларында сынала. Кайчагында мондый сикәлтәле юллар геройларына һәм әдипнең үзенә бердәй якын һәм уртак булып тоела. Китапларын укучыга бер хакыйкать ачыла: әлеге юллардан адашмыйча барыйм дисән, тормышнын үзендә кайнарга, шунда сыналырга, тик кайда гына булсан да, Кеше дигән олы исем йөртүенне онытмыйча, алга карап атларга кирәк. Гомер юлындагыларга без дә хәерле сәфәр теләп калабыз.

**Рифат СВЕРИГИН**

**Редакциядән:**
*Бу айда Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге премиясе лауреаты Рәфкать Кәрамигә 70 яшь тула. Каләмдәшебезне юбилее белән котлыйбыз, сәламәтлек, иҗади уңышлар телибез.*

# «ШИГЫРЬ — МИНЕМ ЯШӘҮ РӘВЕШЕМ»

КАДЫЙР СИБГАТУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Үз чорының әдәби барышында лаеклы урын алып та, вафатларыннан соң иҗатлары күләгәдә калучы каләм ияләре бар. 1960-90 еллар поэзиясенең күренекле вәкиле, күпсанлы шигъри җыентыклар авторы Кадыйр Сибгатуллин шундый язмышка дучар булып, бары тик соңгы елларда гына иҗатын өйрәнүгә ныклы нигез салына.



Кадыйр Сибгатуллин (Кадыйр Һидиятулла улы Сибгатуллин) 1942 елның 15 февралендә Татарстанның Корноухово (хәзерге Балык Бистәсе) районы Балыклы Чүкәй авылында туып, балалык һәм яшьлек еллары Кече Укмаста үтә. Яшьли ятим калган малай сугыш һәм сугыштан соңгы елларның бөтен авырлыгын башыннан кичерә. Әлеге авыр чорның шигъри сурәте аның иҗатында аерым урын тота. «Кар шыгырдый» шигырен тетрәнмичә уку мөмкин түгел.

*Салкын өйдә ике ач бәндә без,*
*икебез дә елап арыган.*
*Караңгыда иске шәлен капшап,*
*иңнәренә барып сарылам.*

Кадыйр Сибгатуллин 1949 елда Балык Бистәсе районы Кече Укмас авылы башлангыч мәктәбенә укырга керә. 1960 елда Олы Солтан урта мәктәбен тәмамлый. Олы Солтан мәктәбендә укыганда беренче шигырьләре район газетасында басыла башлый. Менә аның тәүге шигырьләреннән берсе:

*Йомшак кына җиңел карлар ява,*
*ә мин барам мәктәп юлыннан.*
*Кемнәр генә килеп чыгар икән,*
*Кече Укмас, синең улыңнан?*

Балык Бистәсендә чыгып килүче «Октябрь юлы» исемле район газетасы редакциясе каршында шагыйрь һәм мөхәррир Рәшит Гарипов әдәбият түгәрәге оештыра. Түгәрәккә районның ике ягыннан ике егет килеп йөри башлый: Олы Солтаннан — Кадыйр Сибгатуллин, Котлы Бөкәштән — Равил Фәйзуллин.

Укытучы Анна Андреевна Кутузова укучысы Кадыйр Сибгатуллин турындагы истәлегендә болай искә ала: «Берсен һич онытмыйм. Яз көне, бозлар агып киткәч, Минкадыйр иптәш малае белән инеш буена төшкән. Шул чагында алар янына авылдагы хәлле кешенең малае килеп чыккан. Кулында — көлгә күмеп пешерелгән ике бәрәңге. Ач балаларның күзләре, билгеле, бәрәңгедә! Теге малай шарт куйган: кем инешнең теге як ярына йөзеп чыга, шуңа бер бәрәңге. Башта бу эшкә иптәш малае тәвәккәлләп карый. Юк, су тәнне өтә, кире борылып чыга. Шуннан Минкадыйр, тиз генә чишенеп ташлый да, суга кереп китә. Инешне йөзеп чыга, теге малай да куйган шартын төгәл үти, каршы як ярга бер бәрәңге ыргыта».

Шагыйрьнең «Гамь» дип исемләнгән китабында ике шигырь янәшә тора:

«Бозлар» һәм «Саллар». Шул шигырьләрдәге ике строфа әлеге истәлектән соң бөтенләй янача ачыла.

*...Боз белән дә кыен саубуллашу,*
*томанланып тора күз алды.*
*Җанымда да, ахры, бозлар булган,*
*барысы да эреп кузгалды...*
(«Бозлар»).

*...Салдагылар, и-и, бәрәңге ашый — тозга мана-мана.*
*Бу җиһанның бар ләззәтен җыеп*
*салмак саллар ага.*
(«Саллар»).

К.Сибгатуллин иҗатының башлангыч чорында ук метафоралар белән иркен эш итә алучы шагыйрь булып таныла. Шигырьнең көче дә шунда — гади генә төшенчә, күренешләр артында киң мәгънә катламы ачуга ирешү. «Боз», «Бозның китүе», «Сал», «Сал агышы» — барысы да метафоралар, реаль күренешләрнең күңел халәтенә тәңгәлләштерелгән үзгәреш кичерүе, метаморфозасы.

Балачак чорында тагын бер тетрәнү кичерә булачак шагыйрь. Тугыз яшьләр тирәсе булыр, ул бик каты авырып китә. Сырхауханәдә терелтәселәренә өмет беткәч, инде үлсә өйдә үләр, дип, улының сөяккә калган гәүдәсен күтәреп ун чакрымлап җирне үтә ана. Бу хәлләр булачак шагыйрь күңелендә берегеп кала: «Ни гаҗәптер, биреште тиф — терелә башладым. Тагын чыктым урамга. Малайлар йөгерәләр, ә мин карап кына торам шул, кызыгып. Хәлем юк, егылам. Оят. Бик йөгерәсе килә. Йөгереп кенә киттем дим..., тагын барып төшәм. (...) Торам. Барыбер йөгерәм, егылам, тагын торам. Коточкыч бу. Җиргә лапылдап барып төшкәндә, дөнья гөж килә, ниндидер авазлар ишетелә, мин каядыр очмакчы булып талпынам, ниндидер җиңеллек һәм гайрәт тойгандай булам... Минем шигырь яза башлау тилелекләрем дә шул егылу-чирләрдән башланмады микән әле, ишеткәнемчә, шундый чирләрдән соң булгалый бугай ул андый хәлләр. Нәселдә кулына каләм алып шигырь язган бер генә кеше дә юк, ә мин шигырьдән башка яши алмыйм, шигырь — минем яшәү рәвешем».

Кеше тик торганнан гына каләмгә үрелми, тик торганнан үзен «бәхетсез» итәчәк гаять авыр иҗат сукмагына кереп китми. Монда кем дә төгәл аңлатып бетерми торган нәрсәләр бар. «Беренче шигыремне хәтерләмим, — дип яза ул истәлекләрендә. — Табигый, ул беркайчан да басылмагандыр. Ләкин ышанам, ул — минем белән уйнап үскән песи баласы, урамыбыздагы каз бәбкәләре, өебезнең ишек каты почмагында минем бишмәт итәген чәйнәп аптыраткан бозавыбыз турында булгандыр. Минем яшәвем дә, туган илем дә шуннан башланган бит. Ә соңрак — кешеләр, авылыбызның тол апалары, бик иртә ир булып җитешкән малайлары, каберләре бөтен Европа буйлап сибелгән ир-атлары турында язасы килде минем. Еллар безнең үскәнне сизгер күзәтеп тордылар. Арбасына буй җитә башлагач, тормыш безне ат җигәргә өйрәтте. Ул авыр елларны җилкәсенә ирләрчә күтәргән кешеләр кемнәр булсын? Алар безнең әниләр, толлар һәм аларның балалары!..»

Кадыйр Сибгатуллин яшьтән үк олы йөрәкле, мәрхәмәтле, игелекле шәхес буларак формалаша башлый һәм рухы күрсәткән шушы юлны беркайчан да ташлап чыкмый. Иҗатыннан күренгәнчә, аның холкы формалашуына зур йогынты ясаган, кальбенә иман сеңдергән кешеләрнең берсе — әбисе. «Рәхмәт, әби!» шигырен укыгач, моның шулай булуына шик калмый:

*Әби юмарт иде.*
*Ачлык елда,*
*килеп кергәч сукыр теләнче,*
*елый-елый мичтән алып бирде*
*соңгы алабута күмәчен.*

*«Бабабагыз да сукыр иде, — диде, —*
*бу кеше дә сукыр...*
*Жәлләдем...»*

Сабыйлар әбиләренең бу гамәлен анлый алмыйлар. «...Без әбигә шундый үпкәләдек..!» Алга табан шигырьдә көчле гомумиләштерүләр ясала.

*Мин аңладым еллар үткәч кенә*
*аңа ничек кыен булганны.*
*Соңгы күмәч...*
*Бәгыреннән өзеп*
*биргән икән аңа ул аны.*
*Алабута,*
*ат колагы,*
*юкә...*
*алып калды безне үлемнән.*
*Алар түгел,*
*китми әбиемнең*
*кешелеклелеге күңелдән.*
*Суынып беткән*
*ул бер күмәч кенә*
*коткара алмас иде ачлыктан.*
*Саклап калган әби рухыбызны,*
*җаныбызны ялангачлыктан.*

1960-66 елларны шагыйрь иҗатының башлангыч чоры дип исәпләсәк, 1966 елдан алып 1978 елга кадәр араны шагыйрь иҗатының икенче чоры дип атарга була. Бу чорда аның иҗатында, башка бер генә шагыйрьне дә кабатламыйча, авыл тормышы, сугыш, язмышы авыр дәвергә юлыккан хатын-кыз (иргә чыкмый калган апалар, толлар) темасы үзәк урынны алып тора. «Гел үткәннәр турында гына язып булмый. Ләкин бүгенге матур авыл тормышының чын мәгънәсендә иҗат кешесенә әверелгән кешесе турында язганда, чабатадан язгы суда тартып симәнә ташыган тол әниләребез, бүгенге шат, көләч кызларыбыз турында язганда, кияүгә дә чыга алмый калган, сугыш елларында яшьлекләрен салкын фермаларда үткәргән апаларыбыз, бүгенге чая һәм бәхетле малайлар турында язганда, ун-унбер яшьтән ярым ач килеш колхоз эшеннән кайтып кермәгән абыйларыбыз һәм сугыштан соңгы елларда тормышның бөтен ятимлеген тоеп үскән безнен буын турында дәшми калу кыен», — дип искә ала К.Сибгатуллин.

Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Нури Арсланов кебек татарның олпат әдипләре аны шигырьгә тормышны алып керүче буларак билгелиләр. Туган җир, авыл һәм язмышлар хакында уйланып язылган шигырьләре башлыча «Беренче карлыгачлар», «Юл башы», «Әманәт» китапларына кергән. «Туган җир», «Кырларым күмелгән рәшәгә», «Иргә чыкмый калган апалар», «Әтисезләр болар димәгез», «Ирләр», «Заман көтә» кебек шигырьләре мона ачык мисал. К.Сибгатуллин үзенен остазы итеп Х.Туфанны саный, шуна да ана килгән күпсанлы хатлар арасында ин кадерлеләре Хәсән Туфанныкы. Беренче хат мондый: «Кадерле Кадыйр! «Беренче карлыгачлар»дагы шигырьләреңне күздән кичергәннән сон: «...Шатланып мин кысам кулыңны. Иненә канатлар үссеннәр!» — диясем килә сина. Шигырьдә үз телен, үзенә хас үзенчәлегең бар. Шуна күрә үз сүзле кеше булырга теләвең табигый хәл ул. Туачак җырларына «Тузан ерып каршы» бар, әйдә, энекәш! Иманнәр кебек үк сабыр итмәскә, бәлки каеннар кебек, яшелгә чумарга кирәктер.Тынма, яхшы мәгънәсендә тынгысыз бул: «Еллар үпкәләп еларлык булсын». Үз халкыбыз офыкларынын теге якларындагы «тыныч утраулар» тирәсендә «романтика» эзләп маташучылардан аерылып торуың шатландыра... Шигырьләреңне көтеп, сәлам белән Х.Туфан.10.03.70.

Елдан артык вакыт үткәч, Х.Туфан икенче хатын юллый: «Кадерле энебез

Кадыйр! Син безне (Хәкимне, мине, Бәширне, Әмирханны) шатландырасың: № 2дәге шигырьләрен № 1дәге («Казан утлары» журналы турында сүз бара — Ф.С.) Хәким, Әгъләм, Равил шигырьләре белән бер сафта тора алалар. Синең иҗат турында матбугатта берәр җылы сүз әйтәсе килә. Һәм акыллы бул: безнең ышанычны, безнең өметләрне шагыйрь хәлдә генә түгел, шәхес хәлендә дә акларга тиешлегеңне бик нык аңла, безне бервакытта да уңайсызлыкта калдырырга тиеш түгеллегеңне искә алып яшә. Бу көннәрдә генә түгел, иртәгәләрдә дә, иҗади гомереңнең иң соңгы елларына, чорларына кадәр дә, безнең кебек кенә дә түгел, бездән дә иманлырак хәлдә бул. Бу сина — әмер дә һәм алдан ук әйтеп куелган васыять тә... Синдә дә Зөлфәттәге, Әгъләмдәге (һәм Равилдә дә туа башлаган) гүзәл гамь, илең, халкың күнеле белән тоташкан әйбәт тынгысызлык бар, һаман үсә барган гүзәл иман бар, көнем өчен түгел, Денем, Илем өчен! дигән иман бар. Иманыңны ата шайтанга да бирмә, Кадыйр! Сәламнең иң җылысы белән Х.Туфан. 26.04.71.

К.Сибгатуллинның беренче мөстәкыйль китабы «Әманәт» (1974) дөнья күргәч, Х.Туфан яшь шагыйрьгә Язучылар берлегенә әгъза итеп алу өчен тәкъдимнамә яза һәм иҗатына «... шигъри вакыйга ул!», — дип бәя бирә. Язучылар берлегенең шагыйрьләр секциясен җитәкләгән Х.Туфан эшне озак сузмаска тели. Үзенең чордашларыннан яшь шагыйрьнең шигырьләрен укып фикер әйтүләрен үтенә. Аларның берсе С.Хәким була: «Кадыйр туган! Туфан миңа синең шигырьләрне укып күрсәтте, укып кара, диде. Укып чыктым, дөресе, рәхәтләнеп укыдым, кайбер юлларын хәтта көйләп укыдым. Бигрәк тә сугыш чоры, толлар, кызлар-толлар, туган җир турындагы шигырьләр әйбәт. Редакциягә яңадан карап җибәр, бәлки кереш язармын. Сәлам белән Сибгат Хәким. 14.06. 1971».

К.Сибгатуллинның икенче китабы «Гамь» дип атала һәм ул 1976 елда басылып чыга. Бу китапта да авыл темасы төрле төсмерләрдә, нечкә тәэссоратлы буяулар белән сурәтләп тасвир кылына. «Атлар көтте авыл малайлары», «...Башак шавы — тәүге бишек җырым...», «Игенче», «Читтәге авылдашлар», «Кибәнче карт» кебек шигырьләр укучыларның күңелен тиз җәлеп итәләр. Ләкин Язучылар берлегенә алыну һаман сузыла килә. Мәсьәләне Татарстанда гына хәл итеп булмасын аңлаганга, аксакаллар ул чакта Татарстан Язучылар берлегенең оештыру мәсьәләләре буенча сәркатибе булып эшләгән Мөсәгыйт Хәбибуллинның киңәшенә колак салалар. Фәкать Мәскәүдә русча китап чыкканнан соң гына мәсьәләне тизләтеп булачагын искәртә ул.

«Полет радуги» (1978) китабы чыгу да җиңел генә булмый. «Вак җанлы чиновниклар үзләре өчен куркып, һәр адымда саклык чаралары күрәләр», — дип яза тәрҗемәче Александр Зорин зарланып. Икенче бер хатында ул болай ди: «Минем эш тәҗрибәмдә бу кадәр дә баштанаяк ботарлауны күргәнем булмады әле. Менә кадәр мин үз фикерен яклый алырлык мөстәкыйль мөхәррирләр белән эш иткән идем шул... Бер сүз белән әйткәндә, шагыйрь үз телендә яңгырарга тиеш, чит тел аның мөмкинлекләрен күрсәтүдән мәхрүм, әгәр дә чит телгә тәрҗемә артында сәяси сәбәпләр дә ятса... Александр Зорин. 06. 12. 1977. Мәскәү». Бу хәлгә аңлатма рәвешендә Сибгат Хәкимнең сүзләрен китерергә була: «Барыбер әле һаман татар язучысыннан куркалар, һаман аннан милләтче эзлиләр. Милләтен, телен, җирен, культурасын, традициясен яраткан өчен дә аны яратып бетермиләр. Ә сугышта без әнә шул тел, шул халык, шул җирне яратканга күрә әйбәтрәк сугыштык. Ул безнең гомуми идеалга һич тә каршы килмәде».

Ниһаять, 1978 елда К.Сибгатуллин СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителә һәм шул ук елны гаиләсе белән яңа төзелешләре илгә шаулаган Яр Чаллы шәһәренә күченеп килә. Каләмдәшләре әйтүенә караганда, ул үзе гел Казанга тартыла. Әмма язмыш башка якка алып китә. 1981 елда басылган «Авазлар» китабында Кадыйр Сибгатуллинның гражданлык позициясе алга бәреп чыга. Күренекле тәнкыйтьче Т.Галиуллин шагыйрь йөрәген — «заман сейсмографы» дип атап, шагыйрьнең тормышка мөнәсәбәтен билгели. Тормыш кырыслыгы «Инвалидлар» шигырендә дә ярылып ята. Сугышлар белән мавыгучы сәяси сукырларны чынбарлыктан сабак алырга чакыру дип кабул ителә әлеге шигырь. Атна саен шәһәр мунчасына берсе сыңар аяклы, икенчесе сыңар куллы икәү юынырга киләләр. Боларның дуслыгы

сугыштан ук килә: чолганыштан үзара ярдәмләшеп чыгып, үлемнән котылып калалар. Берсе аяксыз, икенчесе кулсыз хәлдә, «Инвалидлар булып кына түгел, /туганнар да булып кайтканнар». Уен-көлке сөйләп, гөр килеп мунча керүләренә барысы да күнегеп беткән булалар. Әмма көннәрдән бер көнне аяксыз инвалид мунчага килми... Бер кулсызы үзалдына уйланып, дәшми-тынмый гына юына, каен себеркесенә кул да тигезми. «...Кеше дә күп, мунча тынып калды, / ләүкә хәзер — матәм почмагы». Тагын җан сызлануы, шагыйрьнең күңеле сыктап елый.

Чаллыга күчеп килгәч иҗат ителгән «Хыял» поэмасы шагыйрь иҗатының өченче чорында аерым бер урын тота. Иҗатның өченче чоры дигәндә Кадыйр Сибгатуллин шигъриятенең шәһәр дәвере күздә тотыла. Шәһәр рухы шагыйрь күңеленә ят булып кала.

*Ә шулай да сагынам мин,*
*ямансулыйм кичләрен:*
*Калгандыр качып авылда*
*иң мөкатдәс хисләрем...*

1986 елда басылып чыккан «Хыял» китабында шагыйрьнең уй-хисләре төрле параллель яссылыкларда бәргәләнә. Бер карасаң, шигырьләрендә гаҗәеп шатлыклы мотивлар өскә чыга: «Бәхетенне әгәр шәйләмәсәң, / син язлардан сора. / Мин ышандым быел: безнең гомер / гел язлардан тора!». Икенче карасаң, кешелек кайгы-хәсрәттән, гаять зур сынаулардан әле арына алмый, җирдә оныкларның киләчәген куркыныч астына куйган хәлләр булып кына тора.

*– Бетте! — диеп бүген кем әйталсын! —*
*Бер көне юк дошман атмаган.*
*Без сугышка күптән киткән идек,*
*без сугыштан әле кайтмаган...*

1980 елда Чаллыда Татарстан Язучыларының төбәк оешмасы ачыла. Шагыйрь эшчәнлеген һәм иҗатын тагын да активлаштыра. 1984 елның сентябрь аеннан 1991 елның августына кадәр ул Татарстан Язучылар берлеге матур әдәбиятны пропагандалау бюросының Чаллыдагы вәкиле булып эшли. Сиксәненче еллар ахырында илдә барган үзгәрешләр шагыйрьне тагын да җилкендереп җибәрә. Ул үзгәртеп коруга күп өмет баглый. Бу хактагы уйлануларын шигырьгә генә түгел, публицистик рухтагы язмаларына да теркәп калдыра. «Үзгәртеп коруны кемнәрнеңдер уйлап тапкан, берәр яңалык ясыйм әле дигән эше дип санамыйм мин. ...Мине башка нәрсә борчый. Кеше рухының, кеше күңеленең ничек үзгәрүе. Бүген әле мин андый үзгәреш сизмим. Әгәр без кеше күңелен үзгәртеп кору турында җитди сүз алып барабыз икән, шагыйрьне үзгәртеп кору турында сөйләшергә тиеш түгел. Шагыйрь үзе кешене үзгәртү өчен туган, шуна хезмәт итә, заманасы белән бернәрсә дә үзгәртә алмыйча үлеп тә китә. Менә шушына дучар итмәсен иде».

«Инану» китабы (1988) шагыйрьнең өченче чор иҗатын тәмамлап куя. Китапка эчке рецензияне таләпчән М.Шабаев яза. К.Сибгатуллинның татар поэзиясенең үзәгендә кайнаучы шагыйрь икәнен күрсәтеп, иҗатын унай бәяли: «Кадыйр — иленә, халкына җаны-тәне белән бирелгән шагыйрь. ...Анда (китапта) шагыйрьнең тулы иҗат биографиясе. Кызыклы эчтәлекле биография». К.Сибгатуллин иҗатының дүртенче чоры тулысы белән үзгәртеп кору чорына (1988-1994) туры килә.

1993 елда К. Сибгатуллин «Таңнар, кичәләр» китабы (1989) өчен Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим ителә. Премия аңа бирелми. Шагыйрь, тыштан сиздермәсә дә, бу хәлне авыр кичерә. «Гомерем дулкыннары» китабы (1993), нәшрият планы буенча «Шигырь китапханәсе» сериясендә дөнья күрергә тиеш булса да, билгесез сәбәпләр аркасында гади катыргы тышта, эшләнеш сыйфаты ягыннан шактый кайтыш җыентык формасында басылып чыга. «...Ә ул бик кыен. Аны кичерүе кыен!» — ди шагыйрь.

Татар халкының мөстәкыйльлеге өчен җан атып, даулашып йөргән көннәрендә

Кадыйр Сибгатуллин иҗаты белән генә түгел, үзе дә шушы көрәшкә кушылып китә. 1991 елда Чаллы шәһәрендә бертөркем яшь язучылар әдәби, иҗтимагый-сәяси журнал булдыру артыннан йөри башлый. Әдәби консультант вазифасын башкарган шагыйрь кинәшләре белән генә түгел, кайбер «ишекләрне» ачып керергә дә булыша. Финанс мәсьәләсе хәл ителә. К.Сибгатуллин яна журналны чыгаруга җин сызганып керешә...

1993 елда К.Сибгатуллин сценариесы буенча, беренче мәртәбә милләт язмышын үзәккә куеп эшләнгән татарча «Иманга кайту» документаль фильмы төшерелә. Шагыйрь ул көннәрдә алны-ялны белми эшли, кино дөньяга чыкмыйча тынычланмый. «Иманга кайту» Кадыйр Сибгатуллин публицистикасынын иң югары казанышы, татар әдәбиятында вакыйга булырлык әсәр, публицистик поэма. Әсәрнең Болгар хәрабәләренә багышланган өлешен күзәтик. Чәчмә рәвештә язылган: «Нишләтәсең, тарих аяусыз. Ә тарихны кеше тудыра. Кызганычка каршы, җирдә кеше үзе төзи, үзе үк җимерә дә бара». Шундук шагыйрь тезмә формага күчә: «Киләбез дә... Карап уйланабыз... / Бу ташларның нишләп сүзе юк? /Капкалар да ачык, ишекләр дә... / Нишләп әле хуҗа үзе юк?».

Шагыйрьне тел язмышы, татарның дәүләтчелеге, милләтнең сакланып калу мәсьәләләре борчый. К.Сибгатуллинның гражданлык лирикасы — көчле рухлы лирик геройның дөнья кайгысы өчен битараф булмаган укучы белән сөйләшүе ул. Беренче чиратта, билгеле, татар теленә ихтирамсыз караштан бәгыре яна. 1989 елда язылган «Шәһәрдә татар теле укытучылары» шигырендә ана телен укытучы фидакарьләрнең ачы язмышын ачып сала, укытучы мисалында халкыбызның фаҗигага дучар булуын, киләчәк буынның юкка чыгу хәленә җиткәнен күрсәтеп бирә.

*Директорның нервысында тора*
*интектергән азу теше кебек.*
*Үз-үзенә урын таба алмый*
*хөкем ителгән бер кеше кебек.*
*Дәрес эзли. Сәгать, вакыт эзли.*
*Мәктәп буйлап эзли балаларын.*
*— Укысыннар! Тукай теле бит! — ди,*
*үгетләргә чыккан аналарын.*

Кадыйр Сибгатуллин — поэмалар жанрында да актив эшләгән киң колачлы, эпик карашлы шагыйрь. «Утлар» (1970), «Хыял» (1981), «Уел» (1983), «Каен жаны» (1985), «Туфан белән сөйләшү» (1986), «Зифа килен» (1987) поэмалары татар поэзиясендә лаеклы урын алдылар.

Татар халкының күренекле шагыйре К.Сибгатуллин 1994 елның 4 июнендә, Татарстан Язучылар берлегенең чираттагы корылтаеннан Чаллыга кайткан юлда йөрәге кинәт туктаудан вафат була. Кабере Балык Бистәсе районы Кече Укмас авылы зиратында.

К.Сибгатуллинның иҗатын барлау анын вафатыннан соң дәвам итә. 2002 елда «Мәйдан» журналының 2 нче саны тулысы белән шагыйрь иҗатына багышланып чыга. К.Сибгатуллин мирасын барлауда журнал редакциясе бер үзәккә әверелә. Хатыны Фәния Хамматованың шәхси хезмәте бәяләп бетергесез. Ул шагыйрьнең русча тәрҗемәдәге «Осенняя весна» (1999) һәм «Әйтте шагыйрь» (2002) шигырьләр җыентыгын әзерләп бастырып чыгара. Соңгысында К.Сибгатуллинның моңарчы дөнья күрмәгән, милли хисләр белән сугарылган, халыкның бәхетле булуына хаклы икәнен раслаган, өмет һәм ышаныч белән сугарылган шигырьләр урын алган. 2007 елда Татарстан китап нәшриятында шагыйрьнең «Бер ноктада» исемле күләмле җыентыгы басылып чыга. Чаллыда шагыйрь иҗатына багышланган республика күләмендәге фәнни-гамәли конференциянең (2007) зур уныш белән үтүен искәртергә кирәк. Конференция материаллары аерым җыентык булып дөнья күрә. Шул ук елны К.Сибгатуллин иҗатына багышланган беренче диссертация яклана, 2011 елда мәкалә авторының «Шигырьләрнең кирәк чагы» исемле монографиясе басылып

чыга. Р.Хәмидуллина, Ф.Хамматова тырышлыгы белән әдипнең биобиблиографик белешмәлеге дә укучыларга килеп ирешә.

Кадыйр Сибгатуллин ниндидер тәҗрибәләр белән мавыкмыйча, традицион юнәлештә иҗат итте. Шагыйрь буларак зур исем-дәрәҗәләр ала алмады һәм моның өчен елгырлык күрсәтеп йөрүчеләрдән дә түгел иде. Ул Татар Шагыйре дигән исем белән һәрчак горурланып, дәрәҗәсен белеп яшәде, иҗат итте һәм шигърият тарихында үзенең лаеклы урынын калдырды.

**Факил САФИН**

---

# Кадыйр Сибгатуллин

## Шигырь

**Уйларымны нидер сихерләгән,**
**бөтенләем белән сихерле.**
**Үземне үзем сихерләдем мәллә**
**сихерсез дип йөреп шигырьне?**

**Һәр тарафтан җырлар, моңнар килә.**
**Барысы да якын, илһамлы.**
**Әллә дөнья,**
**әллә үзем сәер,**
**аңлап бетерә алмыйм бу хәлне.**

**Гадиерәк бирәр нәрсә бармы?**
**Барысы да миңа илаһи.**
**Дөньяның бар ишекләрен ачып**
**алып керә шигырь,**
**и, даһи!**

**Уйларымны нидер сихерләгән,**
**уләмени кеше сихердән?**
**Авырырга да мөмкин,**
**терелергә дә,**
**үләргә дә мөмкин...**
**шигырьдән!**

## Кама ярларыннан эзлим сине

Кама буйларыннан эзлим сине,
дулкыннарга карап юксынам.
Шушы ярда сине тапкан идем,
озатып калдым сине шушыннан.

...Итәгенә басып таш ыргыттык,
ачуланып түгел, шаярып.
Йолдызларны санап, айга карап,
уйга талдык ярга таянып.

Яр буена ялгыз килеп бассам,
телгә килеп әйтер шикелле:
«Син берүзең йөрмә монда, егет,
мин күнеккән күреп икене».

Ташында да, соры комында да
юылмаган безнең эзләр бар.
...Кама ярларыннан эзлим сине,
мин дә китсәм, безне эзләр яр.

Кама ярларыннан эзлим сине,
дулкын өсләрендә күләгәң.
Мәхәббәтне юк диюче булса,
андый кеше сине күрмәгән!

* * *

Кешеләрнең барын танып йөрим,
таянганым бары — ышаныч.
Вакытым белән мин алар күк горур,
вакытым белән мин дә кызганыч.

Бер эшкә дә кайчак кулым җитми,
бар эштә дә ләкин хакым бар.
Башкалар күк мин дә йә гаепле,
башкалар күк мин дә хөкемдар.

Күрми диеп кайчак уйлыйлардыр,
кызганычка каршы күрәм мин.
Һәрбер туган белән туа торам,
һәрбер үлгән белән үләм мин.

Шуңа күрә мин бер бәхетледер,
үтмәгәнгә гомер әрнелеп.
Шуңа күрә, бөтен кеше кебек,
бу тормышта мин дә мәңгелек.



Зиннур
Мансуров

# ИЕЛГӘН БАШТА ТАҖ ТОРМАС

*Күпчелек каләм әһелләре көтмәгәндәрәк башына килгән төрле уй-фикерләрен көндәлек битләренә яки аерым кәгазь кисәгенә төртеп баручан. Минем үземдә дә бар андый «төрткеләр». Аларның берише йә шигырь, яисә мәкалә язганда файдаланыла. Вакытын көтеп яткэннары да тора-бара шактыйга җыела. Менә шулай теркәлеп килгән кыска күзәтүләремнең кайберләрен, кадерле укучым, синең хөкемгә дә тәкъдим итәргә җөрьәт кылам. Әлбәттә, фикердәшләр табуыма ихластан ышанам.*

**Автор**

I

• Нострадамус киләчәк турында түгел, ә үткәннәр хакында язып калдырган, чөнки анын әйткәннәре тарихның кабатланып торуыннан гына фаразлау кебек тоела.

• Тарихи мисаллар саклауга куелган яшелчә кебек – артык дәрәҗәдә чистарту аларны бозылуга китерә.

• Хәтер юганнан алтын чыкмас.

• Культуралы катламны кинрәк ачкан саен элек кылынган вәхшилекләр күбрәк күренә.

• Иелгән башта таж тормас.

• Яман атлы Шаһгали женси яктан кысыр булган, әмма анын токымы һәрбер заманда да яши.

• Үлеп яткан империянен гөнаһларын йолып алу өчен, галәттә, анын фидиягә бирердәй малы да калмый.

• Әгәр жинүчеләр – жиңелгән сугышчыларның каберлегең, ә жиңелүчеләр жингән сугышчыларның каберлеген мәсхәрәли икән, якын киләчәктә яңа зиратлар барлыкка килергә мөмкин.

• Тарихтан үзләренә кирәкле гыйбрәт алсын өчен кайбер иләмәннәрнең «арт сабагын» укытырга кирәк.

• Тәхетенә лжедмитрийлар күтәрелгән илдә алдау дәүләт дәрәҗәсенә куелыр.

• Дөньяда көчле затлар зәгыйфь затларга караганда азрак, әмма ана карап кешелек көчкә мохтаҗлык кичерми.

• Сугыш кораллары ясарга остарып киткән илнең яшәү тәртибен көйләргә маһирлыгы җитеп бетмәс.

• Чәнечкеле тимерчыбыктан гөслә кыллары ясап булмый.

• Русия инде күптәннән кан агучанлык — гемофилия авыруы белән сырхаулый.

• Ихтыярсыз аклар һәм кызылларга бүленгән ватандашларның бер-берсе белән сугышуы организмдагы ак һәм кызыл кан тәнчекләренең үзара көрәшенә охшый.

• Бөтенебез бердәй бәхетле, һәркем үзенчә бәхетсез.

• Репрессия елларында адреналин эшләп чыгару буенча Советлар Берлеге дөньяда беренче урынны тоткандыр.

• Үзенең халкын буыннан-буынга үчеккәндәй эзәрлекләп килгән хакимият йодрыгы белән күз яшьләрен сөртүче сабыйдан да шикләнә.

• Салкын сугышлардан сәясәтчеләр җылына.

• Кайчак зур эшләр башкарыр өчен өч тиенлек кенә акыл җитеп бетми.

• Төп Канунга сыешмаган хакимият, кабырчыксыз калган ташбакадай, котылгысыз рәвештә һәлакәткә бара.

• Казанның меңьеллыгын раслаган тәнкәгә беркайчан да девальвация янамаячак.

• Әгәр Мономах бүреген мәчеткә атсалар, аны күпләр кереп алырга тырышыр.

• Бездәй сибелгән халыкларның төгәл саны, мөгаен, Хисап көнендә генә мәгълүм булыр.

• Нобель бүләген дәгъвалаучылар арасында тынычлык өчен көрәшүчеләр иң зур күпчелекне тәшкил итә, әмма җирдә эреле-ваклы сугышларның әле бер генә көнгә дә тынып торганы юк.

• Үзләре өчен яшьли төрбә төзетү хәстәрен күргән «фани иләмән»нәр элгәреге җәмгыятькә кабер казыткан «үлемсез юлбашчы»ларга караганда күпкә зирәгрәк.

• Аш-су остасының итне тапаганын карап торсаң, бездәй кавемнәрнең кагылу-сугылуы күз алдына килә.

• Безнең баш миебез тулы куәтенә эшләсә, бәлки, ахмаклыклар тагын да күбрәк кылыныр иде.

• Яңа торгызылган Кол Шәриф мәчете тирәсендә, имеш, Кремль «гарнир» гына булып тоела башлады, дип хөсетләнүче бәндәләрдән сорыйсы килә: ә Иван Грозныйлар ашап куйган «котлет» элек ни рәвешле күренде икән соң?

• Монафикъ сәясәтчеләрнен «Сөекле халкым!» дип лаф оруы янгыраулы зал мөнбәреннән «...электоратым!» кебегрәк ишетелә.

• Шәһит киткәннәр фәрештәгә әверелгән очракта Аллаһнын безне яклардай илчеләре хәтсездер.

• Ил-йорт тәрәзәсендә тәре барлыгын шәйләсән, Ил-йорт күгендәге айны күрмәмешкә салынма.

• Сәясәтчеләр өчен дистәләрчә ел җирләнмичә яткан меңнәрчә сугышчыга караганда төрле илләрдә ыгы-зыгы тудырып торган бронза солдатлар күпкә кадерлерәк.

• Әгәр үзендә Чыңгыз хан оныгын күрәсең икән, димәк, синең канда Чыңгыз хан рәхәтләнеп ял итә.

• Бәгъзе татарларга дәүләткә ирешү нәтиҗәсе түгел, аны кемнәндер гозерләү барышы күбрәк ошый.

• Бернинди дә сәяси оешмада тормаучы затлар җирдә иң зур фиркане тәшкил итә.

• Иртән оекбашының уңын сул аякка бутап кигәнгә күрә, бездә дәүләт ирләренең еш кына очракта эше уңмый.

• Каешны ныграк будырткан дәүләт гәүдә зифалыгын түгел, ә билнең җинелрәк бөгелергә тиешлеген күздә тота.

• Сталин заманында ирекле шигырь дә үзен хокуксыз итеп тойган.

• Кабер төрлечә яшәп киткән бөкреләрне төзәйтеп яхшы эш башкара кебек, әмма аннан тураеп кайткан бериш бәндәләр барыбер игелек күрсәтмәс иде.

• Бер тамчы никотиннан үлүче атларны саклап калырга омтылу татар баласының фидаиларча тәмәке тарта башлавын аклый алмый.

• Каннибаллыкка каршы таш белән генә түгел, вегитарианнарча, аш белән дә көрәшү мөмкинлеге бирелгән.

• Сөт короле, тәэсирләнеп, Дәрдемәндне укый: «...Сөт калыр, ватан китәр! Сөт калыр, ватан китәр!..»

• Бездә ишек күбрәк ясалган саен керер тишек табу кыенлаша бара.

• Бүре законнарында «лазейка»лар булмый.

• Без еш кына җүкә майлау белән шөгыльләнәбез, шул рәвешле һәйбәт каеш ясаган булып кыланабыз.

• Хәшәрәт микробларны да эчәргә өйрәтсәк, спиртның тыйб эшендә кирәге калмас.

• Безнең динебез адәм балаларын чисталык-пакьлеккә өнди, әмма «акча юучылар»ны тәмуг белән кисәтә.

• Русиядә юллар юк, юнәлешләр генә бар, алары да зиратлар өстеннән үтә.

• Бездә чистартуга бәйле күпчелек гамәлләр пычракны тигезләп таратуга кайтып кала.

• Урыска зирәгрәк уйлар иртән килә, ә татарның акылы төштән соң.

• Бары бер эшсезлек кенә кешелек өчен файдалы — Аллаһ рәхмәте белән Исрафилның сур өрергә ашыкмавы.

• Үткән хакимлек чорын еш сүгәргә яратсак та, ул заманда яшәлгән гомерне сызып ташлап булмый.

• Һәрбер тотрыклылык эчендә торгынлык яшеренеп ята.

• Бездә Аллаһ биргән газны да чит илләргә гаугасыз сата белмиләр.

• Табигать бәла-казасы вакытында электр үткәргечләр өзелсә, электрон хөкүмәт берни дә эшли алмый.

• Жирдә бихисап фажигаләргә сәбәп булган кеше факторы Жирнең үзен дә һәлакәткә алып бара.

• Тиктормас сыерны аякларын бәйләп саву горур кавемне ирексезләп савудан әхлаклырак.

• Культурасы түбән илдә коррупция хәтәррәк булучан.

• Ышанучан беркатлы гавам финанс пирамидаларына лаек.

• Залимлек хакимиятенең чыгыры кан-яшь белән майлана.

• Дәрәжәле житәкчеләр килер алдыннан урам-йортлар, тераkттан соң чиновниклар сафы чистартыла.

• Милләтне «эретү казаны»на бүлгәләп салу жайлырак.

• Хужалар тавы түбәсенә күтәрелгәч, мәхрүмлек офыклары ачыграк күренә.

• Иманасын саткан салым түләр, Ил-анасын саткан калым даулар.

• Кансызлар кан түгүчән.

• Инсаннар катнашында үткәрелә торган реформаларга караганда тычканнар белән уздырылган тәжрибәләр уңышлырак төгәлләнә.

• Тырма уйлап табучының рухы тыныч булсын — кеше кыяматкәчә ошбу коралга кат-кат басачак.

• Бездә таяк ике генә түгел, ә элек-электән күбрәк башлы булган.

• Татарның кайвакыт артык дәрәжәдә тырышып гамәл кылуы үзенең капкасына туп керткән кебек килеп чыга.

• Гәрчә кыямәт көне житмәсә дә, газиз милләтеннең авызы мөһерләнергә мөмкин.

• Безнең жәмгыятьтә зоологлар тартарны арттырып, антропологлар татарны киметеп күрсәтергә тырыша.

• Авыз шәрифендәге телне күзәнәктән дә үстереп булыр, әмма милләт телен янадан яралту мөмкин түгел.

• Совет чоры телевизорлары асылда аклы-каралы сурәтләр генә күрсәтсә дә, ил тормышы чынлыкта башка табигый төсләргә дә бай булган.

• Конституция – халык укымый торган китап.

• Илбасар яулап алынган жирне үзенеке итеп саный башлый, янәсе, ул шушы туфракка үзендә аккан ата-баба канын койган.

• Милли мәнфәгатьләр белән ихтыярлы-ихтыярсыз рәвештә сату итүләр дәүләтчелекне җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять дәрәҗәсенә төшерергә мөмкин.

• Югары даирәдәге «сәяси мәет»ләрне исәпкә алсан, илдәге үлем-китем саны артып китәр иде.

• Руханә бай хакимнәр ил-атны фәкыйрьлектә тотмый.

• Кризис безнен якларга килеп житә алмый, чөнки йөри торган юлларыбыз бик начар.

• Мәчет, чиркәү, костел, синагогаише биналарнын бер-берсе белән бәрелешкәне юк, ә аларны тотучы руханиларның үзара маңгайга маңгай килүе байтак булган.

• Карло атакай түмәрдән бөтен дөньяның сөеклесенә әйләнәчәк Буратиноны гына юнып калмаган, анын озак яшәве өчен әйләнешкә агач акчалар кертеп жибәрергә дә өлгергән.

• Бездә кешенен үз иленә хыянәт итүе һичшиксез гаепләнә, дәүләтнен үз халкына хыянәт итүе мәккәмә хөкеменә житкерелми.

• Үз илендә пәйгамбәр булыр иде, әмма үз дәүләте генә юк.

• Вакыт үлчәү берәмлеген билгеләүдә уртак фикергә килә белгән дөнья башка мәсьәләләр буенча ел әйләнәсендә сүз көрәштерүдән туктый алмый.

• «Марста тереклек бармы?» дип галәми кинлектә кызыксынган халыкны «Казылыкта ит бармы?» дигән сорау да борчырга мөмкин.

• Әгәр урамнарга ишелеп яуган ак-пакь кардан афәт ясамасак, шәһәр кышы белән һәркем Такташча хозурланып йөрер иде.

• Су анасына ышанмаган бәндәләр елгаларны кибүгә дучар итә.

• Читлектә туып-үскән очар кош ирекнен нәрсә икәнен белмәс.

• Гап-гади кендек әбисе шикелле, кирәкле вакытта кирәкле урында булырга өлгерсәк, игелекле гамәлләребез ишәеп китәр.

• Мисыр пирамидалары белән финанс пирамидалары арасында охшашлык-аерымлык шунда: аларны төзү өчен коллар көче файдаланылган; беренчеләре чиксез сокландыра, икенчеләре чиксез гажәпләндерә.

• Тарих агышы кабатланып тора икән, димәк, анын хаталары да әйләнеп кайта.

• Залимнәр тешле булып туучан.

• Илдән качып китсән дә, жиргә чәчеп китәргә кирәк.

• Читлектәге тутый кош «Азатлык!» дип бертуктаусыз кычкырып утырырга мөмкин, әмма ирек яулап алу өчен анлы ижтиһат таләп ителә.

• Әгәр хатын-кыз бер ирне генә булса да зур итәргә алынса, тулаем илне хур итә торган гамәлләр бездә азрак кылыныр иде.

• Сөембикә манарасы чынлыкта туры килеш торадыр, безнең дөнья гына бераз авышып киткәндер.

• Пычрак шөгыль булуга карамастан, күпләребез күрәләтә сәясәткә тартыла.

• Изге саналган әйберне шаһитлеккә чакырып әйтелгән вәгъдә сүзе, әйтик, Изге Китапка кулны куеп ант итү ныграк була.

• Милли тавыктан да тәре эзе кала.

• Күп кенә илләрнең хөкүмәтләрендә балык министрлыгы бар, ә менә халык (ягъни милләт) министрлыгы юк.

• Үзгәртеп кору чорының мәдәнияте юксыллык шартларында бетле киемне үтүкләп кию гажизлеген хәтерләтә.

• Өлкән буын вәкилләре үткән заман режимнарын түгел, ә үзләренең яшьрәк чакларын гына сагына.

• «Ватанның төтене дә татлы вә хуш безгә», дип сокланган якташыбыз Гавриил Державин бүгенге заман шартларында мондый мәдхияләр белән дөреслеккә хилафлык китерергә теләмәс иде: һәркайда да татлы вә хуш түгел инде хәзер Ватан төтене.

• Авызга су салырлык миһербанлы затлар азайган саен халык өстенә суаткыч белән ташланучы җантимерләр күбәер.

* Аллаһ адәмнәрне матурлык нигъмәтеннән аермаса, дөньяны матурлык коткарып калырга мөмкин.

---

## *«Казан утлары»на – 90*

### «Безнең юл»

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ

(1887-1938)



Татар халкының классик әдибе, күренекле җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов, Татарстан автономияле республикасы төзелүнең беренче көннәреннән алып, 1927 елга кадәр җөмһүрияттәге иҗтимагый-мәдәни тормышны һәм әдәби хәрәкәтне әйдәп бара. 1922 елның май аенда «Безнең юл» журналы да аның инициативасы белән чыга башлый. Ул – татар совет матбугатын нигезләүдә һәм оештыруда нәтиҗәле хезмәт куйган шәхесләрнең иң күренеклеләреннән.

Журнал тиз арада җәмәгатьчелекнең яраткан басмасына әверелә. Ул елларда әле язучыларны берләштергән оешмалар булмый. «Безнең юл» исә, төрле юнәлештә иҗат итүче күпсанлы әдипләрне һәм галимнәрне туплаучы бер үзәккә әйләнә.

1925 елда Галимҗан Ибраһимов «Безнең юл» журналын чыгаруда турыдан-туры катнаша: Татарстан Гыйльми Үзәк рәисе вазыйфасын башкарган әдип журналның алтынчы санын редакцион коллегия рәисе буларак чыгаруда катнаша.

# М

**МОДЕРНИЗМ**, 20 йөз башы әдәбият һәм сәнгатьтәге «сул» агымнарның (кубизм, сюрреализм, футуризм, экспрессионизм, символизм, орфизм, фовизм, пуризм һ.б.) барысын берләштергән иҗат юнәлеше. Киңрәк мәгънәдә — 19 йөз-20 йөз уртасы чоры сәнгатенең тарихи чоры.

Әдәби М.ның төп үзенчәлекләре — классик сәнгатьнең гармониягә ия булган формаларына каршы чыгып, яңа формалар тудырырга омтылу, ассызыкланган шартлылык, чынбарлыкны сәнгати дәрәҗәдә бозып үзгәртү, мәгънәләр б-н уйнау, дөнья һәм кеше турында төп, бәхәссез дөреслекнең (хакыйкать) юклыгын раслау. М.ның төп темалары — шәхеснең яшәештәге урынын идея һәм сәнгати чаралар ярдәмендә эзләү һәм бу мәсьәләне гаклый хәл итүгә ышанычның югалуы. М. агымнары сәнгатькә яшәешнең яшерен серләренә ишек ача торган гыйлем итеп карый. Тормышны кабул итү, матурлыкны изгеләштерү модернның төп сыйфатына әйләнә.

Татар әдәбиятына модернистик сурәт тудыру омтылышлары 20 йөз башында керә башлый. Модернистик тәҗрибәләрне үзләштерүгә һәм иҗади төшенүгә татар әдәбиятының тамырлары шәрекъка барып тоташу ярдәм итә. Ш.у. фәлсәфи-эстетик нигезләре символизмга һәм экзистенциаль фәлсәфәгә якын буларак суфичылык мәдәнияте традицияләре модернизм б-н авазлаш тоела. Модернистик стильләрнең реализм һәм романтизм б-н синтезлашуы аеруча Ф.Әмирхан, Ш.Камал, Н.Думави, Г.Ибраһимов, С.Рәмиев, Ш.Бабич һ.б. иҗатында үзен нык сиздерә.

1906-08 елларда Дәрдемәнд, 1920-30 елларда Һ.Такташ иҗатларында символизмның фәлсәфәсе һәм эстетикасы оеша башлый. 1910 елларда проза һәм лиро-эпикада реалистик һәм мифологик, романтик һәм мифологик, шартлы-лирик һәм тарихи катламнарның мәдәни синтезы барлыкка килә. Бу синтезның үзәген символ-идея, яки символ-проблема тәшкил итә (Ф.Әмирханның «Татар кызы», М.Хәнәфинең «Айсылу», Б.Мансурның «Татар егете», Г.Рәхимнең «Хан мәчетендә», М.Гафуриның «Бу кемнең кабере?», «Бер чәчәкнең наләсе» әсәрләре). Татар язучыларын аеруча экзистенциализм фәлсәфәсе (кеше табигатенең камил булмавы, төп мотив буларак, җир тормышының фанилыгын раслый) үзенә тарта. М.Гафуриның «Болгар кызы Айсылу», Ф.Әмирханның «Бер хәрабәдә», М.Хәнәфинең «Милләтем», «Тегеннән», «Гөл бакчасында», Г.Газизнең «Бер хыял» әсәрләрендә тормыш куркыныч һәм акылдан язган «кара көчләр патшалыгы» кебек тасвирлана. Г.Газизнең «Юлдаш эзләгәндә», М.Хәнәфинең «Кайдан? Кайда!», Г.Насрыйның «Мазарстанда» хикәяләрендә кеше тормышы бертуктаусыз көнкүреш ваклыкларыннан качу итеп аңлатыла. Саф импрессионистик характердагы хикәяләр дә языла (кара Импрессионизм), мәсәлән, Г.Исхакыйның «Бер манзара», Фәйзи Вәлиевнең «Көймәдә» һ.б. 20 йөз башында экспрессионизм С.Рәмиев, Н.Думави, Б.Мирзанов һ.б. лирикасы һәм лиро-эпикасында да күзәтелә башлый. 1920-30 елларда Һ.Такташ, К.Нәҗми, Г.Кутуй, Н.Исәнбәт һ.б. иҗатларында исә аеруча зур үсеш ала. Рус әдәбиятындагы кебек артык көчле тәэсир итәрлек сәнгать б-н мавыгу 1920 елларда футуризм (Г.Кутуй) һәм имажинизмнарны (К.Нәҗми) барлыкка китерде. 1930 елларда татар әдәбиятында М. үсеше озакка тоткарлана. 1980 еллардан башлап ул яңадан активлаша, постмодернизм (Ф.Бәйрәмова, З.Хәким, Г.Гыйльманов, Н.Гыйматдинова, М.Гыйләҗев һ.б.) элементлары б-н баетыла. Сынлы сәнгатьтә М. төп үзенчәлекләре — әсәрләрдә тормышны соңгы чиккә кадәр җиткереп каралту яки тормышны үзенә охшатып кабатлаудан тулысынча баш тарту. Аларда, гадәттәгечә, басым сәнгати формага ясала. Форма исә сәнгать әсәренең асылы итеп кабул ителә һәм аның эчтәлегенә тәңгәл була. Футуризм, конструктивизм, абстракт сәнгать стиль үзенчәлекләрен үз эченә алган авангард сәнгатьне модернистик сәнгать дип карап, М.ны еш кына аван-

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынннан басылып килә.*

гардизмга тинлиләр.

Татарстан сынлы сәнгатендә кайбер модернистик агымнарның (кубофутуризм, экспрессионизм, абстракционизм) сыйфатлары 1910 еллар ахырында – 1920 еллар башында «Көнбагыш» («Подсолнечник») (К.К.Чеботарёв, А.Г.Платунова, И.А.Никитин, Д.П.Мощевитин, И.И.Алпатов, Василий Вера (В.Попов), Н.Диомиди (Н.И.Михайлов), П.М.Зотов, Г.И.Потапов, Г.П.Соловьёв-Озеров, Д.М.Фёдоров) төркеме рәссамнары һәм 1920-23 елларда эшләп килгән «Жайдак» («Всадник») графиклар төркеме иҗатларында барлыкка килә. Ике төркем дә 1920 елларда С.С.Фёдоров һәм П.А.Мансуров абстракцияле рәсем сәнгатен укыткан АРХУТЕМАСта (Казан архитектура-сәнгати һөнәрханәләр, 1918-25) оешa. Авангард сәнгатенен башында бу чорда ш.у. ТатЛЕФ (К.К.Чеботарёв, А.Г.Платунова, М.В.Барашов, С.Хромов, А.Н.Кашаев) рәссамнары да була. ТатЛЕВка татар мәдәнияте эшлеклеләреннән торган «Сулф» («Сул фронт») төркеме дә керә; оештыручыларның берсе – ТатЛЕФның президиум әгъзасы, татар полиграфикасына нигез салучы Ф.Ш.Таһиров була. Әсәрләрендә конструктивизм алымнарын (фотомонтаж) файдаланып, татар авангарды тарихында ул якты эз калдырды. Алга таба, 1960 еллар урталарына кадәр Татарстан сынлы сәнгатендә модернистик юнәлешләр үсми. 1960 елларда модернистик юнәлешне сынлы сәнгатьтә А.А.Аникеёнок, Р.А.Килдебәков дәвам иттерә. 1970 елларда экспрессионизм чалымнары В.П.Аршинов, Н.У.Әлмиев графикасында гәүдәләнеш таба; И.К.Зарипов иҗатында халык сәнгате традицияләренә модернистик рәвештә янадан төшенү (неопримитивизм) күзәтелә. 1990 елларда аерым модернистик агымнар кинрәк таралыш ала. Абстракционизм традицияләре эзлекле рәвештә З.М.Миннеәхмәтов (Алабуга ш.), Р.К.Нәфыйков (Казан), сюрреализм – В.Я.Акимов, Ю.Г.Свинин (Чаллы ш.) иҗатларында чагыла. Казан рәссамнары Е.Г.Голубцов, А.И.Дорофеев, А.М.Артамонов, И.А.Хәсәнов, И.В.Гыймранов, А.Р.Ильясова, Р.А.Сәлихов әсәрләрендә төрле модернистик агымнарның стиль үзенчәлекләре постмодернизм контекстында күзәтелә.

Әд.: Сарабьянов Д.В. Стиль модерн: Истоки. История. Проблемы. М., 1989; Саяпова А.М. Дардменд и проблема символизма в татарской литературе начала XX века. К., 1998; Теория литературы. Литературный процесс. М., 2001. Т.4; Нигматуллина Ю.Г. «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. К., 2002; АРХУМАС: Казанский авангард 1920-х. М., 2005; Заһидуллина Д.Ф. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. К., 2003.

*Д.Ф.Заһидуллина, Г.Р.Фәйзрахманова.*

**МОРТАЗА бине ГАДЕЛГАЗИЗ бине БИКМӨХӘММӘТ** (18 йөз башы, Уфа өязе Казан даругасы Каратай а. – 1797, Казан), дин эшлеклесе, язучы. Кышкар мәдрәсәсендә белем ала. Казанда имамхатыйп булып тора. «Нигъмәтулла» (1754) исемле дини-дидактик китап авторы.

Әд.: Фәхреддин Р. Асар. Оренбург, 1901. 2 җөзья.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**МОРТАЗА бине МОСТАФА** (19 йөз), шагыйрь. Фольклор-әкияти мотивлар реаль тормыш күренешләре б-н уралып барган «Хәзрәти Зөлкарнәйн Дахма Шаһанга барганлары кыйссасы» (1889) дастаны авторы. Әсәрнең төп герое Искәндәр (Александр Македонский) шаһлар (Фирдәүсинең «Шаһнамә» поэмасы геройлары) каберлегенә сәяхәт кыла. Кара көчләрнең каршы торуын җинеп чыгып, ул шаһларның юлламалары сакланган табутлар янына үтеп керә. Ул юлламаларда түрәләр үзләренең гаделсез яшәгәннәренә, фәкыйрь һәм ярлыларны кайгыртмаганнарына, үзләре башлаган сугышлар халыкка бәла-каза китергәне өчен үкенә.

Әд.: Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 том.

*А.М.Ахунов.*

**МОСТАФИН Вил Сәлах улы** (3.5.1935, Казан – 16.9.2009, ш.у.), шагыйрь. Рус телендә яза. Казан ун-тын тәмамлый (1958). 1960-65 елларда Казан авиация ин-тының югары математика кафедрасы ассистенты. 1965-77 елларда Хисаплау техникасын халык хуҗалыгында куллану ин-тында (ГНИПИ ВТ) эшли; 1977-81 елларда АСУ бүлеге мөдире, 1981-86 елларда Казан исәпләү үзәге директорының проектлар ясау буенча урынбасары; 1986-89 елларда Автомобильләр транспорты АСУ фәнни-тикшеренү проект ин-тының директор урынбасары; 1990-92 елларда «Сигнал» предприятиесе директоры. Фәнни хезмәтләре гамәли математикага карый. Әдәби иҗат б-н 1960 еллардан бирле шөгыльләнә. «Беренче тапкыр яшим» («Живу впервые», 1997), «Көндезге төшләр һәм төнне йокысыз үткәрүләр» («Дневные сны и ночные бдения», 1998), «Зираттагы әңгәмәләр» («Беседы на по-

госте», 2000), «Шигырь турында шигырь» («Стихи о стихах», 2002), «Сонет вариацияләре» («Сонетные вариации», 2002). Анын поэзиясе шәхеснең киеренке рухи эзләнүләрен, аның җәмгыять б-н булган каршылыклы элемтәләрен чагылдыра. 1999 елдан Россия Язучылар берлегенең Казан оешмасын җитәкли.

Әд.: Кутуй Р. Вдох-выдох // Идель. 1990. №4.

**МОСТАФИН Җәмил Мостафа улы** (20.5.1927, Башкортстан АССР Чишмәле р-ны Усман а. туа), язучы, Башкортстан АССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1991). Рус телендә иҗат итә. Хәрби (Ленинград, 1950) һәм Әдәбият (Мәскәү, 1962) ин-тларын тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген 1942 елда Тайшет шәһ.дә Көнч. Себер тимер юлының механика мастерскойларында башлый. 1950-54 тә Порт-Артур шәһ. дә (Кытай) хәрби-дингез базасында хезмәт итә. «Спортивная жизнь России» (1960-61), «Юный техник» (1961-63) ж-лларында җаваплы сәркатип, «Советская Россия» (1964-71) нәшриятында мөхәррир булып эшли. 1971-90 (бүленеп) СССР Язучылар берлегендә. Беренче хикәяләре 1951 елда «Порт-артурец» газетасында басылып чыга. Әсәрләренә лиризм хас, гуманлылык, гражданлык хисләре белән сугарылган. Аның «Янканский перевал» («Янкан сырты»,М., 1964), «Суровое детство» («Кырыс балачак», 1968), «Сибирское чудо» («Себер могҗизасы», М., 1972), «Живые льды» («Тере бозлар», М., 1976) повестьлары Себер тайгаларында үткәргән балачак һәм үсмерчак хатирәләренә, шәхес культы чорының авыр иҗтимагый-сәяси атмосферасын, репрессия һәм сугыш шартларында кешеләрнең аянычлы язмышларын, аларның рухи ныклыгын, яшәргә омтылышын сурәтләүгә багышланган. «Дикарка» («Кыргый», 1967), «Голубая лошадь» («Зәңгәр ат», 1971) хикәяләрендә геройлар характеры хайваннарга карата мөнәсәбәт аркылы ачыла. «Мост» («Күпер», М.,1975) повесте һәм «Дорога» («Юл», М., 1985; 2 басма 1989) романы Байкал-Амур магистрален төзүчеләр тормышыннан алып язылган. «Балалаечник» («Балалайкачы», М., 2002) дип аталган повестенда беренче мәхәббәт турында хикәяләнә. М.ның әсәрләре кыска һәм ачык, үтә тәэсирле һәм ихласлыгы белән аерылып тора. Ул татар язучыларыннан Г.Ахунов, Г.Бәширов, А.Гыйләҗев, башкорт язучыларыннан И.Абдуллин, Т.Ахунҗанов, Д.Бүләков әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итә. ВЦСПС һәм СССР Язучылар берлеге (1972), ВЛКСМ ҮК һәм СССР Госкомиздат (1972) премияләре лауреаты. «Почет Билгесе», «Алтын Йолдыз», «Дуслык» (Кытай) орденнары, медальләр белән бүләкләнгән.

Әсәр.: Шайтан. Уфа. 2000.

*Г.М.Габделхакова.*

**МОСТАФИН Камил Әхмәди улы** (26.11.1932, г.Зеленодольск — 30.9.2009, Чиләбе өлкәсе, Снежинск ш.), математик, шагыйрь, физ.-мат. фәннәре канд. (1995). 1956 да Казан ун-тын тәмамлаганнан соң Е.И.Забабахин исемендәге Бөтенрос. техник физика фәнни-тикшеренү ин-тының Россия федераль атом-төш үзәгендә (Чиләбе өлкәсе, Снежинск ш.) сектор җитәкчесе (1990 нан соң), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2004 тән) булып эшли. Хезмәтләре гамәли математика, ике үлчәмле системаларда атом-төш физикасының процессларын модельләштерүгә карый. Математик модельләштерү өчен методика һәм программа, ш.у. махсус техника эшләнмәләренең исәпләнгән дәлилләрен эшли. Энергетика өлкәсендәге теоретик хезмәтләр комплексы өчен СССР ның Дәүләт премиясенә (1991) лаек була.

М.ның беренче шигырьләре Казан, Чиләбе, Свердловскида (хәзерге Екатеринбург) чыга торган матбугат битләрендә 1956 да күренә башлый. Аның шигъри дөньясының асылын яхшының яман б-н көрәше, Ватанга мөнәсәбәт, мәхәббәт мотивлары тәшкил итә. «Жыр сафка чакыра» (1966), «Ачкыч» («Ключ», Чиләбе, 1971), «Горур ташлар» (1972), «Июнь таңнары» («Июньские ночи», Чиләбе, 1975), «Хыял кошы» (1984) h.б. шигъри җыентыклар авторы. Татар теленә М.Ю.Лермонтов, В.В.Маяковский, С.И.Чекмарёв h.б. шигырьләрен тәрҗемә итә. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Численные расчёты термоядерной детонации в плотной плазме // Физика плазмы. 1984. Т. 10, вып. 3 (соавт.); Computation optimization of indirect-driven target for ignition and the engineering fest facility // Lazer and Particle Beame. 1997. V. 15, №1 (соавт.).

Әд: Мустафин Р. Сто первое чудо // Образ времени: Статьи. К., 1981.

*Р.Р.Мусабәкова.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Колгына

Колгына авылы Апас районында, район үзәге Апас авылыннан 15 чакрым, җирле үзидарә советы үзәге Дәвештән – 3, Килдураз тимер юл станциясеннән – 2, Тәтеш пристаненнән 46 чакрым ераклыкта урнашкан.

Атама тарихи чыганакларда, белешмәләрдә шактый искә алына. Авыл Казан ханлыгы чоры авылларын барлау исемлегенә теркәлгән.

XVIII йөз мәгълүматларын үз эченә туплаган тарихи белешмәдә (Д.А.Корсаков төзегән) күрсәтелгәнчә, Зөя суы ярына утырган Колгына авылында 45 йомышлы һәм 1 керәшен татары яшәгән. А.Артемьев мәгълүматларына караганда, Зөя суы ярына урнашкан Колгына авылындагы 62 хуҗалыкта 165 ир-ат һәм 184 хатын-кыз көн күргән, мәчет эшләгән.

1898 елда басылып чыккан белешмәдә Колгынада татарлар яшәгәнлеге күрсәтелә. К.П.Берстель җыеп чыгарган белешмәдә билгеләгәнчә, авылда 624 татар кешесе көн күргән.

Н.Б.Борһанова мәгълүматларына караганда, Колгына авылы халкы май ае ахырында күршедәге Өчмунча, Үгез куагы, Кабалан, Кузби, Дәвеш, Килдураз авыллары белән Кәлти җыенын бәйрәм иткән.

Авыл атамасының барлыкка килүен олы буын болай сөйли.

Күрше Коллар авылыннан монда бер кол килеп утырган. Ул берүзе генә булганга, авылны Кол + гына дип атаганнар. Билгеле, бу фараз халык этимологиясенә корылган.

Атамасы бераз сәеррәк булса да, авылның табигате, урнашкан урыны бик матур.

Аның ике ягында да күл бар. Берсе – Кызыл Яр, икенчесе Камышлы дип атала. Икесендә дә камышлар үсеп утыра. Җәй көне биредә балалар су коена, каз-үрдәкләр өчен дә бу күлләр бик җайлы.

Авылдан ерак түгел нарат урманы башланып китә. Бу урын бик ямьле. Тикмәгә генә «Зөя» лагере, «Зөя» санаторие шушы урман буена урнашмагандыр. Ә лагерь һәм санаторий яныннан ук Зөя елгасы ага. Зөя аръягында Кыз тавы, Каравыл тавы бар. Кыз тавының исеме, авыл халкы хәтерендә сакланган хатирәләргә караганда, болай килеп чыккан. Имеш, анда алтын сандыкта бер бай кызы күмелгән. Тауның әкияттәгедәй бер тишеге дә бар, әмма ул тишектән керергә әле берәүнең дә җөрьәт иткәне юк икән.

Таулардан соң кабат катнаш урман башлана.

---

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

Авылда изгеләр зираты бар. Халык аны Ташбилге зираты дип йөри. Авылның олылары, ак әбиләр һәм ак бабайлар зиратка барып Коръән укый, әби-бабайлар рухына дога кылалар. Яңа зиратны да, изгеләр зиратын да авыл халкы карап һәм тәрбияләп тора.

## Тутай

Тутай авылы Апас районында, район үзәге Апас авылыннан 32 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Кызыл Тау авылыннан – 3, Килдураз тимер юл станциясеннән – 17, Тәтештән 71 чакрым ераклыкта урнашкан.

Тутай атамасы тарихи белешмәләрдә шактый кулланыла.

Д.А.Корсаков чыгарган тарихи белешмәдән күренгәнчә, Тутай авылында ясак түли торган 69 татар кешесе һәм 9 керәшен татары яшәгән. Шул ук номер астында Атабай авылы күрсәтелә, анда 10 йомышлы татар көн иткән.

1859 ел мәгълүматларын эченә алган тарихи белешмәдә авыл Тутай Атабай (Тутаево Атабаево) дип бирелгән, андагы 90 хуҗалыкта 282 ир-ат һәм 276 хатын-кыз яшәгән. Авылда мәчет эшләгән. 1898 елда басылып чыккан тарихи белешмәдә Тутай һәм Тукбирде авылларында татарлар яшәгәнлеге күрсәтелә. К.П.Берстель мәгълүматларыннан күренгәнчә, Тутай авылында 692 татар кешесе көн иткән.

Нажия Борһанова Тутай авылы халкы күршедәге Югары Балтай, Урта Балтай, Түбән Балтай, Зур Бакырчы, Кече Бакырчы, Кара Борнаш, Чирү, Каратун, Колчык, Көлкәш, Чирмешән, Чәтбаш, Кызыл Тау (Коллар), Шәмәк, Күкшем, Аксу, Дәүләки, Багыш халкы белән Кушкапка җыены үткәргән дип яза.

Авыл оешу турында өлкән буын болай сөйли. Аның элекке урыны хәзергесеннән 2 чакрым түбәндәрәк Бола суы ярында булган. Рус гаскәрләре Казан ханлыгын җимергәннән соң, Тутай янына килеп урнашкан рус авыллары (Кукау, Чыпчык) кешеләре татарларны кыерсыта башлый. Татарлар бу хәлгә озак чыдап тормый һәм авылны хәзерге урынына күчерәләр. Иң беренче булып Тутый исемле әби күчеп утырган. Вакытлар узгач Тутый исеме Тутайга әйләнгән.

Тутай авылы халкы Чабыр җыены үткәрүдә катнашкан. Бу җыен бик борынгы һәм абруйлы җыен булган.

Авыл янындагы Изге зиратны аерым әйтеп китик. Ул елга буендагы Каеннар арасы тавы өстенә урнашкан. Халык аның изге урын икәнен белә, шуна күрә ул урын сукаланмаган.

Авылда бик матур болын да булган. Болыннарны бетергән, сукалаган игелексез елларда бу болынны да сөреп ташлаганнар. Хәзер анда чөгендер утырталар. Унуы чамалы гына.

Тутай авылы миңа бик кадерле. Һәрберебез яраткан композитор Сара Садыйкова шушы авыл белән бәйләнешле. Сара апа Казанда туып-үсә. Ләкин әнисе Бибигайшә апаның әтисе Тутайда туып-үсеп, Казанга күчеп килеп, пристаньда пароходлар йөртү эшендә диспетчер кебегрәк казна хезмәтен үтәүче Әхмәдиша абый була.

1989 елда Сара апага Тукай бүләге бирелде. Ләкин бу бүләккә ул үзе исән вакытта ирешә алмады. Тутайда яраткан композиторыбызга багышлап ачылган музей эшли. Музей хезмәткәрләре Сара апа белән бәйләнешле экспонатларны кадерләп җыялар һәм саклыйлар, һәр елны аңа багышлап кичәләр уздыралар, һәр сөйләнгән сүз аңа дога булып бара.

## Шәмәк

Шәмәк авылы Апас районында, район үзәге Апас авылыннан 23 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Урта Балтайдан – 4, Каратун станциясеннән – 11, Тәтеш пристаненнән 59 чакрым ераклыкта урнашкан.

Шәмәк атамасы шактый тарихи чыганакларда очрый.

Шәмәк авылы Казан ханлыгы чорында яшәгән авыллар исемлегендә беркетелеп калган.

Д.А.Корсаков белешмәсендә күрсәтелгәнчә, Шәмәк авылында 185 йомышлы һәм 3 керәшен татары көн күргән.

1898 елда басылып чыккан белешмәдә Шәмәк-Ямбакты авылында татарлар яшәве

искәртелә. К.П.Берстель белешмәсендә авыл Шәмәк-Ямбакты дип искә алына һәм анда 1018 татар көн иткәнлеге күрсәтелә.

Олылар сөйләве буенча, Шәмәк авылына атама бирү шактый үзенчәлекле булган.

Авылга исем кушу өчен йөгерү ярышы оештырырга уйлыйлар. Кем алдан килә, авыл шуның исеме белән аталачак дип вәгъдә итәләр. Йөгерешүчеләр арасындагы Шәмәк исемле кеше беренче килә алмаслыгын сизеп, мәйданга бүреген ыргыта. Ул үзе килеп житкәнче аның бүреге мәйданга килеп төшә. Бүрекнең Шәмәкнеке икенен белеп, авылга Шәмәк исеме кушканнар.

Авыл тигез жиргә урнашкан. Янында күл бар, элек ул түм-түгәрәк, тирә-ягы ямь-яшел үлән һәм агачлык, үзе тирән булган. Анда хәтта кешеләр батып үлү очраклары да булгалаган. Хәзер ул саеккан, тирә-яктагы яшеллеге дә беткән. Авыл янында бернича чокыр бар. Аларны Урта чокыр, Атау чокыры һәм Кирәмәт чокыры дип йөртәләр. Кирәмәт чокыры тирәсендә итәк-жиңеңне жыеп йөрмәсәң, кешегә зыяны да тияргә мөмкин дип сөйлиләр. Авыл янында гына болын жәелеп ята. Аны урталай бүлеп Бола суы ага. Бола янында Урта куаклык урнашкан. Аны печәнлек дип тә, көтүлек дип тә әйтәләр.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

---

## *Казан утлары»на – 90*

### «Безнең юл»

ГАСЫЙМ МАНСУРОВ

(1984-1955)



Тарихчы, журналист, педагог, жәмәгать эшлеклесе. Үткән гасырның 20-30 елларында Татарстанда, Мәскәүдә, Төркестанда югары дәрәҗәдәге дәүләти вазыйфалар башкара: Төркестан АССРның җинаятьчелеккә каршы көрәш идарәсе җитәкчесе, ТАССР ХКС рәисе урынбасары, Мәскәүдәге Шәрекъ халыклары этник мәдәнияте институты профессоры. Төп хезмәтләре татарларның милли хәрәкәте тарихына карый. «Беренче революциядә татарлар» китабы (Мәскәү, 1926) авторы. 1931 елда репрессияләнә, 1941 елда азат ителә.

Гасыйм Мансуров – «Безнең юл» журналының беренче җаваплы мөхәррире (1922-23 еллар).

*Хөрмәтле баш мөхәррир Равил әфәнде!*
*Рәфикъ Юнисның «Берләшик!» исемле мәкаләсе белән килешеп үк бетмичә, минә шушы җавапны язарга булдым һәм, дөньяга чыгуына әлләни өметләнмәсәм дә, Сезгә җибәреп карыйм. Мәшәкатьләвем өчен гафу сорыйм.*

**Р.ШӘРӘФИЕВ**
*Сентябрь, 2011 ел.*

# КЕМ БЕЛӘН БЕРЛӘШИК, РӘФИКЪ ЮНЫС?

АЧЫК ХАТ

«Казан утлары» журналында Рәфикъ Юнысның «Берләшик!» исемле язмасы басылып чыгудан соң байтак вакыт узса да (2011 елның июнь саны), аны хуплап та, авторга каршы килеп тә фикер белдерүче күренмәде (Интернетта яшерен исем белән чыккан репликалар исәпкә керми). Хәер, «берләшик!» дигән чакыруга кайсыбыз гына каршы килер икән? Күп бәлаләребезнең бердәмлек җитмәүдән килеп чыгуын беләбез ләбаса. Кемгә кем белән һәм нинди максат өчен берләшергә — мәсьәлә шунда гына. Хокукларыбыз, байлыгыбыз, җәмгыятьтәге урын-дәрәҗәләребез, максатларыбыз һәм карашларыбыз гына дип әйтмим, хәтта татарлыгыбыз да төрле-төрле бит инде, бу каршылыкларны ничекләр генә җиңәргә соң?

Сезнең язмада, Рәфикъ Юныс, моңа җавап бар да кебек: «бер-беребезнең ялгыш фикерен иплләп кенә кире кагарга» да татулашырга чакырасыз. Болай җиңел генә үзе. Ләкин менә Президент атлы баш түрәнең ялгышын күрсәтеп, өстәвенә, кире кагып кара әле син! «Түрәләрнең һәр эш-гамәлен контрольдә тотарга» да өндисез әле. Ялгышын күрсәттерделәр, кире кактырдылар, контрольдә тоттырдылар ди сиңа, бар! Баш түрәне синдәй-миндәйләр белән беркайда күрештермәячәкләр, фикеребезне бер газетада да чыгармаячаклар, хәтта депутатларга һәм хәтта (иң демократияле!) парламент мөнбәреннән дә әйттермәячәкләр бит (үз вакытында хөрмәтле Фәндәс Сафиуллинның ничә йөз тапкыр микрофонын өзделәр?) Тегеләйме-болаймы, әйтә калсак та, безнең сүз Президентны хурлау, аңа басым ясарга маташу, шәхесенә кагылу саналырга мөмкин. Ә болар өчен каты җәза каралган һәм, сабак өчен, кулланылып та тора. Ник сүзне Президенттан башладык әле, диярге телисезме? Чөнки бездә аннан башка берни дә эшләнми: җил дә исми, яфрак та селкенми, (тарихи «Болгар» кунакханәсе дә җимертелми), ул теләмәсә, бернинди берләшү дә булмаячак, байлар-түрәләр, зыялылар, милләтжанлылар, битарафлар аерым-аерым төркем булып яши бирәчәк, ә бәлки, аралар ерагая гына барачак. Чөнки, берләшә күрмәсеннәр дип, бу төркемнәрнең арасын махсус та ерагайталар — хакимнәргә шулай кирәк. Бөтен халык бер йодрыкка тупланып карасын әле! Туксанынчы еллар бердәмлеге матур үрнәк кенә түгел, гыйбрәтле сабак та бирде аларга.

Менә сез мәкаләгездә бер эпизодны язасыз. Янәсе, Шәймиев бер хәлиткеч мәлдә биек тәрәзәдән Ирек мәйданына бага да, «Халык аз бит!» ди. Алайса, нигә безнең җитәкчеләр халыкны урамнарга чыгудан һәрвакыт тыеп киләләр? Нигә

халыкның ул чакта мәйданнарга чыккан кадәре — ирекккә, гаделлеккә сусаганнар, милләт җанлылар, каләм иялəре — Татарстанның ирешкән, яуланган кадәр мөстәкыйльлегеннән, кулына алган кадәр байлыгыннан өлешсез калдырылды гына түгел, матди керемнәре тоталитар хакимият чорындагыдан да начарайды? Күптән түгел ТНВның бер тапшыруында мәшһүр балалар язучысы(!) депутат Роберт Миңнуллин сөйли: элек үзе эшләгән, иҗатчыларга гонорарны иң шәп түләгән газетада шигырен чыгарып, каләм хакы алудан ул да мәхрүм икән. Менә сиңа күпләребез көнләшеп караган «гомерлек депутат»! Әле генә «Татарстан яшьләре» газетасында «депутатларны тыңлаучы, алар сүзенә колак салучы юк бу илдә» дип язган Туфан Миңнуллин мең кат хаклы икән, алайса. Сталинчы-Путинчы хакимнәр аларны да үз кирәкләренә файдалану өчен генә тота булып чыга.

Уйлап карасаң, депутатлар йөзенә дә шактый аяк сөртteләр инде. Бик авыр көрәш аша, сабыйларча куана-куана кабул иткән Конституцияне, һич аңлашылмаган сәбәп белән, депутатларның үзләреннән үк кире сүттерделәр. Гарьлеге ни тора моның! Кабул иткән чакта берләшеп тавыш биргән йөзләрчә депутат түгел, тавыш бирмәгән бердәнбер «кире депутат» Васильев хак җиңүче булып калды түгелме? Аерым бер шәхес мәнфәгате өчен Төп Канунны кат-кат үзгәрттерү дә уйлы депутатлар күңелендә мәңге җуелмас төер булып калмагандыр дисезме? Шундый очракларның соңгысында хөрмәтле Туфан Миңнуллин парламент утырышында «Конституцияне үзгәртми калып булмыймы соң?» дип ничек ачынып сөйләде. Хакимнәр чакырса, шундый эшләргә кабат күнәрләрме алар? Икенең берсен сайлау алдында калсалар, властька, контрольсез хакимлеккә хирыс түрәләр белән берләшерләрме, әллә, ниһаять, вазифалары кушкан урында — җәберләнгән халык ягында булырлармы? Сез бу хакта ни уйлыйсыз, Рәфикъ Юныс?

Мәкаләгездән «түрәләрнең һәр эш-гамәлен контрольдә тотарга» өндәвегезне укыгач, мин «бу Рәфикъ Юныс үзен Штатларда яшим дип белә, ахры» дип уйлап куйдым. Шунда Һелсинки хәрәкәте эшлеклесе, 16 ел мөһаҗирлектә яшәгән мәгълүм Людмила Алексеева сүзләре искә төште. «Америка халкы үз түрәләренә контрольлек итми башласа, ярты елдан ул илдә яшәрлек тә булмас иде» дип язды ул бер газетада. Түрә – кайда да түрә, кайда да азгын. Штатларда халыкның матбугат, электрон мәгълүмат чаралары аша контрольлек итүе генә аларны «кеше кыяфәтендә» тота, күрәсең. Бездә, киресенчә, матбугат чаралары үзләре каты контроль астында, «симереп хуҗасына ябышмаслык» ач паекта утыра, аны шулай утырта алучылар хөрмәттә йөри.

1901 елда Ленин бабай партияне төзү эшен нәрсәдән башларга дигән сорауга «бөтен Русия күләмендә газета чыгарудан» дип җавап биргән иде. Шул вакытта илнең җитәкчесенә булачак фирканe төзешкән, акча табышып яшәткән, аннары миллионлы-миллионлы тиражы белән миллиардлар эшләп биргән, соңрак үзгәртеп кору дигән нәрсәне дә кайнатып чыгарган матбугатка яңа заман «зирәкләре» тиңе булмаган гаделсезлек күрсәттеләр: партиянең этен-бетен диярлек дәүләт хезмәткәре дигән өстен сыйныфка күтәрделәр, ә каләм иялəрен, дәүләттән читкә тибәреп, ярык тагарак янына чылбырлап куйдылар. Язсагыз — түләүсез язугыз, язмасагыз — тагын да әйбәт, диюләредер. Әсез «Казан утлары»нда Тукай ельязмасы биреп, гонорар түләмәүнең әнә шул фәкыйрь заманнарда да, сирәк булганын һәм гадәттән тыш хәл саналганын искә төшерәсез. Әйтегез менә, Мәскәүләрне дә көнләштерерлек йөз меңле тираж белән, ил түрәләренә хәйран акча эшләгән журналда хәзер авторларыгызга күпмерәк түлисез яки түли аласыз? Нигә мин, пенсиядәге журналист, 1969 елдан СССР Журналистлар берлеге әгъзасы, Матбугат отличнигы, җәмгыятьтәге үзгәртеп коруларны кыйнала-кыйнала хуплап язган кеше, үзем тоташ 34 ел эшләп чыккан газетага язмалар биреп (әйе, кулдан килгәнчә эшләп тә!), матбугатка язылырлык булса да өстәмә акча эшләүдән мәхрүм? Хезмәтебез чорында бик күп акча эшләп зур мая тупладык мәллә? Тагын кайсы тармак пенсионеры бар мондый хәлдә? Теге елларда «чукындыгыз шул суверенызыгыз белән» дип йөргәннәр бүген әнә икешәр пенсия ала. Бер милләттәш сеңлебез җырлаган сүзләр белән әйтсәк, «без әллә ямьсез кызлармы, ямьсез малайлар мәллә»? Нигә безнең Журналистлар берлеге матбугатның отыры хөртиләнә барган хәленә

карата мөнәсәбәтен белдереп чыгыш ясамый (каләмдәшләрне туплап урамга чыгу турында әйтмим дә), пенсиядәгеләр тормышы белән кызыксынмый? Берлек җитәкчесенең рәсми хакимият белән артыграк берләшеп ташлавыннан түгелме бу? Ә бит хөрмәтле Римма ханым Ратникова бу вазифадагы эшен аңа кадәр күрелмәгән күркәм гамәлдән — үзсүзлелеге өчен хакимият һәм каләмдәшләре тарафыннан кыерсытылучы гап-гади журналистны ачыктан-ачык, матбугатка язып яклаудан башлап җибәргән иде. Ул чакта, газетадан мәкаләсен укуга, яңа рәисебезгә чылтыратып, аның кыюлыгына һәм Арча журналистын гаделяклавына соклануымны белдердем. Шунда Римма ханым ачылып китеп: «куркак кеше түгел лә мин үзе, шулай да мондый язмалардан соң куркып та калам» — дип әйтеп салды. Инде куркыныч түгелдер, шәт.

Торалар да бер сүзне кабатлыйлар: имеш, чит илләрнең берсендә дә хакимият газета-журнал чыгаруга, китап басуга, язучыларга акча бирми. Гаҗәп, нигә иң башлап каләм ияләре чит илдәгечә яшәргә тиеш икән? Нигә үрчепме-үрчегән дәүләт түрәләре, рәтле илләрнең берсендә дә юк дип, үзләренең галәмәт зур өстенлекләреннән баш тартмыйлар? Байлар белән ярлыларның (яки эшләүче гади халыкның) матди кереме арасында бездәгедәй зур аерма беркайда да юк дип нигә берсе дә байлыгын бүлешми, әле кайберсе каләм иясенең бик хәләл хезмәтеннән дә үзенә табыш күрәмәк була? Менә сез, Рәфикъ Юныс, «Казанькомпрессормаш»ның элекке җитәкчесе Әхмәт Галиевнең (тарихында иң мәшһүр җитәкчесе, Татарстан байлыгын республика халкы файдасына эшләтү өчен янып-көеп көрәшкән, милексез, әдәбият-сәнгать әһелләрен дә янына якын күреп аңлаган зур шәхес дип әйтү дөресрәк булыр иде) айга директор чакта 330 сум алып эшләвен язасыз һәм «Хәзерге директорларныкы күпме икән?» дигән сорау куясыз. Ә хәзерге газеталарның баш мөхәррире күпме ала да, эшләүче журналистына ничегрәк түлиләр? Аерма никадәр? Коллегаларны язасыгыз килмиме? Белмәсәгез, укырга йә тыңларга киңәш итәм: боларны яңа романында Камил Кәримов та язды, телетапшыруда Роберт Миңнуллин да әйтеп узды. Шулай итеп, газеталарның баш мөхәррирләре белән «баш булмаганнар» арасына да ихлас берләшә, якынлаша алмаслык киртә корылган, тигезсезлек упкыны уелган инде. Менә нилектән хәзер газеталарда бар да әйбәт. Хактырмы-юктырмы, «одна бабушка сказала» радиосыннан шундый хәбәр дә ишеткәнем бар: янәсе, җаны әрнүле («Болгар» кунакханәсе җимерттерелгәч «Әрнү» исемле шигырь язуын истә тотам) Равил Фәйзуллин милли әдәбиятның һәм матбугатның аяныч хәле турында сөйләшү өчен бергәләп Президентка керергә тәкъдим иткәләгән, әмма бер мөхәррир дә күнмәгән, аның Президентка күмәк хат язу тәкъдименә дә кушылучы булмаган диләр. Кушылалармы соң... Вәзгыятьтән бик канәгать, авторларга гонорар түләү, ягъни, редакция акчасын читләр берлә бүлешү «бәласеннән» коткарган өчен җитәкчеләргә зур рәхмәтле кебек бит алар. Әйбәт хәтерлим: илдә Горбачев хакимияте чорында Балтачның район газетасы мөхәррире «үзгәртеп кору» дигән нәрсәне үз-үзенә фәрман язып хезмәт хакын бүтәннәрнекеннән күпкә арттырудан башлаган иде.

Мәйданда халык аз димәктән... ГКЧП вакыйгасыннан соң Татарстан башлыгына хәвеф янагач, язучы (шул риясыз җаннар инде, тагын кем булсын. Яраннары посып яткандыр, хәзер генә шәбәйделәр) Фәүзия Бәйрәмова халыкны әйдәп урамга чыкты һәм аның имин калуына ярдәм итте. Мондый чыгышларны хуп күргәч, Фәүзия ханымның үзенә куркыныч янаган, аның өстеннән хөкем барган көннәрдә ник Президентыбыз халыкны җитәкләп урамга да чыкмады, аны яклап матбугатта да берниңди белдерү ясамады? Болар аңа берни тормый иде лөбаса. Әҗәт — түләнүе белән мәгънәле бит. Югары хакимияттәгеләрнең берсе дә эшләмәде моны. Димәк, алар һәммәсе Фәүзия ханымның Президентны бәла-казадан саклап калуын өнәмәгәннәр, шулай булмаса, Илбашының милләт җанлы язучы, гади татар хатыны алдында әҗәтле калуына юл куймаслар иде. Чөнки әҗәт бирүче белән аны түләми йөрүче арасында дуслык-татулык була алуы икеле. Әнә, зур түрәләребезнең өңдәвенә ияреп (кредит алыгыз, бөтен дөнья кредитка яши, янәсе. Алар шулай үз карамакларындагы банкларга олы капитал тупладылар) банклардан әҗәт алган һәм түләр хәле булмаганнар беләнниләр кыланалар!

Берләшеп урамнарга, мәйданнарга чыккан халыкның искиткеч көч булуы, аның белән хәтта Мәскәүдә дә исәпләшүләре безнең түрәләрне сокландырмады, киресенчә, шиккә төшерде бугай. Чөнки, «революцияне гамәлгә ашырып» (бер акыллы немецның «Революцияне даһилар уйлап чыгара, массалар гамәлгә ашыра, ә җимешен әшәке җаннар җыя» дигән сүзләре хәтергә килде), аларны властька күтәрешкән, хәтәр чакта урыннарында саклап калышкан гайрәтле көч бервакыт аларга каршы да эшләргә мөмкин иде. Җыңүдән соң элекке көрәштәшләрен төрле яклап көчсезләндерү, юкка чыгару тираннарның тарих буена кила торган чире. Якын тарихыбыздагы ике зур явызның — Гитлер белән Сталинның – аермасы да шунда: беренчесе, яман кансызлык белән, үзенә каршыларны гына юк итсә, икенчесе — үзенең иң көчле, халык белгән, яраткан көрәштәшләрен дә кырган. Җиңү казанышларын уртаклашмас өчен эшләнә бу. Яннарында көчле, йогынтылы шәхес тотасылары да килми. Әле шуларны уйлагач, матбугатыбыз өчен сөенеп тә куйдым: «революцион» җиңүдән соң таркату-җимерү, халык каршында дәрәҗәсен төшерү (әле сез бер газета-журналга йөзәр меңләп языласызмы? Ә без менә берсен дә укымыйча бөек булдык!), «богау кидерү» эшен матбугаттан башлаганнар икән, димәк, чыннан да көчле көрәштәш булган бит ул. Аннары аның белән ни генә эшләмәделәр: министрлыктан-министрлыкка, бер җитәкчелек формасыннан икенчесенә куалап йөртүләр, татар газета-журналының ни икәнен дә белмәгән төрле түрәләрдән талатулар — берсе дә калмады. Әле дә ничек җан саклый, кемнәргәдер акча һәм дан эшләп бирә. Соңгы ике дистә елда бүтән бер генә тармакның да болай талкынганы юк әле. Хәзер исә бөтен Россия күләмендә милли мәгарифкә тотындылар.

Бердәм күтәрелгән халык кына түгел, богауларын өзеп рухи иркенлеккә чыккан матбугат һәм бер сүздә булган каләм ияләре дә үзенең нинди көч икәнен күрсәтте шул аларга. Халык алдында кемнәр барды? Татарстанның, татар халкы язмышының иң хәтәр, хәлиткеч көннәрендә ачлык мәйданнарына кемнәр чыкты? Республиканың мөстәкыйльлегеннән файдаланып, тиздән исәпсез-сансыз мал әләктерәчәк дәүләт байлары да, чиксез хокуклар белән халык башына утырачак хакимнәр дә, матбугат муенына таш булып асылачак эшем ияләре дә түгел, әлеге дә баягы нечкә күңелле, рухи хөр, риясыз шагыйрьләр, фидакарь язучылар бит. «Суверенлыкны йота алган кадәр алыгыз!» дигән тарихи, инде бүтән беркайчан кабатланмаячак сүзләрнең дә, һәммәсен «булдыра» торган түрәләр мәҗлесендә түгел, нәкъ менә Язучылар йортында, каләм ияләре каршында әйтелүен истән чыгармыйк. Ләкин, максатларына ирешкәч, фидакарь җаннар киләксезгә, хәтта куркынычка әйләнде. Нәкъ шуңа күрә матбугатның, каләмлеләрнең башына тимер кыскыч кидереп куйдылар. Татарстанда «сүндерелгән» «Азатлык» радиосы быел әллә ничек кенә Фәндәс Сафиуллинның: «Татарстандагы кебек каты цензура бүтән беркайда юк» дигән сүзләрен ишеттерде. Бәлки, ул, «гадәтенчә», арттырып җибәргәндер? Бәлки, сез дә «кыскычын кыскыч, шулай да бик кысмый ул, күнегәбез инде» диярге телисездер? Сәерләр бит без: үзебезне каты кыскан өчен «хуҗабызның» Мәскәүдән бүләк алуына да сөенә беләбез, газеталар аны тәбрикләп туя алмый. Тик Мәскәүнең татар милли матбугатын, мәгърифәтен, урысларныкыннан йөзләрчә елга борынгырак булган әдәбиятыбызны һәм матди, һәм рухи изгән, буйсындырган, киләчәк Ельциннары каршына үз таләбе белән бүтән беркайчан чыга алмаслык мескенләндергән теләсә кемгә бүләк бирергә әзер икәнен, монда горурланырлык берни дә юклыгын истән чыгарабыз. Референдумда яуланган мөстәкыйльлекне, милли-азатлык хәрәкәтен Татарстаннан торып буучылар әҗерсез калгандыр дисезме? Алар өчен дә шатланыйкмы?

Ә «кыскыч» тиздән нык сиздереп кысар – сайлау гына килеп җитсен. Узган сайлау вакытларын онытмагыз. Рус булмаган халыкларның теленә, милли мәгарифенә, тарихына балта чаба торган, дустыгыз, Тукай бүләгенә лаек чын көрәшче шагыйрь Илдус Гыйлаҗев шәп бәяләгәнчә, «өчле-тугызлы» (309нчы) закон ашык-пошык әзерләнеп һәм кабул ителеп ятканда, матбугатыбыз тынны да чыгара алмаслык итеп кысылган иде түгелме? Мәскәүләр түгел, сез язганча, эш башына татар булган өчен куелган «үзебезнекеләр» булдырды моны.

Эш узгач, тыпырчынып карадык каравын... Башта үзегез хупладыгыз бит, диделәр безгә. Дәшмәвебезне ризалык билгесе дип кабул иттеләрме, әллә житәкчеләребезнең хуплавы хак идеме — аңламадык та. Шуңа тавыш биргән Дума депутатларының берсен дә кире чакырып алмау төрле уйларга этәрә. Анысы татар теле түрәләребезгә баш авырту гына инде, һәммәсен бүген кисеп атарлар иде. Милли әдәбияттагы яшь өметебез Рүзәл Мөхәммәтшин («Моңлана белгән балаларыбыздан гайрәт көтеп юанабыз» — ди Мирхәйдәр Фәйзинең «Ак калфак» драмасындагы Хөсәй карт) «Идел» журналында юкка гына бер «баш»ның татарча белмәвенә ачына, чынлыкта «баш» өстендәге «баш»лар да белми һәм кирәксенми аны. Инде күпчелек татар шуларга иярде, түрәгә охшарга һәм ошарга тырышу дигәндә бердәм без, өндәп торасы да юк. Олыбыз-кечебез, баебыз-фәкыйребез, акыллыбыз-тилебез берзаман «Булдырабыз!» дип ничек бердәм кычкыра башлаган идек! Күп еллар элек андый сүзне Мирхәйдәр Фәйзи дә язып караган, әмма беркем күтәреп алмаган. Түрәләр татар газета-журналын, татар китабын укымый дип бөтенебез укудан биздек, янәсе, кайберәүләр кебек, «әдәбият укымыйча гына бөек» булмакчыбыз. Менә «Идел»нең тиражы 1805кә калды. Яшь каләм ияләренең һәм язу-сызулы ижатка тартылучыларның бөтен саны аннан күпкә зуррактыр, димәк, аларның да байтагы «Идел»гә язылмый. Заманында татарча яшьләр журналы чыгарырга рөхсәт алу өчен, ирекләрен куркыныч астына куеп, Мәскәү һәм Татарстан түрәләре белән җан талашкан фидакарьләр каршында оят! Түрәләрдән күрмәкче, инде әдәби журналларыбызга татар әдәбияты укытучылары да язылмый, татар мәктәпләре дә алдырмый. Татарныкы кебек бөек әдәбиятта гына була алган, журналның меңенче саны чыгу уңаеннан нәшер ителгән «Сүнмәс утлар балкышы» исемле рухи хәзинәне дә әле һаман сатып бетерә алмадыгыз шикелле.

Алны-артны уйлап житкермичә (әллә бик уйлап микән?) Мәскәүләрнең һәр эшен хуплау гадәтебез бар инде үзе. Конституцияләрне бозып, республикалар халкын үзенә житәкче сайлаудан мәхрүм иткәч, Путинның шул гамәлен ничек сикереп төшеп якладык. Россия Президенты урынында без дә шулай эшләр идек, аңа үрнәкне Татарстан бирде, янәсе...

Ельцинның «Суверенлыкны «йота» алган кадәр алыгыз!» дип Кремльдә түгел, «ниндидер писакалар» каршында әйтүе, ягъни, үзләре мәңге әйттерә алмаячак сүзне каләм ияләренең, милләт җанлыларның әйттерүе и көнләштергән, и женләндергән, тәмам хәтерләрен калдырган икән «тегеләр»нең. Ельцин әйтә дә китә ул, без, моңда калучылар, күрсәтәбез әле сезгә мөстәкыйльлекне һәм сүз ирегән, үчен кайтармый калмабыз бу жиңүегезнең, бик иртә куанасыз, диешеп утырганнар икән. Менә алалар үчләрен, чыда гына. Шулай да, беләсе иде: Равил Фәйзуллин кебек, заманыбызның зур шагыйрен, Туфан Миннуллин кебек, мәшһүр Гаяз Исхакыйларга тиң бөек әдипне мәңгелек әрнүләргә салырлык һәм шундый йөзләгән гамәлләре өчен аз гына да үкенү белдермәслек кем булган әле алар? Үзләрен кем дип уйлыйлар? Ни хаклары бар? Сез, хыялыгыздагы милли берләшү хакына һәммәсен кичерергә әзер Рәфикъ Юныс, боларга бер-бер аңлатма бирә аласызмы? Тәкәбберлекнең дә бер чиге булырга тиештер, ләбаса. Кайсы бәхетсез милләт үстереп кеше иткән аларны?..

Халык шагыйре Равил Фәйзуллинмы, бүтән бер мәшһүребезме мөхәррирләрне туплый алып Президентка кумәк хат юлласа да (хат Р. Фәйзуллин тарафыннан язылып һәм аның имзасы белән М. Шәймиевкә житкерелде. – Ред.) әлләни уңай нәтижә булмас иде, минемчә. Һаман да шул «аларча булмасын әле, аларга бер тапкыр юл куйсаңмы!» дигән мин-минлекләре жиңәчәк бит. Андый хатларны «кирелән уку» тәжрибәләре дә бар, берсен сез дә әйбәт хәтерлисездер, Рәфикъ Юныс. Ун еллар элек бер төркем каләм ияләре, кулындагы матбугат басмасы аша коллегаларының байтак нервысын ашаган бер галим-мөхәррирне ипкә китерүдә ярдәм сорап, Татарстан Президентына Ачык хат юлладылар. Хатка кул куйган берничә дистә кеше арасында депутатлар, Тукай бүләге ияләре, хөкүмәт әгъзасы, фән эшлеклеләре, күпчелек татар газеталарының баш мөхәррирләре иде. Ә нәтижә нинди булды? Иң элек, иң югары мөнбәрдән, Ачык хатны дөньяга чыгарган газетаны ябып кую белән янадылар, янәсе, ул үзенеке булмаган эш белән шөгыльләнә. Бераздан әлеге галим-мөхәррирга

«Татарстанның атказанган фән эшлеклесе» исеме бирделәр. Ачык хатка кул куючыларны мыскылларга теләгәндәй, мактаулы исем бирү турындагы фәрманда... «матбугат өлкәсендәге нәтиҗәле хезмәте өчен» дигән сүзләр бар иде. «Матбугатта нәтиҗәле эшләгән» эшлеклене соңрак Татарстан Язучылар берлеге үз сафыннан чыгарырга мәҗбүр булды, ул җитәкчелек иткән бик кирәкле басма матбугат кырыннан юкка чыкты. Әгәр Ачык хатта иплəп кенә әйтелгән фикерләргә вакытында колак салган булсалар... Бу сәер хәлләрнең дәвамы да кызык: түрәләр даирәсендә эшләп, Президентка Ачык хатны укытмыйча, якын дустына мактаулы исем бирү турындагы фәрман проектын төрткән каләм иясе барлык матбугат басмаларында да хөрмәттә йөри.

Менә сез, Рәфикъ Юныс, мәкаләгездә татар телен саклап калу, татар мәктәпләрен кубәйтү, татар җитәкчеләрен халык белән үз телендә сөйләшергә, ана телен санга сугарга өйрәтү юлында онытылмаслык эшләр башкарган урыс Семен Игнатьевны хәзергеләргә үрнәк итеп куясыз. Ә бит бу игелекле зат әлеге эшләрне нәкъ менә язучылар белән җыелып сөйләшкәннән соң, аларны тыңлап башлаган. Көенечебезгә күрә, Татарстанның шуннан соңгы җитәкчеләре язучыларны ничек шәбрәк тыңлатырга дип кенә баш ваталар, тырышып-тырмашып шуның әмәлләрен эзлиләр. Шуңа күрә милли эшләрдә чигенүдән бүтән хәрәкәт юк.

Берләшик, дисез сез. Кем белән? Путинчы түрәләр ниндидер (кем белән сугышыргадыр?) фронтка берләште инде, тик анда синдәй-миндәйләрнең кирәклеге сизелми. Завод-фабрикалары, җирләре, газета-журналлары, китап нәшриятлары, милли мәктәпләре, мәгарифе, ана телендә белем алу хокукы тартып алынган юксыллар аерым берләшсәк тә хәтәр: Алла сакласын, безгә каршы берләштегез дип, «фронт»тагылар ут ачарга да күп сорамас. Телевизордагы чырайлары әнә нинди ачулы! Ачуланмаска, булдыксызлыгыбыз аркасында, аларга акчаны аз эшләп бирәбез ич. Без пенсиядәгеләр, вакытында үлмичә, алар дәүләтенең җилкәсен кимереп ятабыз.

Беләсезме, берләшик дигән чакыру сезнең кебек укучысыз кала барган бер каләм иясеннән түгел, ниндидер могҗиза булып, өстәгеләрдән килсә дә кушылучы аз булыр иде. Тагын кайсы рәхмәтсезенә власть, өлешчә булса да мөстәкыйльлек алып, дәүләт төзешеп бирергә чакыралар инде, дип уйлаячак туксанынчы елларда каты алданган, беркемгә ышанычы калмаган гаҗиз буын. Димәк, сез теләгәнчә түгел, түрәләр астыртын гына уйлаганча бара дөнья. Бигайбә!

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ**

# ИҢ ӘҮВӘЛ ИКӘҮ БЕРЛӘШИК, АДАШЕТДИН!

Юк, синнән мондый хат килер дип көтмәгән идем, Рәфыйк. Монарчы хуплау сүзләре генә ишетә идем бит үзеңнән. Һәрхәлдә, төп, принципиаль мәсьәләләрдә.

Гел аралашмасак та, журналистлар буларак танышлыгыбызга егерме еллап бардыр инде. Шуна күрә синең күк «сез»ләп тормыйм, «син» дип кенә «дәшәм» менә. Җитмәсә, адашлар да. Синең белән исәнләшүем дә гел «Нихәл, Адашетдин!» була бит.

Хәер, безнең юллар күп элегрәк кисешкән инде. Мин эшләгән «Идел» журналы редакциясендә беренче кат бер-беребезне күреп, сөйләшеп утырганда белдем: сине заманында «Татарстан яшьләре»нә эшкә алырга вәгъдә итеп тә алмый калганнар икән бит. Шуны ишеткәч, унайсыз, хәтта авыр булып китте. Мине, журналистика бүлеге студентын, үзем практика үткән «Социалистик Татарстан» газетасының баш мөхәррир урынбасары Шәех Зәбиров тәкъдиме белән, нәкъ шул урынга алганнар икән! Сиңа исә нәүмизләнеп кире Балтачка кайтып китәргә туры килгән. Кызганыч. Район газетасында да (ни икәнен беләм!) шулай хөр фикерле, көчле милләтпәрвәр журналист булып үсә алганны «минем» урында нишләмәс идең икән син?

Кереш сүзе озын булды моның, боргаланып-сыргаланып үткән мәсьәләләрдән

качмакчы бит бу дип уйлый күрмә тагын. Халкыбызның һаман берләшә алмавы күпләр уйлаганча олы мәсьәлә генә түгел, күп-күп ваклыклардан торган үтә нечкә мәсьәлә дә ул. Һәм төп фикеремә нәкъ менә шулар аша килеп ятуым бу.

Теге сөйләшүдән соң, каршында кем утырганын белгәчтен дә, сөбханалла, мина карата шул ук Шәрәфиев булып кала алдың син. Минем ирешкән азмы-күпме уңышларымны күрә белден, аларның кайберләрен хәтта республика матбугатында да күрсәттен, ягъни син, милләт җанлы кеше буларак, аларга уртак сөенеч дип карый белден. Ләкин син һәм синең кебекләр «татар холкы» дигән уртак кагыйдәдән матур чыгармалар гына бугай шул.

Эреләрне, асылларны үткәреп (теге дөньяга яисә төрмә-каторгага), ваграклар, мескенрәкләрне калдыра торган «кире иләк»тән гасырлар буена иләнә килгән халкыбызның шулай ваклана-затсызлана, мескенләнә баруы гаҗәп түгел. Киресенчә, 80нче еллар азагында Марат Мөлеков, Фәүзия Бәйрәмова, Фәндәс Сафиуллин, Рафаэль Хәким, Зәки Зәйнуллин, Индүс Таһиров кебек затларның көтмәгәндә «каяндыр» килеп чыгуы гаҗәп булды. «Фәүзия Бәйрәмова татарга кем тия ул?» дигән мәкаләмдә (2010, № 12) мин милли хәрәкәтнең 29 әйдәренең исемен атадым. Аларның күпчелеге кайда, нишли хәзер? Ә сафтагылары нигә үзара берләшеп, милләтне үзенең һәлакәтенә каршы тап-табигый көрәшкә туплый алмый соң? Чөнки шул ук «татар холкы» төрле микъдарда аларга да хас.

Алда саналган «олы бишлек»кә (мәрхүм М.Мөлековтан тыш бу) кергәннәр арасында да тирән каршылыклар, хәтта дошманлык галәмәтләре дә барлыгын беләм. Берсе хакында язганым да булды. Аларны бергә җыеп (үзләре җыелуны әйткән дә юк) олы эшләр эшләтү түгел, бер бүлмәдә төн кундыру да мөмкин микән әле? (Кулыннан килгәннәргә шул төн турында сәяси драма язарга тәкъдим итәм.)

Шөһрәт тансыклау, үз-үзеңне сөю еш кына милли гамьнән алдарак йөри. Син дә, әнә, адаш, берләшү һич мөмкин түгел дигән нәтиҗә ясыйсың кебек. Ләкин башка юл юк бит. Милләтебез исән калсын дисәк, безгә чыннан да бу авыр мәлдә мин-минлекне артка чигереп, вак-төякләрдән башлап иң олы мәсьәләләргә кадәр, дөрес уртак фикергә килергә өйрәнергә кирәктер.

Беребез дә фәрештә түгел. Үзенчә уйламаганны, синеңчә яшәмәгәнне, сиңа мөкиббән китмәгәнне дошман күрмик. Бер-беребездән аерган якны түгел, уртак якны алга чыгарыйк, уртак кыйблага төбәлик. Шулай булмаганда безгә «Әнә ул гына гаепле!», «Юк, син гаепле!» дип бер-беребезгә төртеп күрсәтә-күрсәтә бер карабта бергәләп бату гына насыйп булачак бит.

Татар язмышын үз мин-минлегеннән өстен куйган ихлас милләтпәрвәрләр күп түгелдер. Бу авыр мәлдә алар бер-берсенең кадерен белеп, кайгы-сөенечләрен уртаклашып, бер-берсенә таяныч булып, уртак олы гамьгә төбәлеп яшәргә тиешләр. Безгә хәзер шулай берәмтекләп берләшергә генә калды бугай инде. Ләкин бу да өметсез юл түгел. Халыкны аны бербөтен булып тупланган берничә дистә кеше дә уята ала.

Менә без дә, Адашетдин, иң әүвәл икәү берләшик. Моның өчен фикер каршылыкларын күздән кичереп, уртак фикергә килергә омтылыйк. Мина синең берләшә алмавыбыз фаҗигасен үз кайгың итеп, газапланып кичерүең ошады. Мәкаләмнең дөрес санамаган урыннарын күрсәтеп, җавап таләп итүең дә әйбәт. Мин дә шуннан башлыйм.

Менә хатыңнан бер өзек. «Янәсе, Шәймиев бер хәлиткеч мәлдә биек тәрәзәдән Ирек мәйданына бага да, «Халык аз бит!» ди. Алайса, нигә безнең җитәкчеләр халыкны урамнарга чыгудан һәрвакыт тыеп киләләр?» Болар икесе ике чор хәлләре бит, адаш. Язучылар берлегенең Тукай клубында да 1990 елның 9 августында Ельцин янәшәсендә баштагы Шәймиев утыра иде әле. Һәм ул син әйткәнчә каләм әһелләренә теш кайрап түгел, ихластан сөенеп утырды (ә очрашуны Язучылар берлеге рәисе, РФ Югары Советы депутаты булгач Ельцин белән шактый якынайган Ринат Мөхәммәдиев оештыра алды).

Үзгәреш Мәскәүдә, референдумыбызга таянып, безнең өчен бик тә унай Шартнамәгә кул куелганнан соң, ягъни 1994 елны, һич көтмәгәндә башланды. Моның сәбәбен мәкаләмдә әйткән идем. Шуңа өстәп бер мәкаль дә китерим әле: «Татар түрә булса, чабатасын түргә элә». Моны күптән инде болай дип үзгәртү

тиештер: «Татар түрә булса, түргә урыс чабатасын элә». Түрәләребезгә бәйле сорауларына шушы янартылган мәкаль җавап була ала, минемчә...

Син хаклы, адаш, милли матбугат бары дәүләтнең, әлбәттә инде, авторларга тиешле күләмдә каләм хакы да түләргә җитәрлек, матди ярдәме белән генә яши ала (ярдәмне өзүчеләр аны үтерүчеләр була). Ләкин «богауларын өзеп рухи иркенлеккә чыккан матбугат» дип, «нинди көч икәнен күрсәтте» дип югары пафос белән язуың - гаҗәпләндерә. Журналистларыбыз, бик азларны гына санамаганда, коллык психологиясеннән арына алмады шул. Референдум алдыннан ике төрле җавапны яклап бер ай буена барган матбугат көрәшенә дә әнә татар журналистлары кушылган яки хупланган эш, әйтик, урып-җыю кампаниясе ише бер нәрсә итеп караудан әлләни ерак китә алмадылар. Язучылар, галимнәр, юристлар активлык һәм осталык күрсәтмәсә, без бу көрәшне һичшиксез оттырачак идек.

Казан алынганнан соңгы чорда татар тарихында иң олы вакыйгаларның берсе булган референдумны, аның яна референдумнан тыш беркемнең дә юкка чыгарырга хакы булмаган нәтиҗәсен Татарстан хакимиятенең дә, татар матбугатының да бергәләп шулай тиз «онытулары» шаккатыра. Газета-журналларыбыз референдумны үтүенә 5, 10, 15 ел тулганда да искә алмадылар диярлек. 21 мартта менә 20 ел тула. Яңа Президентыбыз әнә үзенең Яңа ел котлавында син язганча «депутатларның үзләреннән үк кире сүттерелгән» Конституциябезнең 20 еллыгын да, Изге Казан иконасының кин танылуына 400 ел тулачагын да онытмады, референдум турында гына ләм-мим бер сүз әйтмәде.

Газета-журналларыбызның күбесе әле дә татарның (димәк, үзләренең дә) исән калу-калмау кимәлендәге хәп-хәтәр хәлен күрмәмешкә салыша, курка-мескенләнә икән, монда иң әүвәл журналистлар һәм, әлбәттә, баш мөхәррирләр гаепле. Баш мөхәррирләр эштән алынудан (атудан да, төрмәгә утыртылудан да түгел!) куркып дер калтыраганда татар матбугаты ирекле була алмый шул. Чын журналистика беркайчан да, беркайда да куркаклар эше булмаган...

Түрәләрне, иң югарыларын да, контрольдә тотыйк дигән фикеремнән баш тарта алмыйм. Тиешле мәлдә матбугат аша, кирәк булганда, әйе, мәйдан аша да, басым да ясыйк. Әгәр дә татар матбугатын, татар мәдәниятен, татар мәгарифен, тулаем татар милләтен саклый алмый икән, безгә урыс Игнатьевны сагынырга кала икән, мондый хакимият *Татар*станга гомумән дә кирәкме әле ул? Шундый чакларда да «әдәп саклап», тәтиләнеп утырсак, йә, без үзебез кем булабыз инде?..

Хакимият дигәннән, түрәлекнең үзенә күрә бер сихере бар бугай аның, әйе. Моны мин үзем дә тойдым. Хәтерлисеңме икән, мин бит синең исемеңне үзгәрткән кеше, адаш! Шул ук «Идел»дә эшләгәндә, баксам, өстәлемдә өч адашның кульязмалары тупланган. Берсен үзем, ягъни Рәфикъ, икенчесен син, ягъни Рәфыйк, өченчесен Рафикъ язган. Мин мондый тәртипсезлеккә чик куярга булдым. Хакым бар, янәсе, беренче урынбасар бит! Исемебез гарәптән кергән. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеген ачып карасам, анда минем вариант бирелгән. Шуннан сина шалтыратып, хәлне аңлаттым. Син исә, ярар, үзеңнекечә куй инде, дидең. Һәм мин, тавышыңдагы «агу»ны да тоймыйча, синнән «Рәфикъ Шәрәфиев» ясадым. Ләкин мәкаләң басылып чыккач, ялгышканымны аңладым. Мин бит сине укучыларың ияләшкән исемнән аерганмын. Ягъни синнән бүтән автор ясаганмын. Шуннан соң янә элекке исемең белән чыга башладың... Әгәр дә мин берәр зуп-зур түрә булып, 10-15 ел эшләсәм, мина, бәлкем, хәтта халкыбызның язмышын үзем теләгәнчә үзгәртергә дә хакым бар кебек тоела башлар иде. Мона тагын бераз Мәскәүдән шөлләү һәм нәфес дигәне дә өстәлә төшсәме?!

Әйе, менә шундый «нечкәлеге» дә бар бит тормышның...

Шушы урында күп нокта куйыйк, адаш. Татарның хәзерге хәле турында мәкалә әзерлим, кайбер җавапларны аннан да табарсың...

**Рәфикъ ЮНЫС**

# ТАТАРНЫҢ БӨЕК АРТИСТЫ ХӘЛИЛ ӘБҖӘЛИЛОВ

Безнең Щепкин исемендәге театр училищесын тәмамлаган татар студиясе язмышында Хәлил абый Әбҗәлиловның нинди роль уйнаганын язарга әллә кайчан кирәк иде. Бүген язам, иртәгә язам дип гомер дә узып китте. Кем иде соң ул безнең өчен Хәлил абый Әбҗәлилов?

Мәскәүнең Щепкин исемендәге театр училищесында укыган татар студиясенең язмышын Хәлил абый Әбҗәлилов хәл итте дисәк, дөрес булыр, чөнки ул безне укытып чыгарыр өчен бөтен күңелен, көчен бирде. Татар академия театрына яшь артистлар укытып кайтарырга кирәклеген дә дәүләт житәкчеләренә аңлата алды. Хәзер академия театрында эшләгән Наил Дунаев, Ринат Тажетдинов, Равил Шәрәфиев, Фирдәвес Әхтәмова, Гөлсем Исәнгулова, Нәҗибә Ихсанова, Флера Хәмитовадан башка бүгенге академия театрын күз алдына да китерү мөмкин түгел! Халкыбызның кадерле язучылары Рабит Батулла һәм Туфан Миңнуллин, телевидение режиссеры Әхтәм Зарипов, телевидениедә диктор булып эшләгән Иркә Сакаева, телевидениенең баш режиссеры Клара Газизова, бик иртә вафат булган талантлы артист Дамир Хәйруллин, аның җәмәгате Мәсхүдә Хәйруллина, халкыбыз белгән шәхесләр Хәмзә Арсланов, Миргалим Харисов... Барысын да искә төшереп бетерә алмадым — без бит 23 кеше идек. Менә бүген татар сәнгатен, аның әдәбиятын шул кешеләрдән башка күз алдына китереп карагыз әле. Ул шактый фәкыйрь күренер иде.



Без Хәлил абыйга бик рәхмәтлебез, ул безгә тормышыбызда дөрес юл сайларга ярдәм итте. Ачлы-туклы йөргән чакта ашатты, кияргә кием булмаганда киендерде, бүтән милләтләр алдында ким-хур булмавыбызны теләде, чөнки безнең белән таҗиклар, молдаваннар, монголлар һәм башка бик күп милләт балалары укый иде. Мәскәүгә килгән саен хәлне белеп, ничек укуыбызны тикшереп, биш ел буе күзәтеп торды. Хәтта безнең «Тукай» спектаклендә бәләкәй генә бер рольне уйнап, диплом эшебезнең дәрәҗәсен күтәрде.

Әлбәттә, мондый артистлар сирәк була, ул чын күңелдән безнең барыбызның да театрга кайтып, талантлы артистлар булып эшләвебезне теләде. Татар театры киләчәктә башка милләт театрларыннан ким булмасын дип тырышты. Ул, үзенең бөеклеген аңлаган хәлдә, татар театрын бар нәрсәдән өстен күреп, гомерен шуңа багышлаган кеше.

Хәлил абый Әбҗәлилов Ырынбур өлкәсе, Мостафа авылында, Гали абый белән Фатыйма апа гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе — авылның бик булдыклы балта остасы. 1905 елдагы корылыктан бөтен малларын суеп, алар Ырынбурга күчеп

китәргә мәҗбүр булалар. Хәлил 13 яшендә беренче мәртәбә цирк карый, шунда клоунның уйнаганын күреп шакката. Үзенен дә цирк артисты буласы килә, театрга мәхәббәте шул рәвешле цирктан башлана.

Беренче бөтендөнья сугышы чыккач, Хәлилне армиягә алалар. Ул сугышта батырлык күрсәтә. Ләкин үзе дә инвалид булып кала — бер кулы күтәрелми иде. Бик озак больницаларда интегеп ятканнан соң, яшь егет дип кызганып, көч-хәл белән үлемнән коткарып калалар. Терелеп чыккач, ничек тә артист булам дип хыяллана. Үзе күргән, үзе кичергән михнәтләрне сәхнәдән күрсәтергә тели. Шуңа күрә Ырынбурның «Ширкәт» труппасына килеп, артист итеп алуларын сорый. Бу вакытта «Ширкәт» труппасынын режиссеры Вәли абый Мортаза-Иманский була. Ул әйтә, иртәгә сәгать сигезгә кил, «Казанга сәяхәт» әсәрендә Идрис ролен уйнарсын, ди. Бу — маклер роле, репетицияләр ясап, ике көн узгач, Хәлил абый сәхнәгә чыгарга тиеш. Менә ул беренче мәртәбә сәхнәгә чыга. Зал тулы халык, аның йөзенә көчле утлар, йөзләгән күзләр төбәлгән. Ул каушавыннан нишләргә белми, үзен сәхнәдә шәп-шәрә калдырганнар кебек хис итә, шул хәтле каушый, хәтта ике сүзне кушып та әйтә алмый, ык-мык килеп тик тора. Партнеры, ачуыннан нишләргә белмәгәч, чыгып кит, дурак, дип, сәхнәдән куып чыгара үзен. Пәрдәне ябалар. Спектакль беткәч, режиссер Мортаза-Иманский аңа: «Синнән артист чыкмый, син безгә сәхнә корырга булышырсың, бүтән эштә ярдәм итәрсен», ди. Хәлил абый бу вакыйганы шул хәтле авыр кичерә ки, үз-үзенә: ничек кенә булса да барыбер артист булачакмын, дип ант итә. Хәзер ул һәр көнне, айлар буе, иртә-кич татар, урыс артистларынын уенын карап утыра. Анын өчен театр мәктәбе әнә шуннан башлана. Гогольнең, Островскийның, Шиллернын геройларын урыс профессионал артистлары башкаруында кат-кат күрә.

Бер вакытны «Ширкәт» труппасы Владимир Соловьевнын «На пороге к делу» әсәрен сәхнәгә куярга уйлый. Ләкин старшина Буравин роленә кеше җитми. Шунда бер артист әйтә, монда артист булырга хыялланучы Хәлил исемле егет бар, әйдәгез, шуны сынап карыйк, ди. Артистларның күбесе каршы киләләр, аннан барыбер артист чыкмый, диләр. Ләкин нишләсеннәр, уйнарга кешеләре юк. Бу юлы Хәлил абый бик нык әзерләнә: ашамый-эчми, көне-төне ролен ятлый, үзенчә репетицияләр ясый. Бүтән артистлар килгәнче ике сәгать алдан килеп утыра. Бәхетенә күрә, сәхнәгә чыккач югалып калмый, ролен әйбәт кенә башкара. Спектакль беткәч, күзлекле бер кеше сәхнәгә менеп, хөрмәтле тамашачылар, без бүген сәхнәдә беренче мәртәбә күргән яшь артист Хәлилнең киләчәгенә ышанабыз, аңа зур өметләр баглыйбыз, театрда үз юлын табар дип уйлыйбыз, ди. Бу сүзләрне әйтүче халкыбызның кадерле язучысы Шәриф Камал була. Шуннан соң Хәлил абыйның күнеле күтәрелеп китә. Анын киләчәк язмышын бигрәк тә Нури Сакаев, Нәгыймә Таҗдарова кебек талантлы артистлар белән очрашу хәл итә. Нури Сакаев белән бергә уйнап, ул сәхнәдә образ тудырырга өйрәнә. Бари Тарханов исә аңа комедия жанрында нинди алымнар кулланырга кирәклеген аңлата.

Хәлил абый Октябрь революциясен бөтен күнеле, җаны белән кабул итә. Барлык изелгән халыклар: безнен, ниһаять, үз дәүләтебез була, республика төзибез, дип чын күнелдән ышаналар. Шуңа күрә Кызыл армия сафларында татар-башкорт бригадалары акларны җиңүдә вакыты-вакыты белән хәлиткеч рольне уйный. Дутов гаскәрләрен татар бригадасынын тар-мар итүенә Хәлил абый шаһит була. Ул татар бригадасы каршында оештырылган театрга эшкә керә һәм җитәкчеләренең берсенә әйләнә. Гомумән, Хәлил абыйда оештыру сәләте көчле була. Татар бригадасы дип шуңа әйтәм, чөнки беренче спектакльләре Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану»ы була. Урыс кешесе «Галиябану»ны карап утырмас бит инде. Бервакытны, әле «Ширкәт» труппасында эшләгәндә, Хәлил абыйга Галиябанунын әтисе Бәдри ролен бирәләр. Гыйлемхан дигән артист белән бергә чиратлап уйнарга тиеш булалар аны. Хәлил абый, үзен бик зур артист санап, Гыйлемханга әйтә: «Син репетицияләр ясый тор, мин премьераны гына чыгып уйнармын, миңа репетиция кирәкми. Менә сиңа визиткам, күз карасы кебек сакла!» — ди. Шулай беркөнне репетициягә Вәли абый Мортаза-Иманский килә. Сәхнәдә Гыйлемханны күргәч, «Кайда Хәлил?!» дип

кычкыра. Гыйлемхан шунда Әбҗәлилов әйткән сүзләрне әйтә. Кич белән Хәлил абый Бәдри ролен шулхәтле начар уйный ки, хәтта онытып бер күренешкә чыкмыйча да кала. Спектакль беткәч, Мортаза-Иманский: «Нәрсә, зур артист булдынмы? Менә визиткан», — дип визиткасын йөзенә бәрә. (Күрәсең, визиткада «татар халкының талантлы артисты Хәлил Әбҗәлилов» кебек сүзләр язылган булгандыр инде.) «Беләсеңме, син бүген нәрсә эшләдең? Син театрга, иптәшләреңнең йөзенә төкердең! Син нәрсә, безнең эштә көне-төне эшләмичә генә уңышка ирешәм дип уйладыңмы? Синең бит театр белемең дә юк, син бит надан! Ичмасам, талантлы артистлардан уйнарга өйрән», — дип елатканчы сугә. Шуннан соң Хәлил абый үзенә гомерлек сабак ала.

Революция биргән иректән файдаланып, Ырынбурда беренче татар стационар театрын ачалар, ана «Шәрык театры» исемен бирәләр. Бу театрны ачуда башлап йөрүчеләрнең берсе Хәлил абый Әбҗәлилов була. Артист халкы кызык бит ул — революцияне дә үз файдасына бик акыллы файдалана, декорациягә кирәк тактаны, реквизитны, киемнәрне, костюмнарны бай кешеләрдән кереп алалар. Янәсе, революция театры таләп итә, безнең үзебезгә бер әйберегез дә кирәкми, театрга кирәк. Шулай гөрләп эшләп торганда, 1921 елгы ачлык башлана, артистлар ризык эзләп төрлесе төрле якка таралалар. Революция вакытында үзен бик яхшы яктан күрсәткән өчен Хәлил Әбҗәлиловны Төркестанга, Бохарага театр ачарга җибәрәләр.

Күз алдына китерегез әле — 1921 елны Бохарада театр ачуны. Әмма Хәлил абый бик оста оештыручы була. Беренче эше итеп армиядә хезмәт итүче яшь солдатлар, яшь кызлар арасыннан сәләтлеләрен җыеп, «Бохараның җимерелүе» дигән агитка яздырып, шуны сәхнәгә куя. Сәхнәсе кайда диген, спектакльне әмир сараенда уйныйлар! Декорация кирәкми, кием кирәкми, реквизит кирәкми — бөтенесе әмирдән калган. Хәлил абыйның уенына шаккаталар, бигрәкләр дә килештереп уйный, әйтерсең лә гомер буе әмир белән бергә яшәгән. Хәлил абый башта кешеләрдән сорашып Бохара әмиренең сөйләшү рәвешен, үз-үзен тотышын, холык-фигылен өйрәнгән. Спектакльдә кулына әмирнең чын кылычын алгач, бөтен халык куркып, аптырап кала. Аның искиткеч шәп артист булуы турындагы сүз бөтен Бохарага тарала. Ул үзбәк халкының талантлы балаларын җыеп, Мәскәүгә укырга җибәрә. Ләкин булачак яшь артистларны юлда басмачылар суга батырып үтерәләр. Хәлил абыйны да бик нык кисәтәләр, әгәр театр уйнавыңны туктатмасаң, без сине барыбер үтерәбез, дип яныйлар. Шуна күрә аны сакларга ике милиционерны билгелиләр.

Кайвакыт тормышта шулай була бит, көтмәгәндә кешенең язмышы үзгәрә дә куя. Бохарага кино төшерергә киләләр. Хәлил абыйга бәхет елмая, ул татар артистларыннан беренче булып киногa төшә. Кино дигәч тә, дистәләгән кеше, зур-зур декорацияләр, машиналар, көчле утлар, шаккаткыч аппаратлар булмый, бу бит Мәскәү түгел. Хәлил абыйның беренче эше «Үлем манарасы»нда атаман Кырбашый роле була, аның артыннан — «Икенче хатын», «Хакимият кем кулында?». Ә инде «Рәвәт шакаллары»ндагы Нәби бай роле белән ул бөтенсоюз тамашачысы алдында дан казана. Аны мактап, «бик интересный» артист дип хәтта Мәскәүдә дә язып чыгалар.

Үзе сөйләгән бер кызык хәл искә төште. «Рәвәт шакаллары»нда шундый бер күренеш бар, бөтен халык алдында егет белән кызга мулла никах укырга тиеш була. Күз алдына китерегез, 1924 елда үзбәк халкы ничек инде киногa төшсен, бөтен кеше, җаныбыз сурәттә кала дип, Аллаһы Тәгаләдән куркып, качып бетәләр. Шунда милиция, солдатлар халыкны бик нык куркытып (ягъни, төшмәсәгез, зинданга ябабыз, малларыгызны алабыз), акча биреп, киногa төшәргә мәҗбүр итәләр. Мулладан, матур, яна киемнәр кидереп, чын никах укыталар. Ул вакытта телсез кино, тавыш язылмый. Төшереп бетергәч муллага киемнәрен салып бирергә кушалар. Ләкин мулла киемнәрне бирми, никах укыган өчен ул мина бүләк, аның йоласы шул, ди. Режиссер түзми, мулланың өстендәге киемнәрен салдырып ташлый. Шулвакыт бөтен халык, муллабызны талыйлар, муллабызны талыйлар, дип,

режиссерга, артистларга ташланалар. Халык кычкыра, ишәкләр акыра. Әйтерсең лә, дөнья купкан, артистлар көчкә качып котылалар. Менә шул турыда Хәлил абый бик кызык итеп сөйли иде.

Ләкин Хәлил абый артист буларак кинога төшүеннән канәгать булмый, телсез кинода, монда бас, тегендә бас, бер адым алга, бер адым артка, күзенне ач, күзенне йом, күккә кара дип роль өстендә эшләүне аңламый да, кабул да итми. Иң аянычы — тамашачы юк, алар алдында уйнап күрсәтмәгәч, синең уеныңны ничек кабул иткәннәрен күрмәгәч, кинода артист буларак үзенә азык тапмый ул. Шуңа күрә, бик зур эшләр тәкъдим итсәләр дә, 1928 елда Татар академия театрына — Казанга кайта. Монда аны бик зур эш хакы куеп (аена 170 сум) каршы алалар. Чөнки Әбҗәлилов инде бөтен союзга танылган киноактер. Беренче эше Борис Лавреньевның «Разлом»ында — Боцман роле. Бу ялагай, сатлык җан, гомумән, спектакльдә иң әшәке кешеләрнең берсе. Хәлил абый, мин мондый рольне уйный алмыйм дип режиссер Гомәр Девишевка килеп әйтә, ярар, ди режиссер, мин рольне бүтән артистка бирермен, ләкин ни өчен син рольдән баш тартасың? Хәлил абый: «Бу рольдә уйнарга миңа бернинди материал да юк, чөнки бу кеше бары тик кабахәт, сатлык, әшәке җан гына», — ди. Гомәр Девишев Мәскәүдә Е.Вахтангов җитәкчелегендәге театр студиясен тәмамлаган беренче профессионал татар режиссеры. Ул аңа ялагайлар, сатлык җаннар, кабахәтләрнең бу дөньяда ничек барлыкка килгәннәрен, аларның психологиясен, язмышын тирәнтен ачып бирә. Октябрь революциясе менә шундый кабахәт җаннардан чистарта дип дәлилләп аңлаткач, Хәлил абый бу рольне уйнарга риза була. Ул үз гомерендә беренче мәртәбә чын, укыган, талантлы режиссер белән эшләргә өйрәнә, Станиславский системасы белән таныша. Әлеге спектакльне мактап, Хәлил абыйның эшен аерым зурлап язган мәкаләләр бик күп. Шуңа да карамастан, аны яңа сезонда театрга эшкә алмыйлар. Синең кебек артистлар театрда күп, син үзеңә башка җирдән эш эзлә, диләр. Шулай да, Хәлил абый бик ялынгач, аена 40 сумга эшләргә риза булгач, аны театрда калдыралар. Уйнарга рольләре юк, гел күмәк сәхнәләрдә, үзен-үзе кая куярга белми йөргән чакта, бервакыт Шәриф Камалның «Козгыннар оясында» әсәрен сәхнәгә режиссер Сөләйман Вәлиев-Сульва куярга алына. Хәлил абый сүзсез рольдә катнаша, ягъни «массовкада» — безнеңчә, халык ролендә. Репетиция вакытында ул үзен шул хәтле табигый тота, сәхнәдәге вакыйгалар белән шулхәтле дөрес яши, тамашачылар бу сүзсез рольне автор тарафыннан шулай язылган дип кабул итәләр. Спектакльне карагач, Шәриф Камал Хәлил абыйның уенына шакката, бу сүзсез рольгә Хәлил исеме бирә. Менә шушы рольдән соң Хәлил абыйның театрдагы тормышы янадан башлана. Ул иптәшләре тарафыннан сәләтле артист булып кабул ителә. Берсеннән-берсе катлаулы рольләр уйный башлый. Бу турыда театр тәнкыйтьчесе Хәмит абый Кумысников шул хәтле тирән, акыллы итеп язган ки, аларны кабатлап тормыйм. Мин бары тик Хәлил абый Әбҗәлиловның катлаулы иҗат юлын гына аңлатырга теләдем.

Мин үзем Татар академия театрын 1957 елда Мәскәүдә Декада вакытында күрдем, аңарчы минем профессионал татар театрын күргәнем юк иде әле. Миңа үзбәк, казакъ, кыргыз, төрекмән, таҗик, әзәрбайҗан театрларын карарга туры килде. Болар бит — союздаш республика театрлары. Мөмкинлекләре зур, чөнки үзләренә күрә дәүләтләре дә бар. Татар театры исә боларның берсеннән дә ким түгел, киресенчә, өстен икәнлеген күрсәтте. Театрга билетлар сатылып беткән, тамаша заллары тулы, моңа Мәскәүдә яшәүче татарларның күп булуы да ярдәм иткәндер. Юк, алай гына түгел, татар артистының уены ул заман өчен сәнгатьнең югары баскычында булу да. Безгә хәтта Мәскәүдә татар театры ачарга тәкъдим иттеләр, ул гына да түгел, Советлар Союзының иң югары бүләге — Ленин ордены белән бүләкләделәр, мондый бүләк союздаш республика театрларына да бик сирәк эләкте.

Без, беренче курс студентлары, К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл», Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин», В.Шекспирның «Король Лир» әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә күмәк сәхнәләрдә катнаштык. Шуңа күрә миңа Хәлил абыйны

сәхнәдә күрергә насыйп булды. Хәлил абыйның Хуҗа Насретдин ролендә ничек уйнаганын гомеремдә дә онытасым юк. Равил Шәрәфи белән «Хуҗа Насретдин» спектаклендә Җиһангир ханның иң явыз, этләр кебек теләсә кемнең башын чәйнәп өзәргә әзер ерткыч сакчылар кыяфәтендә хан сараенда басып торабыз. Хан сараена керү түгел, безне күргәч тә кешенең куркуыннан йөрәге ярылып үләргә тиеш! Безне шулай киендерделәр, йөзебезгә шундый куркыныч грим салдылар. Менә бервакыт сәхнәгә Хәлил абый килеп керде, безгә күз кыса-кыса, шундый итеп карады ки, мин нишләргә белми катып калдым, аның башындагы кәләпүш чукларын әле болай, әле тегеләй итеп хан янына ничек кереп киткәнен сизми дә калдым!

Хәлил абыйның уенынан үземнең сәхнәдә икәнемне онытканмын. Бер заман айнып китсәм, авыз ерылган, үзем шырык-шырык көләм, һич кенә дә тыелып булмый. Равилгә карасам, ул да шырык-шырык көлә. Без бит яман куркыныч яугирләр, әгәр безнең менә шулай сәхнәдә көлгәнне күрсәләр, үтерәчәкләр бит! Көлүдән бер-беребезне көчкә тыеп торабыз. Әгәр сәхнәдә артистлар бар дөньяларын онытып рәхәтләнеп көләләр икән, тамашачы ничек көлмәсен инде. Талантлы артистның ничек уйнавын мин беренче мәртәбә шунда күрдем. Хәлил абыйның уены нәрсәсе белән үзенә әсир итте соң? Шушы рольгә генә хас эчке һәм тышкы органикасы, сүз уйнату түгел, шул сүзләрнең мәгънәсенең сәхнәдә тууы. Без бит гадәттә комедия уйнаганда ничек кенә булса да тамашачыны көлдерергә тырышабыз. Әлбәттә, Нәкый ага Исәнбәтнең



*Х. Әбҗәлилов — Хуҗа Насретдин ролендә*

сүзләрен кеше аңларлык итеп сөйли алсаң да, тамашачы рәхәтләнеп көләчәк. Ләкин Хәлил абый сәхнәдә нәрсә генә эшләмәсен, искиткеч кызык, ул үзенә җәлеп итә, шуннан мәгънә таба. Хәлил абый уйнаган Хуҗа Насретдиннең һәр нәрсәгә, һәр вакыйгага үз карашы, үз фикере бар. Бигрәк тә эчке темпераменты артист тарафыннан шундый итеп табылган ки, чыннан да мең тапкыр уйналган спектакль шул. Хәлил абыйның артист буларак чын-чынлап чәчәк аткан чагы! Ул татар кешесенең зирәклеген, тапкырлыгын шундый югарылыкта уйнады ки, үз милләтенең бөеклеген Хуҗа Насретдин роле белән ачып бирде. Татар тамашачысы Насретдинне үзенең милли герое итеп кабул итте. Аның уены татар дөньясында гына түгел, бөтен шәрык иленә һәм Европага күрсәтеп була иде. Мондый артист белән сөенеп, горурланып утырасың. Менә бүген президенттан, министрлардан, депутатлардан бик күпкә акыллы булган гади кешене сәхнәгә чыгарсаң, тамашачы ничек кабул итәр иде икән? Бу әсәрдә шундый бөек фикер ята: халык җитәкчеләр уйлаганча сарык түгел, барсын да күрә, аңлый һәм дөрес бәя бирә. Мәскәүдә «Хуҗа Насретдин» спектаклен тамашачының ничек кабул иткәнен күрсәгез икән! Татар артисты, татар театры белән милләттәшләребез шул хәтле горурландылар, бу спектакльне татар театрының бәйрәме итеп кабул иттеләр.

Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар» драмасын мин залда утырып карадым. Авылда туып-үскәнгәдер инде, андагы вакыйгаларны бик якын кабул иттем. Күп вакытта авыл тормышын сурәтләгән әсәрләргә ышанмыйсың, күңелең белән кабул итмисең, чөнки анда ялган күп була, нәкъ менә бүгенге көн кебек. Тормышта бер нәрсә, театрда, телевидениедә бөтенләй башка нәрсә күрсәтәләр. Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар» драмасы татар драматургиясендә иң көчле әсәрләрдән санала. Биктимер роле спектакльнең язмышын хәл итә торган рольләрнең берсе. Аның мәгънәсе шунда — кешедә мондый тормышта яшәү мөмкин түгел, бу тормышны үзгәртмичә, кеше үзенә бәхет тә, күңел тынычлыгы да таба алмый дигән фикер, авыл

агае Биктимер язмышы аркылы, образлы итеп сәхнәдә күрсәтелә. Хәлил абыйның уйнаганын карагач, мин шаккаттым. Чөнки шул хәтле гади, табигый, тышкы яктан беркатлы булып күренсә дә, эчке дөньясы шундый бай, тирән, зирәк акыллы авыл кешесен сәхнәдә беренче мәртәбә күреп, сөенечемнән нишләргә белми утырдым. Хәлил абый сәхнәдә берсүзсез басып тора. Мин аның нәрсә уйлаганын, ниләр кичергәнен аңлап, тоеп утырам. Ул безгә, шәкертләргә, сәхнә сабагы биргән кебек булды, рольне ничек эшләргә, сәхнәдә үзенне ничек тотарга, бигрәк тә сәхнәдә уйлый белергә кирәк икәнлегенә юл күрсәтте. Андый артистны урыслар «он умеет паузу держать» диләр. Бер күренеш хәзер дә күз алдыннан китми. Тормышының иң чигенә житкән Биктимер карт улы Мирвәли яшереп калдырган пистолетны шүрлектән эзләп таба. Юк, болай яшәп булмый, монын кирәге чыгар дип пистолетны кулына ала. Менә шушы күренеш мине тетрәндерде. Авыл кешесенең кулга корал алуын актер шундый-сәнгати югарылыкта уйнады ки, минем күнелемнән менә шундый гади авыл кешеләре патша самодержавиесен бәреп төшергәннәр, урыс империясен жимергәннәр дигән бөек фикер узды. Әйткәнемчә, анда бит бер сүз дә юк, әмма барсы да аңлашыла. Әйе, чын артист менә шундый була ул! Үзара сөйләшкәндә ул, мин үз әтиемне уйнадым, ул шундыйрак кеше иде, дия торган иде.


*Х. Әбҗәлилов — Король Лир*

В. Шекспирның «Король Лир»ында без барыбыз да катнаштык. Шуңа күрә миңа аны сәхнә артыннан карарга туры килде. Әлбәттә, мин «Король Лир»ны төрекмән, таҗик, украина, урыс артистларының уйнаганын да караганым бар. Иң беренче игътибарым кыяфәтенә төште: бу — Король түгел дип әйтә алмыйсың, йөзендә үк ниндидер илаһи нур бар, сөйләшкәндә шулкадәр ышандыра ки, аны безнең арадагы тере кеше итеп кабул итәсең. Игътибар иткәнегез бардыр, корольләрне, чиркәүнең дин әһелләрен без гади кеше итеп кабул итәргә өйрәнмәгәнбез, аларның сөйләшүе, киемнәре, үз-үзен тотышлары безгә, гади кешенекенә ошамаган бит. Хәлил абыйдан сез ничек Король Лир роле өстендә эшләдегез, дип сорыйлар. Хәлил абый әйтә: «Мин дөньядагы 26 (!) артистның Лирны ничек уйнаганын өйрәндем, шуннан соң сүз бирдем: минем үз Лирым булачак, ул — татар Лиры! Татар халкының борынгы тарихында да андый вакытлар булган бит. Шуңа күрә Хәлил абыйны Англия короле дип кенә кабул итмисең. Бу — артистның уйнаган ролен үз тамашачысына якынайтырга тырышуыннан да килә. Әгәр син уйнаган роль татар тамашачысына тәэсир итми икән, ул спектакль юк дигән сүз! Хәлил абый Лир ролендә, әлбәттә, кеше язмышын ачып бирде. Иң кызыгы шул: әкрен-әкрен генә Король кешегә әйләнә. Аңлашылсын өчен бик гади мисал китерәм. Әйтик, президент булган зат эшеннән киткәч бөтенләй икенче кешегә әйләнә! Монда да шушы мәгънә салынган, король чагында ул тормышның бөтен фажигасен, рәхимсезлеген, балаларының вөжданссызлыгын күз алдына китерә алмаган, гади кешегә әйләнгәч кенә тормыш шулай рәхимсез-вөжданссыз икәнен аңлый. Гади халык мондый әшәке тормышта ничек яши ала икән, дигән фикерне жаны, йөрәге белән татыгач акылдан яза. Күз алдымда яшен вакытындагы сәхнәсе! Күк күкри, яшен яшьни, көчле давыл куба, ул үзенең иң кадерле монологларының берсен сөйли, тавышы шулкадәр көчле — ул яшеннәрне, давылларны басып китә. Үзенең бәхетсезлеген, фажигасен табигать көчләреннән өстен итеп күрсәтә. Гомумән, гаиләдәге ата белән бала арасында башланган драманың трагедиягә әйләнүен Хәлил абый шундый эзлеклелектә башкара ки, аны гомере буе трагедияләр уйнар өчен туган трагик артист итеп кабул итәсең. Сүз дә юк, драма уйнау әле бер хәл, ә трагедия уйнау артисттан чиксез зур темперамент, көчле тавыш булу өстенә, акыл белән эшләүне таләп

итә. Урыслар моны «иметь глубочайший замысел», диләр. Чөнки трагедия артист уенында ул бөтенләй бүтән баскыч. Мин санап киткән рольләрне уйнаганда Хәлил абый Әбҗәлиловның артистлык сәнгате чәчәк аткан чагы иде. Бу рольләрне уйный башлаганда аңа 40-45 яшьләр булса, мин күргәндә 60тан өстә иде. Бу инде акылның җингән чагы, безнең эштә исә ин кирәк әйбер — акыл, талантың булып акылың булмаса, мондый бөеклеккә күтәрелә алмыйсың.

Хәлил абыйны дөньяның иң бөек артистлары белән тиңләргә мөмкин: грузин Хорова, осетин Дхансаев, украин Бугма, урысның бөекләре — ул алардан һич кенә дә ким түгел иде. Мин моны үз күзем белән күргәнгә генә әйтмим, ә бит миңа шул заманның дөньядагы иң бөек артистларының уйнаганын карарга туры килде.

Комедиядә, драмада, трагедиядә мондый камиллеккә ирешкән артистлар дөньяда бармак белән генә санарлык. Юк, моны мин генә әйтмим, барча татар, урыс тәнкыйтьчеләре язып, сөйләп калдырган. Ул үзенең гомерен татар театрына багышлады. Аның данын бөтен Советлар Союзына күрсәтте. СССРның халык артисты исеменә лаек булды. Әгәр без шигъриятьтә — Габдулла Тукай, музыкада — Салих Сәйдәшев дибез икән, татар театрында исә мин күргән артистлардан — Хәлил Әбҗәлилов.

**Әзһәр ШАКИРОВ,**
*Татарстан һәм Россиянең халык артисты*

---

## «Казан утлары» елъязмасы



*Журналыбыз 1922-1930 елларда «Безнең юл», 1930-1932 елларда «Яңалиф» һәм «Атака», 1933-1965 елларда «Совет әдәбияты», 1965 елдан «Казан утлары» исеме белән дөнья күрә.*

**Февраль**

**85 ел элек (1927)** «Безнең юл»да Һади Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы;

**65 ел элек (1947)** «Совет әдәбияты»нда Габдрахман Әпсәләмовның «Ак төннәр» повесте;

**40 ел элек (1972)** «Казан утлары»нда Мөхәммәт Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романы;

**35 ел элек (1977)** «Казан утлары»нда Гариф Ахуновның «Идел кызы» романы;

**25 ел элек (1987)** «Казан утлары»нда Миргазиян Юнысның «Таңда Босфор аша» повесте;

**20 ел элек (191)** «Казан утлары»нда Гаяз Исхакыйның «Көз» повесте дөнья күргән.

Фәнис
Яруллин

# ХӘТЕР ТӨПЛӘРЕНДӘ УТЛЫ КҮМЕР

КӨНДӘЛЕКЛӘР

**1989**

**11 гыйнвар.** 8нче гыйнвардан 9ына каршы төне буе бик каты чирләп чыктым. Тәннең бөтен мускуллары калтырый, тартыша. Үзем лачма тиргә батам, үзем өшим. Бу кадәр авыр төн кичергән юк иде әле соңгы вакытта. Калтырауны-тартышуны басар өчен 2 таблетка нош-па, 1 баклафен, 1 таблетка йокы даруы эчтем. Шуларның бөтенесен эчкәч, бераз рәтләнеп (2 сәгатькә) торган иде, өр-яңадан тотынды. Иртән клизма куеп карадык, суны эчкә керттерми, спазма җибәрми.

Сәгать 10нарда врач чакырдык. Ул 3ләрдә килде. Больницага салабыз, монда берни эшләп тә булмый, ди. Өч укол кадап, больницага направление язып калдырды. Санитарлар югары этажлардан авыруларны алып төшмиләр икән. 10ысында үзеңне күтәреп төшәргә кеше тап дип шалтыраттылар. Рәшит Әхмәтҗановның эшкә яна барып кергән чагы иде, аны чакырып кайтардым. 9нчы этаждан ул күтәреп төште.

Шулай итеп, 10 гыйнвардан больницаның «тәмле» исләрен иснәп, врач һәм сестраларның: «Син һаман үлмәденмени әле?» — диюен акайган күзләре аша белдерүләрен күзәтеп ятарга туры килә.

**12 гыйнвар.** Бүген кардиограмма ясадылар. Уролог карады кичә дә, бүген дә. Бүген венадан кан алдылар. 300 г глюкоза җибәрделәр венага — система белән.

Кичә главврач обходы булды. Шундый ясалмалылык, күз буяу инде бездә. Тумбочкаларны актаралар, элгечтә торган кием-салымнарны яшерергә кушалар. Кая яшерәсең аны? Минемчә, баш врач обходны алдан белдермичә ясарга тиеш. Шул вакытта гына ул бөтен дөреслекне күрәчәк. Хәер, аларга больницадагы чынбарлык кирәк түгел, югарыдагыларга отчет өчен генә бу обходлар. Баш врач бер авыруның да хәлен сорашмый. Врачлар аңарга менә бу фәлән кеше, бусы төгән кеше дип төртеп күрсәтә дә, шуның белән вәссәлам.

Нурсөягә никотин кислотасы, В6 витамины һәм брофин бирә башладылар. Аягына рентген ясадылар. Аякларының сызлавын врачка әйткән иде. Рентгенны уң як тезгә ясадылар.

Мина йокларга назипам биреләр.

Монда жырчы Шамил Әхмәтҗанов та ята икән. Тын юлларына салкын тидергән булган, хәзер терелгән инде. Кичә безнең палатага бер егет белән кергән иде. Озак кына сөйләшеп утырдык. Сөйләшергә кызыклы адәм. 41нче елгы. Өч баласы бар.

Аның сөйләве: безнең авылда бер кызык абзый бар иде. Без шуңа чәч кырдырырга бара торган идек. Сабын юк чаклар. Шул абзый безнең чәчне бераз сабыны белән чылата да кырырга тотына. Баш бераздан кибә башлый. Абзый ике уйлап тормый, башка лач итеп төкерә. Шулай төкерә торгач, авызы кибә моның һәм ул хатынына, балаларына кычкыра: даваегыз сез менә бу башка төкерә торыгыз, мин бер тартып

*Дәвамы. Башы 2011 елның 1нче санында.*

керәм. Ул тартып керүгә баш юешләнә. Эш дәвам итә.

Шамилләр дә алты бала үскәннәр. Атасыз. Аталары мулла булган. Кайчанрак үлгәндер, сорамадым.

**13 гыйнвар.** Бүген Ш.Әхмәтҗанов чыгып китте. Аның әле шатлыклы көннәре. 4 бүлмәле квартирга күчәргә торалар...

**14 гыйнвар.** Нурсөя шул ике уколын ала. Кичә беренче тапкыр утырып бераз телефоннан шалтыраткалап, кешеләр белән сөйләшкәләп кердем. Татарлар күп. Бер палатада укый торырга китапларны сорап алдылар. Нәҗия исемле чибәр генә хатын индийский чәй керткән. Ире жилсоцбанк управляющие икән. Үзе бухгалтер – Таттрансстройда.

**16 гыйнвар.** Нурсөя монда кергәннән бирле коса да коса. Черепное давление түгелме икән, каратырга булыр, диде врач... Нурсөягә монда икеләтә нагрузка: үзе дә дәвалана, мине дә карый. Ә мине карарга таза кешеләр дә теләп тормый.

**23 гыйнвар.** 21е көнне Рәшит Әхмәтҗанов килде. Өйдә җыелган бөтен газета-журналларны алып килгән. Укырга әйберләр күбәйде. Рәшит молодец инде, һәркөнне почта ящигыннан әйберләрне алып, өйгә бер мәртәбә күз-колак булып чыга.

22се көнне Туфан Миңнуллин килде. Озак кына (ике сәгатьләп) сөйләшеп утырдык. Бик күп нәрсәләр турында сөйләшенде. Туфан беркатлы егет ул, аның белән сөйләшеп утыру җиңел, күңелле. Ләкин председатель булгач дошманнары күбәйде. Даныннан да көнләшәләр, малыннан да. СССР Верховный Советына депутатлыкка аны кандидат итеп күрсәткәч, А.лар аны әллә нинди пычраклар белән күмеп ташлаганнар...

Әдәбиятта менә шундый пычрак җанлы кешеләр күбәя. Алар, җитмәсә әле, властька үрмәләргә тырышалар, президиумда күкрәк киереп утырасылары килә. Мондый кешеләрне үзгәртеп булмыйдыр инде.

Хәзер менә язучылар съезды алдыннан әллә никадәр кеше председатель креслосы өчен көрәшүдә үзенә тарафдарлар туплый. Интригалар коралар, берсен-берсе пычраталар. Элек, председательне обком билгеләп куйганда, алай кылану юк иде. Демократия күпләрнең чын йөзен ача. Төп көч иҗатка түгел, биек урындык өчен көрәшкә китә. Шундый атмосферада ничек әйбәт әсәрләр тусын! Начарларны үтереп мактарга гына кала.

**25 гыйнвар.** Тормышның башка якларында ничектер, әмма больницага демократия, тигезлек дигән нәрсә килеп җитми әле. Һаман да люксларда тап-таза, профилактика йөзеннән генә кергән обком инструкторлары, кибет директорлары яки аларның хатыннары ята. Телефонлы, телевизорлы, туалетлы һәм ванналы люкс палаталар безнеңише кузгала алмый яткан авырулар өчен түгел.

Врачларга һәркөн диярлек кемнәрдер нидер китерә. «Мескен» врачлар көчкә күтәреп кайтып китәләр бу бүләкләрне.

**26 гыйнвар.** Кичә Нурсөя бик каты чирләде. Көне буе косты. Эчәгеләре өзелә дип торам. Шар-шар косканын бөтен больница ишетеп тора, ник шунда бер врач яки сестра кереп карасын. Чакырып керткәч тә кан басымын гына үлчәде дә, күтенә ут капкандай чыгып йөгерде. Мин дә төннәр буе лачма булып тирләп чыгам. Бер төнгә әллә ничә күлмәк алыштырам. Бернинди ярдәм юк. Көн саен сумка-сумка әйбер китергән кешеләрне генә карыйлар. Яисә обком тирәсендә эшләүчеләрне. Аларга главврач үзе клизма ясарга әзер. Бу нинди дөнья китте соң?! Башта авырткан җиреңне караганчы кулыңа карыйлар. Кулың буш икән, димәк, син авырмыйсың.

**28 гыйнвар.** Көн кояшлы, больницада ятасы килми. Уколдан веналар бик арыды, калый башласаң – качалар. Чыгып китәр идек, тик Нурсөянең күкрәгендә ниндидер төер таптылар. Әстерхан чикләвеге кадәр. Шуна операция ясарга тиешләр. Дүшәмбе яки сишәмбе ясарбыз дигән булдылар, ди. Аяклары тездән шешенә, шуна электрофарез биргәннәр иде.

**30 гыйнвар.** Гаҗәп хәл: кичә Ренат Харис килде. Өйгә дә килмәгән кеше, монда больницага, җитмәсә күчтәнәчләр белән килгән.

Нурсөягә бүген дә операция ясамадылар. Иртәгәгә калдырдылар. Иртәгә тагын ни диярләр. Миңа пока дарулар (уколларны) туктаттылар. Әллә нинди грипп сыман нәрсә әләкте, борыннан ага.

«Казан утлары»ның 1нче саныннан «Идегәй»не һәм М.Мәһдиевнен «Бәхилләшү» повестен укыдым. «Идегәй»не өр-янадан бер укырга кирәк булыр әле. Анлап житәр өчен. Ә М.Мәһдиев үз язганына үзе ышанып, илһамланып язган. Ышандырырлык итеп язганлый белү әдәбиятнын терәк баганасы инде. Бу — тимер баганада чын табигый яфраклар үстерү кебек.

**31 гыйнвар.** Узган төндә күрше палатада бер абзый үлде. Кайчандыр Апаста беренче секретарь булып эшләгән кеше.

Соңгы вакытларда йоклап булмый. Мин йокламагач, Нурсөя дә йоклый алмый. Бер төнгә унар тапкыр әйләндерә. Кайчан йокыга китәргә өлгерсен инде ул.

**2 февраль.** Операциядән соң Нурсөянен хәле бик мактанырлык түгел әле. Авырта ди. Ярты имиен турап алганнар, авыртмый нишләсен. Әле бит шунын өстенә мине дә карыйсы бар. Бүген минем тышка чыгу көне. Сестралар, санитаркалар ярдәм итешми. Мин больница караватында гына ятам. Мине төрле якка боргалау, перевязкалар ясау Нурсөягә кала.

**5 февраль.** Биргән даруларнын күбесен раковинага тондырып барабыз әле. Өйдә алай эшләмисен бит инде. Монда артыгын күп бирәләр шул. Өйдә бик нык авырганда кирәген генә алып эчәсен дә, бераз рәтләнүгә туктатасын. Монда рәтләнгәч тә бирәләр дә бирәләр.

Таныш кешеләрдән Роберт Миннуллин хатыны Клара һәм Зәки Нури ята. Клара көн саен безгә кереп йөри. Нурсөя тора алмый ятканда газеталар алып менеп йөрде. Берәр нәрсә кирәк булса, әйтегез, дип ярдәм итәргә тора үзе. Болай әйбәт кешегә ошаган. Клара исемле хатыннарнын рәтлесенә очраган юк иде, без белгәннәрнен берденбер әйбәте. Тегенди-мондый сүз сөйләсән, хәтта кызара. Кызару сәләтен жуймаган кешеләр сирәк бит хәзер. Монарда балалык бар әле.

**8 февраль.** Бүген главврач обходы булды. Ике көн буена бөтен жирне чистарттылар, кыргычладылар. Өере белән медперсонал йөрде, нинди жалобаларыгыз бар дип тә сорамады. Кайбер сорауларны әзерләп куйган идем югыйсә. Ачкан авызынны ябарга өлгергәнче чыгып та киттеләр.

Больница бик туйдырды.

Көннәр жылы. Күнелдә салкынлык.

Беркөнне костырырга тотынды. Тын алып булмый. Врачлар кайтып киткән иде инде, дежур врачны сестра чакырткан иде.

−В чем дело? − ди.

−Косам, тышка чыга алмыйм, — дим.

−Это естественно, — ди.

−Үләм бит, — дим.

−Это естественно, — ди.

Ярый әле сестрасы әйбәтрәк булды. Тынычландыргыч дарулар биреп, йоклар өчен уколлар кадап бераз рәткә кертте.

Врачлар безнен ише терелми торган авыруларга: «Күптән кисеп ягарга тиешле утын түмәре», — дип кенә карыйлар. Шуна күрә больницага сирәк керәм. Өйдә ижат эшенә кереп чумсан, авыруларын да бераз онытылып тора.

**9 февраль.** Палатага кояш төшеп тора. Тыш матур. Бүген минем туган көн бит әле. Беркөнне Гәүһәр апа Камалова кереп утырды, ул жиденче этажда ята икән. «Әнә килә автомобиль»дә уйнаган чакларын искә төшереп утырды. Мәскәүдә сатира театры куярлык әйбер иде ул, ди. Режиссерларга бераз «төртергә» кирәк, шунсыз алар әйберне куймыйлар, авторларнын башларын әйләндереп йөртәләр, ди.

Кирәк кешенен кирәк вакытта кесәсен бераз кабартырлык йөзлекләр сала белмәү мина нык комачаулады. Югыйсә «Әнә килә автомобиль»не Мәскәүнен Культура министрлыгы елнын ин яхшы пьесалары исемлегенә кертеп, русчага тәржемәсен эшләтеп, аерым китапчык рәвешендә СССРнын барлык театрларына жибәргән иде. Министрлык тәкъдимен һәм портфель тутырып акча төяп бөтен театрларга йөргән булсам, илне шаулатырлык һәм татарнын драматургиясендә драмалар гына түгел, сатира да барлыгын күрсәтәчәк пьеса иде бу. Проблемасы беренче карашка бик гади күренсә дә, анда 70нче елларда безнен илдә башланып киткән байлык артыннан куу, ләкин илнен сәясәте кешеләрне ярлылык белән авызлыклау икәнлеге сюжетнын

буеннан буена салынган иде. Ничек аны үзебезнен Г.Камал, К.Тинчурин театрлары куярга жөрьәт итте? Һәр театрда иң күп уйналган спектакль булды ул. Ләкин аны телевидениегә төшермәделәр. Эшнең нәрсәдә икәнен аңладылар бугай.

**10 февраль.** Кичә туган көнем иде. Нурсөя мондагы бер кызга акча биреп чәкчәкләр китертте. Тагын элек бу этажда эшләгән сестра – Фәридә Фатыйховна канәфер чәчәк букеты белән бер кечкенә тастымал алып килгән. Булган кадәр сыйны табынга куеп, бик күнелле сөйләшеп кофе эчтек. Дөресен әйткәндә, туган көнне мин бәйрәмгә санамыйм. Әтисез үскән алты балалы гаиләдә туган көн турында кем уйласын. «Тагын бер авыз артты инде», — дип кенә караганнардыр.

**11 февраль.** Кичә уйламаган җирдән туган көн белән котларга дип Миңлегөл апа Рафикова[1] килде. Бер букет канәфер чәчәк алып килгән. Башта ул 9ы көнне өйгә, ягъни 17нче квартирга килгән. Анда торучылар, алар 54 нче квартирга күченделәр бит, дигәннәр. 54тә дә ишек ачучы булмагач, күршеләрдән сораган. Күршеләр безнең больницада ятканны әйткәннәр. Кайсы больницада икәнне чамалап кына тапкан. Шулай итеп, мине туган көнем белән котлаучылар да табылды. Әле 10ысы көнне дәвалаучы врач та котлап чыгып китте. Ул 9ы көнне кайтып барганда Фәридә Фатыйховнаның монда чәчәк күтәреп килгәнен күргән дә, кемгә киләсең дип сораган икән.

**18 февраль.** 16сы көнне больницадан чыктык. Соңгы көннәрдә минем температурам күтәрелә башлады. Берни эшләмәделәр. Нурсөянең аяклары шешенү кимемәде. Көчкә йөри. Ә монда кочагы белән юасы кер көтеп торган. Өйләрне чистартасы. Бөтен җирне тузан баскан. Лифт эшләми. Кайткач та ярты сәгать өйгә менә алмый тордык. Алдан Рәшиткә шалтыратып куйган идек. Ул безне көтеп тунган да, өенә кереп киткән. Нурсөя менеп Рәшитне алып төште, аннары Рәшит мине күтәреп менде. Нурсөянең эше муеннан. Өйләрне бераз чистартып чыгарса, китапны әзерләп бетереп тапшырасы иде. Минем үземнең генә кулдан килә торган эш түгел. Машинкада басылган инде ул басылуын. Әсәрләрнең кайсын кая урнаштырып, эчтәлеген төзеп, битләрен куеп, гариза һәм аннотация язып илтәсе генә бар. Атна-ун көнлек эш.

**20 февраль.** Бүген Фаил Шәфигуллинны төштә күрдем. Матур гына костюм кигән. Мине килеп кочаклады, ни булыр икән?!

**28 февраль.** Февральнең соңгы көне. Яз аена керәбез. Көннәр җылы тора. +2 ләр тирәсе. Бу көннәрдә «Новый мир» журналындагы Александра Толстаяның истәлекләрен укып яттым. Талантлы булган икән Толстойның балалары да. Әлбәттә, тәрбиядән дә күп нәрсә тора инде. Һәрберсе өчәр-дүртәр тел белгән, өйдә кечкенәдән үк музыка дәресләре, рәсем дәресләре алганнар. Талантка ачылырга бөтен мөмкинчелекләр булган. Ә мин бәләкәй чакта бер алама гармун да тотып карый алмадым. Гармун уйнау – хыял иде бит югыйсә. Рәсем сәнгатен әйткән дә юк. Элекке дәреслекләрдә художникларның рәсемнәреннән репродукция дә бирмиләр иде. Безне рәсемнән Роза апа укытты инде мескен. Кая инде анарда рәсемне аңлау. Мин бер урындык рәсеме ясап китергән идем, шуна «5»ле куеп җибәргән иде. Ни өчен урындык ясаганмындыр. Кайдадыр, китапта, ахрысы, бик шәп артлы урындык күргән идем. Ә безнең ул чактагы крестьян өйләрендә артлы урындык дигән нәрсә юк инде. Сәке дә артсыз урындык. Аңсы да юк кешеләрнең — озын эскәмия. Күрәсең, шул китапта күргән урындык рәсеме мине кызыктыргандыр. Ярый инде безнең күңелдә матурлыкка мәхәббәт хисен тәрбияләүдә табигать дигән бөек укытучыбыз булган. Икенче укытучы – китаплар. Хәзер телевизордан дөнья шедеврларын күрсәтәләр. Төрле картиналар карыйбыз. Ләкин китаптан алган кадәр тәэсир юк. Бәлки, олыгайган саен матурлыкны тою хисе тупасланадыр.

Хәер, рәсем сәнгатен өйрәтүче булса, бәлки, уртачарак берәр рәссам чыккан булыр иде миннән. Ясаган рәсемнәрем күп иде бит минем. Классташларга күрсәтсәм, алар моны мин ясаганга ышанмыйлар иде. Җырчы булырга да дәртем көчле иде. Клубтан кайтканда өйгә кадәр җырлап кайта идем. Әле авыргач та, район башлыклары, мине җырлатыр өчен, су буена табын әзерләтеп Нурсөя белән мине шунда алып китәләр иде. Бер туган көндә Гөлчәчәк Галиева, ире Әхмәт абый һәм

[1] Репрессияләр кичергән язучы Мәҗит Рафиковның (1986 елда вафат) хатыны.

тагын кемнәрдер бар иде. Гөлчәчәк апа матур җырлый иде. Бервакыт мин дә ана кушылдым. Мин кушылгач, башкалар тынып калды. «Мондый тавыш, мондый моң кайда сакланган, әрәм булып яткан», — диештеләр. Бу инде артык мактау кебек килеп чыкса да, монда хаклык юк түгел иде. Мин әле дә шигырьне үзем генә калгач җырлап язам. Һәр шигырьнен үз көе була. Ләкин шигырь язылып бетүгә мин аларны онытам. Минем Рөстәм Закиров, Фердинанд Сәлахов, Асаф Вәлиевлар белән ярышып җырлаган бар...

**10 март.** Тагын икенче квартирга күченергә җыенабыз. 7 март көнне ордер бирделәр. Квартиры бик пычрак әле. Бүген Нурсөяләр шуны җыештыралар.

**24 март.** Яна квартирга килүче-китүче юк әле. Язучылардан күчүебез турында мин бары тик Т.Миннуллинга гына әйттем. Аннары күрше буларак Р.Әхмәтҗанов белә. Бу шатлыклы күченү булмады инде. Ике бүлмәлене шундый ук ике бүлмәлегә алыштыру. Тугызынчы катта да яшәр идең — врачлар менми. «Скорый» чакырткан саен Рәшиткә әйтеп булмый бит. Ул да: «Кайчан Фәнис чакырыр икән?» — дип көтеп тормыйдыр.

**4 апрель.** Бу көннәрдә үзем музыкаль комедия либреттосы белән маташам әле. Нурсөя атна буе кибетләргә чапты. Шифоньер, диван булмасмы дигән идек, юк, очрата алмады. Әле больницага да йөри, тешен куйдырып бетерәсе бар. Кичә хирургка да кергән. Операция ясаган күкрәгем бик авырта дип йөри иде. Хирург янадан операция ясарга кирәк дип җибәргән. Күз яшьләре белән кайтып керде. Тазалыгы беткәннән-бетеп бара. Тәмам эштән чыга бугай инде. Өйдә телефон да юк. Алла сакласын, юлда бер-бер хәл була калса, мин өйдә бикләнеп үләрмен. Әй, юк та инде бездә кеше турында кайгырту. Язучы дигән исем йөрткән бул, үзен бер телефон да керттерә алма инде.

Операциядән соң ана авыр күтәрмәскә дигәннәр. Ләкин мине туалетка, ваннага тураклап кертеп булмый бит инде. Житмәсә, менә күченүләр вакытында күпме китап ташырга туры килде. Берәрсен ярдәмгә чакырыр идең, телефон юк. Телефон мәсьәләсе буенча мин генеральный секретарьларга кадәр яздым. Кая күченсән дә шушы үзәккә үткән телефон мәсьәләсе алга килеп баса.

Монда өйләр дә бик суык. Эшләп булмый хәтта. Утырсан да салкын тия. Кай көнне 11-12, кай көнне 14-15ләр. Авыру кеше өчен бу җылылыкмыни?

Бу квартир бер дә шатландырмый. Бик начар эшләнгән. Идәннәре дуңгыз абзары төсле. Тәрәзәләре юньләп ябылмый. Рәтләп буямаганнар да. Ә ямьсез җир кәефне гел бозып тора инде ул. Ремонтлап керәсе калган икән дип утырабыз. Бик арыткан иде шул. Тегеләрен ремонтлау, күченүләр күпкә китте бит. Хәзер, әйберләрне кертеп тутыргач, идән-тәрәзәләр буяп йөреп булмый. Күпме әйбер кузгатасы бар. Алырга буявы да юк икән кибетләрдә.

Яз житә. Машинаны техосмотрга алып барасы бар. Анын өчен Нурсөянен медкомиссия узуы кирәк. Әле менә бу операциясен кайчанга билгеләрләр. Аны больницага салсалар мин кем белән калырмын. Уф, бу дөнья, гел борчу, гел мәшәкать, гел сораулардан тора.

**11 апрель.** Кая гына күченсәк тә, мине гел тавыш эзәрлекли. Менә хәзер безнен тәрәзә төбендә көннәр буе бер минутка да туктамыйча компрессор эшләп утыра. Бойлер тавышы ана караганда җәннәт сандугачы гына булган икән әле. Йөрәк авырта. Тавыш йөрәккә бәрә. Төнлә дә төзелеш туктап тормый. Өстәвенә, һәр төнне нindидер шакылдаулар җанга тия. Нишләп безгә генә шундый төнлә шакылдый торган күршеләр туры киләдер.

**17 апрель.** Нурсөя һаман тешләрен эшләтеп йөри. Унышлы чыкмады. Көн саен игәп җибәрәләр — нәтиҗә юк. Шунда беррәттән ГАИда техосмотр узар өчен медосмотр узып йөри. Дүрт врачтан узган инде. Тагын икәү калган бугай. Шул справкасыз машинаны техосмотрдан уздырып булмый. Машинанын ручной тормозын да каратасы бар. Тормоз эшләмәсә дә уздырмыйлар. Аны каратасы бар берәрсеннән. Көннәр дә җылына алмый. Урамнар пычрак. Температура 3-5 ләр тора. Кичә Әхтәм белән Нурсөя гаражга аккумуляторны алып барып машинаны кабызып карадылар. Майларын алыштырдылар. Тәгәрмәчләрен кабарттылар. Тормозын һәм мичен каратасы калды.

Мин соңгы вакытларда бераз шигырьләр язгаладым. Кәефләр дә шәп түгел. Эшләү авыр. Килгән газета-журналларны уку да күп вакытны һәм көчне ала. Татар телендә чыккан бөтен газета-журналларны: «Казан утлары»н, «Азат хатын», «Ялкын» журналларын; газеталардан «Соц.Татарстан», «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре» газеталарын; рус телендә «Литературная газета», «Волга», «Новый мир», «Аврора», «Дружба народов» һәм тагын әллә никадәр. Аларның бөтенесен хәрефтән-хәрефкә укып булмый, әлбәттә. «Иностранная литература» журналы белән «Литературная газета»ны тулаем диярлек укып барам. Соңгы елларда Африка язучылары роман жанрында көчәеп киттеләр. Аларны укымый булмый. Башка язучыларны уку язучы өчен файдалы һәм кирәкле гамәл. Алар аша дөньяның сулышын тоясың.

**19 апрель.** Менә берничә көннән язучылар съезды. Мин бара алмамдыр инде. Озак утырып булмый. Аннары әйдә барыйк дип кыстаучы да юк. Гомумән, минем дөньяда бармы-юкмы икәнлегемне белүче юк. Һәр язучы үзе белән генә мәшгуль. Һәркем үзе генә бөек. Рәшит тә юбилей китабын әзерләп ята, кирәргә вакыт таба алмый. Сөйләшергә телефон юк.

**3 май.** Соңгы елларда кыр казларының тезелешеп киткәнен дә, кайтканын да күргән юк иде, менә, ниһаять, быел күрергә туры килде. Бакчада раскладушкада ята идем, ниндидер ят авазлар ишетеп күккә карасам, күп булып кыр казлары очып бара. Нишләп алар бер дә безнең тирәгә төшмиләр икән? Үрдәкләр безнең кырыйдагы күлгә оялап бала чыгаралар бит. Быел кышын безнең турдагы камышны кемдер урган, үрдәкләр дә, башка кошлар да ояламас. Болай күл тирәсен әйләнеп очып йөриләр үзләре. Теге як ярда булса да оялары бардыр, күрәсең. Безнең күңелебезгә матурлык өстәр өчен курка-өркә булса да монда оя корып яталар бит алар. Ә көз житкәч, мылтыклы кешеләр шуларга ата. Бер уч ит дип бит. Жылы якларга китәр өчен төркем-төркем очып йөрүләрен карау да ни тора.

**4 май.** Тормыш гел уңышсызлыклардан гына тора башлады. Бер генә эш тә без дигәнчә булмый. Кичә антенна куйдырган идек. Хәтта шул пүчтәк тә эчне пошыра торган булды. Нәрсәдер пытырдап утыра, телевизорда төрле шытырдаулар. Көндез Нурсөя почтага барып бик каты кәефсезләнеп кайткан иде. Тәки журналларны бирмиләр инде. Һәр санны кабат-кабат барып талашып кына алмалы. Баргач та, әле ул номер килмәде, янадан килерсез дип кенә жибәрәләр. Главпочтамтка да шалтыратып карадык, газетага да язып карадык — файдасы тимәде.

**8 май.** Гел күңелсезлекләр әзәрлекли. Бүген Нурсөя машинаны гаражга илтергә киткән иде. Юлда моның машинасын арттан килеп бәрәү бәргән — машинаның сул яклап арты яртылаш изелгән. Капоты ачылмый, двигателенә дә нидер булган. Бәрдергән шофер качкан. Шунда күрүчеләр номерын әйткәннәр. Нурсөя шул ватык машинасы белән ГАИга киткән. Анда 3-4 сәгать торып кайтты. Әле менә кичке тугыз, тагын ГАИга китте. Теге бәргән машинаны эзлиләр бугай. Нишләптер Нурсөянең дә правасын алып калганнар. Ярый Нурсөянең үзенә зыян килмәгән инде.

Кич, дөресрәге төнлә, янадан ГАИга барып кайтты. Теге шоферны тапмаганнар. Мөгаен, ул исерек булгандыр, үзенең исереклеген белгертмәс өчен качкандыр. «Каблук» дип аталган «Москвич» бәргән. Икебезнең дә кәефләр шәптән түгел, жәй буе беркая чыгып булмас инде. Машинаның арты бөтенләй яньчелеп, эчкә кергән. Төзәттерергә техобслуживаниегә илтсәң, анда берничә ай ятачак. Әле янадан ГАИга ике көннән килергә кушканнар. Анда экспертизага, ягъни машинаның ни дәрәжәдә ватылганын ачыкларга кирәк икән. Соңгы елларда машинаны страховать иткән дә юк иде. Расхутыннан да бигрәк мәшәкате. Болай да һәр минут санаулы чакта. Техобслуживаниедә бөтен машинаны чишендерәләр инде, әлбәттә. Машина яңа иде бит әле. 5600 км гына йөргән. Бу соңгы вакытларда килгән бәхетсезлекләрне санап бетерә торган гына түгел. Ижат эшенә вакыт калырлыкмени монда. Жәй буе өйдә ятылса, кышка ничек көч жыярга?

**14 май.** Кичә Нурсөя ГАИга барып правасын алып кайтты. Теге безнең машинаны бәргән машинаны тапканнар. Валерий Успенский дигән бәндә икән. Кичә теге ДТПны тикшерү булган. Безне бәрдергән шоферга берни дә булмаган. Башыннан сыйпап, «Син бераз саграк йөр инде», — дип жибәргәннәр. Хәзер безнең машинаны кем төзәтә инде, дигәч, судка биреп карагыз, гаепледән тиешле бәясен тотып

калырлар, бәлки, дигәннәр. Төзәттерү бер 500 сумнарга төшәр дип әйткәннәр иде караган кешеләр. Ә минем ел буе беркая чыга алмыйча өйдә ятуымны ничә сум белән бәяләргә? Әгәр без бәрдергән булсак, безне бугаздан алырлар иде әле. Аннары бик сәер бер нәрсә: безне бәрдерүче кеше ял көнендә хөкүмәт машинасы белән үз мәнфәгате өчен йөргән. Шуна да карамастан, китерелгән зыянны ул шофердан түләтмәячәкләр икән, судка биргән очракта да зыянны безгә ул эшләгән контор түләргә тиеш икән. Нурсөягә бу хакта ГАИда шулай дигәннәр. Моннан да ахмаграк законны уйлап табарга да мөмкин түгелдер хәтта. Киресенчә, хөкүмәт машинасын үз мәнфәгате өчен файдаланганга икеләтә түләтергә иде. Ул бит хөкүмәт машинасын да ваттырган.

Бүген Нурсөя электричка белән бакчага китте. Кыярлар, редискаларны полиэтилен белән каплап калдырган идек, яныл яталардыр. Су сибеп, өсләрен ачып калдырырга куштым.

Телефон кертмиләр. Әллә голодовка игълан итеп карарга инде. Газетага хәбәр җибәрәм дә, шушы минем хәбәрне газетагызда бастырып чыгарганнан соң бер ай эчендә телефон кертмәсәләр, ачлык игълан итәм дим. Башта врачларны чакырып китерәм, ачлык игълан иткәнче сәламәтлегем нинди булуын һәм ачлыктан соң нинди булуын алар рәсми рәвештә расласыннар. Шуның нәтиҗәсендә үлеп китсәм, минем үлемемдә ГТС начальнигын гаепләгез дип язып калдырам. Чөнки безнең йортта телефон кертер өчен бөтен шартлар бар. Кабель сузылган. Һич югы элекке номерымны бирсеннәр. 100 метр чыбык сузып кертергә генә кеше табачакмын мин. Расходын да үзем түләячәкмен. Бу хакта ныклап уйлап карарга кирәк булыр әле. Инвалидларга чиратсыз кертергә дигән закон бар. Чират белән керткән очракта да бу йорт буенча мин беренче. Техник мөмкинлек бар. Законны үтәмәгән өчен нишләп аларга бернинди дә җәза юк соң? Җәзага тартылмагач, законы нигә?

**15 май.** Бүген Мәскәүдән Щекачев килеп чыкты. Озак кына югалып торган иде. Кайчандыр минем шигырьләрне тәрҗемә итеп йөргән иде, үзе дә шигырьләр яза. Хәзер кайда эшләгәнен дә төгәл генә әйтми. Бәлки, эшләмидер. Утырып та чыкты бит. Ике банка балык консервысы алып килгән бу. Менә Мәскәү күчтәнәче, ди. Чәйләр эчеп китәргә кузгала башлагач, минем материаль яктан авыр вакыт иде, теге консервылар өчен акча бирерсез инде, ди. Бирдек. Сәп-сәламәт кешеләр шул хәлгә төшеп йөрсеннәр инде. Нәрсәдән соң бу? Эш хаклары шулай әзме? Кешенең үзеннәнме? Юньләп эшләмиләрме? Аптыраган. Гомерләрен, тазалыкларын әрәм итеп йөриләр. Ә бит талантлы, югары белемле кеше. Минем шигырьләрне тәрҗемә итеп «Комсомольская правда»га яшь шагыйрьләр конкурсына ул илтеп биргән иде. Русча тәрҗемәләрем «Литературная Россия», «Волга», «Старшина-сержант» кебек газета-журналларда аның тәрҗемәсендә басылды. Русча чыккан күмәк җыентыкларда да аның тәрҗемәләре. Ул рус телендә минем шигырьләрне аерым җыентык итеп чыгарырга хыялланып, минем йөздән артык шигырьне тәрҗемә итеп, үзебезнең китап нәшриятына илткән иде. Китап нәшриятында Марс Шабаев баш редактор булып эшләгән чак. Ул, ни өчендер, Виктор Щекачевны яратмый иде. Барлык тәрҗемәләренә «халтура» дигән мөһер сугып, китапны чыгартмады. Мине дә: «Руслар өчен син беркем түгел, татарча яз, татарларга яз», — дип сүгеп ташлады. Шуннан соң мин тәрҗемәгә суындым. М.Ш.ның һәрбер сүзен мин закон кебек кабул итә идем. Ялгышымны соңрак аңладым. Рус матбугаты һәм укучылары мине онытты.

**18 май.** Бүген бу фатирга күчкәнгә ике ай. Бөтен җире йә җимерелә, йә коела. Рәхәтләнеп ремонтлыйсы бар. Линолиум юк, буяулар юк, эшләтергә кеше юк. Якынча гына исәпләсәң дә, ремонт эшләре 1500гә төшәчәк.

Менә бүген машинаның ватык җирләрен эксперт карап акт төзегән. Төзәттерер өчен 420 сум кирәк икән. Ләкин судка бирсәң, күпме мәшәкать.

**20 май.** Үзебезнең районның райком секретаре Мәүлетхуҗинга: «Машинам ватылды, монда автосервиста бик зур чират, анда районда гына төзәттереп булмасмы?» — дип язган идем. Хатны салып ике көн узгач телеграмма килде. «Кайт, эшләтербез», — дигән. Машинаны кем белән һәм ничек алып кайту турында уйлыйсы гына калды.

**24 май.** Якшәмбе көнне бакчага барып кайттык. Ватык машина белән. Бик

шатыр-бытыр килеп кенә эшли. Көн жылы иде. Бакчаның матур вакыты. Бөтен нәрсә шау чәчәктә. Тюльпаннар, сиреньнәр.

Дүшәмбе көнне суытып җибәрде. Кичә кар яуды. Бер градус салкын иде. Өч көн инде салкын тора.

Нурсөя һаман шул суд эшләре артыннан йөри. Әле машинаны төзәтә башламаган, күпме расхут чыкты инде.

Юристконсультка барды – 3 сум.

Судка заявление яздырып кайтты – 7 сум.

Ни өчендер госпошлина – 8сум 50 тиен.

Автоэксперт чакырту – 42 сум.

Әле тагын нотариуска барырга кирәк булачак икән. Мин судка үзем барып йөри алмагач, минем исемнән Нурсөягә суд эшләрен башкарырга нотариустан раслатылган доверенность кирәк икән. Бүген Нурсөя заявлениене алып судка китте, доверенностьтан башка гына. Нәрсә дип җибәрерләр. Әй бездә кәгазь волокитасы күп тә инде. Машинаны йөртергә доверенносте булгач, шуның белән бөтен эшләрне карарга тиешләр дә бит югыйсә. Шушы болганышлар аркасында авылга кайту сонарды.

**17 май.** Бүген язучыларның съезды. Мине съездга алып бару турында уйлап караучы да юк хәтта...

Ачның хәлен тук белми диләр бит. Мона кеше арасына чыгып йөрү кирәк дип уйлап караучы юк. Нурсөя гарьләнеп елап утыра. «Елама, мин әйтәм, алар синең күз яшенә торырлык түгел». Съездга барасы булыр дип кичә икебез дә әйбәтләп юынып, өс-башларны әзерләп куйган идек. Кичә юынырга кайнар су юк иде, сулар җылыта-җылыта юындык. Бүген иртүк торып костюм-чалбарларны кидем. Көнә дә матур, кояшлы. Съездда берәр тәнәфескә кадәр утырырмын, тәнәфестә кешеләр белән сөйләшеп йөрербез дип уйлаган идем. Нурсөя алдында кыен. Үз иптәшләрең шулай синең авторитетыңны төшереп йөргәч, башкалардан нинди мәрхәмәт көтәсең. Гарьлектән үләсе килә хәтта, Нурсөягә генә сиздермәскә тырышам. Ул болай да бүген көнә буе анга килә алмый йөри.

**18 май.** Кичә съездның бер көнә узды. Шундый-шундый хәлләр булды дип килеп сөйләүче юк. Сәламәт кеше булсам, бу блокнотка съезд тәэсирләрен язып барган булыр идем, хәзер үпкә сүзләре теркәп барырга кала. Шулай итеп, авыру икәненне һәртөрле хәлләр белән сиздереп торалар. Якын дусларның хыянәте аеруча авыр. Ә бит шунда утыручыларның (хәтта президиумда утыручыларның да) күбесе минем кадәр әйбер язмаган. Язганнарының да күбесен халык укымый. Гел кимсенеп яшәү туйдырды. Никадәр генә үз-үзенә мин дә башкалар кебек дип тукыма, тормыш берәр яктан китереп бәрә дә, синең башкалар кебек түгеллегенне анлата. Мин инде урамда мине белмәүчеләр турында әйтмим. Белгән, кырыена килеп йөргән, табынында чәенне эчкән кешеләрнең шулай санламавы рәнҗетә. Нинди генә үзгәртеп корулар ясасаң да, кеше күнелендәге кешелексезлекне кубарып ташлап булмыйдыр, күрәсең. Съездан кайткач бер-ике сәгатькә кереп утыра алмыйлар идеме? Берәү белән аралар 50 метр гына, икенчесе тагын да якынрак юкса. Үзе бит әле минем иҗат портретын язмакчы булып йөри. Иҗат портретын язар өчен әз генә булса да язучының үзен дә белергә кирәктер бит.

Бүген съездда докладлар буенча фикер алышулар барадыр. Бәлки, кызык фикерләр әйтүчеләр дә булыр. Кызык кына түгел, кыю фикер әйтүчеләр булырга мөмкин. Бу үзгәртеп корулар кешеләрне кыюландырып килә. Безнең буын артыгын озак йоклады. Уянырга да озак вакыт кирәк булачак. Әле аның яшь буыны да без тәрбияләгән буын бит. Алар да сүз әйтер өчен башта як-ягына карарга өйрәнгән. Әгәр өр-яңадан дөньялар үзгәреп китсә, бүген кыю сүз әйтүчеләр иртәгесен башын иеп гафу үтенергә бармаслар дигән гарантия юк. Гомумән, бездә хәзергә бернәрсәгә дә гарантия юк.

**19 май.** Кичә Әхтәм Сатеев язучылар съездында гауга күтәргән. «Нигә Фәнис Яруллин бу съездда юк? Нигә алып килүне оештырмадыгыз?» – дип сорау биргән. Т.Миннуллин: «Без аны менә хәзер алып киләбез, председатель сайлаганда», – дигән. Бер тәнәфес үткәч, Әхтәм тагын, нигә алып килмисез, дип тавыш күтәргән. Ләкин

Әхтәм дә анда артыгын кыланган бугай. Усмановтан: «Татарстанга АЭС төзергә син рөхсәт биргән дип әйтәләр, дөресме шул?» — дип сораган. Усманов озын итеп җавап бирергә тотынгач, Әхтәм аны: «Кыскарак тот», — дип туктаткан. Мин сезгә ышанмыйм, дигән. Обкомның беренче секретарена шулай дип әйтү күпләргә ошамаган, Әхтәмне съездан чыгаруны тавышка куйганнар. Күпчелек тавыш «чыгарырга» булган. Берничә кеше генә каршы килгән. Әхтәмне куып чыгаргандай чыгарганнар. Соңыннан Әхтәм янына Усманов, Шәймиев, Мостаевлар килеп, кая, синең нинди фактларың бар безгә каршы, дип, моны кыса башлаганнар. Мин сезгә караганда Наумовка ныграк ышанам. Ул фактларны «Народный фронт»та әйтте, дигән Әхтәм. Наумов дигәне «Веч.Казань» корреспонденты икән. Усмановлар, фактларны табып китер, дип моны кыса башлагач, хәзер шундый вакыт җитте, үзегезнең гаепсезлегегезне исбат итәр өчен сез үзегез халыкка барырга тиешсез, дигән Әхтәм. Болар обкомга кадәр бергәләп кайтканнар. Әхтәмнең адресын язып алганнар. Претензияң булгач, нигә моңарчы обкомга килмәдең, дигәннәр. Мин әллә ничә тапкыр килдем, кабул итмәдегез, дигән Әхтәм. Шулай итеп, шактый тавыш кубарган инде ул анда.

**20 май.** Рәшит килеп съездда булган хәлләрне сөйләп чыгып китте. Председатель итеп Ринат Мөхәммәдиевны сайлаганнар икән. Председательлеккә кандидатлар күп булган. М.Мәһдиев, Р.Харис, Р.Вәлиев, Р.Фәйзуллин һәм Т.Галиуллин. Тәлгать үз кандидатурасын үзе алган. Иң күп тавышны Р.Фәйзуллин белән Р.Мөхәммәдиев җыйган. Соңыннан икесенең арасыннан Р.Мөхәммәдиев җиңеп чыккан. Нәшрият директоры постыннан җайлы котылган. Анда бит эш эшләргә кирәк. Ә Союз председателе бернәрсә өчен дә җавап бирми. Почет зур, депутат булу мөмкинлеге бар. Эш хакы шәп. План үтисе юк. Обкомга чакырып, нигә язучыларыгыз начар яза дип сүкмиләр. Зам. һәм секретарь итеп кемнәрне алыр икән? «Казан утлары»нда Р.Харис калган. Харис белән Мөхәммәдиев дуслар бугай, бәлки, йөкне бер яккарак өстерәрләр...

Ринат Мөхәммәдиев, әлбәттә, эшне нечкәрәк эшләр. Ул бик йомшак кына итеп, еракка карап үз теләгенә ирешә торган кеше. Бәлки, председательлеккә шундый кеше кирәктер дә. Прозаик буларак әйбәт кенә үсеп килә. Тәнкыйтьтә әллә ни тирәнгә керә алмаган иде. Бәлки, ул анда үзенең йомшаклыгын сизгәндер дә. Аннары шунсы да бар: тәнкыйтьчене бит әле язучы дип санамыйлар. Тәнкыйть китабын кем укый инде аны? Язучы булып танылсаң шәбрәк бит. Ринат хәзер хут алды. Повестьлар язды, ниһаять, роман! Язган әйберенне шунда ук басарга торсалар, яхшы якларын күрергә тырышсалар, әсәрләр языла бит ул. Бер уңыш икенчесен тудыра. Язсыннар, әлбәттә. Яза алганда, эше уңайга барганда язучы язарга тиеш. Яза алмаганын сизсә, туктарга да ярый. Ләкин күбесе үзләренең күптән яуланган исемнәрен үтереп үләләр. Үзеннән алда исемең үлсә, язучы өчен иң яманы шул инде.

**24 май.** Узган якшәмбедә бакчага барган идек. Җәүдәт Дәрзаманов килеп утырды. Съезд хәлләре турында сөйләде. Илдар Низамов та бераз ул хәлләргә кагылып узды. Әхтәм Сатеевны Илдар Әфганнан кайткан егет дип уйлый икән. Шуна ул бик кыю чыгыш ясады, ди...

«Вечерняя Казань» газетасының 22 май санында Юрий Афанасьев дигән тарихчының бик шәп мәкаләсе чыккан. Ул анда Маркска, Ленинга да кагыла. Һәм бик ышандырырлык дәлилләр китерә. Ленинның: «Империализм – капитализмның иң югары һәм соңгы стадиясе» дигән концепциясенең расланмавын әйтә. Капитализм соңгы елларда нык үсте, демократия юлында яңа адымнар ясады, ди. Ә социализм киресенчә бар яктан да таркалуга барды, ди.

**9 август.** Менә тагын көзгә килеп кердек. Җәй сизелми дә үтте. 29 май көнне ватык машинаны авылга алып кайттык. Тагын шул Әхтәм Сатеев белән. Нурсөя Казанда калды. Райком секретаре үзе чакыргач, кочаклап алыр инде дип көткән идем. Каршы алу түгел, янга да килмәде. Аның сүзләре чыш-пыш булып чыкты. Йөри торгач, төзәтә белүче кешеләр табылды тагын.

*Дәвамы киләсе саннарда*

*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнен сәхифә!



Мин, **Нотфуллин Илнар Илдус улы**, егерме ел элек Кама Тамагы районының Балтач авылында туганмын... Урта мәктәптән соң, үзе дә укытучы булган әнием киңәше белән Казанга, Татар гуманитар-педагогика университетына укырга килдем. Кечкенә вакытымда әтием кебек механизатор булырга хыялландым, ләкин хәзер сөенәм генә: авылда андый эшләр калмады. Иҗатка кереп китү авыр булмады миңа — әз-мәз генә әдәбият буенча белемнәр Иделгә кушылган Чулман шикелле үзеннән-үзе алып киттеләр, һәм инде, әлбәттә, мәхәббәт!..

## Елыйсы килә

**Күңелемә урын эзләгәндә,**
**Барлык дөньясына төкереп,**
**Биеклектән җирне күзләгәндә**
**Зәңгәр чиксезлектән йөгереп,**
**Хыялымда җәннәт төзегәндә,**
**Тормышыма таба үрелеп,**
**Кинәт бушап калды ошбу дөнья,**
**Җәһәннәмгә төштем ишелеп...**

**Күңел тулган вакыт, авыр миңа,**
**Уйлыйм шунда юк−бар нәрсәләр.**
**Эчтән генә нидер көйләп йөрим,**
**Күзләр күрми...**
**Нәрсә күрсеннәр?**
**Бушатырга иде авыр йөкне,**
**Ничек итеп? Ягез, кем белә?**
**Елау егет эше түгел, әйе...**
**Ләкин... Их, бер елыйсы килә!..**

## Бу көн

**Өч сәгатьтән ун тулганда тордым бүген.**
**Ләкин минем уйда әле уку түгел...**

**Күңел байлыгын арттыру − рухи бурыч.**
**Ләкин һәр сүз күңелемә сибә борыч...**

**Милли бурыч − икенчесе, ләкин иртән**
**Башка болар килми әле, булды, китәм!**

**Юк инде, юк, китмим − очам!**
**Юк инде, юк, очмыйм − кочам!**

**Кемне кочам? Хыялымны инде фәкать.**
**Әнә, таң ата бит, төшкән шафәкъ.**

**Нинди рәхәт! Иде... Әйе, иде.**
**Ул вакытлар чөнки хәзер башын иде...**

## Бәхет

Кирәкми миңа галәм,
Чөнки мин төгәл беләм:
Җирдә минем кояшым...
Караңгыда калсам да,
Төн уртасы булса да,
Кызганмас ул нурларын...

Кирәкми мина тәхет,
Минем өчен зур бәхет —
Синең серле елмаю.

Кирәкми миңа алтын,
Минем иң зур байлыгым
Мәхәббәттән таң калу...

Яратам мин, гүзәлем,
Сине бик нык, беләсең,
Җуеп булмас акылны...
Кояшым син, бәхетем,
Минем алтын тәхетем!
Һәм күзләрең ягымлы...

## Нокта

Чынлап әйтәм!
Инде күптән
Шигырь язу туйдырды.
Кара паста,
Шунда аста
Зур бер нокта куелды...

Өчәү, әйе,
Түгел гаеп —
Калды әйтәсе сүзләр...
Җаным читкә
Китә миннән
Һәм йөри мине күзләп...

Бар юк булды,
Көлке колы
Әйләнде сатирага;
Акка ага
Минем кара
Һәм юкка чыга бара.

Әйтер сүзләр,
Калмый эзләр —
Күп түгел икән алар.
Шуңа күрә
Хәзер менә
Нокта куела ала.

## Очраклылык

Һәр кеше дә бу дөньяга
Очраклы гына туа,
Син булмасаң булырмын мин,
Мин булмасам ул була.

Тормышта булган һәр нәрсә
Бара үзеннән-үзе,
Кемнеңдер язмышы ачык,
Кемнеңдер суык эзе...

Үзе теләгәнчә карый
Бу тормышка һәр кеше,

Ләкин тормыш аңламыйдыр,
Ыржайтып усал тешен.

Ышанабыз һәм телибез
Без бары тик яхшысын,
Ләкин язмыш куя безнең
Алга бары каршысын.

Очраклы шул, киләчәктә
Без кемнәргә очрарбыз?!
Ярдәм итә күрсен бары
Безгә изге Аллабыз!

## Әйдә, киттек!

Әйдә, киттек!
Кая? Дисең.
Кая булсын, беләсең.
Күккә меник.
Йолдызлардан
Ясап бирәм беләзек.

Әйдә инде!
Ерак! — дисең.

Ерак түгел, якында.
Безнең анда менгән дә бар —
Күкнең соңгы катына...

Тизрәк, тизрәк!
Җир һәм кояш
Безгә карап көнләшсен!
Җидегән йолдыз белән эчик
Күктән сөю чишмәсен...

*«Хикәя яза аласызмы?»*

***9нчы санда шундый конкурсның «2нче сериясен» ачкан идек. Беренче хикәяләр 11нче санда басылды. Хикәяләр килү дәвам итә.***

# МИН СЕЗНЕ ЯРАТАМ!

**«Камил Сәлимович! Мин сине яратам!» — кара тактага шулай дип язылган иде! Яшь укытучы кулына акбур алды.**

— Йә, кайсыгыз бу җөмләгә тулы синтаксик анализ ясый? Әйдәгез, әйдәгез, кыюрак булыгыз!

Бу җөмләне кат-кат эченнән укыган Алсу Камил абыйларына назлы гына карап куйды. Аның куе чәче, кара күзе, киң җилкәсе.... әсир итте аны. Үзен укытучы егет кочагында хис итте кыз... Татлы хыялларга бирелеп, Алсу тәмам онытылган икән, берәүнең төрткәненә сискәнеп китте. Артына борылып караса, Ләйсәнне күрде. Ул шыпырт кына аңа:

— Алсу, әйдә, син. Синең татар телennән болай да «бишле» чыга, аннары... үзең беләсең. Син миннән моны бүтән яшерә алмыйсың, беләм мин. Әйе, Камил абый әйбәт, яхшы, җитмәсә, матур да.

— Ләйсән, юк, чыкмыйм. Мин аның күзенә ничек туры карыйм ди? Оялам да аннары...

Бу пышылдашуларны Камил Сәлимович та ишетте.

— Арттагы ике парта, нәрсә, «базар оештырабызмы»?

— Юк, Камил абый, без түгел ул, — диде тегеләр.

— Ярар, кызлар. Әйдә әле, Алсу, син чык әле. Беләм, булдырасың син. Әйдә, әйдә.

— Мин... Мин, — дип, урыныннан торды, тик юньләп бер сүз дә әйтә алмады кыз.

Тактага чыгуга ук, башта каушап калды, ничегрәк тотыныйм дип уйланды. Бу арада класс гөжли башлады. Арттан берсе:

— Алсу, булдырасың син, без сиңа ышанабыз, — диде. Икенчесе исә:

— Әй, Алсу, уку алдынгысы булып, шуны да эшли алмыйсыңмы, — дип оялтырга кереште. Укытучы да үз сүзен әйтте:

— Ярар, ярар, тавышланмагыз, ул бераз каушады гына, хәзер эшләр. Әле сез аңа рәхмәт әйтергә тиешсез. Ул үзе чыкты бит, әнә, башкалар чыксын дип әйтмәде. Алсу, әйт әле, матурым, нигә эшләмисең, аңлата алмыйсыңмы?

Ә Алсуның башына әллә нинди уйлар килде. Ул бераз кызарды, тагын агарынды. Җитмәсә, бу уйларга «матурым» да килеп кушылды бит. Һич көтмәгәндә Алсу укытучы егетнең күзенә туры карады, Камил абыйсы да аңа карап тора иде. Ике күз бергә очрашты, алар арасында нур сызылды. Кыз, фикерен дәлилли-дәлилли, җөмләгә анализ бирде.

— Бик дөрес, Алсу. Синең булдырачагыңа ышанган идем. Утыр, «бишле!»

Тик нигәдер Алсуның аяклары атламас булды.

— Алсу, утыр, «бишле». Берәр нәрсә әйтәсең киләме әллә?

Алсуның тизрәк чыгып йөгерәсе килде. Ләкин ярамый шул. Әкрен генә урынына барып утырды. Бераздан дәрес тә тәмамланды. Укучылар тәнәфескә таралышты. Алсу гына урынында утырып калды. Камил абыйлары да, чыгарга җыенып йөргәндә, Алсуның моңсуланып утырганын күрде, чыгып киткәнче, нәрсә булганын сорарга

дип, анын янына килде. Кыз анын якынлашуын күрмәде, үз уйларына чумган иде.

— Алсу, ни булды сина? – дип сорады укытучы.

Күтәрелеп караса, Камил Сәлимович анын янында тора.

— Бернәрсә дә булмады, Камил абый. Нигә сорыйсыз?

— Алдалама, Алсу, мин нидер сизәм. Сине үпкәләттемме?

— Юк, абый, үпкәләтмәдегез. Бераз монсу гына мина.

— Ярый, минем дәресләрем бар. Берәр ярдәмем кирәк булса, яныма килерсенме?

— Ярар, керермен...

Укытучы ишеккә юнәлде. Алсу, кеше сизмәсен дип, әкрен генә еларга тотынды. Анын күзеннән шатлык яшьләре тама иде...

**«Ярattыручы»**[1]

## УЛ «АЙГЫР» НӘСЕЛЕННӘН...

**Укытучы егет класска килеп керү белән унберенченең, кызлары бердәм хихылдаша башладылар.** Ринат Рөстәмович, каушамаска тырышып, тактага күз ташлады. Исәбе такта сөртелмәгәнлекне исләренә төшерү иде. Тик тактадан үзләренен нәселдән нәселгә күчеп килгән кушаматын — зур хәрефләр белән язылган «Айгыр» сүзен укыды. Бу оятсызлыкка яман ачуы чыкты анын. Алай да үз-үзен тиз кулга алды. Класска карап елмайды да, якын дустына сер сөйләргә җыенгандай әкрен тавыш белән:

— Ә беләсезме, кызлар-егетләр, безнен нәсел нигә «айгыр» кушаматын йөртә? — дип сорап куйды. Кайберәүләр хихылдашып алса да, күпчелек укытучынын тыныч реакциясеннән унайсызланып калды. Алай да, кызыксынулары җиңде. Колакларын торгызып дигәндәй, тынларга әзерләнделәр.

— Әле сугышка кадәрге чорда ук минем бабамнын атасы Салават бик мәһабәт гәүдәле бер таза кеше булган. Үзе бик көчле булса да, Сабан туенда күп тапкырлар батыр калса да, мал-мөлкәте әллә ни булмаган анын. Алай да бер ат һәм бер сыер, сарыклар асрап көн итәргә тырышкан. Шулай бервакыт, җәен печән чапканда, аты сырхаулап китә анын. Ин кирәк вакытта бит! Янгырга чылатмый гына чапкан печәнне ташып каласы килә бабайнын. Ун күршесенә керә ат сорап — күрше авылга китеп барышлары икән, буш кул белән борылып чыга, сул күршесенә керә — тагын ат үзләреннән бушамый. Шуннан бабай нишләсен, авыл халкы көләр дип уйлап тормый, ат арбасына үзе җигелә дә, китә болынга, карчыгы да янәшәсеннән бара икән сәнәген тотып. Авыл урамын чыкканчы әллә ничә әче телле кеше белән очрашалар алар. Берсе хәтта әбиемә:

— Маһинур, сезнен атыгыз, тай иярткәч, бия дип йөри идем, айгыр икән ләбаса! — дип бот чабып көлә. Менә шуннан «Айгыр»лар нәселе булып калганбыз инде. Сез көләргә маташсагыз да , мин кушаматымнан оялмыйм, укучылар, минем бабамнар кыенлыклар алдында югалып калмаганнар. Мин әнә шундыйлар нәселеннән, икенче юк белән кайнашмагыз, — шулай дип сөйләп бетерде дә укытучы, тактаны сөртергә кушты. Тик беркем дә сөртергә атлыгып тормады. Әллә хикәя тәэсиреннән чыга алмадылар, әллә кем язган, шул сөртсен диделәр инде — кымшанмыйча утыра бирделәр.

Ринат Рөстәмович тә, укучыларга сынап кына карап, сөртеп алуларын көтә бирде. Башлар аска иелде. Берничә минутка сузылган тынлыкны Язилә бозды. Ул житез генә чыгып тактаны чистартты. Класс жинел сулап куйды. Укытучы үткән дәрес материалы буенча тест эшләтеп алды, яна теманы анлатты. Яна темага кагылышлы күнегүләрне берәм-берәм такта алдына чыгып та, дәфтәрдә дә эшләп карадылар. Барысы да үткән дәресләрдәгечә булды. Тик Язилә генә, укытучысынын үзенә

[1] Исемен язарга оныткан авторга шундый исем куштык. Ред.

төбәлгән усал карашын күреп, борчуга төште.

Юкка түгел иде анын борчылуы. Озын тәнәфестә ялгызы гына ашханәдән чыгып килгән кызны Ринат Рөстәмович буш кабинетка чакырып кертте.

— Ник яздың? — диде ул, кызның күзенә карап. Язиләнең керфекләре тибрәнеп китте, алардан, үзе дә сизми калды, яшь бәреп чыкты.

— Мин түгел, мин аны сездән оялып' кына сөрттем, яла якмагыз! — диде дә, нагытып елап җибәрде Надия.

— Йә, елама. Син сөрткәч, син дип уйлаган идем, ялгыштым, гафу ит, яме, диде укытучы, унайсызланып.

— Юк, сез безне гафу итегез, Ринат Рөстәмович, — кыз, битен куллары белән томалап, йөгереп чыгып китте.

Өч елдан соң, шушы егет белән тормыш корып, үзенең дә «Айгыр» кушаматы аласын белми иде шул әле ул.

**Әлфия МӘРДӘНОВА**
*Апас районы, Акхуҗа авылы.*

# ОЧРАШМЫЙЧА КҮРЕШҮ...

**Алар аерылышып, инде елыйсы еланып, бер-берсе турында яманы да, яхшысы да сөйләнеп онытылып бетте дигәндә, ул Аны янәдән очратты.**

Очратмады шул, күрде генә... Югыйсә атна буе, юк, кая инде атна гына, илле ел буе ул бу очрашуны көткән иде бит! Күрде, әмма исәнләшә дә, сөйләшә дә, аралаша да алмады. Ник дигәндә, бу очрашу, бу күрешү бер генә яклы булды. Дөресрәге, Хатын Анын белән исәнләште, хәлләрен дә сорашты. Ул гына аны күрмәде, хәтта ана карамады да...

— «Әтнә районы үзешчәннәре җырлый» дип, атналар буе реклама карагач, аны күрәсенә Даниянең иманы камил иде. Ничек инде атаклы гармунчы, оста баянчы бу тапшыруда катнашмасын ди? Катнашачак, билгеле!

Әнә бит, икенче рәттә ак күлмәктән, кара чалбар, чигүле түбәтәйдән ул утыра. Еракта калган яшьлегенең якын, кадерле танышы. Якын бит Ул ана, бик якын! Ул — анын якташы гына түгел, ул анын яшьлеге, җырлы-биюле, хыяллы-өметле, кайнар карашлы, дәртле-ашкынулы яшьлеге бит ул анын!

...Кышның әкияти матур, сихри, мамыктай кар бөртекләре ишелеп-ишелеп яуган ап-ак көннәре иде. Алар, биш-алты кыз-бала — мәктәп укучылары — бер ат чанасына төялешеп, күрше авылга концерт куярга баралар.

Гармунчылары — күрше авыл егете, чибәр, каһәр! Сөрмә күзле, ут карашлы, ә исеме нинди матур — Фирдүс! Ундурт-унбиш яшьтә генә булсалар да, кызлар егетләр белән дуслыкнын да, мәхәббәтнең дә ни-нәрсә икәнен беләләр иде инде (алар бит бик иртә «өлгерәләр», мәхәббәт турында күп укыйлар, акыл белән түгел, йөрәк белән уйлыйлар һәм яраталар, егетләргә караганда хисчәнрәк тә булалар).

Кышлар үтеп, язлар килде, гөрләвекләр йөгерештеләр. Авылның яшь кызлары үз мәхәббәтләрен сабыр гына көтеп яшәгән ул язларда да, көттереп кенә, шомырт чәчәкләре исеннән башлар әйләнгән, зәңгәр күктә якты йолдызлар күз кысышкан сихри моңлы, назлы һавалы, бака тавышлы ямьле май кичләре килде.

Клуб эче яшьләр белән тулган. Фирдүснең өздереп гармун уйнауларын, егет-кызларның очынып, хисләнеп-дәртләнеп биегәнен-җырлаганнарын, уен уйнаганнарын исәннәр барысы да хәтерлидер әле. Их, бар иде яшь чаклар! Ә кызлар? Ана гашыйк түгел идек дип кайсыгыз әйтә ала, йә?

Исәнме, дустым! Бәхетлеме син, ерактагы якын кешем? Мин сине онытмадым. Яшьлекне онытырга мөмкинме соң? Бәхетле балачак, дәртле үсмерчак! Күңелләрне ымсындырып, күкләргә күтәреп, хыялланырга, шатланырга, моңланырга, тормышны яратырга, яхшы һәм якты күңелле кеше булырга өйрәткән тальян моннарын, гармун җырларын, баян көйләрен өчен мең рәхмәт сиңа. Якташым! Синең үзеңне күреп

сөйләшү, аралашу, тыңлау бәхетенә ирешкән меннәр дә бу сүзләргә кушылып, рәхмәт әйтерләр дип уйлыйм мин.

Җыр-моң безгә көч һәм яшәү дәрте, өмет-ышаныч бирә бит ул. Димәк, син, кешеләргә гомерең буе җыр-моң өләшкән зур талантка ия кеше, — көчле дә, ышанычлы да, бөек тә.

Даниянең атна буе Фирдүсне күрәсенә ихлас ышанып, илле ел буе ышанмыйча көткән, утыз минутка сузылган «Җырлыйк әле» тапшыруындагы бу күрешү-очрашу шулайрак узды. Дания бәхетле иде...

**Надия ВӘЛИЕВА,**
*Казан*

---

**Биредә файдаланылганнардан тыш тагын дүрт башлам бар. Менә алар:**

*Кунакханәнең мин туктаган бүлмәсе кояш карый торган якта булып, төн уртасы якынлашуга карамастан, һаман бөркү иде. Йокыга китә алмаячагымны аңлап, диңгез ярына чыктым...*

***

*Халык агымына ияреп җир астына төшеп барганда Аяз сискәнеп китте: аның аяк очында — эскалаторның көмеш баскычында — ике нәни песи баласы утыра иде. «Карале син, әй, болар да Тукай мәйданында булачак пикетка ашыгалар, ахрысы!» — дип уйлады егет.*

***

*Айратның бармаклары шуып китте һәм Фәридәгә диган СМС ялгыш Миләүшәгә «очты»: «Мин бер сәгатьтән килеп җитәм. Чәеңне куя тор».*

***

*Яшь адвокат Нуриев кесә телефонының онытылып калганын вокзалга килеп җиткәч кенә сизеп алды. Такси тотып, тиз генә яңадан фатирга кайтып килергә кирәк иде.*

*Кайтса... Кыңгырау сүнгән, тимер ишек эчтән бикле.*

**Бу җиде башламның һәркайсын үзегезнеке итә аласыз. Ләкин хикәячекләрнең күләме бер журнал битеннән артмаска тиеш.**

---

**Узган сандагы ребус җавабы:**

«Балаларга өлкәннәр өчен язган кебек үк,
әмма тагын да яхшырак язарга кирәк».

---

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*
*E-mail: kazanutlari@yandex.ru*

## Күзләрең ачык, колакларың тырпайган булса

Казансуның исемсез кушылдыгы буйлап елга ярына таба атлыйм. Инешнең бераз гына тирәнрәк, агымы бик сизелми торган тыныч урынында су өстендәге көчле чупылдау дикъкатемне җәлеп иткәч, тукталып, куаклар арасыннан шыпырт кына күзәтеп торырга булдым. Казансудан сай, шарлавыклы инешкә нинди «крокодил» килеп кергән икән дим. Озак көтәргә туры килмәде. Койрык белән бәргәндәге кебек дулкын кузгалды, су өслегенә якында гына йөзеп йөргәнниндидер зур балык, кинәт борылып, агымга каршы менеп китте. Кояшның су өслегеннән кайтарылып уйнап торган нурлары күзне чагылдыра иде, шуна күрә балыкны бүтән күзәтә алмадым.

Кайтканда әлеге балык чупылдаган урында янә тукталдым. Шактый вакыт узган, кояш нурлары күзәтү өчен унайлы юнәлештә төшә иде. Ни хикмәт, баксам, суда зур балык түгел, ә бихисап маймычлар дисән, маймыч «яше»ннән өлкәнрәк булсалар да олыгаеп житмәгән үсмер балыклар төркеме йөзеп уйный имеш. Балыкларның барысының да ничектер бер, бөтен организм шикелле үзара бәйләнештә, көйләнеп хәрәкәт итүләре шаккатырган иде. Спортчы гүзәл затларның «синхронлы йөзү» дигән чыгышларын телевидение аша гына булса да күргәнегез бардыр, мөгаен. Андый «шоу»да спортчы кызларның барысы да бер үк хәрәкәтләрне башкара. Ә биредә төркемнен судагы хәрәкәтләре бер зур балыкның хәрәкәтләренә охшаган, вак балыкларның төрле төркемчекләре аның аерым органнары вазифаларын башкарган шикелле иде. «Зур балык»ның «башы» һәм «койрыгы» урыннарындагы төркемнәр бер үк мизгелдә тиешле хәрәкәтләрен кирәкле юнәлештә башлап җибәрәләр: төркемгә хәрәкәт юнәлешен үзгәртергә, мәсәлән, сулга борылырга кирәк булганда, «зур балык гәүдәсе» сул якка «кәкрәя» иде, ягъни балыкларның «койрыктагылары» да, «баш»та йөргәннәре дә сул якка каерылып борылалар иде. Кыскасы, бихисап вак балыклар ниндидер серле дирижерның миңа ишетелми һәм күренми торган командалары буенча бөтен төркем өчен кирәкле хәрәкәтләрен тиешле мизгелләрдә башкарып та, үзгәртеп тә торалар. Бу балык затларын нинди «дирижер» идарәле икән? Ул «оркестрант» балыкларына тиешле сигналларын ничегрәк житкерә икән?

Менә шундый «сәер» сораулар баш миемне шактый күп еллар буена бораулап аптыраткан иде. Аннан да әлегрәк булган сәер вакыйгалар да исемә төште. Ниһаять, дүрт ел чамасы элек мин фәкыйрегез Альберт Эйнштейнның атом энергиясен файдалану идеясен тудырган масса белән энергия бәйләнешын тасвирлаучы тигезләмәсенә информация дигән зурлыкны да «кыстыру» кирәклеген аңлый алдым.

Бу язма кысаларында барысын да тасвирлау мөмкин дә түгел, кирәкмәс тә. Бер генә җөмлә белән әйткәндә, фән даирәләрендә информация дип атала торган мәгълүматны масса һәм энергия белән тыгыз бәйләнештә торучы реаль зурлык дип күзаллаган очракта безгә әлегә аңлашылмый торган шактый күп вакыйгалар һәм күренешләрнең серенә төшенү мөмкин булачак. Мәсәлән, кайбер очракларда юш килә торган төш күрүләр, ниндидер мөһим вакыйга булачагын алдан сиземләү кичерешләре, якын туганың белән булган хәвефле вакыйга турында белмәгән очракта да борчылулар...

Шундый фикерләремне галим халкы тарафларына рәсми форумда житкерү форсаты да чыкты. 2011 елның август аенда, Халыкара астрономия һәм космонавтика конференциясендә, докладым әчтәлеге буенча конференциянең көн тәртибе темаларыннан шактый ерак булса да, чыгышымны делегатлар унай кабул иттеләр. Хәер, моны аңлатырлык сәбәбе дә бар иде: астрономнар кызыксынып өйрәнә торган «караңгы энергия» һәм «караңгы материя» проблемаларын хәл итүгә дә докладымның әчтәлеге этәргеч дип кабул иттеләр делегат коллегаларым.

**Ким ШАКИРОВ**

## Камил Сәгъдәтшинга 60 яшь



Камил Сәгъдәтшин — 1952нче елның 29нчы февралендә дөньяга килә. Урта белемне туган авылы — Иске Рәҗәп мәктәбендә ала. Районда чыга торган «Яңа тормыш» газетасында мәктәптә булган кызыклы вакыйгалар турындагы язмалары белән катнаша, каләмен чарлый. Шулай ук «Татарстан яшьләре» газетасы, «Ялкын» журналының да актив хәбәрчесе була. 1969нчы елда исә Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә.

Камил Сәгъдәтшин профессиональ журналист буларак хезмәт юлын 1974нче елда, университетны тәмамлаганнан соң, Казан телевидениесендә яшьләр өчен тапшырулар мөхәррире булып эшли башлый.

1976нчы елдан Татарстанның комсомол өлкә комитетында эшли. 1978-1982нче елларда КПССның Татарстан өлкә комитеты газета-журналлар нәшриятында партия оешмасы секретаре вазифасын башкара. Аннан соңгы елларда профсоюзларның «Яңа аваз» һәм «Новое слово» газеталарының берләштерелгән редакциясендә баш мөхәррир, бер ел «Казан утлары» журналында җаваплы сәркатип булып эшли. 1992нче елдан исә «Ватаным Татарстан» газетасында бүлек мөхәррире, газетаның авыл хуҗалыгы, авыл тормышы, җәмгыять-көнкүреш темаларын яктыртып язучы әйдәп баручы журналисты.

Камил Сәгъдәтшин — кешеләр белән аралашып, җанлы тормыш эчендә кайнап яшәргә ярата. Башкалабызда туган якларыннан читтә яшәүчеләр берләшеп якташлык җәмгыятьләре барлыкка килә башлагач, ул «Болгар» якташлык җәмгыяте оештыра, аның рәисе булып сайлана.

Язучы буларак, К.Сәгъдәтшин ике шигырь китабы авторы. Аның иҗаты лирика, сөю-сәгадәт темаларын эченә ала, күпсанлы җырлары үзешчән композиторлар тарафыннан көйгә салынган. 1996 елда Казанның «Стар» нәшриятында «Җан ярам», 2002 елда «Идел-пресс» нәшриятында «Янам әле хәзергә» дип исемләнгән шигырь җыентыклары басылып чыга. Ул чәчмә әсәрләр дә иҗат итә, «Рәнҗү» исемле повесте, күпсанлы хикәяләре матбугатта дөнья күрде.

Камил Сәгъдәтшин 2002нче елда әдәбияттагы һәм журналистикадагы уңышлары өчен «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек була. 2007нче елда Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителә.

## Рөстәм Зариповка 60 яшь



Шагыйрь һәм публицист Рөстәм Зарипов әдәбиятка язучыларны мул биргән як — Саба районы Түлешкә авылында 1952нче елда дөньяга килә. 1974 елда Саба урта мәктәбен тәмамлаганнан соң Казан төзүче инженерлар институтында белем ала, инженер белгечлегенә ия булып төзелештә инженер, юл төзелешендә мастер һәм башка оешмаларда үз белгечлеге буенча хезмәт куя. 1984-1990 елларда исә Мөслим милиция бүлегендә сәяси эшләр буенча башлык урынбасары, аннан соңгы елларда Шәмәрдән магистраль газүткәргечләр идарәсе башлыгы урынбасары, «Таттрансгаз» җәмгыятендә техник күзәтү инженеры булып эшли.

Мәктәп яшеннән үк матур әдәбиятны яратып, үз итеп үскән Р.Зариповның беренче хикәясе 1976 елда «Идел» альманахында дөнья күрә. Рөстәм Зарипов үз шигырьләренә үзе көйләр дә яза. 80нче елларда аның «Тамчы гөл» җыры яратып җырлана иде. Шулай ук «Мөһаҗир җыры», «Бүре» һ.б. җырлары да сәхнәләрдән еш яңгырый.

Р.Зарипов холык-фигыле белән милләтпәрвәр, халкыбызның киләчәге, мәдәнияте-әдәбияты өчен борчылып яшәүче кыю фикерле, үзенчәлекле шәхес. Татар әдәбияты белән танышып барып, үзен борчыган мәсьәләләрне киң яктыртып, республикабыз матбугатында үткен язмалары белән чыгышлар ясый. Әнә шундый рухтагы язмалары, шигырь-юморескаларын туплаган «Тамчы гөл» исемле беренче китабы 1999 елда Казандагы «Мәктәп» нәшриятында дөнья күрә.

«Тамчы гөл»дән соң Рөстәм самими лирикадан зәһәр сатирага, төртмәле һәм гамьле публицистикага кадәр үсә алды. Алай гына да түгел, язучылыкның шул өлкәләрендә, бүтән һичкемгә охшамаганча, үз почеркын булдырды», — дип яза аның турында каләмдәше З.Кыдашева. («Татарстан яшьләре», 2004 ел, 27 март) Бу җәһәттән публицистик язмаларын туплаган «Чыңгыз хан китергән бәйрәм» 2007 елда «Фән һәм техника» нәшриятында, шигырь һәм хикәяләрен эченә алган «Әфлисун җиле» (2008) китабы «Татарстан китап нәшрияты»нда басылып чыга.

Р.Зарипов — 2005 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### МАТБУГАТ БӘЙРӘМЕ

Россия матбугаты көнендә ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Журналистлар йортында республика телекомпанияләре, газета-журналлары, мәгълүмат агентлыклары мөхәррирләре белән очрашты.

Тантаналы чарада шулай ук Республика Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, «Татмедиа» басма һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы житәкчесе Марат Моратов та катнашты. Фәрит Мөхәммәтшин журналистларга хезмәтләре өчен рәхмәт сүзләрен житкерде һәм аларны «басма сүз»гә тагын да игътибарлырак булырга чакырды. Чыгыш ахырында ул лаеклыларга рәхмәт хатлары тапшырды.

### «АТНА ВАКЫЙГАЛАРЫ»

Татарстан Хөкүмәте, «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы белән берлектә, «Атна вакыйгалары» дип аталган газета чыгара башлады. 80 меңгә якын тиражы булган бу газета «ШК» базасында әзерләнә.

Узган ел ахырында башкалабыз Казанда Башкортстан, Марий Эл, Чуашстан, Удмуртия, Самара, Оренбург, Түбән Новгород, Ульян, Пермь, Әстерхан, Төмән, Свердловск һәм Омскида туган телебездә нәшер ителә торган басмаларның баш мөхәррирләре Казанга фикер алышырга жыелды. Очрашуда төп сүз «Шәһри Казан» газетасы базасында чыгып килүче «Атна вакыйгалары» газета кушымтасы турында булды. Мәгълүм булганча, әлеге газета татарлар яшәгән чит төбәкләрдә тарала. «Атна вакыйгалары» Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов биргән хәер-фатиха белән дөнья күрә башлаган.

### ИСЛАМ ДӘҮЛӘТЛӘРЕ ФӘННИ АКАДЕМИЯСЕНДӘ

Ул академия моннан 25 ел элек төзелгән иде. Күптән түгел Катар дәүләтенең башкаласы Доха шәһәрендә әлеге юбилей кысаларында үткәрелгән XVIII халыкара фәнни конференция һәм IX диннәрара диалог конференциясендә Татарстан Фәннәр академиясе президенты Ә.Мәзгаров һәм ТР Президентының Дини берләшмәләр белән үзара багланышлар идарәсе башлыгы М.Гатин да булды. Бу мәртәбәле жыеннарда Россиядән беренче тапкыр буларак РФАның Океанология институты директоры, РФА һәм Ислам дөньясы фәннәр академиясе (ИФА) академигы Р.И.Нигъмәтуллин катнашты.

Катарның Тышкы эшләр министрлыгы һәм Доха диннәрара диалог үзәге (DICID) оештырган халыкара форумны ачу тантанасында «Ислам дөньясы — Көнбатыш: фәнни-техник хезмәттәшлек» турындагы тирән эчтәлекле докладлар белән Иордания Падишаһы Галиҗәнаплары Принц Әл-Хәссән бин Талал (ИФАны оештыручыларның берсе) һәм Нобель бүләге лауреаты Фәрит Морат чыгыш ясады.

Катарга визиты вакытында Әхмәт Мәзгар улы дәүләтнең тышкы эшләр министры урынбасары Мөхәммәт Әр-Румәйхи һәм DICID Рәисе Ибраһим Әл-Наими белән очрашты, Татарстан Фәннәр академиясе институтлары белән Катар Дәүләте гыйльми учреждениеләре арасында фәнни-техник хезмәттәшлек урнаштыру мөмкинлеге турында фикер алышты.

ИФА конференциясе кысаларында үткәрелгән Ислам дәүләтләре фәннәр академияләре ассоциациясе (NASIC) утырышында ТФАга шушы альянска әгъза булып керергә тәкъдим ясалды.

### ЯҢА ФОНД ОЕШТЫ

ТР Мөселманнарының диния нәзарәте «Татарстан Республикасы Вакфы» фондын оештырып жибәрде.

Фондның генераль директоры — Гамир Рәхим улы Гыйбадуллин. Фонд мөселман дини оешмаларына, шул ук вакытта мөселман белем бирү учреждениеләренә, балалар йортларына, социаль һәм матди ярдәмгә мохтаж булган аерым гражданнарга ярдәм күрсәтә; мәдәният, хәйрия һәм башка биналарны саклау, төзекләндерү, яңартып коруда катнаша.

### ЙӨЗ ЕЛЛЫК УҢАЕННАН

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында әдәбиятыбыз

классигы Сибгат Хәкимнең тууына 100 ел тулу уңаеннан «Сусау» дип исемләнгән тантаналы кичә булды. Анда ТР Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева, мәдәният министры Айрат Сибагатуллин катнашты.

Кичәне Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов ачып җибәрде.

— Тукай заманында шигырь милләтне уяткан, Такташ үзенең ялкынлы чыгышлары белән халыкны шигърият ялкынына бөтереп алып кереп киткән. Сибгат Хәким исә — поэзиябезнең аталары булган әлеге шәхесләрнең өченче буынын тотып торган әдип. Гасыр кичкән шагыйрь гомере буе сагыш-моңга сарылып, сагынып иҗат итте, — диде ул.

Аннары Татарстан Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева чыгыш ясады.

— Сибгат Хәким үзендә татар зыялыларының тулы бер образын гәүдәләндерә иде, — диде ул. — Шагыйрьнең әсәрләре — татар әдәбияты һәм мәдәниятенең олы мирасы. Үз вакытында Мөхәммәт Мәһдиев, аның иҗатында татар халкының мирасы ята, дип әйткән иде. Чыннан да, Сибгат Хәким шигырьләренә язылган бик күп җырлар да халыкныкы кебек кабул ителә.

— Сибгат Хәким — минем өчен әти дә, иҗат та, үрнәк тә иде, — диде үз чыгышында шагыйрьнең улы, күренекле галим һәм сәясәтче Рафаэль Хәким. — Мин көчле буын вәкилләре арасында үстем. Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Нәби Дәүли, Габдрахман Әпсәләмов, Риза Ишморат заманында безнең күршеләребез иде. Инкыйлабны, сугышларны, ачлыкны, ана телебезне кысрыклаган чорларны узган бик тә көчле буын иде бу. Алар татар мәктәпләрен саклап калды. Телне, рухны саклады. Безнең тарих исә шәхесләрдән тора.

Кичәдә шулай ук Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрә Лена Шагыйрьҗан, КФУ галимәсе Нурфия Йосыпова, яшь шагыйрьләр Рүзәл Мөхәммәтшин, Йолдыз Миңнуллина, Булат Ибраһимов һ.б. чыгыш ясады. С.Хәкимнең шигырьләрен танылган артистлар Илдус Әхмәтҗанов, Зөлфирә Зарипова, Инсаф Абдулла, Олег Фазылҗанов, Фәнис Кәлимуллин, Ришат Әхмәдуллин һ.б. укыды. Шагыйрь шигырьләренә язылган җырларны Зилә Сөнгатуллина, Рафаэль Сәхәбиев, Римма Ибраһимова, Гөлшат Имамиева кебек сәнгать осталары башкарды.

Кичәне артистлар Луара Шакирҗан белән Фәнис Җиһанша алып барды.

### «ИДЕЛ»ДӘ ЯҢА БАШ МӨХӘРРИР

«Татмедиа» җитәкчелеге тарафыннан яшьләр журналы «Идел»гә яңа баш мөхәррир — Рөстәм Госман улы Галиуллин билгеләнде. Ул 1987 елны Арча районының Наласа авылында туа. 2009 елны Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетын тәмамлый, 2010 елда әдәбият белеме буенча аспирантурага керә. Республика дәрәҗәсендәге төрле әдәби конкурс-ярышларда призлы урыннарга лаек була. Ул — «Гипнозчы малай» китабы, матбугатта яңа чыккан повесть һәм хикәяләр авторы.

Хезмәт юлын Рөстәм Галиуллин «Шәһри Казан» газетасында эшләүдән башлады. Соңгы елларда (2010-2011) «Казан утлары» журналында публицистика һәм тәрҗемә буенча редактор вазифасын башкарды.

### ГРАНТКА ИЯ БУЛДЫЛАР

Татарстан Мәдәният министрлыгында иң яхшы мәдәният, сәнгать хезмәткәрләренә Татарстан хөкүмәте грантлары тапшырылды. «Иң яхшы җитәкче» төрендә җиңүчеләр арасында Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев, ТР дәүләт җыр һәм бию ансамбле җитәкчесе Айрат Хәмитов та бар. «Терәк һәм абруй» төрендә Татарстанның халык артисты Ирек Баһмановка грант тапшырылды.

### ТАКТАШ ТУРЫНДА ФИЛЬМ

«Татаркино» оешмасы «Мир» кинотеатрында «Поэт на все времена» фильмын тәкъдим итте. Ул — шагыйрь Һади Такташның тормышы һәм иҗаты турында публицистик нәфис фильм. Шагыйрь ролендә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Эмиль Талипов уйнады. Анда гаилә альбомындагы фотолар, архив материаллары файдаланылган. Композитор Мәсгудә Шәмсетдинова көйләре дә яңгырый. Сценарий авторы — Эльвира Кудрецкая. Фильм Мәдәният министрлыгы тарафыннан төшерелгән.

### ӘДИП ПРЕМИЯСЕ

Быел Мамадыш районындагы «Агымсу» әдәби-иҗат берләшмәсе оешуга — 50, Шәйхи Маннур исемендәге премия бирелә башлауга 30 ел тулды. Күптән түгел әдип исемендәге премиянең быелгы лауреатлары игълан ителде. Татарстан Язучылар берлеге белән Мамадыш районы хакимиятенең әлеге мәртәбәле бүләгенә, әдипкә багышланган очерк-зарисовкалары өчен «Ватаным Татарстан» газетасының бүлек мөхәррире, журналист Люция Мәүлиева-Фаршатова; Мамадыш районы газетасы редакциясе каршында әдәби берләшмәне оештырганы өчен матбугат ветераны һәм прозаик Зәки Хәнәфиев; Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Җан фасылы» китабы өчен шагыйрь

Рәис Габдулла; күпләгән яшь талантлар тәрбияләп үстергәне өчен мөгаллимә һәм шагыйрә Рәсимә Галиева; хезмәттәге югары күрсәткечләре өчен «Вамин-Тәкәнеш» агрофирмасы механизаторы Равил Сәйфуллин лаек булды.

### АКМУЛЛА КӨННӘРЕ

Башкортстанда Мифтахетдин Акмулла көннәре булып үтте. Ел саен уздырыла торган чараның быелгысы күренекле мәгърифәтче һәм шагыйрьнең тууына 180 ел тулуга багышланды. Соңгы елларда Башкортстанда Мифтахетдин Акмулланың истәлеген мәңгеләштерү өчен байтак эшләр башкарыла. Миякә районы Туксанбай авылында Акмулланың музей-йорты эшләп килә, Башкортстан дәүләт педагогия университетына 2007 елда Мифтахетдин Акмулла исеме бирелде. Университет биналары арасындагы мәйданда атаклы мәгърифәтчегә һәйкәл дә куелган.

Милли мәдәниятне үстерүгә зур өлеш кертүче әдипләр, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре казанышлары Акмулла исемендәге бүләк белән бәяләнә. Тырыш студентларга атаклы шәхес исемендәге стипендияләр дә булдырылган.

«Акмулла көннәре» уңае белән үткәрелгән фәнни-гамәли конференциядә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының директор урынбасары, филология фәннәре кандидаты М.Х.Вәлиев, әлеге институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире, филология фәннәре директоры Р.Ф.Исламов, Казан федераль университеты доценты Ә.М.Закиржанов, Казан дәүләт бюджет аграр университеты доценты Г.У.Алиева катнашты һәм чыгыш ясады.

### ИСТӘЛЕК МЕДАЛЕ

Россия Мәдәният министрлыгы тарафыннан күренекле рус шагыйре Александр Твардовскийның тууына 100 ел тулу уңаеннан истәлек медале булдырылган иде. Әлеге бүләккә Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Хисам Камалов лаек дип табылды.

Фронтовик язучының шигырь-поэмалары, повестьлары, романнары киң катлам әдәбият сөючеләргә яхшы таныш. Узган атнада әлеге бүләкне әдипнең өенә барып, Татарстан мәдәният министры А.Сибагатуллин тапшырды. Айрат Миңнемулла улы фронтовик язучының әсәрләрен тәэсирләнеп укуын, аларның бүгенге көндә дә әдәбият сөючеләрдә зур кызыксыну уятуын һәм Интернет челтәрендә дә аларга күп мөрәҗәгать итүләрен билгеләп үтте. Әдипкә, гаиләсенә саулык, иминлек теләде.

Истәлекле бүләкне тапшыру тантанасында Татарстан Язучылар берлеге рәисе И.Ибраһимов катнашты.

### ЯКТАШЛАРЫ АНЫ ОНЫТМЫЙ

Баулы мәдәният йортында якташлары, күренекле шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановны искә алдылар. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов белән бергә каләмдәшләре дә кайтты. Шагыйрьнең шигырьләре балалар укуында да яңгырады. Рәшит Әхмәтҗановның сәхнәдә үз шигырьләрен укыганын ишетүчеләр аның кабатланмас тавышын искә алдылар. Р.Әхмәтҗановның туганнары гаиләсендә дөньяга килгән малайга Рәшит исемен кушканнар. 14 яшьлек Рәшит тә шигърияткә ярата икән. Быел Г.Тукайның 125 еллыгына багышланган район конкурсында ул иң зур бүләккә лаек булган.

### ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

***

Күпьеллык иҗади эшчәнлеге, татар әдәбиятын үстерүгә лаеклы өлеш керткәне өчен язучы **Гыйләҗев Мансур Аяз улы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлеге өчен Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре, безнең даими авторыбыз **Гарипова Фирдәвес Гариф кызы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казандагы Апанай мәчете.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Лондонда яшәүче татар шагыйре **Рөстәм Сүлти**.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Республикабыз җәмәгатьчелеге зур югалтуга дучар булды. Шагыйрь, прозаик, драматург һәм тәржемәче, Г.Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе һәм М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты **Равил Рәис улы Бохараев** 24 гыйнвар көнне 61нче яшендә кинәт вафат булды.

Р.Бохараев 1951 елның 18 октябрендә Казан шәһәрендә туа. 1974 елда Казан дәүләт университетының механика-математика факультетын тәмамлаганнан соң 1977 елда Мәскәү дәүләт университеты аспирантурасына укырга керә.

Аның шигъри таланты инде студент елларында ук ачыла. 1969 елда «Комсомолец Татарии» газетасында тәүге шигыре басылып чыга. 1977 елда СССР Язучылар берлеге әгъзасы була, 1992 елдан — Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы. Р.Бохараев озак еллар буе чит илләрдә эшләде. Әмма ул якын һәм ерактагы чит илләрдә күпмилләтле Россия, Татарстан мәдәниятен армый-талмый танытуга күп көч куйды.

Равил Бохараев — Татарстан Республикасы мәдәнияте, тарихы һәм сәяси икътисадына багышланган кырыктан артык проза, поэзия китаплары, тарихи-сәяси тикшеренүләр авторы.

Аның хезмәтләре Россия һәм чит илләрдә рус, татар, инглиз һәм венгр телләрендә басылып чыкты. Р.Бохараев татар шигърияте һәм прозасының берничә китабын рус һәм инглиз телләренә тәрҗемә итеп бастырып чыгарды. 2000 елда инглиз телендә «Татар шигъриятенен тарихи антологиясе», 2010 елда — Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасының инглиз телендәге тәрҗемәсе дөнья күрде.

Равил Бохараев танылган сценарист һәм балалар драматургы да иде. Аның пьесалары Казан телевидениесендә, Камал театры сәхнәсендә куелды. Курчак театры өчен язылган «Апушның тылсымлы төшләре» пьесасы 1986 елдан бирле Казанның «Әкият» курчак театры сәхнәсеннән төшми. Ул 2006 елда «Мең еллык күршеләр: тарихта рус-татар мөнәсәбәтләре» триптихында «Үзгәрешләр дәверенең төсләре» документаль фильмының иң яхшы сценарие өчен Казан кинофестивале лауреатына әйләнде.

Равил Рәис улы илебез тарихы өлкәсендәге хезмәтләре өчен «Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының мактаулы докторы» исеменә лаек булды.

Милли мәдәниятебезне үстерүгә зур өлеш керткәне өчен Р.Бохараевка «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Талантлы, намуслы, зыялы кеше арабыздан мәңгегә китте. Аның якты истәлеге күңелләребездә озак сакланыр.

**Р.Н.Миңнеханов, М.Ш.Шәймиев, Ф.Х.Мөхәммәтшин,**
**И.Ш.Халиков, Ю.З.Камалтынов, А.М Сибагатуллин,**
**И.Р.Метшин, И.М.Ибраһимов.**



**Рөстәм Сүлти**

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)